# казан утлары

7

ИЮЛЬ • 1978

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

7
ИЮЛЬ
1978

## Бу санда

Р. МИҢНУЛЛИН. Күзләреңә карап сөйләшәм. Шигырьләр . . . . . . . . . . . 3
Т. ӘЙДИ. Бөжра. Мажаралы повесть . . . . . 4
Ә. РӘШИТОВ. Тормыш әлифбасы. Поэма . . . 74
Х. ВАХИТ. Ике килен-килендәш. Комедия . . . 83

КЛАССИК ПОЭЗИЯ ҮРНӘКЛӘРЕ

Гаделлек һәм ирек җырчысы . . . . . . . . 125
Уйгыр шагыйре Билал Назыйм газәлләре . . . 126

ОЧЕРКЛАР

А. СӘЛӘХЕТДИНОВ. Сынатмас Сомовлар . . . 129
У. БЕЛЯЛОВ. Ир асылы — илгә таяныч . . . . 137

Н. Г. ЧЕРНЫШЕВСКИЙНЫҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

К. ФАСЕЕВ, Я. АБДУЛЛИН. Чернышевский һәм татар иҗтимагый фикере . . . . . . . . 145

СӘНГАТЬ

А. АЛМАЗОВА. Илләр гизәр алдыннан . . . . 153

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

М. МӘҺДИЕВ. Бүген дә хәрәкәттә . . . . . . 160

БҮГЕНГЕ ПОЭЗИЯ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Т. ГАЛИУЛЛИН. Җитмешенче еллар авазы . . . 171

КИТАП КҮЗӘТҮ

Н. ШӘФИГУЛЛИН. Хакыйкатьне таплап булмый . 180
Ф. САФИУЛЛИНА. Дөньяны сүз бизәр . . . . 182

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Р. ИШМОРАТ, Һ. МӘХМҮТОВ. Бәян Гыйззәткә 60 яшь . . . . . . . . . . . . . . . 187
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-69, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов** (баш редактор урынбасары), **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 21/111-1978 ел. Басарга кул куелды 26/V-1978 ел. ПФ 09003. Кәгазь форматы 70×108 1/26. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 91000. Заказ В-97. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1978 ел.

## Роберт Миңнуллин

### Күзләреңә карап сөйләшәм

Үпкәләмә миңа, Татарстан,
Гел яратам сине димәсәм.
Мин үземне синең улың диеп
Йөрер идеммени, сөймәсәм?

Синең белән бүген мин ирләрчә
Күзләреңә карап сөйләшәм.
Сөйләшергә сүз табалмас идем,
Чын күңелдән сине сөймәсәм.

Ышан миңа, зур горурлык белән
Сине мактап, яклап сөйләсәм,
Горурлана алыр идемме соң,
Җаным белән сине сөймәсәм?!

Кичермәсләр, бәркет итеп сине
Ил күгенә әгәр чөймәсәм.
Мин үзем дә күтәрелә алмам,
Азаккача сине сөймәсәм!

### Кояшлы җыр

Без — бер җирнең газиз балалары,
Җылынабыз Кояш учагында.
Һәр кешегә җирдә Шатлык тиеш —
Барыбыз да Кояш кочагында.

Күзебездә уйный Кояш нуры,
Кояш алсулыгы — йөзебездә.
Очкын булып чәчри Кояшлы Җыр,
Кояш очкыннары — үзебез дә.

Пикассоның аппак күгәрчене
Канат җилпи аяз күгебездә.

## Тәүфикъ Әйди

# БОЖРА

МАҖАРАЛЫ ПОВЕСТЬ



Өлкән инспектор Айбулат Байчурин склад мөдире Гайния Хаҗиевадан тагын бер кат, җентекләбрәк сорау алды.

— Көмешне заводтан ничек алып чыкканнар дип уйлыйсыз?

Хаҗиева тынычлана төшкән иде:

— Бәлки әле заводтан алып та чыкмаганнардыр, бары яшереп кенә куйганнардыр? Төнлә урлап, көндез озатырга да була ич аны. Төзүчеләр кагылмады микән? Алар яңа корыла торган корпуска машина белән ком, измә, кирпеч ташый.

— Кызык.

Айбулат, көмеш урлауга катнашулары ихтимал дип, Хаҗиева атаган кешеләр исемлеген күздән кичерде. Аларның һәммәсе белән дә очрашу зарури иде. Ярдәмчесе инспектор Касыйм Вилданов әйткәннәрне истә тотып, ул склад мөдиренә байтак сорау бирде, әмма Гайниянең җаваплары шик уята алмады. Кара халатын салып ташлагач, яшь бу хатын тагын да чибәрләнә төшкән иде. Кызгылт итәге һәм чак кына алсуга манылган, эре күзәнәкләр ясап бәйләнгән ак йон кофтасы аны аеруча ыспай күрсәтә. Тулы алсу бит, туры борын, җиңелчә генә иннек сөрткән килешле иреннәр. Түшендә инде бая ук игътибарны җәлеп иткән затлы брошка. Хатын-кызның кайсы гына такмый хәзер андый бизәнү әйберләрен! Килеш-килбәте, йөз үзгәрешләре табигый, җавапларында боргалану-сыргалану сизелми. Күзләре туры карый, җинаятьнең тизрәк фаш ителүе белән чынлап та кызыксына кебек. Әле яңа гына беренче адымнарын атлаган инспектор хыялына ни килмәс!

— Бу вакыйга минем исемгә дә шик төшерә инде, билгеле,— дип, Хаҗиева үзенең хәвефле, уңайсыз хәлдә калуын таныды. Үзен бераз гаепле дә сизә, акланырга да омтыла сыман. Берәү дә «мин гаепле» дип әйтмәячәк, әлбәттә. Әмма беренче тәэсиргә, беренче тойгыга гына ышанырга ярамый иде.

Аның бу уен складта җыештыручы булып эшләгән Клавдия Алексеева көтмәгәндә ныгытып та куйды.

---

Әсәр кыскартып басыла.

— Чираттагы ялымнан соң яңа эштә мин. Гайния белән бергә биш ел хезмәт иттек. Тик аны начар белэм, йомык характерлы ул,— диде.

Алексеева илле яшьләрдәге юан гына хатын иде. Тышкы кыяфәте буенча һич тә җыештыручы булып эшлидер дип уйламассың. Кашларын нечкәртеп, битенә кершән сөрткән, иреннәрен кызарткан. Матур гына куе зәңгәр җәйге пальто кигән. Эшләпәсе астыннан чыгып торган салам чәчләре көдрәләнгән. Тукта, бу җыештыручы ханым сәеррәк сүзләр сөйли түгелме соң әле?

— Йөкне биш ел бергә күтәреп тә бер-береңне начар белүне ничек аңларга? Төшенмим әле сезне,— диде Айбулат башын селкеп.— Әллә тату эшләмәдегезме?

— Дошман да түгел, дус та түгел ул миңа. Биш ел бергә эшләп, аларның өендә биш тапкыр булдыммы икән? Бай, безгә пар кеше түгел.

— Ничек инде бай? — Айбулат хәзер инде Алексееваны тагын да игътибарлырак күзәтте.

— Менә шулай, квартирасына керсәң, әйләнеп чыга алмассың. Машина аласы гына калган инде!

— Эрерәк бавырлымы әллә? Сезне санга сукмыймы?

— Кем белә аны. Кунакка дәшсәң — килми, үзе чакырмый. Әмма сүз тыңлаучан үзе, бурычка акча да биреп торганы бар.

Алексеева зур кызыксыну белән бүлмәне күздән кичерде. Почмактагы сейф, тәрәзә каршындагы гөлләр, ике тумбочкалы олы өстәл, пыяла астына җыеп салынган күп санлы язулар, күксел төстәге телефон, калын тәрәзә пәрдәләре, телефон белән янәшә торган Җәлил сыны аңа тәэсир ясады, ахры — ул канәгать төстә урындык аркасына сөялде. Почмактагы сейфны искә алмасаң, бөтенләй өйдәге кебек икән ич. Ишек төбендә шкаф та бар икән әле. Сер әнә шул сейф белән шкафка яшерелгәндер инде. Аксыл костюм кигән, муенына чуар галстук бәйләгән инспектор үзе дә караклар, кеше үтерүчеләрне тота торган гайрәтле егеткә охшамаган. Алексеева аларны башкачарак, зәһәррәк карашлы, усалрак кыяфәтле итеп күз алдына китерә иде. Ә бу тикшерүче миһербанлы, йомшак мөгамәләле сыман. Эре гәүдәле, киң җилкәле, көчле ир күренә. Буй җиткән кызына менә шушындый кияүне эләктерсәң, начар булмас иде. Мондый ирләр вакчыллык белән җанны кыйнамый...

Өлкән инспектор Байчурин яңа соравы белән Алексееваның кирәкмәгән якка ага башлаган уйларын бүлде:

— Көмеш урлауда аның катнашы бар дип уйлыйсызмы?

— Белмим,— диде Алексеева Айбулатның күзенә карап.— Тиктомалдан кеше өстенә кара ягасым килми.

— Ничек баеган икән соң ул? Хезмәт хакы зурмы?

— Үзем дә баш ваттым инде, белә алмадым. Окладны да ташка үлчим генә, унны бетергән булсам, ул акчага селкенеп тә йөрмәс идем. Ә Гайния министр кебек тора!

— Акчаны күп туздырамы? — Айбулат Алексеева җавапларын беркетмәгә терки бара иде.

— Юк, артыгын ычкындырмый. Мал җанлы.

Алексееваның шадраграк йөзендә пошыну галәмәтенең әсәре дә юк. Үзен файдалы бер эш эшләгән кебек тоя, ахры, күңеле көр, кәефе шәп күренә. Әгәр каршысында тикшерүче утырмаса, мөгаен, Хаҗиеваның бераз гайбәтен дә сатып алыр иде.

— Көмеш складында эшләвегезне кемгә дә булса әйткәнегез бармы? — диде Айбулат.

— Складта бер көмеш кенә түгел ич. Көмеш ул бер генә бүлектә. Бездә төрле нәрсә бар.

— Әлегә көмеш белән генә кызыксынабыз.

— Бардыр инде, сөйләшкәндә сүз чыга бит.

Алексеева сагая калды. Беркетмә язып утырган өлкән инспектор күзәткәндә эсселәп киттеме, пальто изүләрен ычкындырып куйды. Кызык, өйләнгән кешеме икән бу тикшерүче дип уйлый башлады ул аннары. Аның кызыннан ничә яшькә олы булыр икән?

— Сездән көмеш сораучы булмадымы?

— Һи, бездә саф көмеш юк ич. Ниндидер катнашма шунда. Фототасма ясаудан башка нәрсәгә ярамый ул?

— Менә шуны сораучы булмадымы? — Айбулат Алексееваның артыграк иркенәеп китүен ошатмаса да, кисәтү ясарга базмады.

Клавдия тагын да батырая төшеп:

— Тагын нәрсәгә файдаланып була соң аны? — дип төпченергә кереште.

— Сорауларга гына җавап бирсәгез иде... Көмеш катнашмасын сораучылар булдымы?

— Юк, хәтерләмим.

Коридорда Гайния Хаҗиеваның турыдан-туры җитәкчесе, «Тасманур» берләшмәсенең тәэминат бүлеге инженеры Рахман Сабирҗанов сорау алуны көтеп торганын искә төшергәч, Айбулат Алексеевага кайтып китәргә рөхсәт итте.

Сабирҗанов өлкән яшьтәге ябык кеше иде. Ялтыравык кара галстугын төзәтә-төзәтә нәзакәтле, салмак кына сөйләшә:

— Хаҗиеваны байтактан беләм. Үзен бары уңай яктан гына күрсәтте. Әйткәнне җиренә җиткереп үти. Минемчә, намуслы хатын. Яманатын чыгарганчы, җанын чыгара торган зат. Складта кайчан да булса җитмәүчелек чыкканын хәтерләмим.

— Көмешнең кайсы каплары югалганын белеп булачакмы? — дип сорады Айбулат.

— Ревизиядән соң, һичшиксез, мәгълүм булыр. Һәр капның ярлыгы бар.

— Хаҗиева материаль яктан мөмкинлегенә караганда иркенрәк яши дип әйтәләр,— диде Айбулат.— Окладны, үзегез дә беләсез, зур түгел. Әнкәсе дә бар икән, бер малай да үстерә, диләр. Ялгызы эшләп дөнья көтәргә кирәк бит, иеме?

— Хаҗиеваның гаилә яклары, өй хәлләрен белмим, гафу итегез. Эше хакында булса, фикеремне әйтергә әзер, баймы ул, ярлымы,— анысы миңа караңгы.

— Көмеш нитраты ниндирәк әйбер соң ул? Нәрсәгә ярый?

— Менә бусы танышрак өлкә. Үтә күренмәле аксыл кристалл, бөртек инде ул. Нигездә, кино-фототасма, фотокәгазь җитештерүдә кулланыла. Медицина хаҗәтенә ляпис ясала.

— Тагын?

— Тагын... көмеш, үзегез дә беләсез, ювелирларга кирәк. Химик яктан тотрыклы булганга, техника өчен тансык нәрсә. Тик саф көмешне кустарь шартларда нитратыннан аерып алуны, белмим, булдыра алырлар микән...

Рахман Сабирҗанов Айбулатның Хаҗиевага карата булган ышанычын яңадан ныгытты. Өлкән инспектор, составын ачыклау өчен складтагы көмеш нитраты үрнәген экспертка тапшыргач, сорау алу нәтиҗәләрен анализларга кереште.

Көндезге сәгать икедә ревизор юкка чыккан көмешнең күләмен ачыклады һәм нәтиҗәләрен телефоннан Байчуринга шалтыратып әйтте: йөз кап көмеш җитми иде.

Бераздан җинаять вакытын ачыкларга ярдәм итә торган мәгълүмат та алынды. Эксперт, көмеш капларына кунган тузанны үлчәгәннән соң, Хаҗиева күрсәткән урыннарда тузанның чыннан да азрак

булуын раслады. Димәк, өстәгеләрен алганнар, яңаларына әле тузан кунып өлгермәгән!

Бер тонна нитрат югалган, димәк, карак ялгыз булмаска тиеш дип уйлады Айбулат. Билгеле инде, йөз кап көмешне күтәреп әллә кая элдертә алмыйсың. Машинага төягәннәр. Ревизия нәтиҗәсе эзләнүләрне чын мәгънәсендә ышанычлы юлга кертә. Машиналы каракны табу күп өлеш җиңелрәк.

Көмешнең әле күптән түгел генә урлануын ачыклау да Айбулат файдасына. Бу хәл склад мөдиренә карата туган шикләрне бик нык какшата иде.

Заводта шик төшәрлек кешеләрне Вилданов тикшерергә тотынганга, Байчурин җинаятьчеләрне икенче яктан эзли башларга булды. Товар акчага әйләндерелергә тиеш. Бигрәк тә турыдан-туры кулланырга ярамаган көмеш нитраты. Шәһәрдә кемнәргә кирәк икән соң ул? Алучыны тапсалар, җинаятьче эләкте дигән сүз. Нитратны ничек саф көмешкә әйләндереп була икән?

Бу турыда Нәҗибәдән дә сорашырга була ич. Көтмәгәндә очрап, телефон номерын үзе язып бирде, шалтырат дип әйтте ләбаса! Сылтавы барда нигә сөйләшеп карамаска дип, Байчурин куен дәфтәреннән Нәҗибәнең язуын эзләп тапты.

Әйе, Нәҗибә белән кичке мәктәптә очрашканнар иде алар. Кыз инде ул чакта ук «Тасманур» заводында аппаратчы булып эшли иде. Юктан да кызык табып кеткелдәргә ярата торган ачык йөзле, теләсә кем белән бик тиз уртак тел таба торган үйнак күңелле Нәҗибәгә барысы да тиз ияләшә иде. Сөяксез дип әйтерлек сыгылма гәүдәле, сөрмә тартмаса да, бик килешле кара кашлы, почык борынлы кыз күп егетләргә ошый иде. Егетләрнең теләсә кайсы белән киногa, театр, танцыга бару аңа бер ни тормый. Тик үзе аларның берсенә дә шуннан артык аерым игътибар галәмәтен күрсәтмәде. Айбулат та әнә шул киртәне атлап уза алмады. Җитмәсә:

— Алып хәтле гәүдәң белән урам чатында багана кебек басып торганчы, иләк белән су ташы, буыннарың катмас,— дип мыскыл катыш шаярулы киңәш бирә иде.

Кичке мәктәпне тәмамлагач та алар ара-тирә очрашкалап тордылар, әмма Айбулат күпме генә Нәҗибә күңеленә тирәнрәк керергә тырышмасын, кыз уен-көлкедән узмады. Соңгы тапкыр очрашуларыннан соң инде берничә ел узып киткән иде. Бүген менә уйламаганда әллә кайдан килеп чыкты да, гомердә булмаган хәл — шалтырат дип, телефон номерларына кадәр язып бирде. Шатланыргамы моңа, көенергәме? Мәченең тычкан белән уйнавы түгелме икән? Беркатлы гашыйк булып, тагын көлке хәлдә калмасмы ул? Хәзер уйлап эш итсә дә ярар иде инде, унсигез яшь түгел егеткә. Шалтыраткан хәлдә дә, эше өчен кирәк нәрсәне генә сорашыр Айбулат. Коры гына, кыска гына итеп.

Айбулат трубканы алгач та бер мәл икеләнеп торды. Аннары кирәкле номерны кыю гына җыйды. Ерактан таныш тавыш ишетелде.

— Бу мин әле,— диде өлкән инспектор.— Менә ничек тиз шалтыраттым. Әйе, Айбулат инде.

— Ай, телефоннан тавышың шундый матур ишетелә, танып та булмый! — дип җавап бирде Нәҗибә.

Айбулат моны, билгеле инде, чынга алмады.

— Шаяртма әле,— диде ул.— Мин сиңа бер йомыш белән шалтыратам. Институт тәмамлап йөрдең, файдаланыйк әле белемеңне. Көмеш нитратыннан саф көмешне ничек аерып була?

— Безнең лабораториягә кил, аерып бирербез.

— Авыз ерма әле, эш өчен кирәк миңа.

Нәҗибә химик реакция ясар өчен кирәкле өстәмә матдәләрне, аларны файдалануның кайбер ысулларын әйткәч, көлгән булды:

— Син нәрсә, әллә алхимик булырга җыенасыңмы? Гомер аяк басмаган заводка да килеп кергәнсең.

— Кая инде безгә.

— Һаман шул иске эшеңдәме?

— Әйе. Бүлекчә генә үзгәрде.

— Нинди гә?

— Җинаятьләрне ачу бүлекчәсе дип аталабыз хәзер.

— Ки-и-ит әле, менә бусы кызык,— диде Нәҗибә.— Болай булгач синең белән берәр яры очрашу да зыян итмәс иде. Маҗаралар эчендә кайный торган кеше белән бер сөйләшүе ни тора!

— Күрешергә ашкынып дигән идем аны.— Айбулат та Нәҗибәне үртәп алырга булды.— Вакыт ягы тар шул, бу арада очрашулар артык күбәеп китте, өлгерә алмыйм. Бик ялынып сорасаң гына инде. Яратам дип әйтергә исәбең юктыр ич?

— Булса гаепмени? — дип көлде кыз.

Айбулат тагын да тәкәбберрәк тавыш белән дәвам итте:

— Уңыш казанырга өметләнәсеңме?

— Билгеле!

— Менә оптимист,— дип көлде Айбулат. Ул урындыгыннан торып трубканы тоткан килеш тәрәзә янына килде һәм яфракларын коя башлаган агачларга күз салды. Алар өчен тагын бер ел гомер тәгәлләнде дигән сүз. Гомер дигәне бик тиз уза шул. Еллар үзгәрә торса да, Нәҗибә белән Айбулатның сүзләре һаман бер турыдарак бара тагын. Тик бу юлы рольләрне генә алмаштылар кебек.

— Я, кайда очрашабыз? — дип сорады Нәҗибә.

Башка вакытта җитди сөйләшүне дә уенга гына борырга ашыккан Нәҗибәнең бу юлы чынлап та күрешергә әзер торуы Айбулат өчен яңалык иде.

— Кай тирәдә әйбәтрәк булыр икән соң? — диде ул сәгать ничәләрдә бушыйсын чамалап.

— Ничә ел күрешмәгән иптәш белән, билгеле инде, бары тик ресторанда гына. Түгәрәк дата ич, билгеләп үтәсе булыр. Музыка, шәраб... Биисе дә килеп тора әле тагын.

Ресторанда акча туздыручылар арасында «Тасманур» заводында шик астына алынганнар да юкмы икәнлеген ачыклыйсы бар иде. Айбулат шуны да күздә тотып Нәҗибәгә очрашу вакытын һәм урынын әйтте. Аннары, экспертларга һәм көмеш нитраты белән эш итә торган цех башлыгына шалтыратып, шәһәрдә нитрат куллана торган оешмаларны тагын бер кат ачыклады да юлга җыенды.

Урамда хәзер инде ыгы-зыгы көчәйгән, шау-шу арта төшкән иде. Кояш юмартланып киткән, көн җылынган. Башка вакытта мондый көзге көннәрдә урамда йөрергә яратса да, бүген Айбулат тансык һавада хозурланырга онытты. Күләгәдәге таш бүлмәдән чыккач, башта аңа тышта артык бөркү сыман тоелды. Плащын салып, хәтта галстугын да бераз бушатып куйды. Әмма бераздан кәефе үзгәрде. Троллейбусларда әле һаман тыгыз, мыж килгән халык булуга да исе китмәде. Нәҗибәнең бүген болай ачылып сөйләшүен Айбулат кызның борылыш ясарга ниятләвеңер дип юрады. Аның бер-ике ягымлы сүзе егет күңеленә әллә рәхәт яңгыр булып яуды — дөнья яктырак булып күренә башлады сыман.

Көзге эшләү мастерскоеның пыялага көмеш элпәсе җәя торган цехында аны сөйкемле генә бер ир уртасы кеше каршылады. Мускуллары биеп торган йөзендә сәламәт алсулык. Кылыч борынлы, калын муенлы.

Айбулат кергән кабинетына кызыксынып күз салды: язу өстәлләре, китап шкафы, сейф аны кысанайтып күрсәтә. Стенага берничә портрет эленгән, түр почмакка байрак сөяп куелган.

Йомшак урындыкларның берсенә килеп утырган өлкән инспектор таныклыгын күрсәткәч, кабинет хуҗасы:

— Мортаза Гобәйдуллин,— дип үзен танытты һәм хәвефләнеп сорады: — Әллә өстебездән әләк язганнармы?

— Юк, борчылмагыз. Күзге ясау серләрен сорашырга килдем. Нинди чимал кирәк, ничек эшләнә — барын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирегез әле!

Гобәйдуллин гаҗәпләнә калды. Ул аңлаткан арада Айбулат яңа сорауларын яудырды:

— Нитратны кайдан аласыз?

— Махсус почта белән Мәскәүдән килә.

— Көмеш әйләнеше документларын күрсәтегез әле. Калдыгыгызны да үлчәп карамый булмас.

— Бездә телгә алырлык көмеш юк бит,— диде Гобәйдуллин.— Бик аз. Аны инструкциядә язылганча гына файдаланабыз. Кушылганча эшләсәң җаның тыныч.

— Саф көмеш тә кулланасызмы?

— Юк, нитрат кына.

— Нитрат белән кемнәр эш итә?

— Өлкән оста Шакиров белән Федотов. Федотов ике атна элек кенә чираттагы ялын алып Кырымга китте әле.

— Ял йортынамы?

— Санаторийга,— диде Мортаза.— Врачлар кушуы буенча дәваланa, путевка алып бирдек. Теләсәгез, Шакировны чакырып китерәм.

Мортаза Гобәйдуллин күрсәткән документларны уку, көмеш калдыгын үлчәп, аны кәгазьдәге саннар белән чагыштырып карау өчен күп вакыт кирәкмәде. Көмеш нитраты калдыгы документтагылар белән тулысынча туры килә иде.

— Сезгә ялгыш кына булса да көмеш нитраты я саф көмеш тәкъдим итүчеләр юкмы? — дип сорады Айбулат.

Гобәйдуллин кулларын ук җәеп:

— Юк, юк,— диде.— Сорап килүчеләр генә бар.

— Кемнәр сорый?

— Аларның кем икәнен кем белсен? Я теш куйдырырга, я йөзек, беләзек йөгертергә кирәк, диләр.— Мортаза көлемсерәп өстәде:— халык бизәнергә ярата бит хәзер.

— Шәһәрдә тагын кайда көмеш белән эш итәләр? — Айбулат мастерской башлыгының җавапларын терки барырга да онытмады.

— Мебель комбинатында.

— «Тасманур» заводында көмеш урланганны ишеттегезме? — Өлкән инспектор, урамга караган булып, ачык тәрәзә өлгесендә чагылган Гобәйдуллин йөзендә берәр төрле үзгәреш булмасмы дип күз салды. Мастерской башлыгы кызыксынып Айбулатка карады да:

— Юк, сездән беренче мәртәбә ишетүем,— диде.— Шаяралар, әә?

Айбулат Байчурин үзеннән сорашканны яратмый иде. Шуңа күрә Гобәйдуллинны кисәтергә ашыкты:

— Сүзебез ике арада гына калсын. Кая, Шакировны да чакырыгыз инде.

Мортаза Гобәйдуллин бүлмәдән чыгып киткәч, Айбулат остаханә мөдиренең җавапларын, килеш-килбәтен күз алдыннан үткәрде. Ул бер генә вак детальне дә игътибарсыз калдырмый, кызыксынган, тикшергән кешесенең киемен дә, тегe яки бу сүзне әйткәндә тавыш үзгәрешен дә, йөз сызыкларын да исәпкә ала иде. Остаханә мөдиренең исә көмеш вакыйгасына мөнәсәбәте бардыр кебек тоелмады. Әмма аның

турында да кайбер нәрсәләрне ачыкларга туры киләчәк. Йөзек, беләзекләргә көмеш йөгертергә дип, бәлки монда юкка гына килмиләрдер. Ымы-шымы чыкмаса, кайдан белсеннәр икән? Әллә осталары үзләре генә астыртын эшләп, Мортаза Гобәйдуллин белми каламы?

Гобәйдуллин берничә минуттан бүлмәгә кырык яшьләрдәге таза бер кешене ияртеп керде һәм:

— Шакиров менә шушы була инде,— дип, Айбулат белән таныштырды.— Сезгә комачауламыйм, карыйсы эшләрем бар иде, чыгыйм әле.

Шакиров үзенең әле ни өчен кирәккәнлеген белмәсә дә, бик кәефле кыяфәттә иде. Айбулатның:

— Үзегез, эшегез хакында сөйләгез әле? — дигән соравына шыңгырдап торган тавыш белән җавап бирде:

— Нәрсәсен сөйлисең инде аның? Эшлибез дә ашыйбыз. Ун ел буе һаман бер шөгыль. Эшне сөйләп торасы юк, әнә теге якка керегез дә карап китегез. Биш тапкыр ишетүдән бер тапкыр күрү яхшырак. Эш кыз түгел, сез караганнан гына оялмас.

— Заказлар ничек бирелә соң?

— Үзебезнең мастерскойда алалар, Татарстан урамында да кабул итәләр. Квитанция нигезендә эшлибез. Бар да советча, тәртип белән теркәлә. Квитанциясез заказ алудан ходай сакласын. Квитанцияләр администраторда, рәхим итеп карагыз. Аның өчен нигә мин тырышам соң әле, үзе сөйләсен,— дип үзенә-үзе гаҗәпләнде Шакиров.— План бар бит безнең, план!

— Чимал белән эшләргә ничек соң? Читтән тәкъдим итмиләрме? — Айбулат көзгече останың кыяфәтенә елмаеп карамый булдыра алмады. Шакиров утырганда да тик кенә тора алмый, кулындагы ниндидер пумаланы йомшартырга тырышып угалый, шул арада мастерской башлыгының өстәлендә яткан кәгазьләргә дә караштыргалап ала, Айбулатны да күздән ычкындырмый иде. Җавапка да кесәгә керә торган кеше түгел. Чәчен бер кырыйга аударып тараган, беленеп килә башлаган пеләшен яшерә, ахры. Костюм якасына Казан сурәте төшерелгән значок тагып куйган. Калку яңаклы, мыеклы. Күз-кашлары чыршы ботаклары кебек кыйгач.

— Каян алсыннар аны, бәрәнге түгел лә ул,— дип җавап бирде өлкән инспектор соравына.— Мәскәүдән кайта безгә, Мортаза әйтмәдемени? Аннары, китерсәләр дә, халыктан химикат алу тыела. Китермиләр дә. Патша тәңкәләре дә бетте инде.

— Йөзек, беләзекләргә көмеш йөгертәсезме соң?

— Кирәк иде дә, юлга салынмаган әле. Китерәләр, ялыналар, әмма ул эшкә алынганыбыз юк. Прейскурант та билгеләнмәгән, чималы да андый максатка җибәрелми.

— Йөзек, беләзекләр белән нишләп сезгә киләләр соң? Көмеш йөгертүегезне каян чамалыйлар? — Өлкән инспектор юри Шакировның махсус койдырып алган киң алтын балдагына ишарә ясады.

— Без көмеш йөгертмибез, йөзек-беләзеккә катнашыбыз юк,— диде оста ваемсыз гына.— Көзге яңартучылар мөрәҗәгать итә, янәсе, көмеш булгач, көзге дә, йөзек тә кирәк инде.

— Шәһәрдә көмеш белән эш итүчеләр тагын бармы икән, белмисезме?

— Булса кирәк. Базарларда искергән көзгеләрне яңартып сатучылар күренгәли. Кустарьлардыр, ахры.

— Алар чималны каян ала икән? — Айбулат беркетмә янәшәсенә блокнотын да чыгарып куйды.

— Белмим. Кустарьлар барлыгын да тәгаен өзеп әйтә алмыйм. Бәлки алар юктыр да. Әллә йөзегегезгә көмеш йөгерттерәсе бармы?

— Булдыра алсагыз, түләвеннән эш тормас,— диде Айбулат Шакировның күзенә карап.— Әллә безгә андый үтенеч белән килү тыеламы?

— Һи-һи-һи. Шаяртмагыз, тапкансыз беркатлы кешене.— Көзгече, Айбулатның хәйләсен ачуын белдереп, янгыратып көлде.— Күтәрегез бу мәсьәләне. Сораучылар байтак, җайларга кирәк ул эшне. Йөзек, беләзеккә көмеш йөгерткәнне белсәләр, халык агылып кына торачак. Аш сервизларын да китерә башлаячаклар. Гомерлек нәрсә юк бит, көмеш катлавы да ашала.

— Ярый, иптәш Шакиров, сезне бүтән тоткарлый алмыйм,— диде Айбулат кәгазьләрен җыеп.— Менә монда кул куегыз. Кызганыч, сезнең тәкъдимнәрне мин күтәреп чыга алмыйм шул. Эшебез башка. Аннары көмеш йөгертү проблемасын сезгә күтәрү кулайрак. Халыкка кирәк икән, нигә бу эшне дә юлга салмаска? Заказ күп булгач, планыгыз да тизрәк үтәлер.

Көзге мастерскоенда Айбулатны менә шулай һәр соравына тәфсилле җавап биреп, хаҗәте төшсә, тагын килегез дип, якты чырай белән озатып калдылар. Монда бернәрсә дә шик уятырлык түгел иде. Хуҗаларга рәхмәт әйтеп, Айбулат мебель комбинатына кузгалды.

Монда да көзге цехын тикшерде, әмма игътибарга лаек нәрсә таба алмады. Көзгече кустарь осталарны эзләргә базар тарафына китәргә җыенган иде, соңга калган булып чыкты — базар таралып чак житкән иде. Шуңа күрә мебель комбинатыннан туп-туры җинаятьләрне ачу бүлекчәсенә юл алды.

*
* *

Инспектор Вилданов заводның кадрлар бүлегендә спирт, фототасма урлап тотылган кешеләрне белешкәннән соң, исемлектәге затларның күптән түгел кичен һәм төнлә эш урыннарыннан югалып торуларын ачыкларга кереште. Унөченче цехта Лена Корниловаңы күргәннән соң, янәшәдәге корпуска юнәлде. Цех башлыгы, әйтеп бетергәнне дә көтмәстән, бүлмәсеннән чыгып китте һәм бераздан ике егетне ияртеп керде дә:

— Хуҗа Насретдин әйтмешли, менә сезгә табип, менә сезгә кабер казучы! — дип елмайды.— Таныш булыгыз: Валентин Николаев шушы егет була инде,— диде ул керүчеләрнең яшьрәгенә баш изәп.— Берьюлы смена башлыгы Хөсәеновны да чакырдым.

Цех башлыгының ашыктырып чакырып алуы Николаевны беркадәр гаҗәпләндергән дә иде, ахры. Касыйм үзенең кем икәнлеген танытып сораулар биргәч, ул тагын да аптырый төште.

— Бишесе көнне башта калорифер моторын төзәттем,— диде Николаев авырлыгын бер аягыннан икенчесенә күчереп.— Аннары ике үткәргечне сүтеп җыйдым. Эш көне шуның белән узды да китте, тирне сыпырып ташларга да вакыт тимәде.

— Эшегез шул хәтле каты булган, тугарылып беткәнсез,— дип шаяртты Касыйм Валентинның шнуры чишелгән ботинкасына ымлап.

Николаев шул шнурын бәйләргә иелгәндә түш кесәсеннән куен дәфтәре төшеп китте. Касыйм аны идәннән алып, ачык битләренә күз салды: адреслар, шигырьләр, кеше исемнәре, саннар язып тутырылган. Инспектор Вилданов исем, фамилияләр янына саннар язылган биткә аеруча игътибар итте. Әле яңа гына кадрлар бүлегендә шәхси документларын караган кешеләргә юлыкмасмы? Юк кебек. Билгеле, бу дәфтәрчекне яхшылап актарса шәбрәк булыр иде. Әмма моңа нигез юк, файдасы чыгу да икеле тоелды. Хөсәенов белән цех башлыгының үзенә карап торуын белгәнгә, инспектор Николаев дәфтәрен карауны уенга борды:

— Сиңа бурычка баткан кешеләр күп икән.
— Киресенчә, мин баттым ул,— диде Николаев.— «Планета» мотоциклы алган идем.
— Әйе, хәзер техникасыз берни эшләп булмый,— дип, Касыйм әңгәмәгә җилем кушарга ашыкты.— Егет булып, мотоциклың да булмаса, кызлар да карамый. Алар да хаклы: гөмбәгә барсаң да, балыкка йөрсәң дә, кешегә ялыныч бетә. Яшь-җилкенчәккә бер җилләнеп кайту да ни тора бит ул!
Ботинкасын бәйләп бетергән Валентин турайгач:
— Кызлар мотоциклсыз да кире какмый иде безне,— дип каршы төште.— Әмма аларга үземнең исем китмәде. Гыйшык сатарга хирeслек юк.
— Бигрәк тә хәзер, өйләнеп алгач! — дип көлде Хөсәенов.— Төн кыска дип зарлана торган чаклары бит әле.
Валентин чыгып киткәч, инспектор Хөсәеновка:
— Димәк, Николаев кичә һәр вакыт эш урынында булды? — диде.
— Әйе. Үз эше үзенә җиткәч, тагын кая йөрсен? Күз алдында булды. Бер тотынса, кулы кулга йокмый аның.
— Теге юлы ничә кап фототасма чәлдергән иде әле?
— Ун белән тотылды,— диде Хөсәенов.— Аның өчен җелеген суырдык инде без аның.
— Каян алган булган?
— Калорифер бүлмәсеннән таптым, диде.
— Ничек соң, бүтән андый эше юкмы?
— Бер хата ун хатадан саклый,— диде смена башлыгы.
— Андый-мондый нәрсә беленсә, хәбәр итәрсез. Миңа телефоным,— диде Вилданов.— Җинаять ачылганчы бу әңгәмәбез фаш итәлергә тиеш түгеллеге сезгә аңлашыладыр инде?
Пропуск бюросында Вилдановны милиция бүлегеннән җибәрелгән шофер каршылады.
— Беләсезме, әкәмәт булып алды бит әле,— диде ул җанланган кыяфәттә.— Килүебезгә унбиш минутлап бар инде. Тәмәке кабыздым да, машинадан чыгып, белдерүләр тактасы янына килдем. Малай машинада калды. Бер заман кычкыра бу, «әти» дә «әти» ди. «Нәрсә булды?» дим. «Монда бер апа килде», ди. Калганын үзең сораш, әнә ул.
Вилданов көлемсерәп, бичарадан ни чара гына тыңлагандай, малайга күз салды. Җиде яшьләр чамасындагы сипкелле, тезләре, терсәкләре сыдырылып беткән елтыр күзле, йомры гына малай.
— Я, нәрсә булды, герой? — дип елмайды инспектор малайның ком кереп тулган чәченнән сыйпап.— Нинди апа килде?
— Атаң каракларны эзләргә килдеме әйтте,— диде малай.
— Син ни дидең?
— Үзеннән сора, белмим, әйттем.
— Шәп, шәп, чая егет икән ич син! — дип көлде Касыйм.— Юкка гына борының күккә карамаган. Шуннан тагын нәрсә ди?
— Атаңа әйт, алар ялгыш юлга кергәннәр, әйтте. Сумкасында тимере дә бар.
— Нинди тимер? — Касыйм малайның янына чүгәләде.
— Йозагы! Сары тимер.
— Я, я, тагын нәрсә диде? — Вилданов ваемсызлыгыннан арынган иде инде. Ул шофер малаен кирәкле эзгә төшерергә теләп, сумканы оныттырырга тырышты.
— Алар каракны янгын командасыннан эзләсеннәр, әйтте. Янгын сүндерүчеләр заводка гел машина белән кереп-чыгып йөри, ди. Әти, әти,— диде малай күзен очкынландырып,— без янгын машинасын узабыз бит, име?

— Я, я, ул апа тагын нәрсә диде? — Касыйм түземен җуя башлады.

— Янгын сүндерүчеләрне тикшерсеннәр, диде.

— Тагын? — Касыйм кесәсендә актарынса да, малайга бүләк итәрлек берни таба алмады.

— Онытгым инде.

— Яле, исеңә төшер. Хәзер үзеңә шоколад алып бирермен шуның өчен.

— Бар, ал! — Шоколад сүзен ишетү белән малай тагын җанланып китте. Әмма Касыйм абыйсына бик үк ышанып та бетмәде сыман.

— Я, исеңә төшер әле, теге апа тагын нәрсәләр әйтте? — дип сорашуын дәвам итте инспектор.

— Тагын... капкада янгын машинасын карап тормыйлар, диде.

— Кызы-ы-ык! Ә нинди рәк иде ул апа?

Әмма малай үзе белән сөйләшкән хатын-кыз турында, ялтыравык сары йозаклы сумкасыннан башка, бер әйбер дә әйтә алмады. Смена алышына торган чак булганга, бу вакытта эшкә баручылар да, аннан кайтучылар да күп иде. Билгеле инде, һәр хатын-кызда диярлек сумка булып, аларның нәкъ яртысы сары йозаклы иде.

Көтелмәгәндә юлыккан бу табышмак Касыйм уйларына өстәмә юнәлеш бирде. Әгәр хатын үз фаразын гына белдергән булса, аны табуның әллә ни әһәмияте юк. Әгәр җинаятьчеләр белән бәйләнгән булып, хәзер аларны фаш итәргә карар биргән булса? Ул чакта хатынны табу каракларны кулга төшерү белән бер иц! Әгәр... әгәр серле хатын җинаятьчеләр төркеме белән бәйләнгән, хәтта көмеш урлауда катнашкан икән, өерне тоттырудан аңа ни файда? Бәлки аның тикшерүне ялгыш юлга гына кертәсе киләдер? Чынлап та, әгәр ихлас күңелдән җинаятьне ачтырасы килә икән, нигә бала белән бәйләнергә? Нигә аның атасына әйтмәскә?

Әгәр ул иптәшләренең күзәтүеннән курыкса? Шунлыктан ашык-пошык, кача-поса гына ярдәм итәргә мәҗбүр булган булса? Бәлки суд, милициягә шаһит булып йөрергә теләмәүдән генә үзен белгертәсе килмидер? Шулай икән, нигә ул хатынга ышаныч белән карамаска? Касыйм, әлбәттә, аны эзләп табар. Әлбәттә, ул хатынны бергәләп эзләү җинаятьне ачу вакытын шактый ук кыскартуы ихтимал.

Әмма Вилданов ашыкмаска карар итте.

*
* *

Байчурин киңәшмәдән соң кабинетына кереп сигарет кабызды. Нәҗибә белән сүз куешкан очрашуга кадәр әле шактый вакыт бар иде. Хаҗиевадан сорау алу беркетмәсен эзләп тапса да, аны яңадан укып чыгарга түземе җитмәде — җөмләләре генә түгел, һәр сүзенә хәтле болай да таныш иде. Хәер, әгәр үз ихтыярында булса, беркетмәдән кызыклырак нәрсәләрне дә укырга алынмас иде. Соңгы вакытта, әгәр хезмәте генә таләп итмәсә, кызлар белән бөтенләй аралашмас булды. Инде бүген күңелгелгән гадәтне бозарга туры килә икән, нигә аны тулысы белән ял итү, күңел ачуга әйләндермәскә? Күңел ачуга ЖАБ [1] эшен дә өстәргә мөмкин. «Мөмкин генә түгел, син нәкъ менә шулай эшләргә тиеш тә!» — дип уйлады ул. Эш-хәрәкәтләрен генә тезгенләргә түгел, уйларын да авызлыкларга өйрәнгән Айбулат сигаретын төзәтә-төзәтә әле яңа гына Касыйм алып кайткан беркетмәләрне актара һәм заводта тормышы кыек юлларга кереп баручы эшчеләрнең фоторәсемнәрен күздән кичерергә кереште. Аларның берсен икенчесе белән

[1] ЖАБ — җинаятьләрне ачу бүлекчәсе.

чагыштырды һәм характерлы йөз сызыкларын истә калдырырга тырышты. Аннары үзен сынар өчен күзен йомды һәм күңелендә шуларның сурәтен барлыкка китерде, хәтеренең ялгышмавын белер өчен тагын фоторәсемнәргә төбәлде. Бу юлы аларны системалаштырып, охшашлыклары буенча төркемләп чыкты. Инде мөгаен, ялгышмас, бер көн эчендә хәйран ишәйгән кәгазь боткасын папкаларга да тутырырга мөмкин. Тәртипкә салып тегеп куярга дәрте кузгалса да, очрашуга барасын уйлап, Айбулат кул селтәде. Соңыннан да өлгерер. Әйгә шалтыратып кисәтеп куйса, яхшырак булыр.

Сеңелесе белән сөйләшкәннән соң сәгатенә караса, аңа кузгалырга вакыт икән. Шул чак бүлмәгә дөбер-шатыр Касыйм килеп керде.

— Китеп бармаса ярар иде дип курыккан идем, ярый әле, өлгердем,— диде ул елмаеп.— Капкалап килдем. Сезнең беркетмәләрне укып чыгармын диген идем.

Айбулат, сейфны ачып, Касыймга беркетмәләрне тоттырды.

— Беләсезме,— диде Вилданов,— мин склад бары тик үткән төнне генә басылгандыр дип тулысынча ышана алмыйм. Чөнки Хажиева: көндез көмеш бүлегенә кермәдем, ди. Бәлки ул аның бигенә дә юньләп игътибар итмәгәндер? Биге исә иртән үк ачык булгандыр? Хажиева, гомумән, пәрәвезгә эләккән чебен кебек талпына шикелле.

— Хажиева тузанны үлчиселәрен белми иде дип саныйк. Кайбер капчыклар өстендә тузан аз булу аннан чималның яңа гына алынуы турында сөйли ич.

— Бәлки каравыл башлыгының да гаебе бардыр? — диде Касыйм.— Бәлки аңа күптән пенсиягә китәргә кирәктер?

— Ачыкларбыз,— диде Айбулат.— Тикшерүче тойгыларны онытып, бары фактларга гына таянырга тиеш. Көчебез арта әнә: Шәмсия Зиннәтева вокзалларны, Даниэль Соломонович үзе оптика заводын тикшерергә алынды. Ә без заводта казынырбыз. Ярый, хәзер мин ашыгам, бер эш килеп чыккан иде, сыпыртыйм әле.

Айбулат троллейбуста барганда сеңелесен искә төшерде һәм эшнең болай уңайсыз килеп чыгуына уфтанып куйды. Ә бит сеңелесе булдыклы! Абыйсыннан алда тормыш та корып җибәрде, малай да үстерә. Канат чыгарган оясын да онытып бетерми — әнкәй, абый, энем дип хәзер килеп җитә. Керләрен дә юып китә. Ә Айбулат менә аларны ничә тапкыр парлап кунакка чакырып, соңгы айларда бер генә мәртәбә дә өйдә каршылый алмады. Үпкәләүләре бар. Сеңелесе әле ярар, тугызынчыда укып йөргән энесе дә «абыйдан алда үзем өйләнәм әле» дип үртәгән була, шайтан алгыры! Мыскыл итәргә җае бар шул. Уен эш түгел, быел егерме сигезне тутыра Айбулат.

Әлегә кадәр моңа бик үк пошынмаган, баш исән булса, бүрек табылыр дип йөргән Айбулат, әлбәттә, озаккарак сузылган буйдаклыгын нормаль хәл дип санамый иде. Әмма бер селтәнү белән үзгәреш ясарга да ашыкмады. Нормаль тоелмаса да, сәбәпләре җитди булды ич. Армиядән кайткач башта кичке мәктәптә, аннары читтән торып институтта уку күпме айлы төннәрне ашаганын ул бер үзе генә белә. Шуның өстенә озак еллар буе гел кичке якта эшләү дә кызлар компаниясеннән эз мәхрүм итмәде. Ә бер заман тормыш иптәшен югары белем алгач кына сайларга кирәк дип исәпли башлады. Янәсе вуз бетергәч ул кызлар өчен кызыктыргычрак кавалер булыр, димәк, үзе дә зурракка дәгъва ясый алачак! Буш вакытның шактый өлешен самбо секциясенә сарыф итү дә аны кыз-кыркыннан шактый ераклаштырды, ахрысы. Хәзер дипломы да кесәдә, шәп кияү егете булыр өчен бүтән сыйфатлары да җитә кебек: иптәшләре арасында авторитеты бар, перспективалы исәпләнә. Икенче яктан, ярыйсы ук тормыш тәҗрибәсе туплады Айбулат. Эше дә гыйбрәт бирә торган. Шулай булгач, үзенә пар сайлау шактый җиңеләергә тиеш иде. Әмма бу читтән караганда

гына шулай икән. Дипломлы һәм эштә перспективалы булу, мәсәлән, кызларның хисеннән бигрәк исәп-хисабына, ягъни бик үк эчкерсез булмаган акылына күбрәк тәэсир ясый икән! Моны Айбулат берничә ел дәвамында бергә эшли яки күршедә яши торган тәкәббер кызларның таш йөрәкләре «эреп», үзенә мөнәсәбәтләре үзгәрүдән чамалады. Ә хистән башка ничек бергә оешмак кирәк? Дөрес, Шәмсия андый кызларга охшамаган. Дәрәҗәгә табынса, күрше районнан килеп сүз кушып йөргән капитанга якты чырай бирер иде. Ә ул һаман Айбулатка тартыла сыман. Бер оператив төркемгә эләгеп эшләргә тырыша. Үтенеч, йомышларны канәгатьләндерми калмый. Шаярырга да әзер. Әмма чытлык түгел. Горурлык та бар бугай кызкайда үзенә карата. Шәмсиянең аерым игътибар күрсәтүен белеп тора Айбулат, тик моңа тәгаен генә җавап бирергә кыймый әле. Бергә эшлиләр, әллә кая качмас, янәсе. Тормыш үзе күрсәтер: дусларча һәм иптәшләрчә җылы мөнәсәбәте тагын да үсеп китәрме, сүрелерме...

Алар Татар ашлары йорты янында очраштылар. Нәҗибә шаян елмаеп:

— Бүген җинаять ясамаска сүз бирәм! — дип күреште.

— Ә ни өчен бүген? — диде Айбулат тигез ак тешләрен ялтыратып.

— Элегрәк яшь егетләрнең мин-минлегенә тия идем.

— Ялгышмасам, ул нәрсә җинаять дип аталмый.

— Нәрсә соң ул?

— Үзеңә гашыйк иттерү, базарыңны күтәрү өчен хәйлә генә. Без аны рәхәтләнеп гафу итәбез.

— Ипле җавап,— дип көлде Нәҗибә.— Өч ел күрешмәдекме? Тагын бер-ике ел үтсә, билләһи, танымас идем!

— Аның каравы, синдә үзгәреш юк.

Үткән еллар эчендә кыз һич тә үзгәрмәгән дип әйтү акылга сыймый иде. Фәлән яшькә олыгаюы, аның кызлар хәвефләнә торган яшькә җитүенә киная ич. Әмма Нәҗибә, гомер узуына үч итеп дигәндәй, чибәрләнә генә төшкән, хәтта бераз яшәргән дә кебек тоела иде. Бүген иртә белән очрашкандагы кыяфәтенә дә яңа бизәкләр өстәргә өлгергән. Кара сумкасын искә алмаганда, бөтен киемен һәм кулындагы әйберләрен алыштырган. Аягында лакланган кара туфли, тик ул иртән кигәне түгел. Бусының энҗеле брошкасы бар, шуңа күрә ул нәфисрәк һәм купшырак. Иртән маңгаен каплап торган чәчләре арттан элэктереп куелган булса, хәзер алар баш түбәсенә өелеп, үрелгән шиньон белән уратып алынган, аның берничә җиренә ялтыравык брошка кадалган. Аяк битенә җитә язган шоколад төсендәге озын йон күлмәк кигән. Күлмәкнең җиң очлары һәм изүенә татар орнаментына хас нечкә, катлаулы үсемлек бизәге чигелгән. Ул бизәкнең һәр чәчкәсе, чәчәкнең һәр мыекчасына энҗеләр тезелгән.

Ресторанның ак мәрмәр баскычыннан өскә күтәрелгәндә Нәҗибәнең киңәеп килгән җиң очындагы һәм изүендәге энҗеләре, чәчендәге брошкалары йолк-йолк итеп бәйрәмчә кәеф тудыралар иде. Урам утларының юка яшел тәрәзә пәрдәләре аша үтеп кергән яктысында зал диңгез аквариумын хәтерләтә. Анда инде яңа кунакларга урын да калмаган. Бирге баштагы өстәлдән:

— Менә монда утыра торыгыз, без хәзер түлибез дә китәбез,— дигән чакыру ишеткәч, Нәҗибә стенадагы җиз рәсемнәргә карап:

— Уңдык, өстәлебез нәкъ су анасы каршында гына,— дип елмайды.

Айбулат раслап баш какты. Нәҗибә нинди генә тәэсир ясамасын, бу юлы ул үзен, үткән еллардагыдан аермалы буларак, аның янында ягымлы, әмма битарафрак тотарга, артыгын мавыкмаска, кызның күзенә кереп маташмаска карар иткән иде. «Ошамаганмын икән, нәрсә башны кайгыга салырга»,— дип уйлады ул.

Үзгәрешне Нәҗибә дә сизеп алды.

— Шушы су анасы каршына утырырга яратам. Кара әле, чәчкәйләре нинди озын! — диде ул стенадагы панного баш изәп.— Су буен, таллар һәм серле төнне, сыек кына ай яктысын күз алдына китерә. Җаен менә шундый җирдә утырсаң, чайрап, онытылып ятсаң икән, ә!

— Монда начармыни?

— Монда ни, таш та пыяла. Чын матурлык табигать кочагында инде ул.

— Матурлык безне чолгап алган, үзен һава сулагандай сулыйбыз, игътибар гына итмибез, дигән Бодлер.

Айбулат, өенә кагылырга өлгермәгәнлектән, монда эш киеменнән килгән иде. Затлы киенгән-ясанган Нәҗибә янында ул ефәк янәшәсендәге ситса кебек калды. Шулай да кыз Айбулатка кызыксынып күз ташлады һәм күңеленнән аны үзе өчен якын булган икенче берәү белән чагыштыра башлады. Озын төз гәүдәле, тонык ак чырайлы, туры кылыч борынлы, асты калын, өске яктагысы юкарак сусыл иренле, уйнак күңелле, берәр танышының килеш-килбәтен, хәрәкәтләрен, сөйләү рәвешен кыланып күрсәтергә яратучан җырчы егетне Айбулат янәшәсенә куеп карады. Җырчы егет дегеттәй кара чәчле, сумала кашлы, киң маңгайлы, басынкы табигатьле милиционер Байчуринга бирешерме икән? Үзе елмаеп та карамыйча, кешене көлдерә алу сәләте генә дә ни тора бит! Берәрсенә охшатып сөйләнә башласа, эчең катар. Нәҗибә менә шуны исенә төшергәч, Айбулатка төрттереп куюдан тыела алмады:

— Матурлыкны якласаң да, тормыш бик баскан әле үзеңне. Өйләнгән ир төсле тугарылгансың!

Башка вакытта үзенә контроль ясарга өйрәнгән Айбулат җиңелчә кызарынып китте. Нәҗибә исә аны көлемсерәп күзәтә, зур коңгырт күзләре ярым җитди төс алган, кашлары күтәрелгән, озын керфекләре ачылган иде. «Нинди чибәр! — дип уйлады Айбулат ирексездән.— Түшләре аккошныкы кебек ак, бит очларына алсулык йөгергән. Чәчләрен кынага буяган, күрәсең. Назланырга, көязләнергә дисәң, тиңе юк. Уф!»

Официант заказ алып киткәч, Айбулат шаярткандай итенде:

— Өйләнсәк тә вакыт инде. Кызыл кар яуганны көтеп тормадым. Әмма бу безнең дуслыкка киртә була алмас дип ышанам.

— Һич тә,— дип көлде Нәҗибә,— киресенчә, кеше ире белән ресторанда утыру минем өчен яңа нәрсә, шуңа күрә тагын да мавыктыргычрак.

— Ә үзең! — дип сорады Айбулат.— Кызларга синең яшьтә, үзең беләсең, кияүле булу хәерлерәк.

Нәҗибә өстәлгә куелган графиннан фужерга ширбәт салып берике йотым эчте дә уңайсызланып кына хәбәр иткәндәй әйтте:

— Аспирантурага керергә кирәк дип уйлаган идем. Шуңа әзерләнгән арада егетләр исәбеннән божыр ите капкалап, шампань да гөпелдәткәләп алабыз менә! Әмма туйдыра башлады бу мине. Уйлап карасаң, исең китәр: егетләр шул кадәр дә бер-берсенә охшар икән. Барысы да эгоист!

— Хатын-кыз үзенә табынмаган теләсә кайсы ирне эгоист дияргә әзер,— диде Айбулат елмаеп.— Нишлик соң, безнең өчен дә мәҗүсилек заманнары үтте ич инде. Теләсә кемне алла итә, теләсә нәрсәгә табына алмыйбыз.

— Мин табыну көтә торган деспотка охшаганмынмы әллә?

— Кем белә аны? Чибәр кызлар кәеф кырырга оста, чәнечкеле чәчәк кебек алар.

— Безнең заводта нинди эшләр майтарасың әле? — дип Нәҗибә сүзне икенчегә борды.

— Безгә эш бетми инде.

— Хәтәр җинаятьме?

— Хатынымның чәченә чал төшү дә җиткән, син дә борчылма инде,— диде Айбулат көлемсерәп. Нәҗибә моңа үпкәләгәндәй булды:

— Ни өчен мине үртәргә булдың әле?

— Ачыктан-ачык сөйләшү үртәү дип аталамыни?

— Иске дуслар аркылы белештем инде, син һаман шундак икән,— диде кыз.— Татлы хыялларга чумган кияү егете!

— Моннан нәрсә үзгәрергә тиеш соң? Әйдә, авыз итик әле,— дип, Айбулат бокалларга шәраб койды.— Нәрсә өчен күтәрәбез?

— Беренче тостны һәркем үзеннән әйтсен!

— Аңламыйм!

— Күпсүзлелек чын фикерләрне яшерүгә генә хезмәт итә.

— Моны үз тәҗрибәң нәтиҗәсе дип кабул итимме?

— Усалланма!

Айбулат яхшы ук ачыккан иде. Күз ачып йомганчы, итле салатны ялт иттерде. Аннары бокалларны янадан тутыргач:

— Ә бусын ни хөрмәтенә? — диде.

Нәҗибә:

— Һәркайсыбызның үз максатына ирешүен теләп,— дип чәкештерде.

Айбулатка уртак бәхет өчен күтәрү ошыйрак төшсә дә, каршы килмәде. Яхшы эчемлек аның арыган буыннарына җылы агым төсле тарала башлады. Вальс биеп килгәч, мәктәп елларындагы хәлләрне, иптәшләрен искә төшереп байтак утырдылар. Айбулат залдагыларны күздән кичерергә дә онытмады. Әкренләп урамда караңгылык куерды, залда кеше тагын да күбәйгәч, тынчу була башлады. Алар урамга чыктылар.

— Кайда торасың? — дип сорады Айбулат.

— Бишбалтада. Стадионга чаклы җәяү барсак та ярый.

Тик Айбулат узгынчы таксины туктатып өлгергән иде инде.

— Бүген бездә кунаклар бар иде, сеңелләр,— диде ул.— Аларның мине көтеп утырулары мөмкин, кызуларга туры килә. Иркенләп башка вакытта йөрелер әле.

Ун минуттан такси «Идел» кинотеатры артындагы йортларның берсе алдына килеп туктады.

— Әйдә, берьюлы күреп тә чык инде,— дип чакырды Нәҗибә.

— Хәзер соң инде, кеше алдында уңайсыз булыр.

— Минем беркемем юк. Үзем генә.

Алар дүртенче каттагы унөченче квартирага керделәр.

— Рәхим ит, утыр. Кофе белән сыйлый алам,— диде Нәҗибә.

— Юк, юк, рәхмәт. Такси көтеп тора. Күрәм, әйбәт оя коргансың. Хуҗа да үзеңме?

— Әйе. Кооперативка катышып алдым.

— Кара аны, баю чыганагыңны ачыкларга туры килмәсен,— дип шаяртты Айбулат.— Кем икәнемне беләсең, саклан!

— Сездән котылып буламы соң, Әбугалисина кебек, келәм астындагы бер бит кәгазьне дә сизеп ала торган кешеләрдән! — дип елмайды Нәҗибә.— Әллә бездәге баючыларны да син тикшерәсеңме?

— Шундый хәбәр бармыни?

— Үзең шалтыратканнан соң сорашкан идем, склад күршесендәге цех лаборанткалары әйтте. Очына чыгып буламы соң?

— Әле бу турыда сөйләшергә иртәрәк. Я, хуш, күңелле булды, әмма яхшы нәрсә күп булмый,— диде Айбулат.

— Миңа да кызык булды.

Бу сүзләр нәрсә аңлатканын юньләп төшенмәгән Айбулат аңлаганын белгерткәндәй баш какты. Хатын-кыз мәкерле дә инде,— дип уй-

лады ул,— әллә ихлас күңелдән әйтәләр, әллә юри котырталар. Белмәссең...

— Иртәгә үзем шалтыратырмын,— диде ул.— Мине игътибарсызлык күрсәтүдә гаепли алмассың инде.

— Күрербез, кешене вакыт сыный.

Айбулат баскыч буйлап аска йөгерде. Ә хыялында ул үзен биеккә, югарыга үрли, кулларына канат үскәндәй тоя иде. Менә бер җилпенеп куяр да еракта-еракта җемелдәшкән йолдызларга хәтле барып җитәр сыман! Урамга атылып чыккач кына үзендә кинәт туган үзгәрешкә хисап биреп көлемсерәп куйды. Тик йөрәген берни дә эшләтә алмады — бүтән кешеләргә хас нәрсә аңа да ят түгел иде.

*

* *

Инспектор Касыйм Вилданов эш көнен янгын командасын тикшерүдән башлады. Анда кызыклы табышка юлыкмагач, Гайния Хаҗиева тирәсендәге томанны таратырга карар итте. Бәлки кулына асыл кош үзе эләгер?

Ишекне алтмыш биш яшьләр тирәсендәге бер карчык ачты.

— Кем кирәк, улым!

— Энергетика бүлегеннән мин.

Көтелмәгән хәлдән куркып калган карчыкның «әстәгъфирулла, бу нинди зәхмәт?» дип хәлсезләнеп стенага сөялүенә дә игътибар итмәстән, электр санагычның пәрдәсен күтәрде. Аннары дөбер-шатыр кухняга кереп, утларны элдерде. Хәзер инде керүченең бандит та, карак та булмавын төшенгән карчыкка хәл кергән иде булса кирәк:

— Улым, ботинкаларыңны салып керергә кирәк, бу нинди сансызлык. Уф, котымны алдың, фетнә! — дип сукрана башлады.

Вилданов карчыкны өркетүенә эченнән уңайсызланса да, үзен нәкъ контролерларча тотарга карар биргән иде.

— Зарыгызны эш урыныма хәбәр итегез, бездән аяк киемнәрен салып тору таләп ителми,— диде коры гына.— Һәр фатирда чишенә башласак, ничек өлгерик?

Көньякка караган ике тәрәзәдән каршыдагы пианино өстенә мул яктылык төшеп клавишларда чагыла иде. Түрдә уң якта «Рубин» телевизорының соңгы маркасы, сул чатта «Ригонда» радиоалгычы урнаштырылган. Тәрәзә буендагы диванга затлы келәм капланган. Шундый ук йончалы келәм түргә, тагын берсе ишек катына идәнгә җәелгән. Янә бер кечерәге ишек янындагы тахтадан асылынып тора. Ялтыравык сервант эчендә импортный сервиз. Кухняда «Мәскәү» суыткычы кукыраеп утыра. Кәнәфи, өстәл-урындыклар да, массив кием шкафы, сервант, радиоалгыч һәм телевизор, хәтта чехословак пианиносы да бер үк төстә — яхшы зәвык белән сайлап алынган. Бүлмә җыйнак, күңелле. Касыйм канәгать төстә тамак кырып, кесәсеннән блокнотын чыгарды һәм электр санагыч күрсәткечен язып алды. Аннары кухнядагы утны сүндереп бүлмәдәгене элдерде, тузанлы ботинкалары белән лап-лоп басып, радиоалгычларны электр челтәренә тоташтырды. Электр санагыч тәгәрмәче куәтлерәк әйләнә башлады.

— Ярый, әби, сау булыгыз. Эшләр уң икән.

— И-и, алла колы, шакшы эзләреңне кара син, «уң» ди тагын,— дип ачуланды карчык.— Хөкемәт тиененә калмаган без, болай рисвай итеп йөрисе юк. Йөрәгемне алдың, абау!

— Эшебез шундый безнең, әбекәй. Ярый, киттем.

Вилданов, шик тумасын өчен, күршедәге тагын өч-дүрт фатирны тикшерде. Бу эшне шома гына башкарып чыккач, җиңел сулу алып, ҖАБка юнәлде. Хәзер ул Алексеева сүзләренең дөрес булуын үз күз-

ләре белән күреп ышанды. Әгәр саклык кассасында акчасы да булса, склад мөдире Гайния Хажиевадан кабат сорау алырга кирәк булачак.

Касыйм әчке эшләр бүлегенә канатланып кайтты һәм саклык кассалары идарәсенә рәсми бер кәгазь әзерләде.

*
* *

Өлкән инспектор Байчурин кустарь көзгечеләрне барлауны Казанның үзәк базарыннан башлады. Базарның Нәриман урамы чатына кулдан сатучылар җыела иде. Тотылган кием-салым, комган, чүлмәк, посылка тартмалары һәм башка вак-төяк сатучылар арасында көзгечеләр күренмәгәч, милиция постына мөрәҗәгать итәргә булды.

— Соңга калгансыз, иптәш Байчурин,— диде аңа инде байтак еллардан бирле таныш булган сержант.— Элегрәк килсәгез, өсләренә генә барып чыгадырыегыз. Бетте алар хәзер, җир уптымыни. Кибеттә тулып ята көзге.

— Китсәнә, ничек алай кинәт бетсен икән ул?

— Кинәт түгел. Әле моннан унбиш-егерме еллар элек кенә дә базарның Нәриман ягы кайнап торадырые. Һи-и-и, нәрсә генә юк! Икенче Саручи! Ә хәзер һөнәрчеләре дә юкка чыкты аның. Анда-санда карт-коры гына күтәреп чыкмаса, әйбере дә күренми.

— Башка базарларда да шулаймы икән?

Айбулат өлкән яшьтәге сержантның җыерчыклы битенә, юаная, салына башлаган гәүдәсенә күз төшерде. Әле кайчан гына егет сымак йөри, базар уртасында хан кебек басып тора иде ул. Бирешә төшкән сыман тоелса да, күзе очлы булырга тиеш әле аның.

— Сәүдәгәрлек һәр җирдә тыйлыкты хәзер,— диде сержант.— Көзге дигәннәрен телефоннан да белешә алабыз, бүтән базарларда да белгәннәрем эшли.

Айдар урамындагы базар кеше күзе төшми торган бер җирдә, ике катлы тәбәнәк таш йортлар арасында икән. Авылча гына корылмалар, биек агач капка. Койма буйларында яшел чирәм үсеп чыккан. Җиләк-җимеш, яшелчә сатучы унлап кешегә, алучылар булмаганлыктан, бик күңелсез иде, ахры, Айбулат күренүгә җанланып киттеләр. Әмма өлкән инспектор туп-туры кәнсәләргә таба атлады. Монда утырган ак халатлы хатын кассир икән. Айбулат көзгечеләрне сорашырга кереште.

— Монда берәү генә күренгәли,— диде кассир.— Шушы тирәдә генә тора, үзе каравылда эшли. Пенсионер. Озын буйлы, көрәк сакаллы абзый. Степан исемле, фамилиясен белмим. Алар базарның тышында сату итә. Якшәмбе көннәрдә халык бик күп була бездә, койма эченә сыймый. Шуңа күрә алардан урын өчен түләтеп тә булмый. Квитанция язмагач, фамилиясен каян белим? Якшәмбедә килегез, базарга чыкмый калмый ул, күрсәтермен.

— Миңа ашыгыч кирәк иде шул,— диде Айбулат.— Аны яхшырак, якыннанрак белүчеләр юкмы?

— Ит чабучы Гыйльметдин белә аны. Тик ул хәзер монда түгел, төп базарда. Монда филиал гына безнең.

— Аны телефонга чакырып булмыймы?

— Карап карыйк.

Кассир, төп базарга шалтыратып, трубканы Айбулатка бирде. Берәздән Гыйльметдинне табып китерделәр. Ул көзгеченең яшәгән урынын ачыклады.

— Исемен генә беләм мин дә,— диде ул.— Торуы базардан түбән таба өч квартал узгач, аркылы урамда. Ашхабад урамы белән төшсәгез, чаттан бишенче йорт.

— Ул көзгене әле хәзер дә ясыймы?

— Әйе.

Айбулат көзгече Степаннарга барганчы, прокурордан тентү ясарга санкция алырга булып, ЖАБка кайтты. Кем белә, дөресен сөйләргә теләрме әле Степан, әллә юкмы? Чималны үзе дә суддан тапкан кеше нишләп барысын да җинел генә ачып салсын икән? Өметләнергә ярамый. Әгәр көзге ясарга заказ бирүче булып кына килеп керсә? Ул чакта кызыксындырган бөтен сорауларга да җавап алу икеле. Заказчының чимал турында сорашуы ук Степанны шикләндерер, итәгенҗиңен җыярга мәҗбүр итәр. Әллә соң көзгече һөнәренә өйрәнергә телим дип барсынмы? Белмим, Степан мона риза булып торыр микән? Халәл ризыгына кул сузучы итеп кабул итсә, якын да китермәс. Менә шулай берсе арты икенчесе барлык вариантларны күңелдән кичергәч, Айбулат рәсми тикшерүче буларак килеп керергә карар итте. Сорау алу кулга канәгатьләнерлек материал төшерергә мөмкинлек бирмәсә, тентү ясар.

Өлкән инспектар Байчурин резервтан бер милиционер алып, бүлек машинасында Ашхабад урамына юлга чыкты.

Машина авылныкы кебек чирәмле тыныч урамнарның берсенә борылып, сарыга буялган болдырлы зур таш йорт каршында туктады. Күршеләрдән шаһитлыкка ике кеше чакырып, өй эченә керделәр. Әле буяу исе бетеп тә җитмәгән алгы бүлмәдә аларны кассир әйткән карт каршылады.

— Чакырылмаган кунаклар килә,— диде Айбулат хуҗага. Аннары үзенә ияргән кешеләргә борылып әйтте:— Сез, иптәшләр, шушында гына торып торыгыз.

Озынча йөзле, конгырт чәчле, уртачадан калкурак буйлы, кул артларына саргылт идән буявы каткан карт тынычсызланып Айбулат артыннан кереп килүче милиционерга карады, араларында Байчуринның баш булуын белгәч, аны-моны дәшми зал ишеген күрсәтте:

— Керегез.

Айбулат картның тупас тукымадан тегелгән зәңгәр чалбарына, чабулары чалбар өстеннән җибәрелгән вак шакмаклы соры күлмәгенә, конгырт төкләре ачык изүеннән күренеп торган күкрәгенә йөгерек караш ташлады да:

— Көзгече Степан сез булсагыз, керергә туры килә,— диде. Искерәк фасондагы мебель белән җиһазланган залга бер күз салгач, аяк өсте торган хуҗага:— Утырыйк, сүзебез житди безнен,— дип өстәде.— Менә таныклыгым. Сез дә пастортыгызны күрсәтегез, танышыйк.

Хуҗа буфет тартмасыннан паспортын алып бирде һәм Айбулат каршына килеп утырды.

— Димәк, Степан Муллин. Өченче төзелеш идарәсендә эшлисез. Каравылчы. Алтмыш өч яшьтә.

— Шулай, гражданин инспектор.

— Буш вакытта көзгеләр ясыйсызмы? — дип сорады Айбулат.

— Аптырый калдым әле, — диде Муллин,— нәрсәгә кирәк булдым икән?

Карт бүлмәгә килеп кергән оныкларын җәлт кенә чыгарып җибәрде дә янадан урынына утырды.

— Көзге ясаучыларны барлыйбыз,— диде Айбулат.

— Ул эшне ташлавыма биш былтыр инде.

— Үткән базарда да биш былтыр элек ясаганнарны саттыгызмы?

Муллин өлкән инспекторның чәнчеп каравыннан соң, аның базар хәлләрен белүен сизенеп, көзгегә катнашы булуын бөтенләй кире кагып булмасына ышанды булса кирәк:

— Электән калган товар бар иде, сатылмый ул хәзер,— диде.

— Әйдә, дөресен генә сөйләшергә килешик,— диде Айбулат.— Бушка вакыт уздырмыйк, прокурорның тентү ясарга рөхсәтен ала килдем. Безне күзге ясавыгыз түгел, чималны кайдан алуыгыз кызыксындыра. Әллә баштан ук мастерскоегызны күрсәтәсезме?

Муллин кара көеп тышка атлады. Кирпеч келәтнең ишеген ачып, карагыз дип ишарә ясады да, үзе кырыйга кагылып, Айбулат белән шаһитларны алга уткәрде.

Мастерской итеп көйләнгән келәтнең уртасында зур киң өстәл, аның артына верстак куелган иде. Шүрлекләрдә балта, пычкы, ышкы кебек кораллар, зур тәрәзә төбендә буяу банкалары. Бер почмакта тартмасы белән табаклы калын пыяла тора. Шуның янәшәсендә парикмахерская-дагыча киң, әмма алардагыдан шактый биегрәк өч күзге. Айбулат асылма шкафны ачты. Аның шүрлекләрендә ике бөркегеч, скипидар исе аңкытып торган буяу пумалалары. Аптекадагы кебек төрле зурлыктагы пыяла банкалар. Әмма Айбулат монда үзе эзләгән көмеш нитратын күрмәде. Сыеклык тутырган шешәләрнең «лигроин», «уайт-спирт», «ксилол» дигән язуларын укыгач:

— Монда лаборатория кебек! — дип куйды.— Химикат белән лыкма тутыргансыз, буяуларның ниндие генә юк, хәтта сумала да кантары белән! Гражданин Муллин,— дип эндәште ул күзгечегә,— остаханәгез ташландыкка охшамый бит. Табаклы пыялалар да хан заманында ук алынмаганнар, иеме? Бакчы, бу күзгенең буявы да кибеп җитмәгән төсле!

Айбулат мастерскойның астын өскә китереп эзләсә дә, нитратка юлыкмагач, шаһитларны иярТеп өйгә керергә булды.

— Пульверизатор, пумалаларыгызны алып китәргә туры килә,— диде күзгечегә.— Экспертлар нинди химикат, буяулар белән эш иткәнлегегезне ачыклар. Кайда тагын нәрсәгез бар, үз ихтыярыгыз белән чыгарып бирегез. Амальгама катлавын нәрсәдән җәясез?

Муллин китап шкафыннан көмеш сыман ак порошок тутырылган банка алып Айбулатка сузды.

— Нәрсә бу,— дип сорады Байчурин.

— Хлорлы көмеш. Ялтыравык элпә катлавын шуңардан җәя идем.

— Каян алдыгыз?

— Базардан. Күптәнге запас инде.

— Бу арада тагын тәкъдим итүчеләр күренмәдеме?

— Юк.

— Хлорлы көмеш сатучы кешеләр белән безне дә таныштыра аласызмы?

— Аларны үзем дә белмим.

— Алар сезне ничек таба соң?

Муллин иңбашын сикертеп куйды да:

— Базарда күзге сатканга тәкъдим иткәннәрдер инде,— диде.

— Күрсәгез, аларны танырсызмы?

— Танырга тиеш.

«Эзгә төшә башладым бугай», дип уйлады Айбулат. Ул Муллинның паспортын яңадан кулына алып, аның «аерым билгеләр» дигән битен ачты. Паспортта «Тасманур» заводының кадрлар бүлеге мөһерен күргәч, кычкырып җибәрүдән үзен көчкә тыеп калды. «Көмешне әллә кайдан эзләп йөрисе булмаган икән ич сиңа», дип уйлады Айбулат. Бәлки менә шуңа күрә дә көмеш тәкъдим итүчеләрне төртеп күрсәтә алмыйдыр?

— «Тасманур»ның ничәнче цехында эшләдегез? — Айбулат сораштырган арада өстән-өстән генә булса да бүлмәләргә күз салып чыкты.

— Җиденчедә,— дип җавап бирде Муллин.

Складтан нитрат нәкъ менә шул цехка барып керә ич! Хәер, хлорлы көмеш, ди бит әле. Нәрсә икәнен лабораториядә ачыкларлар. Тик

шунысы бар, химикатны тикшерәселәрен белә ич Муллин, алдамас. Ә бәлки нәрсәгәдер өметләнәдер? Әгәр хлорлы көмешне нитраттан чыгарып булса? Шик төшүдән саклану өчен нигә шулай эшләмәскә?

Айбулатның уйларын укыгандай, Степан Муллин телгә килде:

— Әйтергә онытканмын, үткән атнада берәү нәрсәдер китермәкче булып сөйләшеп торган иде.

— Кайчан, кая китермәкче?

— Иртәгә көндезге унда үзәк универмаг янында очрашырга сүз куешкан идек.

Айбулат күзгечене сынап күздән кичерде. Муллин, үз хәлен җиңеләйтергә исәп иткән кешедәй, инспекторга туры караган иде.

— Күпме китерәчәк.

— Белмим.

— Үзен кем дип таныштырды?

— Мондый очракта исем, фамилияне әйтеп сөйләшмиләр,— диде күзгече.— Сорамадым, ул да паспортын күрсәтмәде.

— Иртәгә аны безгә күрсәтерсезме? — диде Байчурин.

— Булдыра алмыйм.

— Ни өчен?

— Шулай. Яхшы түгел. Ул мине хыянәтсез кешегә санап товар тәкъдим итсен дә, аны шуның өчен тотып бирим икән. Юк, булмый. Намусым кушмый.

Ачуы ачы катык сыман кабара башлаган өлкән инспектор гаҗәпләнде:

— Намус? Намус, имеш! Дәүләт милкенә кул сузып, спекуляция ясап ятучыларны яшерүче һәм... намус! Беләсезме, абзыкаем, бу нәрсә дип атала?

— Дәүләт үзе гаепле,— диде Муллин гөнаһсыз төстә,— сатуга чыгарса, спекуляция дә булмас иде.

— Минә нәрсә,— диде өлкән инспектор Байчурин кырыс кына,— кемнең гаепле, кемнең гаепсез икәнен суд хәл итәр. Сатуга түгел, дәүләт хаҗәтләренә дә җитми ул.

Бүлмәләрне дә җентекләп тентеп бетергәч, Айбулат Степан Муллинны ияртеп ҖАБ машинасына утырды һәм район милиция бүлегенә юнәлде.

— Нинди рәк кеше иде ул? — диде Байчурин юлда Степанга.

— Яшь, егерме-егерме өчләрдәге егет. Уртача буйлы, ябык. Кара тутлы, кылыч борынлы. Уң күз төбендә миңе бар.

Өлкән инспектор ҖАБка кайтып җиткәнче күзгечегә бүтән сорау бирмәде. Бөҗра кысыла башлаган кебек тоелды Айбулатка.

*

* *

Инспектор Вилданов, Гайния Хаҗиева исеменә салынган акчаны ачыклагыз әле, дип язган рәсми мөрәҗәгатен саклык кассалары идарәсенә үзе илтеп бирде.

— Безнең өчен моны белү гадәттән тыш әһәмиятле, мөмкин кадәр тизрәк ачыкларга тырышсагыз икән, сәгать саен шалтыратып белешә торырмын,— диде ул аларга.

Моннан соң инде ул тыныч кына эшли алмады. «Тасманур» заводына килеп яңа корыла башлаган бина тирәсендә әйләнеп-тулганып йөргәндә дә, төзүчеләрдән сорау алганда да күзгә күренмәгән чүкеч өзлексез рәвештә миен кыйнап торды. Шуңа күрә ул төзүчеләрне тикшерергә махсус килгән инспектор Шәмсия Зиннәтованы күргәч, җиңел сулап куйды. Шулай булмыйча! Төзүчеләрнең ике генә смена эшләүләрен белгәч үк кәефе кырылган иде инде. Аларның көмеш эшенә катнашлары булу мөмкин түгел. Әлегә анда ташчылар гына кайнаша:

коммунистик хезмәт бригадасы, бригадирлары — Татарстанның атказанган төзүчесе! Баш күтәрми эшлиләр, уч тутырып тияреп алалар. Хәрам малга кызыгучылар түгел. Алар тирәсендә шоферлар да үтә эшлекле кылана: кирпечен, измәсен тиз-тиз бушата да китү ягын кайгырта.

Кассалар идарәсенә инде берничә тапкыр шалтыратырга өлгергән Касыйм, Шәмсиядән аерылгач, телефоннан сөйләшү максаты белән, якындагы цехларның берсенә керде. Бу юлы җавап әзер иде: саклык кассасында Хаҗиеваның тугыз мең сум акчасы булуын хәбәр иттеләр. Менә, ичмасам, яңалык! Хаҗиеваның кассада акчасы булса да, бу кадәр зур сумма булыр дип уйламаган иде Касыйм. Мондый хәбәрне хәзер үк Байчуринга яки майор Винергә җиткерсәң дә ярый.

Менә хәзер Хаҗиевадан җәһәт кенә сорау алырга кирәк иде. Вилданов аны склад конторында очратты. Хаҗиева ЖАБ инспекторын күргәч, әллә ни гаҗәпләнмәде. Әмма инспекторның беренче сүзләре үк аны сискәнергә мәҗбүр итте.

— Әгәр үзегезгә җиңеллек китерим дисәгез, бары дөресен генә сөйләргә тиешсез,— диде аңа Касыйм.

— Әлегә кадәр ялганлады дип уйлыйсызмыни?

— Яңа мәгълүматлар алай уйларга да нигез бирә. Мәсәлән, гаепне каравыл башлыгына аударырга тырышу нигә кирәк булды?

— Ничек инде аудару? — Гайниянең алсу битләре агарына башлады.

— Менә шулай! — диде Касыйм, тавышын күтәрә төшеп.— Гази Гафуров йозак алыштыруны искәрткәнлегегезне кире кага. Склад тирәсен яктыртуны да сорамагансыз.

— Әйтмәсәм, ни өчен телгә алыйм инде аны? — диде Гайния аптырап.— Кирәкмәгән гәптән болай да гарык.

— Димәк, сезгә шулай файдалырак... Без Гафуров белән икегезне күзгә-күз дә очраштыра алабыз.

— Гази абыйга ут турында әйткәндә янныбызда кеше дә бар иде әле,— диде Гайния, бар хәтерен эшкә җигеп.

— Чехословак пианиносы кыйммәт торамы? — диде инспектор Вилданов, кисәк кенә бөтенләй икенче нәрсәгә күчеп.

Хаҗиева бу күчешне төшенмәде.

— Монда пианиноның ни катнашы бар? — диде ул.

— Бар шул. Шуның янына «Мәскәү» суыткычын, «Ригонда» радиоалгычын, «Рубин» телевизорының соңгы моделен һәм башкаларны... Сезнең окладка көч килә түгелме соң?

— Ә, менә нәрсәдә икән хикмәт,— диде борчылган Гайния, җиңелрәк сулап.— Әнкәем дә пенсия ала ич.

— Күпме?

— Илле тәңкә. Шуның өстенә ирем алимент түли. Уртача аена кырыгар тәңкәдән.

— Ашарга, киенергә кайсы кассадан тотасыз? — Касыйм юри «кассадан» сүзенә басым ясады. Гайния бер мәлгә икеләнә калган сыман булса да, бирешмәде:

— Саклап тотасың инде. Әрәм-шәрәм итсәң, өең шып-шыр тора. Без, хатын-кызлар, әйбергә кызыгабыз.

— Исегездә тотыгыз, сезгә намуслы рәвештә гаебегезне танырга мөмкинлек бирдем, гражданка Хаҗиева,— диде кыза башлаган Касыйм коры гына.— Акча чыганагыгыз турында сөйләгез. Әнкәй пенсиясе белән генә әллә кая китеп булмый.

Гайния тәшвишләнеп Касыймга карады, йөзе караңгыланды, хуш исле кулъяулыгын чыгарып борынына орынып алды һәм контора ишеген ябарга ашыкты — күрше бүлмәдәге бухгалтер хатыннар, сорау алуны ишетеп, колакларын торгыза башлаганнар иде инде.

— Алай бик булдыклы булгач, бәлки безнең гаилә бюджетын да сезгә тапшырыргадыр? — диде Касыйм ишарә белән.— Биш-ун ел да үтмәс, кассада түгәрәк кенә мая да хасил булыр. Әйтик, тугыз мең, ә? Хәзер бәйнә-бәйнә барын да беркетмәгә языйк. Складта көмеш кимүгә пропорциональ рәвештә кассадагы акчаның артуы физика законнарына каршы килми үзе. Әмма физика законнары җәмгыять законы алдында көчсез! Алар бурлыкның хурлыкка илтүен инкарь дә итә, булдырмый да кала алмый.

Касыйм үзенең хикмәтле сөйләшә алуына үзе дә сокланып куйды. Билләһи, юристлар табынган Конидан кай җире ким аның?

Ишек шапылдавына Гайния башын күтәрде — күрше бүлмәдәгеләр эштән кайтып баралар икән. Сәгать алты тулып килә.

— Башладык,— диде Касыйм, язарга кәгазьләрен әзерләп.

— Сезгә берничек тә ярдәм итә алмыйм, складтан көмеш югалуга берниндн катнашым юк.

— Нинди ярдәм? Сезгә үзегезне коткарырга кирәк! — диде Гайниягә исе киткән Вилданов.

Әмма Касыйм күпме генә тырышмасын, Хаҗиева бүтән авызын ачмады. Үз ихтыяры белән генә аны кулга ала алмый иде Вилданов. Тагын бер сәгать склад мөдирен үгетләп, исбатлап, гаебен икърар иттерергә тырышса да, уңышка ирешмәгәч, шәһәрдән чыгып китмәү шарты белән аны кайтарып җибәрде.

Хаҗиева шәп планнарны өзсә дә, Касыймның күңеле көр иде. Дәшми озак түзә алмас, хәзер иң мөһиме — аны тизрәк кулга алу. Даниэль Соломонович ҖАБта очраса, эш бүген үк пешә дигән сүз.

Вилданов район эчке эшләр бүлегенә таба кузгалды.

*

* *

Өлкән инспектор Айбулат Байчурин ничек кенә ашыгып атламасын, каравыл бүлеге башлыгын барыбер күрергә өлгерә алмады — Гафуров каядыр чыгып киткән иде.

— Гази Сәләхович бу арада йөгерә дә йөгерә,— диде урынбасары.— Әле кабинетына кереп бикләнеп утыра, әле цехлар буйлап чаба. Төн дими, көн дими. Агымдагы эшләрен миңа тапшырды, үзе көмеш каракларын эзли.

— Дөрес эшли. Казынган карга кар астыннан калҗа таба.

— Ул монда тагын керми калмас.

— Юк, көтеп тормыйм инде, иртәнге якта әйләнермен.

Кадрлар бүлегендә әллә кайчан пенсиягә чыккан Степан Муллинны берсе дә хәтерләмәде. Боерыклар кенәгәсендә игътибарга лаек нәрсә табылмады.

— Җиденче цехның профкомы — хезмәт ветераны,— диделәр кадрлар бүлегендә.— Белсә, Муллинны шул белер.

Айбулат аның адресын алып ҖАБка кайтырга мәҗбүр булды. Бүлекчәдәге инспекторлар инде өйләренә таралышып беткән иде. Тын бүлмәдә иркенләп көмешчеләргә кагылган һәр фактны яңабаштан хәтердән кичерергә, әле бөтенләй юлыкмаган сукмак табарга теләде Байчурин. Шул вакыт кабинетка җилле генә Вилданов килеп керде.

— Ай-яй, синең килешең, бардыр синең бер эшең!

Байчуринның уйнак сүзләреннән аерым мәгънә төсмере эзләп тормаган Касыйм каударланып:

— Даниэль Соломонович кайда икән? — дип сорады.

— Белмим. Сәгать сигез тулгачтын өенә кайтып китсә дә гаҗәп түгел, иеме. Берәр операциягә ычкынуы да мөмкин. Ул бит бер көмеш эше өчен генә җавап бирми. Нәрсәгә кирәк булды әле ул сиңа?

— Гайния Хаҗиеваны кулга алырга кирәк!

Өлкән инспектор Касыймга җитди, сораулы караш ташлады.

— Нәрсә нигезендә? Дәлилләрең бармы? — диде ул.

— Көл астында ут ята,— диде Касыйм.— Аның кем икәнен башта ук төшендем. Менә бүген шигем расланды. Өйләренә барган идем, түр тутырып чехословак пианиносы, «Мәскәү» суыткычы, «Рубин» телевизорының соңгы маркасы, «Ригонда» радиоалгычы тора! Бүлмәсендә келәм түшәлмәгән җир калмаган! Хаҗиева бит әлегә завод директоры түгел, склад мөдире генә. Окладкы нибары сиксән тәңкә, премияләре белән дә йөздән артмый.

— Сорау алдыңмы? — диде Байчурин.

— Әлбәттә.

— Ниләр сөйләде?

— Күз яше агызды.

— Тагын?

— Тырышты инде, кинәт кенә бирешәсе килми. Имеш, әнкәсе иллешәр сум пенсия ала, имеш, ире кырыгар тәңкә алимент түли. Имеш, ул малның кадерен белә, акчасын әрәм-шәрәм итми.

— Ә моның нәрсәсе ышандырмый? — диде Айбулат, урыныннан торып.

— Аның пианиносы гына да мең ярым тора!— диде Касыйм.— Саклык кассасында Хаҗиеваның тугыз мең акчасы да ята.

— Тугыз мең?! — дип кабатлады Айбулат шаккатып.

— Әйе, тугыз мең!

— Менә бусы таң калдырырлык табышмак. Арест салдырдыңмы?

— Әйе. Үзенә дә шәһәрдән чыгып китмәскә дип кул куйдырдым. Кайгы басты чибәркәйне.

— Кая, беркетмәләренне бир әле.

Өлкән инспектор Байчурин Касыймның тары кебек вак, түгәрәк хәрефләр тезеп язган беркетмәсен тиз генә караштырып чыкты.

— Димәк, акча чыганагын әйтүдән баш тартты?

— Күрәсез ич. Мин-минлек дигәнең җитәрлек аңарда.

— Эзләнүләрне бөтен каналлар буйлап дәвам иттерәчәкбез,— диде өлкән инспектор.— Даниэль Соломонович тикшерүне киңәйтергә кушты. Иртәгәдән фототовар сатучы кибетләрне капшарга тотынабыз. Даниэль Соломонович иртүк килә, диде, тикшерәсе кибетләрне әйтер, аны күрерсең. Бу эшкә башка иптәшләр дә җәлеп ителә. Склад мөдире турында өстәмә мәгълүматлар туплауны Шәмсиягә тапшырырбыз.

Айбулат сүзләре дәлилле күренде.

— Оптика заводында булмадыгызмыни? — диде ул.

— Анда Даниэль Соломонович кереп чыккан. Буш кул белән кайтты. Шәмсия вокзалларны тикшерүен әйткәндер инде, заводта күрешкәнсез бугай.

— Әйтте.

— Хаҗиева турындагы хәбәрең мине аптырашта калдырды әле: бәлки син хаклыдыр да. Бәлки склад мөдире чыннан да кылана гынадыр. Шикле сумма, телен тешләве дә аның файдасына түгел, иеме,— диде Айбулат урыныннан торып.

— Менә шул шул!

— Тик без аны иртәгә ачыклыйк инде, яме?

Касыйм килешкәнлеген белдереп баш какты.

— Автомобиль кибете синең зонага керә икән,— диде Айбулат Касыймга.— Юл уңаенда кагыла чык әле шунда. Машина сатып алырга чират торучылар арасында «Тасманур»да үзең барлаган шикләләр дә юкмы икән? Мин дә товар төрү цехында кайберәүләрне исемләккә

керттем. Кучереп алсаң да ярый, алар фототасма, фотокәгазь урлап тотылганнар. Я булмаса табып биргәннәр.

— Табып биргәннәре нәрсәгә инде? — диде Касыйм төшенмичә.

— Ә бәлки алар заводтан алып чыга алмаганга гына «табып» бирергә булганнардыр? — диде Айбулат.— Ахыр чиктә югары аңлылык, намуслылык күрсәткән өчен премия алу яки рәхмәт ишетү дә ярап тора ич.

Касыйм Айбулатның куен дәфтәренә теркәлгән «Валентин Николаев 50/10» дигән язуны күреп алгач, гаҗәпләнгән күзләрен күтәрде:

— Бу саннар нәрсәне аңлата?

— Төрү цехыннан илле каплы бер партия фототасма юкка чыккан, шуның ун кабын алып чыгып барганда Валентин Николаев тотылган.

— Калган кырыгын тапканнармы соң? — дип сорады Касыйм.

— Әйе. Бакчы, вакыты да күрсәтелгән. Ундүртенче цехның калорифер камерасыннан бер компрессорчы күреп алган.

Инспектор Вилданов ашыгып үз блокнотын актара башлады.

— Менә ул. Гаҗәп, кырык каплы өлеше Николаев тотылганчы ук иясенә кире кайтарылган булып чыга ич! Валентин да үзендәге фототасманы «таптым» дип аңлаткан. Әгәр тапса, пленкаларның барын бергә күрергә тиеш иде ләбаса, ә ул кырыгы турында ләм-мим! Тукта! — диде Касыйм, нидер исенә төшереп.— Мин Николаевның куен дәфтәрендә дә «50/10» дигән саннарны күрдем ләбаса. Ә аның янына... аның янына «Җәмил» дигән исем дә теркәлгән иде әле. Аларны уйный-көлә сорап та караган идем. «Мотоцикл сатып алганда иптәшләргә әҗәткә керергә туры килде, шуның исәпләре ул»,— диде.

— Кайда соң ул дәфтәрчек?

— Тимәдем. Арест салырга нигез юк иде. Идәнгә төшеп киткән жиреннән хуҗасына гына алып бирдем. Язуларын да очраклы рәвештә генә күреп калдым.

— Бәхетле очрак! — диде Байчурин.— Ул блокнотны хәзер төшендә дә күрмәссең инде.

— Монда бер нәрсә ачык шәйләнә,— диде Касыйм.— Без Җәмилнең кем икәнлеген һәм аның Валентин Николаев белән нинди рәк мөнәсәбәттә торуын ачыкларга тиештер.

— Ие, моны кичектерми ачыкларга кирәк,— дип куәтләде Айбулат.— Әгәр «50/10» саннары янында Җәмил исеме тора һәм 10 саны турыдан-туры Валентин исеме белән бәйләнгән икән. Җәмилнең бу ике санга яки аларның берсенә мөнәсәбәте булырга тиеш. Язу үзе үк алар арасында мәгълүм бәйләнеш барлыгын исбатлый. Моннан нәрсә фараз итәргә мөмкин? Беренчедән, Валентин иптәше белән илле кап пленканы я төрү цехыннан бергә урлаган, я калорифер камерасыннан бергә тапканнар. Яисә фототасманы берсе ялгыз гына төрү цехыннан чәлдергән, икенчесе заводтан алып чыгарга тиеш булган. Бу очракта төрү цехыннан товарны Җәмил сыптырган дияргә туры килә. Икенчедән, Җәмил белән Валентин пленканы икесенә бүлгәннәр — Валентинга унысы гына тигән.

— Бәлки Валентин Николаев Җәмилдән илле сум бурычка алып торып, шуның унысын түләгәндер? — диде Вилданов.— Әгәр фототасма бергә сүз куешып урланса, ни өчен аның бер өлеше генә калорифер камерасында икенче мәртәбә табыла? Җитмәсә, калган өлешен үзләштереп бетергәнче үк!

— Валентин Николаев башта үз өлешен шуытырга маташкандыр,— диде Айбулат.— Моның өчен ул аны икегә аерып, бер кадәресен үзенең кием шкафына яшерә ала иде. Шулай эшләгәндер дә. Ул арада калорифер камерасында калган өлешне табып, төрү цехына тапшырганнардыр.

Җәмилнең кемлеген ачыкларга кирәк булу бәхәссез иде.

*
* *

Айбулат Байчурин фототовар бүлекләрен тикшерүне шәһәр кырыендагы кибетләрдән башларга булды. Сулдан товар китерүчеләргә алар кеше күзеннән, шул исәптән, тикшерү органнары контроленнән дә читтәрәк торган төсле тоелырга тиеш. Коллектив кечерәк булган саен сатучыга эш җиңеләя төшә. Гадәттә, кечкенә магазиннарда кассага түләү системасы да кертеп җиткерелмәгән була. Сулдан кергән әйберне мондый шартларда акчага әйләндерүнең мәшәкате бөтенләй юк дәрәҗәсендә.

Айбулат исемлегендә андый кибетләр өчәү иде. Ул аларның һәркайсына яртышар сәгать сарыф итәргә чамалады. Әмма тикшерү чагыштыргысыз дәрәҗәдә озакка сузылды. Чөнки ҖАБ инспекторына сатучыларның үзләренә берни сиздермәскә кирәк иде. Юкса, өркетелгән кешегә итәк-җиңен җыештыру да читен түгел. Шуңа күрә өлкән инспектор Байчурин башта витриналардагы сатуда булган фототасма, фотокәгазьләрне карап, блокнотына товар маркаларын терки барды. Барлык товарны исәпкә алып бетергәч, өлкән инспектор кибет директоры кабинетына керә һәм фототовар бүлегенә соңгы вакытта алынган товар накладнойларын сорап ала, накладнойдагы исемлекне әле яңа гына үзе барлаган әйбер төрләре белән чагыштырырга керешә иде. Директордан фототасма, фотокәгазьләрнең сатылу срокларын сораша һәм шикле нәрсә сизелмәсә:

— Читтән товар сатып бирүне үтенеп мөрәҗәгать итүчеләр юкмы? — дип сорый.

Тикшергән өч кибеттә дә ачмаган ишеге, кермәгән урыны калмады, әмма ул үзенә кирәкле уңай җавап ала алмады һәм шулай ук шикле товар да тапмады. Күңелеңне төшермә, дип юатты ул үзен. Сулдан юнәтелгән товарны саттыру өчен таныш-белеш кирәк. Ә андый кешенең нәкъ менә аулак җирләрдә генә эшләгәнен кайдан табып бетерәсең? Шулай булгач, җинаятьченең теләсә кая барып тыгылуы мөмкин. Димәк, Айбулат та хәзер кибетләрнең очраган берсенә керә барачак. Ә бәлки сул товарны сату өчен алучылар кайнап торган урын кирәктер, дип, Байчурин баштагы фикерен үзгәртте. Мондый җирдә кытлык әйбер күз ачып йомганчы юкка чыгачак. Әйтик, үзәк универмаг. Шәһәр кешеләре генә түгел, читтән килүчеләрнең дә күбесе монда керми калмый. Төшкелеккә туктамый эшләве дә уңай — сатучылар алмаш-тилмәш кенә ашап килә. Димәк, бүлектәгеләр бер сәгать чамасы ярты штатка гына кала. Файдаланырга иң кулай вакыт. Менә хәзер шундый чак җитеп бара.

Айбулат үзәк универмагка килеп, беренче катка урнашкан пыяла витрина һәм шүрлекләрдәге товарны блокнотына теркәгәч, директорга үзенең нинди эш белән йөрүен әйтте. Фототовар бүлегеннән товар эксперты накладнойлар тегелгән папканы алып килде. Айбулат, монда бар да тәртиптә икән, дип, папканы ябарга торганда гына төсле фототасма накладное күренмәвен шәйләп алды. Ул дулкынлануын басарга тырышып, мөмкин кадәр битараф кыяфәттә:

— Төсле фототасма сирәк була, ахры, сездә? — дип сорады.

— Соңгы тапкыр июньдә алдык,— диде товар эксперты.

— Димәк, инде өченче ай бирмиләр? Тиз сатыла бетәме соң ул?

— Көне белән юкка чыга, әлегә дефицит.

Айбулат, товарчыга рәхмәт әйтеп, фото әйберләре бүлегенә төшеп китте һәм биш кап төсле пленка сатып алды. Бер читкә китеп тагын берничә кешенең кытлык малны соравын көтеп торды. Ике егет сөенеп унарны алды. Айбулат, артларыннан чыгып, аларга сүз кушты:

— Шәһәребездә заводы була торып, төсле пленкага тилмертәләр, аптырап йөр инде,— диде ул, әле генә сатып алган товарын күрсәтеп.

— Ә без? Күргәч күзгә яшьләр килде! — диде егетләрнең берсе көлемсерәп.— Ярты ел эзли идек инде. Әле фототүгәрәк исеменнән йөрдек, алай да таба алмадык.

— Кайсы фототүгәрәктән соң сез? — дип сорады Айбулат.

— Идел буе районы культура сараеннан. Үзебезнең генә хәлдән килми әле.

— Көне белән булмыйдыр инде ул, иеме. Мин дә фототасма эрәм итүдән уза алмыйм. Төсле фоторәсем рәссам иҗатына тиң бит ул. Әллә миңа да берәр түгәрәккә йөрисе инде, сездә җитәкче кем анда?

Айбулат әдәп йөзеннән тагын берничә сүз алышты да. «Ярый, егетләр, миңа бу якка»,— дип уңга борылды.

Әгәр кирәге чыкса, бу егетләрне җиңел эзләп табачагына ул шикләнми иде. Хәзер тагын бер-ике шундый шаһит табарга кирәк. Фотоһәвәскәрләр күздән югалгач, Айбулат яңадан универмагка әйләнеп керде, әмма төсле фототасма сатуда күренми иде инде. Сатучылар да алмашынып өлгергән иде.

— Әле яңа гына монда сату иткән кыз кая китте ул? — дип сорады Айбулат яңа сатучыдан.

— Хәят апамы? Сез аның кеме соң?

— Танышы.

— Ә-ә-ә. Хәзер килә ул.

Айбулат универмагтан чыгып, автомат-телефон аша майор Винергә шалтыратырга булды.

— Иптәш майор, үзәк универмагта әле яңа гына төсле фотопленка саттылар. Тентү ясыйбызмы?

— Хәрам малмы?

— Ие. Накладнойларын карадым, төсле фототасма июньнән бирле алынганы юк. Дефицит.

— Әле дә саталармы?

— Беткән, ахры. Аны аулакта гына күрсәтеп алсалар кирәк. Сатучылар әбәткә алмашлап кына барып килә. Менә шул чакта кешекара юкта гына саталар, ахры. Берәвенең генә кулы уйныйдыр бәлкем.

— Сабыр итик. Бүлектә хәзер бармы, юкмы ул син күргән товар, белмибез ич. Әгәр беткән булса, шом салу бушка булачак. Алучыларны барларга иде.

— Ике егетне соңыннан таба алырмын сыман.

— Менә яхшы булган,— диде майор.— Безгә хәзер фототасманың кайдан, кем аркылы килүен белергә кирәк.

— Аңлыйм, Даниэль Соломонович. Үзем дә шулай уйлаган идем.

— Әле син төшкене ашарга да кермәгәнсеңдер?

— Өлгермәдем.

— Менә нәрсә: күзәтү урнаштырыр өчен кеше җибәрермен хәзер. Зиннәтова заводтан кайткан иде, аны күздә тотам. Ул килмичә китми тор.

— Тыңлыйм, иптәш майор!

Айбулат үзендә әллә нинди көч, куәт артканын тоеп, нык адымнар белән кире универмагка атлады. Өлкән инспекторга көзге кояш нурлары бүген аеруча назлы, бөтен кеше шат күңелле, әле бая гынак күзенә күренмәгән гөлләр үзенә бер төрле нечкә ямь белән универмаг алдын бизәп торалар кебек тоелды. Ишек төбендә:

— Пәрәмәч, пәрәмәч!

— Дөгеле сумса, кайнар сумса! — дип кычкыра-кычкыра сату иткән апайлар ягыннан борынны кытыклый торган тәмле ис килеп бәрелде. Өздереп ашыйсы килә башлады. Монда килгәндә ашханәгә күз салса да, чиратның шактый озын булуын күреп, тукталмаган иде. Кайчан өйгә кайтасын белмәгән өлкән инспектор хәзер берничә пәрә-

мәч алырга булды. Аларны тиз-тиз капкалап йотканнан соң, Шәмсия Зиннәтева килгәнче фототовар бүлегенә күз-колак булып торды.

Әнә, Хәят эш урынына килде дә, ахрысы. Өлкән инспектор буялган салам чәчле, көянтә кашлы сатучыга бер карап алды да, үзенә игътибар иттермәс өчен, кырыйгарак китте. Тырнакларын лаклаган, күз төбенә зәңгәр күләгә, яңагына бер миң дә төшергән. Авызы уймак кадәре генә, биле нечкә, колаклары әйтерсең көяз кызны бизәр өчен генә ябыштырылган, ә борыны гүя менә минем хуҗам нинди матур дияр өчен беркадәр һаваланып өскә чөелгән! Бәлки менә шушы туташ көмеш складны басучыларга сукмак салыр?

Айбулат, вакытны җилгә очырмыйм дип, яңадан универмаг дирекциясенә керде һәм фототовар бүлегендә эшләүче Хәят турында сорашырга кереште.

— Хәят Галиева әле икенче генә ел бүлек мөдире булып эшли,— диде кадрлар бүлеге инспекторы.— Кызурак канлы, тупасрак. Кул астындагыларга каты бәрелгән өчен профкомда да тикшерелде. Кисәтү ясадык. Эш ягына килсәк, белдекле инде ул. Өстенә чыкканы юк. Тик җәмәгать эшләреннән читкә тайпылырга ярата. Белемен күтәрергә өндәгән идек тә, ашыкмый әлегә.

— Сәүдә тәртипләрен бозганы юкмы? — диде Айбулат.

— Булгалады.

Айбулат, сорыйсын сорап бетергәч, универмагның беренче катына төшеп, ишек төбендә Шәмсияне көтеп алды. Аулаграк җиргә алып китеп сорады:

— Я, Хаҗиева турында тагын нәрсәләр белә алдың?

— Касыймның шиге дөрескә чыгар кебек. Күршеләре белән сөйләштем. «Аны төшенә алмассың. Үзе болай әйбәт хатын да сыман, әмма бик йомыкый», диләр. Кеше белән аралашырга яратмый икән. Үзен һавалы тотуымы, әллә дөньяга бер үпкәсе янсә ачуы бармы? Кияүгә чыккач та, озак тормыйча, аерылышкан булган.

— Шул ире хәзер кайда?

— «Тасманур» заводында эшли. Хаҗиева складыннан цехларга йөк тә ташый икән әле. Әмма иң гаҗәбе — Гайниянең шофер булып эшләүче шул Хәяли Байхуҗинга мөнәсәбәте. Гадәттә, аерылган хатын-кызның күпчелеге бөтен гаепне ире өстенә аудара ич. Аны хурлау, бәгыренә тоз салудан тәм таба. Гайния исә Хәялидән һич тә зарланмый икән. Әйтерсең араларыннан җил дә үтмәгән. Гомумән, телгә дә алмый. Бу факт, мактауга лаек булса да, миңа сәеррәк тоелды.

— Кызык. Склад мөдире һәм аның элекке ире. Җитмәсә, шофер! Көмеш ыгы-зыгысы өчен мондый туры килүләр артык куе булмасмы икән? Алар күптән аерылганмы?

— Ун ел элек.

— Ире яңадан өйләнгәнме?

— Әйе. Әмма Гайниядәге баласы янына да килгәләп йөри икән үзе. Элек балалар бакчасына баргалаган, хәзер мәктәптә күрешеп чыга икән.

— Хаҗиеваның үзен очраттыңмы?

— Еракган гына күрдем. Йончыган шикелле тоелды.

— Төзүчеләрне тикшерүең ничек булды? — дип сорады Айбулат.

— Файдасыз. Коры кул белән кайттым. Мине сорау алырга гына көтеп торгансың икән. Я, монда миңа тагын нинди эш таптыгыз?

— Берничә көнгә сатучы роленә керергә туры килер сиңа,— диде Айбулат житди генә.— Үенчыклар белән сәүдә иткән булып, фототовар бүлеге мөдире Хәят Галиеваны күзәтерсең. Әле бая гына төсле фототасма сатты. Сулдан кергән товар. Аңарга пленканы кем китергән икән? Шул сорауга җавап табарга кирәк. Әйдә, универмаг дирек-

циясенә керик әле, таныштырырмын. Ул-бу булса, безгә шалтырат. Мин хәзер Гайния Хаҗиева мәсьәләсенә тәмам ачыклык кертергә тырышырмын. Болытлар аның тирәсендә куера шикелле.

*
* *

Өлкән инспектор Айбулат Байчурин универмагтан соң «Тасманур» заводына китте. Склад мөдире Гайния Хаҗиева өстендә куерган кара болытка яки таралырга, яки күкрәп-яшьнәп бозлы ташкын булып яварга вакыт иде. Мәгълүматлар шактый тулы тупланды, алар барысы да склад мөдиренә күләгә төшерә иде. Гайния никадәр яхшы, әйбәт булып тоелмасын, өлкән инспектор фактларга каршы бара алмый иде. Вилданов Хаҗиеваны элек субъектив рәвештә генә шик астына алса, соңыннан моны кире кага алмаслык дәлилләр белән ныгытып та куйды. Иң яхшы җиңел машина сатып алырлык акчаны аның өчен рәхмәт хакына кассага беркем салмаячак. Дөрес, кассадагы акчаны ул кичә-бүген генә салмаган. Әмма аңа элегрәк шик төшмәгән икән, бу әле Хаҗиеваның шушы көнгә кадәр сөттән ак, судан пакь булуын раслый алмый. Дөрес, склад мөдиренең турыдан-туры башлыгы булган Рахман Сабирҗанов Гайниянең сабырлыгы, эшне тәртипле һәм тыныч алып баруы, инсафлы, гадел һәм әдәпле булуы турында сөйләде. Әмма Сабирҗанов аңа көн дә контроль ясап тормый ич! Хәтта складка атнасына бер тапкыр да кереп чыкмый. Нәтиҗәсе күз алдында. Ә эксперт үлчәгән тузанны кая куясың? Моңа да баш ватасы түгел. Шүрлекләрдәге көмеш каплары өеменнән өстәгеләрен алып икенче урынга күчерү җитә.

Айбулат троллейбуста менә шундый уйлар белән барса да, күңеленең иң тирән почмагында Гайния Хаҗиевага ышаныч яшеренгән иде. Намуслы кешегә охшаган ич ул. Күзенә ничек туры карый, синең сүзләреңә ничек сизгер колак сала, йөзендәге һәр үзгәреш иң нечкә төсмерләренә кадәр табигый! Хәйлә яки кылануның заты да юк!

Гафуров бу юлы да кабинетында очрамады. Аның урынбасары өлкән инспекторны бүлмәсенә кертте дә, Хаҗиеваны чакырырга алынды. Ун-унбиш минуттан ишектә склад мөдире дә күренде.

Айбулат, каршысында утырган Хаҗиевага күз ташлагач, күрешми торган арада Гайниянең аксыл йөзенә кара суккан кебек булуына игътибар итте. Юка ирennәре кысылган, иңбашлары салына төшкән, күз төпләре дә күгелҗемләнеп тора. Мөгаен, төнне йокысыз уздырган. Күзләре томаланып киткән, сумала чәчләре маңгаена күләгә төшергән. Бу юлы Айбулатка да икенче төслерәк карый — ятсынган һәм ниндидер мәкер көткән сыман. Карашында бик үк тирән яшерелмәгән горурлык та бар. Хаҗиеваның үзен киеренке тотуын бер карауда ук күреп алган Айбулат:

— Я, без сөзешергә җыенган тәкәләр түгел, иеме, миңа болай төксе карамагыз,— дип башлады.— Инспектор Вилданов белән сөйләшкәндә томанлы калган нәрсәләрне генә ачыклыйк әле.

— Яңа нәрсә өсти алмыйм,— диде Хаҗиева.

— Менә бу сүзегез урынсыз. Хиресләнеп җинаять юлына баса торган адәмгә охшамагансыз. Әмма кешене мәҗбүр итүләре мөмкин. Бәлки бөтенләй гаебегез юктыр, иеме. Әгәр үзегезне шулай серле тотсагыз, моңа ничек ышаныйк? Корыга кушып чи дә яна. Кассага ничек итеп тугыз мең тәңкәне салуыгызны аңлатсагыз, түземлегебез төкәнгәчтен, башкалар белән сезне дә...

— Кичә мин аңлаттым ич инде,— диде Хаҗиева газап белән.

— Исәпләдек. Хезмәт хакыгызга әнкәгезнең пенсиясен дә, ирегез

түли торган алиментны да өстәдек, барыбер ышандырмый. Өйдәгеләренә җитәр дә ди, ә минә кассага? Бакчагыз юктыр ич?

— Юк.

Гайниянең йөзе яңадан агарынды, чигәләре тимгел-тимгел кызарып чыкты. Айбулатның йомшак мөгамәләсе әлегә аның күз яшьләрен тыеп торса да, күңеле мөлдерәмә тулган иде, ахры, авырайган, дымланган күз-керфекләрен чыт-чыт йома башлады. Айбулат өстәлдәге стаканга Гази Гафуровның салкын чәен салып Хаҗиева алдына куйды.

— Без бер-беребезгә ярдәм итәргә тиеш, иеме? — диде ул. — Кассадагы акчагызның көмеш урлануга да, заводтагы бүтән җинаятьләргә дә, ихтимал, бөтенләй катнашы юктыр. Әмма склад мөдиренә бәйләнгән ул фактны без читләтеп уза алмыйбыз. Шуңа күрә акча чыганагын яшереп калырга тырышуыгыз җинаятьчеләрне эзләү өчен кирәкле вакытны ала. Кадерле вакытны.

Гайния Айбулатны игътибар белән тыңлый иде. Өлкән инспектор дәвам итте:

— Сез — акыллы кеше, аңларга тиеш, иеме, кырын эш кырык елдан соң да беленә. Әгәр акча намуссыз юл белән җыелган булса, аны барыбер иртәме-соңмы беләчәкбез. Совет законнарын бозып тупланмаса, куркырга да, оялырга да нигез юк. Сезне баштан ук гаепсез кешегә чыгарган идем. Инспектор Вилдановка җавап бирүдән тайчануыгыз тәмам аптырашта калдырды, иеме. Ялгыштыммы икән?

Айбулатның кешелекле эндәшүе ярдәм иттеме, әллә үзен гаепсез санавы ошадымы, Гайния Хаҗиева йомшый башлады.

— Кассадагы акчамның көмеш урлануга бернинди катнашы юк. Тик миңа аның кайдан килүен сөйләп бирү оят, — диде ул карлыккан тавыш белән. — Сөйләсәм, кешегә фаш итмәссезме?

— Әйттем ич: әгәр законны бозмаган булсагыз, куркырга урын юк. Көмеш юкка чыгуын тикшерүче берничә инспектордан башка берәү дә белмәячәк.

— Беркетмәгә дә кермәсен иде. Дөрес аңлар өчен, ерактан башларга туры килә. Моннан унбер ел элек җәй көне ял итәргә Кырымга бардым. Шунда Уфа егете Рәфикъ белән таныштым. Ял йортында һәр көнне, һәр сәгатьне бергә үткәрдек. Үземне Рәфикъ янында бәхетле хис иттем. Тик очрашу — аерылышуның башы булган кебек, безнең санаулы көннәр бик тиз үтеп китте. Хат язышып торырга, озакламый яңадан күрешергә вәгъдә куешып аерылыштык.

Әмма ул нигәдер бик озак хат язмады. Бер елга якын. Үземне беркатлылыкта битәрләдем. Рәфикъ та кайбер башка ирләр кебек тасма теллеләнгәндер, инде бүтән кирәгем калмагандыр, дип гарьләнеп еладым. Ялганчы, вәгъдәсендә тормаган, мине мәкерле рәвештә алдаган кешене эзләп барырга да, үзем башлап хат язарга да горурлыгым юл куймады. Аңа шундый нәфрәтләндем, исеме искә төшсә дә, каным кайный башлый иде.

Менә шундый көннәрнең берендә язмыш мине Хәяли Байхуҗин белән очраштырды. Ул — шофер, безнең складка чимал ташый башлаган иде. Беренче күргән көннән үк миңа ягымлы сүз кушып, кино, танцыларда бергә күңел ачарга тәкъдим итте. Рәфикътан күңелем бизгән, аңардан өметемне өзгән көннәр булганга, ризалык бирдем. Озакка сузмый, бер кызудан өйләнешеп тә куйдык. Тик безнең никах кыска гомерле булып чыкты. Хәяли: «Миңа син кыз килеш чыкмадың», дип тавыш куптарды, аерылышырга судка бирде. Аны гаепләмим. Өйләнешкәнче Рәфикъ белән булганны сөйләп бирергә йөрәгем җитмәде. Яшерәсем килүдән түгел, оялу, кыенсынудан.

Хәялидән авырлы булып, бала табу йортына керергә җыенганда, бөтенләй көтмәгәндә Рәфикътан минә шушы хат килеп төште.

Гайния Хаҗиева Айбулатка саргаеп беткән конверт сузды. Өлкән

инспектор Гайниянең яшьле күзләренә карап алды да, уңайсызланып китеп, хатка күз төшерде. Анда менә нәрсәләр язылган иде:

«Гайния!

Аяк астыннан килеп чыккан бәла аркасында бу хатны нәкъ бер елга кичегеп язам. Булдыра алсаң, гафу ит. Синең алда гаепле булып калганымны беләм, тик башкача бер хәл дә итә алмадым. Язарга кулым күтәрелмәде, сине борчырга үземне хаклы санамадым.

Ял йортыннан кайткач ук укулар башланды. Мин дә лабораториядәге тәҗрибәләремә керештем, гыйльми тикшеренүләремә тотындым. Квартир ягы хәл ителгәнче үк сиңа хат язарга, я үзем Казанга барып килергә план корып куйган идем. Әмма бәхетсезлек килеп чыкты да, ул планнар өзелде, ниятләрем эшкә ашмады.

Сөйләгәнемчә, мин студентлар белән лабораториядә практик дәресләр алып барам. Бервакыт әнә шул дәресләрдән соң лабораториядә калып үз хезмәтем өчен кирәкле тәҗрибәне ясап карарга булдым. Мавыгып эшкә тотындым. Әмма катлаулы реакция ясаганда аппарат шартлады. Студентлар практик дәрес вакытында тартмалардагы химикатларны саташтырып, аралаштырып бетергән булганнар икән, аны җентекләп карап тормаганмын. Бәхетсезлек аркасында, битем яраланып, бер күзсез калдым. Озак кына шифаханәдә яттым, аннары санаторийга җибәрделәр. Бу хәлләр турында язып, сине борчыйсым килмәде.

Хәзер савыктым, яңадан эшкә чыктым. Билгеле инде, мин элекке чибәр бүйдак түгел, бер күзем пыяла, борын өстенә күзлек атландырып йөрим. Йөзгә дә ясалма бизәкләр кунды. Мондый хәлдә мәхәббәт дәгъвалап, гаилә бәхете өмет итеп йөрисем килмәде. Үземне тулысынча фәнни эшкә багышларга карар иттем.

Сүз дә юк, дөньяда бөтенләй гарип кешеләр дә гаилә корып яши. Арада бәхетле тормышка ирешкәннәре дә бардыр. Тик, минемчә, бу алардан, барыбер, нинди дә булса ташламалар ясауны, нәрсәдә дә булса чигенүне, корбан бирүне таләп итми калмый. Бер отыш икенче җирдә оттыруны, кайсыдыр өлкәдә бәйле хәлгә төшүне котылгысыз итә. Соңыннан мәхрүмлек яки гарьлек кичерү рухыма үтергеч яра ясар, йөрәкне сызлатыр иде. Нигә үзеңне әнә шундый икеле-микеле хәлгә төшереп торырга дип уйлыйм. Шундый уйлар мине хәзер кайбер планнардан баш тартырга мәҗбүр итә. Минемчә, бу иң акыллысы булыр. Ни генә әйтсәң дә, кеше үз характерын үзе әйбәтрәк чамалый.

Үзеңдә ни хәлләр бар? Әгәр мине гафу итсәң, хат яз. Сиңа теләсә кайчан кулымнан килгән ярдәмне күрсәтергә әзер. Әмма башыбыздан үткән хәлләр элек хыялланганча уртак оя кору, бергә оешу уен пыранзаран китереп ташлады. Минем өчен моны белдерү кыен булса да, язарга мәҗбүрмен.

Сәлам белән Рәфикъ Гатауллин. Уфа каласы. 7/IX — 1964».

Айбулат «башыбыздан үткән хәлләр» дигән сүзләр астына яшел кара белән сызылуына игътибар итте һәм хатны кире Хаҗиевага сузды.

— Бу хатны укыгач, тәмам мыңгерәдем, — диде Гайния, сүзен дәвам итеп. — Бердән, үземнең сабырсызлыгыма үкендем. Ахмакларча горурлык саклавымны гаепләдем. Әгәр үзем хат язып салган булсам, Рәфикъ белән күптән аңлашкан булыр идек. Үзе язмаса, иптәшләре, я туганы, хезмәттәшләре берәр нәрсә хәбәр итәр иде. Рәфикъны болай җиңел генә югалту белән килешмәгән булыр идем. Ул үзе дә, димәк, ярдәмгә, кайгыртуга мохтаҗ булган. Ә мин, ашыгып һәм үчләнеп, шуның өстенә яңа юләрлек эшләп ташлаганмын!

Аның шушы хатын кабат-кабат укыдым. Димәк, онытканга яки ят иткәнгә түгел, бәлагә тарыганлыктан язмаган. Мөгаен, терелгәч, барысын берьюлы хәбәр итәргә җыенгандыр. Алай дисәң, нигә бик кыюсыз соң әле ул? Тәкъдиме дә хәтер саклап кына әйтелгән кебек. Укымышлы

кеше шулай тәрбияле буладыр инде! Мөрәүвәтле күренәсе, намусын, вөҗданын тынычландырасы киләдер. Рәт белеп кенә язылган сүзләргә мохтаҗмы соң мин? Шуның өчен генә күнелем табыламы соң? Юк, андый хәергә мохтаҗ түгелмен, дип уйладым. Шунда ук сискәнеп тә киттем: чү, аңардан ни дә булса дәгъваларга хакым да юк ич. Хәялидән бала көтәм ич. Тукта, тукта! «Башыбыздан үткән хәлләр...» Нәрсә, әллә кияүгә чыкканлыгымны белгәнме? Шуны күздә тотуымы?

Хатны укыган саен уйларым чуала барды. Берни төшенмим. Бер күзен югалткан. Бите яраланган. Күзлек кия. Шифаханә, санаторий... Димәк, сәламәтлеге чынлап та нык какшаган? Әмма эшкә чыккан ич, димәк, гарип-гораба түгел. Хезмәткә сәләтле, акылы аек. Фәнни хезмәткә баш кирәк. Тыштан килбәтсез күренсә дә... Хәер, аны берничек тә килбәтсез итеп күз алдына китерә алмадым. Ак йөзле, дулкынланып торган шомырт кара чәчле, кара кашлы, озын буйлы, мәзәк керпе мыеклы, тулы гәүдәле асыл егет! Ходай аңа матурлыкны чеметемләп түгел, учлап-учлап биргән. Бәлки, бүген-иртәгә бала табарга торган ташланган хатын булганга күрә генә аның гариплеген күрмәмешкә салынырга ризамындыр?

Озакламый улым туды. Атасы араны нығытып өзгән иде, алимент түләүгә дә исе китмәде, бераздан яңа гаилә корып җибәрде. Күпме теләсәм дә, Хәялине гаепли алмый идем. Гореф-гадәт шундый, ирләр үзләре бик ак-пакь булмасалар да, хатын-кыздан күпне дәгъва итәргә осталар. Менә шул хәлдә Уфага, Рәфикъка хат язып җибәрдем. Аңа карата үпкә сакламавымны, әмма язмый торуына гаҗәпләнүемне, хәзер ярдәмгә мохтаҗ булмавымны әйттем. Бала үстерүемне хәбәр иттем. Тик аның атасы Хәяли булуын гына ачмадым.

Билгеле, иртәме-соңмы, баланың Хәялидән булуын Рәфикъка әйтергә туры киләчәк иде. Тик ашыкмадым, әрсез өмет юл куймады. Һаман яратам, дип тә яза алмадым. Аптыраганнан ябышу сыман күренүе мөмкин иде. Ә баланы телгә алу Рәфикъны кузгатырга тиеш иде. Ул, чыннан да, озак көттермәде, хат язып, рәсемебезне сорады. Үзе килеп күренергә әле һаман уңайсызлана иде, ахры. Әмма бала үстерүемне белгәч үк, акча белән ярдәм итә башлады. Ай саен иллешәр тәңкә сала. Акчасын алырга хакым юк иде, әмма чын дөресен ачырга да батырчылык итмәдем. Шуңа күрә акчасын җыеп барып, бер аңлашкач, үзенә кайтарырга исәп иттем. Тик аңлашырга туры килмәде. Ваемсызлыгым менә хәзер бәла булып үземә әйләнеп кайтты.

Гайния Хаҗиева сумкасыннан алып Айбулатка бер бәйләм почта талоннары китереп тоттырды. Әйе, алар барысы да Рәфикъ Гатауллинның акча җибәреп тору документлары иде.

— Ни өчен аңлаша алмадыгыз? — дип сорады Айбулат.

— Казанга килмәде, үзем эзләп баруны яхшысынмадым. Хәтта бу турыда сүз кузгатырга да теләмәдем.

— Хәяли Байхуҗин белән мөнәсәбәтегез ничек?

— Ничек дияргә инде, ул үзенә, мин үземә бер тормыш белән яшибез. Дус та, дошман да түгел, гәп кыска.

Өлкән инспектор Байчурин Рәфикъ Гатауллинның адресын һәм акча талоннарын алгач, күңел ярасына кагылуы өчен гафу үтенеп, Хаҗиева белән саубуллашты.

— Рәфикъка хәбәр итәчәксезме? — диде комач кебек кызарган хатын.

— Борчылмагыз, сезне гаепләрлек нигез юк. Адресын кирәге чыкса дип кенә теркәдем.

Гайнияне озаткач, Байчурин, заводның транспорт бүлегенә шалтыратып, Хәяли Байхуҗин турында белешмә алды. Аннары капкада торучы вахтерның кенәгәсеннән нитрат урланган төнне заводка кереп йөр-

гән машиналарны барлады — алар арасында Байхуҗинныкы юк иде. Димәк, ул төнне бөтенләй эшләмәгән.

Җинаятьләрне ачу бүлекчәсенә кайтканда, Айбулат сорау алу нәтиҗәсеннән канәгать иде. Тагын бер фараз юкка чыкты, бу ничә инспекторның кадерле вакытны, бер уйлаганда, бөтенләй бушка сарыф итүе дигән сүз. Әмма тагын бер кешенең намуслы булуын исбатлау шатландырмыймыни? Шатландыра!

Шунда ук Айбулат шикләнә куйды: Хаҗиева бик үк пакь тә булып чыкмады түгелме соң? Дөрес, ялмакайланган-шантаж ясаган дип гаепләп булмый. Рәфикъ Гатауллиннан ни дә булса таләп итү түгел, ярдәм итимме дигән тәкъдимен дә кире каккан. Шулай да җибәргән акчаларын кабул итеп барган! Ә соң аның бала үстерүе турында телгә алуы кинаялэп ярдәм соравы, Гатауллинга басым ясавы түгелме? Һәрхәлдә, кайберәүләр шулай дип хөкем итәчәк. Әгәр Даниэль Соломонович та шул фикергә килсә? Аннары ун ел буена акча җибәреп торып та, Рафикъ Гатауллинның Гайнияне күрергә тырышмавын ничек аңлатырга? Бигрәк тә баласын күрергә тырышмавын?! Ул бит Гайния үстергән баланы әле һаман үзенеке дип хисаплый сыман. Юкса, суд хөкемен дә көтми, ни өчен ярдәм итәргә алынсын икән ул? Димәк, Рәфикъ Гатауллин белән сөйләшү котылгысыз. Әгәр боларның барысы да бик матур итеп оештырылган әкият кенә булса?!

Өлкән инспектор Байчурин ҖАБка кайтуга, Уфа белән телефоннан сөйләшергә заказ бирде.

*
* *

Инспектор Касыйм Вилданов ундүртенче цехта Валентин Николаев эшли торган смена башлыгы Хөсәеновны эзләп тапты һәм аны аулакка чакырып чыгарды.

— Тагын йомыш төште әле, — диде ул, — вакытыгыз бармы?

— Киңәшмәгә дип алданрак килгән идем. Рәхим итеп сорагыз, белгәнемне әйтермен.

— Валентин Николаевның Җәмил исемле дусты янсә иптәшен белмисезме?

— Җәмил Гайнуллинныймы? Нигә белмәскә, беләм.

— Кем соң ул?

— Безнең цехта эшли, Валентин кебек үк приборчы слесарь.

Касыйм, эзләгән кешесен бик җиңел табуына сөенеп, гөлҗимеш куаклары арасындагы аркалы эскәмиягә утырды.

— Николаев белән бергәме? — диде ул, сорашуын дәвам итеп.

— Юк, ул аны алмаштырып «В» сменасында эшли.

— Җәмил Гайнуллин турында нәрсә әйтә аласыз?

— Бүтәннәрдән әллә ни аерылмый. Бераз «минбеләмлек» чире бар икән. Педагогия институтының өч курсын читтән торып тәмамлаган. Бәлки шуңа күрә борынын күтәрәдер. Укымышлылыгына бик үк шаккатмагач, хәтере дә каладыр. Берни эшләп булмый, бездә химия дәрәҗәле. Җәмил — тарихчы.

— Укуын нигә ташлаган? — диде Вилданов кызыксынып.

— Заводта эшләр өчен дипломының файдасы булмаячак. Укытырга теләми — мәшәкатьле дә, читен дә. Хезмәт хаклары да мондагыдан түбәнрәк буласы, имеш. Югары разрядлы приборчы ул, кулы алтын. Шуның өстенә Казанда тарихчыларга кытлык юк, урын табу да бәла.

— Фототасма, спирт-фәлән урлап тотылганы юкмы?

— Хәтерләмим.

— Җәмил нәрсә белән мавыга? — Касыйм Җәмил Гайнуллин турында бүтәннәрдән сорашмаска да булыр, ахры, дигән карарга килгән иде инде.

— Хоккей, футболга йөрергә ярата. Тамашачы буларак кына, билгеле. Киноларны да калдырмый, һәр яңа фильмны цехта беренче ул карап бара. Бу яктан ул безнең җанлы энциклопедия. Шөһрәтле артистларның тормыш юлын да сөйләп бирергә әзер. Тавышы ярыйсы, җырлый.

— Өйләнгәнме?

— Юк әле. Типтерергә ярата бугай үзе.

— Җәмилнең Валентинга акча биреп торуын белмисезме? — диде ул, яңадан телгә килеп.

— Белмим. Бирсә, монда гадәттән тыш нәрсә булыр икән? — диде Хөсәенов. — Бер-беренә йомыш төшкәли бит. Көмеш урлаучыларның берсен тотканнар икән дип ишеттем, дөресме ул?

— Әйе, эләктердек, — диде инспектор Вилданов, күзен дә йоммыйча. — Без капчыкта ятмый, бер килеп чыга. Әмма дөньяда бер көмеш кенә түгел бит әле. Бүтән уңайдан да мәгълүматлар җыярга туры килә.

Касыйм киңәшмә башланганчы цех башлыгы белән дә сөйләшергә өлгерде, тик аңардан яңа нәрсә белә алмады. Җәмил Гайнуллинның ни яхшы, ни начар яктан күзгә ташланганы юк икән. Валентин Николаевны яхшы белгән аппаратчылар аның Гайнуллиннан башка Җәмил исемле бүтән дусты да, иптәше дә булмавын расладылар.

Инспектор Вилданов ундүртенче цехтагы эзләнүләренә бик канәгать булды. Кадрлар бүлегендә Җәмилнең анкетасын, хезмәт кенәгәсе һәм башка кәгазьләрен ул инде күңелсез, әмма котылгысыз бер бурычын үтәгән кебек кенә күздән кичерде.

*
* *

Телефон өзлексез шалтырый башлады. Уфаны бирәләр икән.

— Рәфикъ Гатауллиннан сорау алгач ук, нәтиҗәсен телефоннан хәбәр итсәгез иде, — дип үтенде Айбулат, үзен кызыксындырган сорауларны әйтеп бетергәч. — Ашыгыч кирәк.

Трубканы куйганнан соң өлкән инспектор Байчурин «Тасманур» хәлләренә кадәр үзе тикшергән бер җинаять материалларын актара башлады. Беркетмәләрнең берсендә спирт эчү факты теркәлгән иде. Спиртны кайдан алганнар дигән сорау үзеннән-үзе куелырга тиеш ләбаса! Ә монда берни тикшерелмәгән, андый сорау куелмаган. Ә бәлки... ие, ие, бер генә шик тә тикшерелми калырга тиеш түгел. Әгәр хулиганнардан кабат сорау алса? Алар изоляторда гына ич әле.

Өлкән инспектор бандитлыкта гаепләнгән үсмерләрне үз кабинетына китерергә боерды. Кикриге шиңгән әтәчләрнең берсе Равил Сабитов үз язмышын җиңеләйтер өчен белгән теләсә нинди нәрсәсен сөйләп бирергә әзер иде.

— Спирт Габдуллиннарда гел була. Зөбәер — шофер. Аларда аратирә сатлык та булгалый. Иптәш өлкән инспектор, сезгә ярдәм итәргә теләвем судта исәп алынып бит?

— Һичшиксез. Спирт сатып алучыларны да хәтерлисезме?

— Безнең йортта да бар алар, — диде аклана алуына сөенгән Сабитов. — Хәбибуллин Ислам, Митяев Сергейлар алды. Литрын җидешәр сумнан.

— Зөбәер Габдуллин кайда эшли?

— «Тасманур» заводында.

Өлкән инспектор моннан артыгын көтми иде. Хулиганнарның икенчесе авыз ачарга теләмәвенә дә аның исе китмәде, үсмерләрнең һәр икесен кире изоляторга озатты да, Равил Сабитов атаган кешеләрдән сорау алырга китте. Ислам Хәбибуллин һәм Сергей Митяев спиртны Зөбәер Габдуллиннан алуларын яшереп тә маташмадылар. Хәзер инде Байчурин Зөбәер Габдуллинның спиртны «Тасманур»дан алып чыгуына шик-

ләнмәде. Чөнки утлы суның оясы шунда. Аны машина белән кереп-чыгып йөрүчегә сылау бермә-бер җиңел. Көмеш урланган төнне кайда булуын да ачыкласалар...

Байчурин, «Тасманур» заводына килгәч, беренче чиратта, җиденче цехның профком председателен күрергә ашыкты. Степан Муллин турында элекке хезмәттәшләренең фикерен белү көзгечегә төшкән шикне ачыкларга тиеш иде.

— Степан белән биш ел чамасы бергә эшләдек,— диде карсак буйлы юантык ир кеше. — Аның турында нинди дә булса начар сүз кузгатылганын хәтерләмим. Иренмәс, тиктормас җан. Нәрсә кушсалар да карышмады. Карусыз адәм.

— Аның көзгеләр ясавын беләсезме? — диде Байчурин.

— Ишеткәнем бар. Бездә эшләгәндә андый нәрсә белән изаланмады. Теләсәгез, аны белүче башка иптәшләрне дә чакырам, барысы да минем сүзне раслар.

Карт эшчеләрдән тагын берничә кеше Степан Муллинның нәкъ менә профком председателе сурәтләгән сыйфатларына басым ясады. Аның көмеш нитраты белән кызыксынуын берәү дә хәтерләмәде. Өлкән инспектор Байчурин көзге ясар өчен чималны Муллинның базардан сатып алуына ышанырга мәҗбүр иде. Әмма ул Степанның нәрсәнедер әйтеп бетермәвен дә чамалады.

Айбулат җиденче цехтан транспорт капкасына юнәлгәндә караңгы төшә башлады, салкынча җил чыкты. Цехларда ут алынды. Нәҗибә эшләгән лабораториянең якты тәрәзәләре күңелле бер нәрсә вәгъдә иткәндәй үзенә тартып торса да, ул анда кереп чыгарга батырчылык итмәде. Эш урынына ешлату килешмәс. Әгәр Нәҗибәнең хәзер кереп чыккан хәлдә чын күңелдән сөенәсен белсә, Айбулатның һәртөрле шартлы гадәтләргә, әдәп кагыйдәләренә бик исе китмәс иде дә бит... Кызның чын тойгыларын белми шул әле ул. Әгәр Айбулатка кичәле-бүгенле якты чырай бирүе, тик торганнан тиген эш дип, бер мөгез чыгаруы гына булса? Нәни тәпиләренә, сөйкемле борынына сокланып, бер сөеп-сыйпап алыйм әле дигәндә генә, керпе инәләрен тырпайта, йомарлана түгелме?! Бәлки шушы көмеш эшен уңышлы башкарып чыкса, Нәҗибәгә якыная төшәр? Үз заводларында ясалган җинаять булганга, киләчәктә дә кызыксынып торыр әле. Җинаятьчеләрнең тизрәк тотылуын теләр. Каракларны фаш итүче герой буларак танылса, Айбулатның дәрәҗәсе, мөгаен, аның карашында да үсеп китәр. Әгәр бик үк исе китмәсә, иптәшләре, дусларының сокланып сөйләгән сүзләре колагына керер. Хәер, ул кадәр битараф калмас Айбулатның уңышына. ҖАБта эшлим дигәч, кызыксынарак караган төсле булды ич. Димәк, моннан соң икеләтә тырышлык куйса, Нәҗибәсенә дә, аның тансык назларына да бермә-бер якынаячак.

Өлкән инспектор Байчурин транспорт капкасында мөһим бер нәрсәне ачыклады: шофер Габдуллин көмеш склады басылган төнне икенче ярты белән өченче ярты арасында «Тасманур» заводында булган. График буенча бу вакытта капкада каравылчы Җаббар Гыйбадуллин торган. Үзенең вахтерларын Гази Гафуров яхшы белергә тиеш дип, Айбулат каравыл башлыгын күрергә булды. Бу юлы Гафуров үзенең кабинетында иде.

— Исәнмесез, Гази абый! Сезнең койрыкны тоту үзе бер бәла икән. Ничә килсәм, чыгып китте, диләр.

— Бу арада йокы качты, аягым җиргә тими, — диде Гафуров. — Әле тегендә чабам, әле монда. Тәмам теңкәгә тиделәр, шушы көмеш нитраты урлану уңаеннан партком утырышында отчет бирергә куштылар. Бүген барлык транспорт чараларын, үземнең кешеләрне сәгатьләп, минутлап барлап чыктым.

— Бер эш артыннан йөрибез икән, — диде Айбулат. — Алтысы көн-

не Зөбәер Габдуллин машинасының икенче ярты белән өченче ярты арасында нишләгәнен дә белдегезме?

— Тулы алиби. Өч шаһит раслап тора, йөк белән кергән дә, бушаткач ук чыгып киткән.

— Ә Җаббарыгыз нindirәк кеше?

— Җаббар Гыйбадуллин бездә сигезенче елын эшли,— диде Гафуров.— Башта эленке-салынкы йөрде. Ара-тирә кәгеп. Акча юнәтергә хирес. Тик ул балта остасы бит, читтә эшләштергәли. Бездә стаж өчен генә йөри. Хәзер капка ясап биргәнгә дә алтышар йөзне тамызалар. Бер ай балта тукылдатса, бездәге ун айның окладын чыгара. Шуңа безрик кәперәергә ярата. Әйбер чәлдерүчеләрне тотканы бар. Кеше белән аралашырга да алгыр. Күңеле бер дә тәнкыйтьне сөйми тик. Әмма үзе әйбәт эшли, таләпчән.

— Зөбәер Габдуллин белән танышмы икән?

— Әйтә алмыйм.

— Моны ачыклагыз әле. Зөбәернең спирт сатуы мәгълүм булды. Артык чая адәм түгел микән?

— Менә бусы яңалык. Тырышырмын. Бездә калай да юкка чыгуын ишеттегезме әле? Телефоннан хәбәр иткән идем, мин белмәгән яңа инспекторлар килде.

— Беренче ишетүем. Кайчан юкка чыкты?

— Вакытын белмибез. Бер кырыйдарак ятканга, игътибар итүче булмаган. Җиде йөз илле табактан җилләр искән. Әле ике сәгать элек кенә белдек. Калай өеме яткан тирәдә автотөягеч тәгәрмәче эзләрен күрдем. Бүген төнлә заводта Галимҗан Әхмәтгалиев автотөягечә генә эшләгән. Тик, эзнең кайчан калдырылуы мәгълүм булмагач, аны гаепләү дә нигезсезрәк. Дөм сукыр көе капшанабыз, экспертларыгыз гына ачыкласа инде. Хәзер автотөягеч эшенең һәр минутын диярлек тикшерергә туры килә. Алгы бүлмәдә, күргәнсездер, хәтсез кеше утыра. Шаһитлар табылмасмы дип чакырттым.

— Эт белән килделәрме?

— Эзне алмады. Калай төялгән машина асфальттан читкә чыкмаган. Шуңа күрә көпчәге эзен дә шәйләп булмый. Автотөягечкә юлдан кырыйга тайпылырга туры килгән, балчыкта тәгәрмәч эзләре ярылып ята.

— Бәлки ул күптәнге эздер? — диде Айбулат.

— Бөтен бәла дә шунда шул. Әмма калайның хуҗасы булган склад мөдире әйтүенчә, соңгы вакытта ул тирәдә автотөягеч файдаланылмаган. Калай исә яз көне үк китерелгән. Әлеге Галимҗанга ныклап тотындым. Төнге унбердән иртәнге җидегә чаклы аның сменасы. Калайны көндез төяп булмый. Галимҗанның кыек куллы булганы өчен бер тапкыр хөкемгә дә тартылганы бар.

— Болар сорау алу беркетмәләремени инде? — диде Айбулат һәм Гафуров өстәлендәге борчак кебек эре хәрефле язмалар белән тутырылган бланкларга баш изәде.

— Әйе.

— Галимҗан белән сөйләшкәндә сак булыгыз, — дип киңәш итте Байчурин. — Бәлки без килгәнче тимәссез? Ярдәм итәр идем, хәзер ашыгыч эшләрем бар.

— Киңәш итү җиңел,— дип уфтанды каравыл башлыгы.— Бүген завод директоры минем урынга яңа кандидатура эзләргә кушкан. Илгә иң авыр вакытларда кирәкле кеше идем, хәзер нindiдер жулик аркасында...

Айбулат Гази Гафуровның тавышы калтыранып китүенә гаҗәпләнмәде. Бөтен гомерен илгә хезмәт итүгә багышлаган кешенең пенсиягә чыгар алдыннан гына эштән куылуы фаҗига түгелмени? Ничек кенә әле! Димәк, төнлә завод мәйданында берәнбер автотөягеч, аның шоферы — элек хөкем ителгән кеше. Гаепле булса, тәҗрибәле җинаятьче, кире кага алмаслык дәлилләр белән исбатласаң гына бирeләчәк.

— Кулдан төягән булсалар, нишләрсез? — диде Айбулат.

— Җиде йөз илле табак бит, — диде Гафуров. — Автотөягеч аны биш минутта алып сала. Кулдан бер сәгатьтә дә өлгерә алмассың. Җитмәсә, шалтырый, доңгырдый ул.

— Кичке сменада да төяүләре мөмкин ич, — диде Айбулат.

— Ачыкладым инде, автотөягеч кичен калай янына бара алмаган.

— Калайның да көмешчеләр тарафыннан урлануы ихтимал. Майордан аңы тикшерүне дә үзебезгә тапшыруын үтенермен, — диде Байчурин. — Фиргавен нәфесе бу угрыларда, үз башларына җилкенәләр. Саграк булыгыз.

Өлкән инспектор Байчурин милиция бүлегенә кайткач, дежур торучыдан Уфа хакында белеште. Әле шалтыратмаганнар икән. Айбулат, спиртка нядәшкән Хәбибуллин, Митяевләр күрсәтмәсенә нигезләнеп, прокурордан Зөбәер Габдуллиннарда тентү ясар өчен рөхсәт ала торырга карар итте. Бу эшне дә башкарды, тик Уфа әле һаман дәшми иде. Буш вакыттан файдаланып, Айбулат Нәҗибәгә шалтыратырга булды.

— Үзең кереп чыгарсың, дип уйлаган идем, — диде кыз яңгыравык тавыш белән. — Бүген дә бушый алмыйсыңмы? — Безнең цех буеннан узып киттең ич, нигә кагылмадың?

— Күпне күрәсең икән! — диде Айбулат гаҗәпләнеп.

— Мин түгел, лабораториядәге кызлар күреп калган. Әнә, кичәге баһадирың бара, дигән булалар. Чеметкәләп маташалар әле.

— Нигә?

— Егетләрне иләсләндереп йөрисең, берсе тәкъдим ясады ич инде, җитмәдемени, бу баһадирың безгә булсын, диләр. Миңа карый торган кавалер түгел бусы, дип көчкә тынычландырдым үзләрен, — диде Нәҗибә көлеп.

Нәҗибә шаярта идеме, чынлап әйтәме — Айбулат төшенмәде. Ничек кенә булмасын, хәвефләнә калды. Байчурин бу хакта хәтта шаярып сөйләшүне дә өнәми иде. Шукланам дип нигә кылтаерга инде?

— Тәкъдим ясыйлар, алайса? — диде ул, битараф тавышын көчкә саклап.

— Апаеңа өченче тәкъдим инде бу! — диде Нәҗибә бөтенләй шаяртмаган тавыш белән. — Бер биздергән идем инде, кичәле-бүгенле тагын тәмам балга ябышкан чебенгә әйләнде! Әллә синең хакта ишетеп көнчелеге кузгалган? Иптәшләрчә генә сөйләшеп йөргәнеңне беләмени ул? Вакыты да исәпсез, тагын килеп җитәр инде, хөсет. Кайчан карама, безнең тирәдә сөрәеп тора.

«Вакыт» дигән булып Айбулатка төрттерә инде. Байчуринда һич тә шаяру кайгысы юк иде. Кая ул шаяру! Кешенең матурны күрәсе, яхшыны аласы килә. Дөньяда Айбулат кебекләр әзмени? Әлегә кадәр кыз аспирантурада укыйсын уйлап ашыкмаган булса, моннан соңгы ниятләрен кем белә? Шуңа күрә Байчурин катгый карарга килеп:

— Әйдә, иртәгә кичен очрашыйк әле? — диде. — Ул егеткәеңә нинди рәк җавап бирергә кирәклеген киңәшербез. Мин күптәнге танышың ич, бала чак дустың, хакым бардыр. Торнаяз урамындагы Җәлил панносы янына җидегә килә аласыңмы?

— Эшләреңне кая куясың? — диде Нәҗибә.

— Синең хакка кичектерербез, иеме. Тик моны берәүгә дә ычкындыра күрмә. Югыйсә, чыбыксыз телефонның артык шәп эшли дип ишеттем. Безнең тирәдә сер тотучыларны яраталар.

— Шул кадәр яшерен, ә? Астыртын, алиментттан куркып алдан чарасын күрәмени! Чит ил шымчысы түгелсеңдер ич?

— Эшебез аннан ким түгел, — диде өлкән инспектор. — Авызны уйлап кына ачарга туры килә. Сиңа да киңәш шундый, ишеттеңме?

— Тырышып карармын, — диде Нәҗибә.

*
* *

Айбулат соңрак кайтасын кисәтеп өенә шалтыраткач, ҖАБ башлыгы кабинетына килеп керде. Винер сейфтагы папкаларын актарып ята иде.

— Ә, Айбулат, кер, кер, әйдә, — диде ул, кәгазьләреннән аерылып. — Сезгә ярдәм итәргә җыендым да, вәгъдәмне үти алмадым. Менә әле яңа гына министрлыктан кайтып кердем. Әле тегендә, әле монда чакырталар, аптырап беттем. Я, көмеш эзләү хәлләре ничегрәк хәзер?

— «Тасманур» заводына кереп-чыгып йөрүче шофер Зөбәер Габдуллин ара-тирә спирт саткалый икән. Өендә тенту ясарга уйлыйм. Без үз эшебез белән мавыгып йөргән арада тагын бер ботка пешергәннәр икән анда, ә?

— Әйе, аны тикшерергә кеше билгеләгән идем инде, — диде Винер.

— Даниэль Соломонович, калай эшен дә без алып барсак, яхшырак булмасмы? Шофер Габдуллинның эзенә төшү перспективалы. Калайны да, спиртны да, көмешне дә култык астына кыстырып кына шуытып булмый. Ә ул — шофер.

— Чәчелеп, таркалып йөрмәгез әле, бар хәсрәтегез көмеш булсын. Эш уңаенда яраса гына инде. Аннары... әле Габдуллинны фаш иткәнегез юк ич?

— Бүген очына чыгарбыз. Инде билгеле булган фактлар да игътибарга лаек. Шаһитлар җитәрлек дәлил бирде.

Шул вакыт бүлмәгә кызу гына атлап Шәмсия килеп керде.

— Берәр хәл булдымы әллә? — диде майор.

— Юк. Универмагта эш көнем тәгәлләнде.

— Ревизия беттеме?

— Ревизия башлангач, Хәят Галиева үзен бик тынычсыз тота. Таркауланды, берничә иптәшенә тупас кына эндәшергә дә өлгерде. Тик бүтән товар китерүче булмады. Җыештыручы гына аңа ниндидер язу китереп тоттырды. Хәят шуңа каршы җавап язып бирде, ахры.

— Кызык, — диде ҖАБ башлыгы, — хатларын да укыган булсаң, тәмам егет икәнсең, дия идек үзеңне.

— Хәят язганны җыештыручы алып китте. Галиева үзенә бирелгәнне укыгач ук ерткалап чүп савытына ташлады. Менә ул, мин аны җыеп ябыштырдым, — дип, Шәмсия ярты бит язулы кәгазьне сузды.

Винер корама кәгазьдәге язуны укыды да елмаеп Шәмсиягә карады. Инспектор Зиннәтеваның бүген күңеле шат иде. Тар борынлы түгәрәк йөзе, нечкә кашлары белән күк күзләре, бөдрә дулкынлы коңгырт чәчләре, ябыграк сылу гәүдәсе үтә сөйкемле күренә иде. Даниэль Соломонович яшь инспекторына яратып күз салган арада, Байчурин да Шәмсия Зиннәтева кулга төшергән хат кисәге белән танышып чыкты: «Хәят, сәлам. Әйтергә онытканмын, миндә тагын кайбер нәрсәләр бар иде. Үзең яратып ала торган әйберләр, аллы-гөллесе. Хәлләрең ничек, иртәгә китерсәм ярыймы? Тиз генә апа аркылы җавап бир, урамда көтеп торам. Ж.».

Ул арада кабинетка Вилданов та килеп керде.

— Дүрт күз белән көтеп торабыз үзеңне, — дип елмайды Айбулат.— Без сөйләшкән Җәмилне ачыкладыңмы?

Килеп кергәч үк сорау биргәнгә, нишләп болай мушкага алалар соң әле болар, дигән төслә, Касыйм бүлмәдәгеләрнең һәммәсенә дә йөгерек күз йөртеп алды. Аннары ышанычлы тавыш белән җавап бирде:

— Николаевның танышы Җәмил Гайнуллин үндүртенче цехта эшли.

Майор Винер Айбулатка мәгънәле генә карап алды.

— Ниндирәк кеше соң ул? — диде өлкән инспектор Байчурин.

— Әйбәт кеше, диләр. Биографиясе керсез. Приборчы слесарь. Квартал премияләреннән дә мәхрүм калмый.

пектор Вилданов Җәмил Гайнуллин турында үзе белә алганнар-
...иләп биргәч, Шәмсия Зиннәтева телгә килде.

— Даниэль Соломонович, бер егетнең Хәят Галиевага товар китерүен телефоннан әйткән идем ич, язуга игътибар иттегезме, анда «әйтергә онытканмын» дигән җире бар. Бәлки товар китерүче белән язуның авторы бер үк бәндәдер? Әйберен тапшырганда сөйләшкәннәр дип уйласак, ул әнә шуны күздә тотып искәртәчәк.

Винер Зиннәтева алып кайткан язуга тагын бер кат күз салды.

— Нинди рәк егет иде соң ул? — диде Винер.

— Кылыч борынлы, калын иренле, төз гәүдәле озын кеше.

— Син ачыклаган Җәмил Гайнуллинга охшыймы? — диде майор Касыймга.

— Даниэль Соломонович, аның үзен күрә алмадым.

ҖАБ башлыгы инспектор Вилдановка карап куйды. Байчурин исә кызыксынып Зиннәтевадан:

— Димәк, тагын товар китерделәр? — дип сорады.

— Әйе, — диде кыз.

— Ревизорлар фототовар бүлегендә берничә йөз кап төсле фототасма һәм фотокәгазь тапты, — диде Вилданов. — Дефицит товар. Коллектив заказ бар дип кире складка алдырттым.

— Товар китерүче артыннан инспектор Сафинны җибәргән идем, — дип өстәде Шәмсия. — Базарда югалткан.

— Автомобиль кибетендә нәрсә белә алдың? — дип сорады Айбулат Касыймнан.

— Кызыклы берни дә юк.

— Степан Муллин хакында яңа нәрсә әйтә аласызмы?

ҖАБ башлыгының соравы Айбулатка адресланган иде.

— Безне кызыксындырган рухта мәгълүмат бирмәделәр, Даниэль Соломонович. Ул әлек эшләгән цехта булдым.

— Бәлки өендә җентекләбрәк яңа тентү үткәрергәдер? — диде Винер кинәшкән төстә. — Хәзер өметле фаразлар аз калды. Башта спирт белән фототасма йомгакларын сүтик. Үзәк универмаг белән «Тасманур» арасында нык бәйләнеш бар. Зиннәтева кулга төшергән хат бәлки шәхесләрнең берәрсен ачыкларга ярдәм итәр. Беренче чиратта, Җәмил Гайнуллинны тикшерә аласыз: Хәятка хатны ул язганмы? Сатучы Галиеваны да күздән җуймагыз. Сорау алырга, әгәр кирәк булса, аны изоляцияләргә дә мөмкин. Хәзер ул, мөгаен, саграк кылана башлар.

Бүлмәдә бер мәлгә тынлык урнашты. Инспекторларның һәркайсы әзләнүләрне киләчәктә ничек дәвам итәсен уйлый иде. Көмеш эше өчен тулаем җавап биргәнгә, Айбулат беренче сүз башлады.

— Хәзер үк Габдуллиннарга тентү ясарга барам. Җәмил Гайнуллинны Вилданов үзе ачыклап бетерер инде. Сатучы Галиева Зиннәтева карамагында калыр. Универмагта фототасма сатып алучыларны да шаһитлыкка чакырырга вакыт. Идел буе районы культура сарае фототүгәрәгенә йөрүчеләрне табарга җитәкчеләре булышыр.

— Рестораннарны йөреп чыктыгызмы әле? — дип сорады Винер. Берәү дә уңай җавап бирмәгәч, дәвам итте: — Юк? Өлгерергә кирәк. Әле бүген дә соң түгел. Күңел ачуларның иң кызган чагы!

Инспекторлар җинаятьләрне ачу бүлекчәсеннән чыкканда сәгать кичке тугыз тулып килә иде инде. Айбулат берничә авыз сүз белән Касыймга склад мөдире Хаҗиеваның ничек акланүы турында сөйләп бирде. Инспектор Вилданов берни җавап бирмәде, сүрән генә тыңлады да, Зиннәтева белән рестораннарны йөреп чыгу өчен җиңел машинага утырып китте. Өлкән инспектор Байчурин милиционерлар белән автофургонга кереп урнашты. Ишекләр шартлап ябылуга машина урыныннан кузгалды.

* * *

Җаббар Гыйбадуллинны кулга алган инспектор Касыйм Вилданов тутый кош тоткан малай сыман сөенде. Әйтерең бармы, бу бит калайга гына түгел, фототасма, спирт, көмешкә дә юл ачу дип уйлады ул. Алар бар да капка аша үтә. Ә анда постта Касыйм фаш иткән Җаббар тора! Әгәр бу хәбәрне Даниэль Соломоновичка җиткерсәң, ул тырышлык һәм булдыклылыгы өчен, әлбәттә, ашчыны да хупламый калмас. Өлгер хезмәткәренә рәхмәт белдерү, премия яки бүтән бүләкләнүгә тәкъдим итү башлык кеше өчен кыенмыни?!

Касыйм каравыл бүлеге башлыгы Гази Гафуров тапшырган егермеләп беркетмәне тагын бер кат күздән кичерде. Әйе, картлач коточкыч олы эш башкарган. Бу кәгазьләр бит чынлыкта егерме кешедән сорау алу нәтиҗәсе генә түгел. Беркетмәгә теркәлгәннәре көмеш һәм калай юкка чыгуда теге яки бу дәрәҗәдә, һичшиксез, катнашы булган яки потенциаль мөмкинлеге бар кешеләр генә. Аларны табу, сайлап алу үзе катлаулы башлангыч тикшеренүләр ясауны таләп итә. Коллективны, завод атмосферасын яхшы белмәгән яңа кеше кирәкле исемнәргә юлыкканчы гына да күпме вакыт үтәр иде. Беренче тапкыр сорау алырга чакырылган шаһит яки үзең шикләнгән адәм белән сөйләшү еш кына уңай нәтиҗәләргә китермәскә мөмкин. Сорау алучыларның тәҗрибәсен, зирәклеген, елдамлыгын да соңгы исәпкә куярга ярамый. Гафуровның мактауга лаек булуын танымау гаделсезлек булыр иде.

Каравыл башлыгы завод милкенең иминлеге өчен җавап бирә. Урланган әйберләрнең кире үз хуҗасына кайтарылуы — Гафуров өчен барыннан да бигрәк мөһим нәрсә кыйммәт. Ул күрәсен күргән, эшлисен эшләгән. Тыныч күңел белән пенсиягә китә алса, бүтән тагын ни кирәк? Рәхмәт хакына дип йөримени ул? Рәхмәт ишетәсе килә икән, аны кем белдерсә дә барыбер. Касыйм аңа рәхмәтне бер тапкыр гына әйтмәде инде. Димәк, Гази абыйсы үз өлешеннән коры калмады.

Касыйм ҖАБка кайтканда, Җаббарларда арест салдырган сыеклык хакында эксперт фикере әзер иде инде. Төрү цехы эшчеләре исә коедан чыгарылган дерматин капчыкның үзләренеке булуын таныдылар. Касыйм тәвәккәл адымнар белән Винер кабинетына юнәлде. Анда район эчке эшләр бүлеге башлыгы подполковник Сафиуллин утыра иде. Касыймның икеләнә калуын күреп, майор:

— Я, я, иптәш Вилданов, сөйләп җибәр! — диде.

Вилданов Сафиуллинның да монда булуына чынлыкта сөенә генә төште.

— Иптәш майор, минем яңалык бар: калай урлаучыларның эзенә бастым. Аны капкадан чыгарган каравылчы Җаббар Гыйбадуллинны кулга алдым.

— Дәлилләр ышанычлымы?

— Әйе. Беренчедән, Җаббар Гыйбадуллинның шофер Зөбәер Габдуллин белән план корып, сүз берләшеп торуын күргән вахтер бар. Икенчедән, төнге өчтә калай төяп капкадан чыккан вакытта янгын командасы сержанты машинага каршы очраган. Өченчедән, Зөбәернең машинасы белән иртәнге якта алты сәгать буе кайдадыр югалып йөрүен диспетчер раслап тора. Шуның өстенә без машинаны эксперт белән карадык: бортында калай эзләре аермачык беленә.

Майор Винер җанланып китте.

— Сорау алдыңмы? — диде ул.

— Җаббар Гыйбадуллин кире кагып маташа. Тик без тентү вакытында аның өендә урланган спирт белән дерматин капчык, торбалар таптык. Капчыкны төрү цехында таныдылар. Сыеклыкның спирт икәнен эксперт раслады. Составы заводныкы белән туры килә.

— Аларны ничек аңлата?

— Капчыкны беренче мәртәбә күрүе, имеш. Спиртны билгесез кешедән сатып алган!

— Сержант калайны үз күзе белән күргәнме?

— Ул ни, ул... — Касыймның юк дип әйтергә теле бармый иде, — ул машинага авыр йөк төялгәнен күргән. Көпчәкләр яньчелгән, рессорлар сыгылган булган. Авыр йөкнең калай икәнлеген борттагы сыдырылу, тырналулар күрсәтә инде.

— Әй-йе-е, — диде Винер, беркетмәләрне караштырып.

— Шоферны кулга алдыгызмы? — дип сорады подполковник Сафиуллин.

— Таба алмадык әле. Бүген эшкә чыкмаган, өйләре бикле иде.

— Сиңа Айбулат әйтмәдемени? — диде Винер гаҗәпләнеп. — Габдуллинны ул кичә үк кулга алды ич инде. Тик ул аңардан спирт урлауда гына шикләнә иде бугай әле, — дип өстәде майор. — Фактларны үзенә яратыр өчен тартып-сузып җыймыйсыңмы икән? Мавыгып китеп, артыгын бөгештермисеңме?

— Сез нәрсә, Даниэль Соломонович? — дип үпкәләде Касыйм. — Фактларга әз генә каршы барсам да, автотөягечтә эшләүче Галимҗанны аклар идеммени?

— Галимҗан, димәк, гаепсез?

— Бернинди гаебе юк! Мин сорау алган кешеләр барысы да шуңа шаһит.

Касыйм алып кергән беркетмәләргә подполковник Сафиуллин да күз салды. Майор:

— Бүген сатучы Хәят Галиевагыз эшкә чыкмаган иде, — диде. — Кулга алырга туры килде. Шәмсия тентү ясаган, өендә берни юк икән. Әмма мөмкинлегенә караганда иркенрәк яши, ди. Бухгалтерияләре еллык керемен исәпләп биргән. Саклык кассасында да акчасы бар икән. Җинаятьтә катнашуын кире каккан.

— Ә фототасма? Хат?! — диде Касыйм.

— Хат сездә, шуңа күрә Зиннәтева аны телгә алмаган. Пленканы, үткән кварталдагы товар, танышларыма сакладым, дигән. Хатка нигезләнеп яңадан сорау алырсыз.— Винер беркетмәләрне Касыймга сузды.— Котлыйм! Дәлилләрең саллы, булдыргансың. Ерак китми тор, Айбулат та авылдан кайтып җитәргә тиеш. Нәрсәдер озаклады.

— Әгәр бер кешене кулга алырга да рөхсәт итсәгез... — диде Касыйм.

— Уйларбыз, соңыннан,— дип туктатты аны Винер.

Касыйм ҖАБ башлыгы кабинетыннан канатланып чыкты.

Инспектор Вилдановны күз кырые белән озатып калган подполковник Сафиуллин:

— Күрәм, егет өлгер, үз эшенә нялэшкән, синең стиль сизелә инде, — дип елмайды.

Бу вакытта Касыйм өлкән инспектор Байчурин кабинетында иде инде.

— Сәлам, кайтып җиттегезме? — диде ул Айбулат белән исәнләшеп.

— Көчкә. Безнең юлларны беләсең бит, — диде Айбулат. — Я, синдә нинди уңышлар бар?

Касыйм бу сорауны бик көтә иде инде. Әмма чыраена чыгармады. Шапырынудан сакланса да, бүгенге табышларын бераз ирәймичә сөйли алмады. Аның уңышлары нигезендә Гафуров салган ташлар ятуын чамалаган Айбулат:

— Бик кәпәренеп китмик, — дип кисәтте. — Калай урлану хәзер үч төбендәге кебек ачык. Аңа арест салдык инде. Тик бу — иптәшләргә ярдәм итү генә. Безнең бурыч — көмешне табу. Аны бөтенләй башка өер үзләштерүе ихтимал. Химикат серен белүчеләр.

— Зөбәерне кулга алуыңны әйтмәдең дә.

— Кичә ашыгыч булды, өлгермәдем, — диде Айбулат. — Бүген иртән күрешә алмадык. Спирт белән эләкте ул. Синең табышларыңа да юлны спирт салды. Ачыклагыз дип, Гафуровка әйтеп киткән идем.

Касыйм өлкән инспекторның яңа беркетмәләре белән танышкан арада Байчурин, экспертизага шалтыратып, авылдан кайтканда биреп чыккан сыеклык турында белеште һәм Зөбәер Габдуллинны сорау алырга чакырды. Вилданов та тизрәк хәрәкәтләнергә булды: Винердан ризалыкны ишетмәсә дә, яңа гына барган сөйләшүне сылтау итеп, Айбулатка белдермичә генә Гайния Хаҗиеваны кулга алырга чыгып китте. Җиңүгә ул да өлеш кертергә тиеш ләбаса!

*

* *

Габдуллинны кич белән кулга алган иде Байчурин. Күршеләрдән чакырылган ике пунәтәй һәм берничә милиционер килеп кергәч, хуҗа каушый калды. Анасы белән хатыны тагын да зуррак хафага төштеләр. Өлкән инспектор, прокурор санкциясен күрсәтеп, үз эшенә керешә. Ана кеше хәсрәтен, шомлануларын яхшы аңласа да, җәмгыять алдындагы җаваплылыкны онытырга һич теләми иде. Буфеттагы аракы шешәсендә исе дә, төсе дә спиртка охшаган эчемлек табылды. Шундый ук сыеклык келәттәге колоксилен тартмасы төбендә дә ун литрлап бар иде. Аларга арест салынуын әйтеп, өлкән инспектор Зөбәергә киенергә кушты.

— Безнең белән барырсыз, аңлатма аласы бар.

Елый-елый озата чыккан хатынына Зөбәер кырыс кына кычкырды:

— Үкермә! Балавыз сыгарлык гаебем юк, тикшерерләр дә җибәрерләр.

Көр күңелле егет бу дип көлемсерәде Байчурин. Мәгәр сыекча спирт булып чыкса, хәлең өметсез бит, егеткәй. Бүрек кайтармасы эченнән килеп чыккан хат та сәер.

«Зөбәер, монда күчтәнәчегез бик мач килде әле, — диелгән иде анда, — тагын чамагыз булса, иренмә. Мохтаҗлык зур, әмма безнең кибеткә кайтармыйлар шундый товарны...»

Бер караганда игътибар җәлеп итәрлек нәрсәсе юк та кебек. Тик бу хат ни өчен кием шкафындагы көя даруы исе сеңгән бүрек кырпуы астына кыстырылган соң әле? Әлегә бүрек кимиләр ләбаса, ә бу хат шушы арада гына килгән. «Иренмә» сүзе дә бик урынлы түгел. Конвертның адресына караганда, хат Зөбәернең Мари АССРдагы бер авылда яшәүче туганы Шамилдән иде.

Өлкән инспектор Габдуллинны изоляторга, тентеп алган сыеклыкларны экспертизага җибәрде һәм, өенә кайтып башын мендәргә тидерүгә, изелеп йоклап китте.

Гадәтенчә, иртәнге алтыда уянды, герләре белән уйнап физзарядка ясады, аннары күңелле җыр көйли-көйли кырынды. Аның шат күңеллелегенә сөенгән анасы:

— Йомырка салырга кытаклаган тавык кебек кыланасың, нәрсә булды? — дип кызыксынды.

Айбулат йокыдан торырга иренеп яткан энесен караватыннан сөйрәп алып түшәмгә чөя башлады. Кытыкланган малай шаркылдап көләргә, тиберченергә тотынды. Төпчегә өчен курыккан анасы:

— Куй, имгәтерсең баланы, люстраны ватасыз, рәхмәт төшкерләре! — дип чәбәләнә башлагач кына Айбулат энесен мендәрләр өстенә тондырды.

Абыйсының тыгыз мускулларына кызыккан малай янадан юрган астына кереп качты. Үртәп маташса да, Айбулат аның өчен абый гына түгел, тере герой иде. Бүтәннәр шикелле мажаралы романнардагы ка-

һарман шәхесләргә табынып торасы юк. Хәтәр җинаятьләрне ачучы, серле вакыйгалар эчендә кайнаучы инспектор, самбо буенча беренче разрядлы көрәшче анын белән янәшә йоклый бит.

Иртәнге сигездә өлкән инспектор Байчурин үзенә тагын бер ярдәмче алып милиция машинасында шәһәрдән чыгып бара иде инде. Бүрек кайтармасыннан табылган хаттан соң ул Степан Муллиннан сорау алуны билгесез вакытка кадәр кичектерергә булды. Винер кинәшен истә тотып, бары тик көмеш урлауны гына тикшерәсе иде дә бит, юк, монысы да кызыктыра. Ә бәлки? Бәлки яңа юл шушы сәфәрдә салыныр?

Әле көзге яңгырлар коя башламаганлыктан, юллар тузанлы иде. Урман арасындагы сикәлтәләрне исән-имин узгач, машина тизлеген арттырды, бераздан асфальтланган Дөбьяз юлы күренде. Сул якта көзге чуар киемен киеп көязләнгән агачлар, уңда бушап калган кырлар, сары салам эскертләре тезелеп калды. Бу якларга беренче тапкыр юлга чыккан Айбулат татар авылларындагы бизәкле капкаларга, йортларның төрле төсләргә буялган челтәрле кыек, кәрнизләренә, төзек каралты-кура, эре бүрәнәләрдән салынган ак мунчаларга сокланып карап узды.

Машина Әтнәне үтеп сәгать ярым баргач, күрше республиканың Бәрәнге районына килеп керде. Килгән авылда өлкән инспектор, беренче нәүбәттә, авыл советы председателен эзләп тапты. Соңгы вакытта өй түбәләрен калай белән япкан берничә кешене кәнсәләргә чакырдылар.

— Калайны апрель аенда сатып алдым, — диде арпа керфекле карт. — Товарны Шамилнең туганы Зөбәер кайтарды. Ни эшкә кирәк булды соң әле бу?

— Урланган калай кайтарган сезгә Зөбәер Габдуллин, — диде Айбулат.

— Без аны кайдан белиек? Сорасаң да, әйтмәячәкләр. Шуңа күрә сатучы булгач, бик тикшереп маташмыйбыз. Зөбәер, товар базасында эшлием, шуннан җибәрделәр, дип товарны үз бәясеннән кыйммәткәрәк бирде. Хәзер кулда акча бар, әмма әйберен таба алмый теңкәң корый. Минем төсле интеккән тагын өч-дүрт кеше алды әле. Башкаларга спирт кына эләкте. Анысын җидешәр сумнан дүртәр-бишәр литр алдылар.

Айбулат калай һәм спирт алучыларның исемнәрен ачыклагач, яңа сораулар бирде:

— Тагын нәрсәләр саттылар?

— Бүтәнне белмием. Шамилдән сорарга кирәк, Зөбәер аларга кайтып керә.

— Зөбәер товарларны үзе генә алып кайттымы?

— Әйтә алмыем, — диде карт. — Калай сатканда тагын бер ир бар иде. Озын буйлы, калын иренле, туры кылыч борынлы, тонык ак чырайлы кеше. Кыйбат, ник болай туныйсыз безне, дигән идем, үз бәясеннән биетергә булса, сезгә тәтеми дә ул, тигенгә үзем дә бар, диде.

— Апрель аенда кайсы көнне сатканнарын хәтерләмисезме?

— Ай уртасындарак. Төгәл истә калмаган. Иртән әле томан да таралып бетмәгән чак иде.

Айбулат спирт һәм калай сатып алучы унбишләп кешене тапты. Шамилдә тентү үткәрде. Ачыкланган хәтлесе буенча, Зөбәер йөз илле литрлап спирт, мең табак калай саткан иде. Өлкән инспектор аларга акт төзеп, товарга арест салды. Калайның бер өлеше файдаланылган, спиртның да кырык литры гына калган иде. Әмма дәлилгә кытлык беткән иде инде.

Йөрәге сыкрап киткән Шамил, җаваплылыктан куркып, кырыйда калырга омтылды:

— Төнлә кайттылар, караңгыда киттеләр. Апрельдә исә өйгә дә кереп тормадылар. Ике аягының берсен бастырмас идем, туганнан туган кешем булгач, куып чыгару читен. Малны кайдан табуын әйтеп тормады. Базадан куштылар дигәч, ышандык.

— Хатында бүтәнчәрәк сайрагансың ич, — диде Айбулат. — Үзең чакырып торасың. Күрәсең, хәрам мал акмаса да, тамган кесәңә.

Шамил дәшмәде. Айбулат сорашуын дәвам итте:

— Калай белән соңгы тапкыр кичә кайттылармы?

— Әйе, иртәнге алтыда.

— Товарның бер ишесе чыкмады ич әле. Яшереп калсаң, зыяны үзеңә тиячәк.

— Бүтән әйберләрен күрмәдем, белмим.

Димәк, өмет акланмады, дип уйлады Байчурин. Көмешне авылда урнаштырып булмый шул. Түбә ябарга да, эчәргә дә яраксыз. Күпме вакыты җилгә очты! Бер генә юаныч бар — Зөбәер белән кайтучы кешенең төсмерләре универмагка фототасма китерүче егетне хәтерләтә сыман. Әгәр ул Җәмил булып чыкса? Авыл кешеләренә танытыр өчен фоторәсемен күрсәтү дә җитә ич!

Байчурин хәзер инде Шамилне алып шәһәргә кайтып җитәргә ашыкынды. Әгәр кодрәтеннән килсә, оча торган келәм барлыкка китерер дә, шуңа гына рәхәтләнеп утырып китәр иде. Ниһаять, Әтнәгә җитеп, асфальт юлга аяк бастылар. Барган саен каршыга елдамрак йөгергән баганаларга карап, Айбулат ирексездән, асфальт — машина өчен майлы аш инде ул, дип уйлады. Кайтканда, яхшы юлдан аерылмас өчен, шәһәргә Дәрвиш бистәсе ягыннан килеп керделәр.

Байчурин, җинаятьләрне ачу бүлекчәсенә кайту белән, «Тасманур» заводына шалтыратып, апрель аенда калай югалуын белеште. Андый җинаять ясалуын берәү дә раслый алмады. Өлкән инспектор заводта соңгы вакытта калай әйләнешенә ашыгыч ревизия ясарга тәкъдим итте. Аннары Зөбәер Габдуллиннан сорау алырга әзерләнә башлады.

*
* *

— Карышу мәгънәсез. Җаббар Гыйбадуллин белән төнге уникенче яртыда сүз берләштегез. Сәгать өч тулганда заводтан чыгып киттегез, Мари республикасындагы туганың Шамилләргә килеп җиткәчтен, офыкта якты шәүлә җәелү белән кызу сәүдә башладыгыз. Өегезгә кайтып хәрам акчаны чутлап бетергәчтен, тукта, бу егет төне буе керфек какмаган лабаса дип, сезгә үзем ял юнәттем. Фактлар шундый. Төнге маҗараларыгыз менә монда бәйнә-бәйнә язылган, — дип, Айбулат бер кочак беркетмәгә ымлады. — Үгет-нәсихәт хаҗәте юктыр ич, авылдан гына да унбишләп шаһит барладык. Өендәге дә, авылда саткан спиртың да «Тасманур»ныкы булуын экспертлар раслап тора. Шамил күрше бүлмәдә, күрештерә алабыз.

Зөбәер Габдуллин күзләрендәге очкыннар суга төшкән утлы күмер төсле сүнде, сүрелде. Ул зур дикъкать белән Айбулат кулындагы беркетмәләргә карап катып калды.

— Авылга бергә кайткан юлдашыңнан башлыйк, кем иде ул? — дип сорады Айбулат.

— Юл уңаенда утырды. Мин аны белмим. Сәфәре еракка иде, ахры, иртән җәяүләп ары китте.

— Син нәрсә, ялганга ышанырга безне дивана саныйсыңмы әллә? — Байчурин карашы белән аяусыз рәвештә Габдуллинны бораулады. Беркетмәләр караштырган Вилданов та бар гамен сорау алуга биргән иде.— Юлаучылар кайчаннан бирле җиде юл чатына төнге сәгать өчтә чыга башлаганнар? Спиртны каян алдыгыз?

— Юлаучы миңа Бәрәңге районына кергәч кенә утырды,— диде Зөбәер тексе генә.— Гомумән, уйлыйм әле. Вакыт бирегез.

Айбулатның түземлеге инде байтак кимегән иде.

— Берничә сәгатьтән синең уйларың безнең өчен сукыр бер тиен дә тормаячак. Тормышыңны имгәтергә ашыккач, имен төрмәдә табарсың инде. Бар, уйла, философ!

Айбулат конвой чакырып, Зөбәерне изоляторга ябарга әмер бирде. Әле һаман беркетмәләр караштырган Вилдановка:

— Син теге универмагка язу җибәргән «Ж»не эзләп карадыңмы? — диде аңа Байчурин.

— «Тасманур»дагы Җәмил Гайнуллинның язу үрнәге белән бергә ул хатны экспертизага тапшырган идем. Җәмилне сменасы белән фотога төшерергә куштым, рәсеме шәт әзердер дә. Шалтыратып багыйк, — диде Касыйм.

Вилданов фотограф белән телефоннан сөйләшә башлады.

— Бәрәкәт! — диде ул Байчуринга карап. — Ул юньсез бүген эшкә чыкмаган ич.

— Ни сәбәптән?

— Белмиләр.

— Әйдә, экспертизага да шалтырат инде.

Бу юлы Касыймның чырае тагын да сытыларак төште.

— Нәрсә, әллә анда да эшкә чыкмаганнармы? — диде Айбулат төрпә генә.

— Язуларны бер үк кеше язган дигән фикергә килгәннәр.

Вилдановның җәберсетелгән баланыкы сыман караңгыланган йөзенә карап, Байчурин урыныннан сикереп торды:

— Йөзе кайткан пычакка охшап калдың! Вәсвәсәгә төшәр чакмыни, сөенче сорарга кирәк. Тик, беренче нәүбәттә, Җәмил Гайнуллинга тамга салыйк. Эзенә басыйк әле, ерак шылмагандыр.

Байчурин, теләсә нинди киртәләрне тибеп кенә егачак кеше төсле гайрәтләнеп, майор Винерны яңа мәгълүмат булган дәлилләр белән таныштырды һәм Вилданов белән бергәләп Гайнуллинны кулга төшерергә хәер-фатиха алды.

Инспектор Вилданов исә махы бирдем дип хафалана иде. Универмагта Хәят Галиеваның, заводта Җәмил Гайнуллинның эшкә чыкмавы аңа бер-берсе белән бәйләнгән сыман тоелды. Галиеваны иртәдән үк абайлап кулга алганнар. Күздән югалтырга ярамаган бәндә буларак, Гайнуллин әле менә хәзер генә беленде. Әгәр юкка чыкса, табанын ялтыратып өлгерсә? Ләкин ундүртенче цех башлыгын күргәч кенә аның йөрәге урынына утырды.

— Җәмил Гайнуллин уникенче больницага дәваланырга китте, — диде цех башлыгы.— Завод врачының белешмәсен күрсәтте. Ашказаны хәтсездән авырта аның. Ялыктырса да, кереп ятам инде дип сөйләнде.

— Җәмил Гайнуллинның чишенү шкафын тентергә туры киләчәк, — диде Байчурин цех башлыгына. — Пүнәтәй итеп бер кеше чакырыгыз әле.

Бүлмәдә ят адәм калмагач, өлкән инспектор майор Винерга шалтыратты.

— Даниэль Соломонович, Җәмил Гайнуллин универмагка фототасма китерүче егет булып чыкты. Ул уникенче больницага дәваланырга кергән, диләр. Тикшерәсе һәм күзәтү урнаштырасы бар иде. Без монда Вилданов белән өстәмә мәгълүматлар җыябыз. Зиннәтеваны шәфкать туташы итеп җибәрсәк, ничек булыр икән?

— Сынап карарбыз. Тагын нindирәк фәрманнарың бар? — Айбулатни әйтергә белми дәшми торгач, майор дәвам итте: — Шаяртам. Министрлыктан полковник шалтыратты әле. Тагын күпмегә сузасыз, ди. Истә тотыгыз!

Байчурин икеләнеп Касыймга бер карап алгач, Нәҗибәне дә кисәтергә булды. Бәхетенә, кыз әле лабораториядән китеп өлгермәгән иде.

— Очрашу вакытын кичектерик әле. Эш муеннан, һич тә ташлап китәрлек түгел, — диде ул Нәҗибәгә.

— Син һәр вәгъдәсезлекне эшкә сылтарга яратасыңмы? — диде Нәҗибә.

— Хезмәтем шундый булгач, нәрсәгә сылтыйм бүтән? Һаман сездә кайнашабыз. Озаклап аңлатырга мәҗбүр итмә. Югыйсә, монда синең белән сөйләшкәнне егетләр әрекмән колакларын торгызып тыңлап торалар, — диде Байчурин, Вилдановка күз кысып. — Кайтканда кагыла чыгармын.

— Кайчан?

— Хәзергә әйтә алмыйм, көт.

Айбулат шушы сөйләшүдән Нәҗибәнең очрашуны түземсезләнеп көтүен сизеп алды. Бу аның күңелен кытыклап куйды. Хәзер үзләре язмышында җитди үзгәреш булырга мөмкинлеген ул бик ачык төшенде. Күңеле иләсләнеп, хыяллары талпынып, Айбулатны әллә кая әйди башлады. Тик ул, үзенең кайда икәнлегенә, нәрсә эшләргә җыенуына хисап биреп, татлы уйларны башыннан чыгарып ташларга мәҗбүр булды, чөнки шул чакны ишек ачылды һәм анда цех башлыгы күренде. Өлкән инспектор да трубканы колагыннан алды.

Алар мунчадагы кебек шкафлар тезелгән бүлмәгә керделәр. Душ ишеге ачык торганга, һава җылы һәм дымлы иде. Вилданов, ачкыч яратып, Гайнуллинның шкафын ачты. Инспекторлар төрле эш киемнәрен җентекләп карасалар да, үзләре теләгәнне таба алмадылар. Байчурин кул сөртә торган шаламаларны төргәге белән яктыга, тәрәзә төбенә бушатты. Аның эченнән слесарь ачкычлары һәм куен дәфтәре килеп чыкты.

— Абау, акча! — дип кычкырды таныкитеп чакырылган аппаратчы кыз. — Урын таба алмый аптыраган икән, бичара, шушында яшермәсә!

Айбулат бөгәрләнгән кәгазь акчаларны таслап санады һәм цех башлыгына сузды:

— Сез дә санагыз әле, — диде ул.

Ике йөз җитмеш тәңкә акча һәм куен дәфтәрен тентеп алу турында акт төзеделәр. Таныкларны җибәргәч, Айбулат куен дәфтәрен актара башлады.

— Касыйм, кара әле, монда саннар һәм исемнәр бар, — диде өлкән инспектор. — «Лена Кор. — 100, 150». Нәрсә аңлатуы мөмкин моның? Минемчә, я фототасма, я спиртны белдерә. Спирт булу ихтималы зуррак, чөнки мин авылда Габдуллинның йөз илле литр сатуын белдем. Әгәр шәһәрдә йөзне сатсалар?

— Габдуллин белән Җәмил Гайнуллин таныш микән соң? — диде Вилданов.

— Ачыклыйсы булыр, — дип җавап бирде Айбулат. Аннары ул цех башлыгыннан сорады: — Үнөченче цехта спирт кулланыламы?

— Кулланыла.

— Үзегезнең цехта «Лена Кор.» дигән кеше юкмы?

— Юк.

— Җәмил Гайнуллин турында яңа нәрсә өсти алмыйсызмы? Бәлки, фоторәсеме бардыр? — диде Байчурин.

— Демонстрациядә төшкәнне генә тапсак инде, — дип, цех башлыгы үз кабинетындагы шкафны актара башлады.

Бәйрәм колонналары алдында үндүртенче цех эшчеләрен гәүдәләндергән рәсемне кулга төшергәч, Айбулат:

— Ярдәмегез өчен рәхмәт! — дип, цех башлыгы белән саубуллашты.

Урамга чыккач, Касыйм Айбулатка:

— Җәмилнең куен дәфтәренә үнөченче цех аппаратчысы Лена Корнилова теркәлгән булырга тиеш, — дип, аның турында белгәннәрен сөйләп бирде.

— Ә нигә сиңа Лена белән әле генә эшкә кергән егет булып тагын бер күрешмәскә? — диде Байчурин көлемсерәп.
— Файдалы булырмы икән?
— Зыян да күрмәбез. Ә мин аңардан сорау алырмын.
— Бүген Лена беренче сменада эшләгән булырга тиеш. Иртәгә юлыксам гына инде.
— Аңа кадәр заводтагы бөтен «Лена Кор.»ларны эзләп табарга кирәк. Кызганыч, бүген инде кадрлар бүлегенә кагылырга соңга калдык,— диде Айбулат, сәгатенә карап. — Син хәзер, баш диспетчерга барып, спирт агызып алырлык цехларны белеш.
Өлкән инспектор Байчурин унөченче цехка кергәч инде бер мәртәбә Касыймга Корниловага күрергә ярдәм иткән технологны очратты.
— Менә бу егетне танымыйсызмы? — дип, Айбулат аңа фоторәсемдәге кешеләр арасыннан Җәмилне төртеп күрсәтте.
— Исемен әйтә алмыйм, йөзе таныш. Безнең цехка кергәне бар шикелле. Әйдәгез, бүтәннәрдән дә сорашыйк әле.
Фоторәсемне уңлап кеше карады. Арадан берничәсе Җәмил Гайнуллинны танып, аның күрше цехта эшләвен әйттеләр. Җыештыручы хатын исә моннан бер айлар элек үзе шаһит булган очрашуны сөйләде.
— Мин, җанаш, юынтык суны икенче каттагы эстакада баскычыннан гына чыгарып түгәм, — диде ул. — Яңгыр ява башлаган иде. Басылмасмы икән дип, чиләгемне идәнгә куеп, ишек яңагына сөялеп хәл алырга туктадым. Лена Корнилова аппаратлар тирәсендә әйләнгәләп йөри иде. Шул вакыт, җанаш, аргы ишектән юешләнеп беткән, озын буйлы бер ир-ат килеп керде, рәсемдәге — шул егет инде. Иелеп учы белән чәчләрен сыпырды, пыскак яңгыр җебетеп бетергән плащын салып какты да Ленага эндәште:
— Я, нәрсә карап каттың, матурым, сәлам! — диде.
— Мондый шыксыз кичне кем йөри икән дисәм, син икән. Ташкын агызып китмәдеме, Җәмил абый? — дип чытлыкланды кыз.
— Бездәй батырлар утта янмый, суда батмый. Тынычмы сездә? — дип, Җәмил дигәне күзләрен уйнатып алды. Мине күрмәделәр, җанаш.
— Әле искечә, — дип җавап бирде Лена.
— Ике бак алып килдем,— диде әлеге ир.— Өченче мәртәбә сугылуым инде, ялгыз очрамыйсың, ирегеп беттем. Хәзер тутырсаң, яңгыр астында лүрт-лүрт алып таярга уңай. Җитмеш бишәр литр салсаң, морадыңа ирешәсең — чем-кара тунлы да буласың, чатлама суыкларда да өшетми торган цигейка бүреклек тә сәрмая чыгар. Киеп алып, генерал хатыны төсле кукраеп йөрисең генә кала! Күзләрен челәйтеп тик карап калсыннар! — ди.
— Тунга кулда ике хак сорыйлар, — диде Лена. — Кибеттә эшнәлегем юк.
— Кысыр хәсрәт, матурым! Акча белән эшнә бул син, хирес җаннар үзе килеп таба аны. Озак кайнашма, һаваның рәте юкта сызып өлгерим, — ди әлеге Җәмил.
— Күп бит, шүрләтә. Лакка спирт агызмыйча булмас, — диде Лена.
— Шүрләмә, — дип көлде әлеге ир-ат. — Чимал цехыннан кудырганда үзләштерергә тырыш. Джерси пальто, ахак кашлы йөзек, яңа читекләр эченне тишмәгәндер ич? Кесәң юкарса, хәер сорап булмый, — диде егет. Аннары алар, җанаш, мыдыр-мыдыр сөйләшеп аргы баштагы ишеккә таба киттеләр.
— Бу турыда беркемгә дә әйтмәдегезме? — дип сорады Айбулат.
— Юк. Аларның нәрсәгә сузылганын да белмәдем ич. Үзең кыйшык юлда йөрмәгәч, бурлыкны уйламыйсың да! Янә шунысы да бар, мин су түгәргә ул юлдан йөрергә тиеш түгел. Күрсәләр әрлиләр.
— Соң алар нәрсәгә сузыласын әйтеп үк биргән ич инде! — диде өлкән инспектор Байчурин.

— И, жанаш, монда төрле-төрле майлар идәнгә дә саркып исраф була, юа-юа куллар калмый, — диде җыештыручы. — Аның ишене алып йөгерсәң, әләкләү була ич ул. Кеше чагып куштаннанырга яратмыйм. Актыктан талашып җилегеңә үтәрләр. Бәласеннән башаяк! Сораучысы да булмады.

Айбулат җыештыручы хатыннан Лена Корнилова белән Җәмил Гайнуллин сөйләшеп торган урынны күрсәтүен үтенде. Икенче катның лимондай сарыга буялган залында елан кебек бөргаланып колонналарны урап алган төрле төстәге торбаларга, манометр, винтель, шунт кебек прибор һәм җиһазларга карый-карый, өлкән инспектор спирт кабул итә торган цилиндрик аппарат янына килеп җитте һәм, җыештыручы раславы буенча, аны рәсемгә төшерде.

Хәзер инде Җәмил белән Зөбәер Габдуллин арасындагы элемтә дә ачылса, чылбырның барлык буыннары да спирт мәсьәләсендә бергә тоташа иде. Әгәр Зөбәернең туганы Шамил танса, дәлил өчен Вилдановны Җәмил Гайнуллин фоторәсеме белән Мари республикасына җибәрүдән башка юл юк, дип уйлады Айбулат. Тик бу сәфәрнең төп максатларына якынаю — көмеш каракларын табуга гына файдасы булмаячак. Димәк, кирәге дә шул кадәр генә!



*
* *

Уникенче больницаның баш врачы авыру Җәмил Гайнуллинның үзләрендә ятуын раслагач, инспектор Шәмсия Зиннәтева аңа монда килүенең төп максатын аңлатты һәм өстенә ак халат, башына ак калфак кигәч, чын шәфкать туташына охшап калды. Универмагта күреп хәтерендә калдырмаган булса ярар иде, дигән шөбһә белән палатага килеп кергәндә, Җәмил Гайнуллин калын гына бер китап укып ята иде. Шәмсия больницада тыелырга тиешле шөгыльне кисәтергә ашыкты:

— Бездә китап уку рөхсәт ителми.

— Операциядән чыкмаганнарга ярыйдыр ла инде ул, апасы? — диде Җәмил, уйнап сөйләшмәкче булып.

— Күп баш вату алҗыта. Сәламәтлегегезнең кадерен белсәгез, сез мине вәгазь укытып аптыратырга тиеш түгел. Җыеп куйыйм әле, савыгып чыкканда алырсыз.

Гайнуллин, бер як битен чокырайтып авызын ерды да, китабын мендәр астына куеп көйләде:

Күзкәйләрең кырыс карамасын,
Бер елмайчы, шәфкать туташы...

Палатадагы авырулар кызыксынып башларын күтәрә башлады. Тик Шәмсия Җәмил Гайнуллинның остарып торуына эреп төшмәде, егеткә, теләсә-теләмәсә дә, күнәргә туры килде. Китап Американың мәшһүр байлары Рокфеллерлар токымы турында иде. Шәмсиянең сәерсенүен абайлап, Җәмил аңлатып куйды:

— Тарихчы мин, апасы, кызыксынырга туры килә.

Шәмсия юри белмәгәнгә салышып:

— Мәктәптә укытасызмы? — дип сорады.

— Чамаладыгыз.

— Укытучы эшенә шундый кызыгам. Балалар белән мәш килү күңелледер ул?

— Класста, һич югы, мондагы төсле ис юк. Әмма укытучылар сезне бик үк тансыклап тормас иде, — диде Җәмил.

— Нишләп?

— Усал ич сез.

Шәмсия елмаеп палатадан чыгып китте. Авыруларга күчтәнәч ташучы кыз Гайнуллинга кагылышлы хәлләрдә нишләргә кирәклеге хакында кисәтелгән иде, менә хәзер ял итәргә дә мөмкин.

Кичке җиде тулганда Гайнуллинга да әйбер китерделәр. Шәмсия кәгазь капка тутырылган күчтәнәчне аулакка — баш врач кабинетына алып керде һәм иң аска тыгылган язуны актарып алды. Хатның актыгына «Талчыбык» дип имза куелган иде. «Талчыбык», Җәмилнең хәлен сорашканнан соң, алма сатарга Сәфи килгәнлеген, күрешеп сөйләшүләрен әйткән иде. «Базарыгызда алма күп икән, ди, кире алып кайтып как коярга уйлый. Монда сату акланмый, мин исәпләгән керемнең яртысы кеше кесәсендә кала, ди. Аңа товарын аэропортка илтергә булыштым. Ярдәм иткән өчен бүләк биреп, мине таксига утыртып җибәрде. Ул иртәгә очарга самолетка билет юнәткән. Кибетчене кулга алганнар. Нәрсә булганын белмим».

Татарларда очрамый торган Сәфи исеме генә игътибарны җәлеп итмәсә, хатта әһәмиятле нәрсә юк ич, дип уйлады Шәмсия. Хат авторының чын исемен куймавы да бераз сәеррәк. Сөйгән кызы шулай кылана микән? Әллә хат тулаем кинаяләп язылганмы? Кызганыч, фотоаппарат алмады. Әгәр бу хат дәлил сыйфатында кирәк булса?

Шәмсия кабинеттагы китап шкафының бер пыяласын чыгарып алып, хатны шуның өстенә җәеп салды да, аны ак кәгазь белән каплады. Өстәл лампасын кабызып, аны пыяланы астан яктыртырлык итеп, итәгенә урнаштырды. Ут яктысында хат юллары бер бит кәгазь аркылы да аерымачык укыла иде. Биш минуттан хатның күчермәсе әзер иде инде. Шәмсия, төп нәсхәне үзендә калдырып, Җәмилгә күчермәне бирдертте. Язу рәвешенең охшашлыгына шикләнмәскә мөмкин иде.

Хатка каршы Җәмил дә җавап язды. Ун минуттан бу хат та Шәмсия кулында иде инде. Инспектор аны кире биреп чыгарылган алмаларның берсе эченнән тапты. Бу юлы да баягыча күчермә алып, Шәмсия Зиннәтева адресатка әнә шул күчермәне тапшыртты. Җәмил язуында серле пәрдә күтәрелә төшкән иде. Шәмсия үзенең хәйлә-әмәленә канәгатьләнеп, Гайнуллин җавабын икенче кат укый башлады.

«Сәлам, Талчыбыккаем!

Әйбернең түгелми-чәчелми үз иясе белән китүе яхшы булган. Хәзер мин сөттән ак, судан пакь, курыкма. Кибетченең әләгүе генә каефне бозды. Ул тешләктән сер чыкмас, тик аны ничек тә коткарырга кирәк иде, иртәгә дә яшисе бар ич әле. Кибетче бата башласа мине дә төпкә сөйрәве мөмкин. Акча төртергә кирәк, котылгач исәпләшербез, югыйсә, аның артыннан йөрерлек бүтән кешесе юк. Акчага берсе сатылмаса, икенчесе кызыгыр. Инәсе үткәннең җебе үтә, бүләге үткәннең сүзе үтә, онытмагыз.

Зөбәерләр беленгән кадәресен үз өсләренә генә алсыннар, хәлләрен җиңеләйтергә тырышырбыз. Миңа санаторийга былтыргы якка путевка бирәчәкләр.

Кирәкле кешеләрне күреп кисәтеп чык әле: Җәмил бишесеннән алтысына каршы эшләмәде, кунакка барды, дисеннәр. Мотоцикл белән җизнәсе килеп алды, дисәләр дә була. Кунакта булучыларны да күрергә тырыш. Мин шуннан элегрәк бер төнге сменаны алмашып эшләгән идем, нечкәләп тормасалар, шуның белән саташтыру читен булмас. Бишесе көнне аның өчен бер иптәше чыкты, дип нык тору хәерле.

Зөбәер белән Җаббар абзый нәрсә сөйләделәр икән? Хатыннары белән күрештергәннәрме? Майсыз таба купмый, саранланмасыннар. Аларның нәрсә тангаңнарын белү белән миңа хәбәр китер. Тизрәк кайнаш. Рат урамына барып, шикле әйберләрне юк ит. Апаның үзенә күренмә. Уңны-сулны карап йөр, артыңнан иярмәсеннәр. Әгәр, Җәмилдән сорау алдык, фәлән диде, төгән диде дип ыскыртсалар, берәү дә ышанмасын.

Гыйшык тотуда, Талчыбыккаем, сиңа тулы ирек бирәм. Уңыш казануның бәя биреп бетергесез роль уйнарга мөмкин. Җаббар абзый хәлен беләсең, минем дә хәвефле. Тик чынлап мавыгып китмә, кара аны. Сәлам белән Җ. 8/Х.»

Һәр ике хатның да чуаланган төенне чишүдә уйнаячак ролен ачык төшенгән Зиннәтева җинаятьләрне ачу бүлекчәсенә ашыкты. Тик монда дежур инспектордан башка җан әсәре калмаган иде инде. Байчурин белән Вилдановның өйләренә шалтырату да файдасыз булып чыкты — алар әле кайтып җитмәгәннәр иде. Шәмсия берәрсен эзләп тапканчы ҖАБта утырырга исәп итте.

*

* *

Өлкән инспектор Байчурин үзе дә ҖАБка әле яңа гына килгән иде. Шәмсия кулга төшергән язулар аның арыганлыгын шундук оныттырды. Нәҗибә алдында ялганчы булып калуы борчыса да, Айбулат үзен бик тиз тынычландырды: соң булса да, барыбер керәп чыгар. Ә хәзер ашыгыч операция көтә. Хаҗиеваны кулга алынган хәлдә күреп гаҗәпләнсә һәм моңа ачуы чыкса да, Вилдановка сорау бирмәде, аны битәрләмәде, егетне баскыч төбендә торган машинага алып кереп, Шәмсия кулга төшергән хатларны гына укытты. Аннары:

— Хәзер аэропортка барып, алма дигән җимешне ачыкламакчы булам,— диде.— «Әйбернең түгелми-чәчелми үз иясе белән китүе яхшы булган. Хәзер мин сөттән ак, судан пакь», дип яза бит Гайнуллин. Алма ни өчен аңа күләгә төшерсен икән? Бик үк чиста түгел монда. Ябышып бетми, нәме. Ә син хәзер аның «Талчыбыг»ын эзләргә кереш. Теге вакытта Зиннәтева больницада Гайнуллинга язу китерүче «Талчыбык»ны күреп кала алмаган бит. Шуңа күрә хәзер Җәмилнең бөтен дусларын, туганнарын ачыкларга кирәк. Аерүча Рат урамындагысын. Рат дигән урам бармы икән? Белмим. Бәлки, Тар урамдыр? Саташтырыр өчен юри киресен язгандыр. Тар урам булса, ул базар артында. Белешергә кирәк. Анда ниндидер әйбер барлыгы аңлашыла, тентү ясарга туры киләчәк. «... шикле әйберләрне юк ит, апаның күзенә күренмә» дигән юлларга игътибар иттеңме?

— Курыккан нәрсәләре өйдә түгелдер, апасы өйгә кергәч күрми калмаячак ич!

— Менә шул шул. Абзармы, келәтме — тентүне шуннан башларга да була.

— Җәмилне кулга алырга да вакыттыр инде безгә? — диде Касыйм.

— Ярамый, кеше дәваланып ята. — Айбулат моны үтә житди төстә әйтте.

— Әгәр чыгып качса?

— Больница җитәкчелеге кисәтелгән. Шәмсия дә анда карачкы булып кына йөрми, күрәсең ич. Курортка җибәрүне, әлбәттә, тоткарларга туры килер.

— Аңа путевканы кая бирәләр? — дип кызыксынды Вилданов.

— Әзербәйҗанга. Ул анда Бадамлы курортында бер мәртәбә дәваланган инде, — диде Шәмсия.

— Я, мин кузгалам, — диде Айбулат. — Син дә тон дип торма, ярдәмчеләр ал да, хәзер үк кит.

Өлкән инспектор Байчурин Шәмсияне уникенче больницага илткәч, аэропортка юнәлде. Монда багаж җибәрү бүлегеннән:

— Иртәгә рейсларда кая да булса күпләп алма җибәрелмиме? — дип сорады.

— Бар андый товар, — диде почта хезмәткәре. — Берәү «Казанда очсызга сатып әрәм иткәнче, үзебезгә кире алып кайтып как коям» дип исәрләнгән, саллы гына багаж тапшырды.

— Кая адресланган?

— Әзербәйҗанга. Хәзер карыйбыз, ерак түгел ул. Өч сәгатьтән самолетка төяү башлана, — дип почта хезмәткәре Айбулатны посылка, чемодан, әрҗәләр төяп куелган арба янына алып килде. — Менә, Сәфи Абдуллаевка адресланган. Җибәрүчесе дә әллә үзе инде, Кавказ кешесенә охшаган иде. Фамилиясен генә үзгәртеп язды, ахры.

Айбулат Байчурин табыштан канәгатьләнеп:

— Менә, ичмаса, хәбәр! — диде үз-үзенә.

Әзербәйҗанны телгә алу аны яңадан армиядә бергә хезмәт иткән дусты Зыятдинны, чираттагы ялын сорап язган гаризасын искә төшерде. Күкрәк кесәсен капшап карагач, кыштырдаган кәгазе шунда йөрүен чамалады. Көмеш табылып, каракләр кулга алынса, Даниэль Соломонович, мөгаен, гаризага кул куяр. Авиапочта белән салган хатны Зыятдин, ихтимал, алгандыр да инде. Кунак каршыларга әзерләнәдер. Тизрәк фаш итәргә кирәк әрәм тамакларны, салкыннар башланганчы барып өлгерә ала әле ул.

Өлкән инспектор, таныклар чакырып, багажны ачтырып карарга булды. Өеп куелган әрҗәләрне фотога төшергәч, арадан берсен сак кына ачтылар. Кат-кат калын кәгазь белән капланган ышкы йомычкасы астына таслап фотокәгазь каплары салынган иде.

«Фотокәгазь» дип укыды гаҗәпләнгән багаж складı мөдире. — Менә сиңа кирәк булса, алма түгел ич бу! Әйтәм әрҗәләре җиңелрәк тоелган иде аны!!

Айбулат ачылган тартманы да фотога төшереп алды. Тагын берничәсен ачтылар, аларга фототасма салынган булып чыкты. Тартмаларның өчесенә төсле пленка тутырылган.

Ачылган әрҗәләрне кире кадаклап, «алма»ны тоткарлау турында акт яздылар. Айбулат аэропортка, финишка якынлашучы спортчы төсле, ашкынып килгән иде. Мондагы табыш исә өметен аклап җиткермәде. Шулай да чытырманлыкның үзәгенә инде ерак түгел шикелле. Канатланган өлкән инспектор Байчурин Сәфи Абдуллаев белән Җәмил Гайнуллинны кулга алырга рөхсәт юллау өчен прокурорны күрергә ашыкты. Чөнки ерактан килгән «кунак»ның биш-алты сәгать эчендә шәһәрдән китеп баруы мөмкин иде. Аэропорт кассасында аңа Сәфи Абдуллаев исеменә чираттагы рейска билет сатылуын хәбәр иттеләр.

Җылы. Яңгыр сибәли. Юеш асфальт май яккан таба кебек ялтырый. Анда күзгедәге кебек чагылган йортларның һәм агачларның соры шәүләләре артка йөгерә. Алар арасына бәлештәге йөзем кебек сибелгән якты ут-күзләр җемелди. Айбулатның, шул көмеш тимгелләргә карыйкарый, күзге төннең пыскак һавасын онытып, күңелле җыр җырлыйсы килде.

Күктә кояш, җирдә гөлләр,
Алда юллар, юлда мин.
Күктә нурлар, җирдә дуслар,
Дөнья матур, дөнья киң!..

Юл буенча ул хәтерендә калган бер үк сүзләрне кабат-кабат шыңшыды. Төнге сәгать унбер тулып килә, кичке аш тәмам онытылган иде.

Үз бүлекчәсенә кайтып җиткәч, Айбулат беренче нәүбәттә аэропортта арест салган фототасма белән фотокәгазь үрнәкләрен экспертизага җибәрергә әзерләде һәм Әзербәйҗанның җинаятьләрне ачу бүлекчәсенә Сәфи Абдуллаев турында мәгълүматлар җыеп җибәрүне үтенеп телеграмма сукты.

Ярты төн җиткәндә район прокурорының ишеген шакый иде инде ул. Татлы йокысыннан уятылган өлкән яшьләрдәге прокурор Байчурин биргән кәгазьләрне теләмичә генә алды.

— Иртәнге сәгатькә кадәр сабырың җитмәдеме? — диде ул. — Син инде кара төндә монда килүең белән үк Конституцияне бозасың. Хәтерењә киртләп куй: СССР гражданнары ял итәргә хокуклы! Менә хәзер куам да чыгарам үзеңне! Сезнең өчен дежур прокурор тоталар ләбаса...

— Мөхәммәтша абый, таң атканчы кошыбыз шәһәрдән очып китә ич,— диде Айбулат.— Сезнең бернинди кодексны да бозарга җөрьәт итмәвегезне нык ихтирам иткәнгә генә батырчылык кылдым.

— Чыпчык кебек чыркылдама әле.

Айбулат шып туктады. Прокурор барлык беркетмәләрне игътибар белән карап чыккач, Шәмсия алып кайткан хатка да күз салгач, башын күтәрде.

— Сәбәпләр җитә төсле. Тик мин, энекәем, өйдә хатынымның ире генә бит.

— Мөхәммәтша абый, машина аста көтеп тора. Сезне прокурор итә торган җиргә алып бара алам. Хатыныгыз бер төш күреп бетергәнче, китереп тә куярбыз. Әйтергә онытканмын икән, бер танышым турист булып сәяхәткә чыккач чит ил таңкаләрен алып кайткан. Бер көмешен миңа бирергә вәгъдә итте.

Прокурор таңкаләр җыю белән мавыга иде. Көмеш сүзен ишетү белән Айбулатка бик үк ышанып җитмәсә дә киенә башлады.

Бер сәгатьтән өлкән инспектор яңадан аэропортта иде инде. Бакуга самолет очарга ике сәгатьләп вакыт бар әле. Радио аша Сәфи Абдуллаевның дүртенче кассага килүен үтенделәр. Өстенә һава флоты костюмы һәм фуражкасын киеп өлгергән Айбулат Байчурин көттерми килеп җиткән Абдуллаевка:

— Бер урынга ике билет сатылган, дежур бүлмәсенә кереп ачыклыйк әле, — дип, аны үзе белән алып китте.

Зур карчыга борынлы, кара куе мыеклы, калын кашлы, таза гәүдәле Сәфи Абдуллаев бер ни сизенмәде. Калын сары свитеры өстеннән кигән буй-буй коңгырт сызыклы затлы, әмма юл йөргәнгә бөгәрләнеп, кыршылып беткән кара костюмын җилбәгәй җибәреп, күн итекләре белән дык-дык басып, өлкән инспектор артыннан күндәм генә атлады. Пассажирлар ыгы-зыгысы тынып бетмәгән вестибюльне узуга, Айбулат күз ачып йомганчы Сәфинең кулларына профессиональ осталык белән богау кидереп өлгерде. Милиция машинасы ишек төбендә үк торганга, «алма» сатучыга буза куптарырга да, кәҗәләнеп маташырга да вакыт тимәде. Машина кузгалып киткәч кенә ул исенә килде, тик, әлбәттә, соң иде инде. Шулай да Сәфи көтелмәгән хәлдән мие түнгән кеше ролен уйнаудан баш тартмады.

— Кадерләләрем, бу нә диян әмәк, нә эш? — диде ул әзербәйҗан сүзләрен татарча белән катнаштырып. — Талыйм дисәгез, кесәмдә пулым, сукыр бир гәпигем йух дияр идем, беш манат акчам калган икән. Дөшенмим, башыма даш илә ордыңызмыни!

Айбулат аңа прокурор санкциясен күрсәтте:

— Сабак булыр, моннан соң урманга утын ташымассыз.

— Алмага үзебездә дә урын күп безнең, неме.

— Нинди алма?

— Багаждагы.

— Кадерлем, сиз нәдир бутыйсыз, наһаг гаеп тагасыз. Мән алмаларымны колхоз базарында саттым. Квитанцияләре кесәмдә, сиз-саватлы киши, грамоталы, бахыңыз.

— Багаж сезгә адресланган, аны үзегез үк тапшыргансыз.

— Чох наһаг! Почта бланкларын бахыңыз, анда мәним әл булмаска лазым. Ким тапшырган, нә өчен мәним адреска — башыма сыймай!

Айбулат мондый ук әрсезлек көтмәгән иде. Әйе, шомарган таш күренә. Димәк, квитанцияләрне-бланкларны очраклы кешегә тутырткан.

Шәһәр тирән йокыга талган. Хәрәкәт тынган. Сәфи Абдуллаевны изоляторга ябып, машинада «Идел» кинотеатры турысына килеп җиткәндә сәгать дүртенче киткән иде. Монда ул тагын бер кешенең ишеген кагарга һәм, әгәр мөмкин булса, төннең калган өлешен шуларда уздырып чыгарга җыена иде.

*
* *

Айбулат кыңгырау төймәсенә кыяр-кыймас кына басты. Җавап ишетелмәгәч, катырак шалтырата башлады. Ниһаять:

— Хәзер, кем ул? — дип Нәҗибә тавыш бирде.

— Мин, Айбулат.

— Кергәч, коридорда гына торып тор, — диде кыз ишекне ачып.

Ул киенеп беткәнче Айбулат ванна ягына узып кулларын юды. Һәм чәчен тарады. Аннары элекке килүендә игътибар итмәгән бүлмәне күздән кичерде. Торшердан төшкән кызыл ут яктысында түр чаттагы роза гөленең яфраклары көзге урманны хәтерләтә иде. Буфет, диван, җыйнак кына өстәл, кәнәфи һәм берничә урындык. Идәнгә калын яшел келәм түшәлгән. Түрнең икенче чатында зур гына телевизор. Искитәрлек нәрсә юк, әмма бар да җитеш.

— Артык ашыкмадыңмы икән? — диде Нәҗибә сәгатькә күз салып.

— Сүз биргәч, үтәргә кирәк, дидем. Яңа гына бушадым әле.

— Шулай еш туры киләме? — Нәҗибә, дебет шәлен иңенә салып, кәнәфигә төшеп чумган Айбулат каршысына диванга утырды.

— Булгалый.

Хуҗа кыз буфет астыннан электр каминын сузылып алып кабызды. Әле ягу сезоны башланмаган, бүлмәдә салкынча иде. Кызгылт яктылык тагын да куера төште. Нәҗибә кынага бүген генә буялган чәчләрен әле хәзер генә тараган, алар дулкынланып тора иде. Өстенә ялтырап торган атластан тегелгән, төймәсез, биле пута белән генә буылган алсу халат кигән. Озын халат итәккә таба киңәеп төшкән, ул кызның болай да зифа буен тагын да сокландыргыч итеп күрсәтә. Халатының киң уелган изүе итәккә таба шулай ук киңәеп төшкән, әз генә яшькелт төсмерле ак ефәк төнге күлмәге күренде каминны тоташтырганда. Аягында соңгы елларда модага кергән кызыл бәрхеттән тегелгән чигүле татар башмагы. Кызның алсу йөзе, нәфис тукымалар аша беленеп торган күкрәкләре Айбулатны сихри көч белән үзенә тарта иде. Аларның ялгыз булуы, ресторанннан чыкканда Нәҗибәнең кунакка үзе чакыруы һәм хәзерге талгын тынлык, кызның нәрсәдер көткәндәй назланып утыруы Айбулатка бик күпне вәгъдә иткәндәй тоелды. Нәҗибәнең озын керфекләреннән күз төпләренә төшкән күләгә, буялган күперенке чәчләренең кызгылт яктылыкта җылы төскә коенып ялтыравы, чаттагы роза гөле куагының галәмәт куе тармаклары, декоратив тукымадан тегелгән тәрәзә пәрдәләре һәм алар арасыннан тар кайма булып кына күренеп торган ак тюль — монда барысы, барысы да искиткеч ямьле иде.

Айбулат костюмын салып коридордагы чөйгә элде дә Нәҗибәгә:

— Кибеткә керергә өлгерә алмадым, ишегеңне коры кул белән шакырга туры килде. Яңа гына ирешкән уңышны юсак та ярар иде, — диде.

Нәҗибә торып өстәлгә эскәтер җәйде, буфеттан юан корсаклы шешә чыгарды. Нечкә билле бокаллар, тозлы кыяр, икмәк, сыр белән лимонад та кунак алдына куелды.

— Эшләп аша әле! — дип ахырда кыз Айбулатка «Сайра» консервасы белән пәке сузды. — Сөйләп җибәр, нинди уңыш? Тагын берәр каракны тоттыгызмы?

— Урланган нәрсәне таптык. Тик бу турыда әлегә ләм-мим ычкындырырга ярамый. Сер!

— Миңа ышанмыйсыңмыни?

— Өч кеше белгән нәрсә сер түгел инде ул. Әлегә моны ЖАБта да икәү генә беләбез. Безнең киңәшәсе бар ич әле. Теге килбәтсез егет сине һаман яучылыймы?

Нәҗибә Айбулатның тупасрак эре гәүдәсенә, куе сумаладай чәчкашларына, киң маңгаена, җәенкерәк борынына бер күз ташлады да:

— Каян килгән матурлык патшасы! — дип пырхылдады. — Әзрәк якты чырай бирсәң, шушы егетләр үзләрен солтан итеп саный башлый! Шалтырый, шапырына...

— Болай ук мактарга сиңа җирлек бирмәдем төсле, — диде Айбулат. — Кара аны, сүз әзләп мин дә кесәгә кермәм.

Хуш исле кара ипи белән майлы сайра балыгы дөньядагы иң тәмле сый кебек тоелды. Айбулатның ләззәтләнеп ашавын күргәч, Нәҗибә:

— Шулпа җылытыйммы? — дип сорады.

— Юк, кирәкми, сый болай да мул монда. Күтәрәбезме? — дип, Айбулат эчемлеккә ымлады.

— Бүген эшкә барасым бар шул.

— Өченче сменага ич әле.

— Кирәкми. Кичтән көттем. Хәзер инде таң ата, баш миңгерәтүдән ни файда?

— Кунакка бик үк сөенмәдең, ахры. Шәрык халыкларында азыкны башта үзе авыз итә, аннан соң гына кешегә суза торган гадәт бар. Әллә оныттыңмы?

— Бүтәннәрне дә шулай кыстыйсыңмы? — диде Нәҗибә көлемсерәп. — Берәрсенең башын да әйләндерәсеңдер әле!

Айбулат гаҗәпләнеп Нәҗибәнең салкынаеп киткән чыраена карады, үртәлгән тавышына колак салды. Капкан сыныгын гына ничек кирәк алай чәйнәп йотты да, урындыгын арткарак этеп күчеп утырды.

— Юк, минем үз башым тизрәк әйләнә. Бервакыт шундый хәлгә төшергән идең инде, оныттыңмыни?

— Кайсы егет кызларга аның хәтле генә илтифат күрсәтми инде?

— Илтифат кына микән? — диде Айбулат. — Карурманга тартылган болыт сыман гел синең тирәңдә әйләндем. Санга сукмадың ич.

— Әйләнү генә булгандыр шул ул. Кеше вакытлыча гына мавыкмаса, дөрләп яна. Кызуы бүтәннәргә дә барып җитә.

— Яна-яна кисәү агачына калу кирәк идемени? Аннары кыскыч белән тотып суга тыгасы...

— Музыка тыңласак яхшырак булыр, — дип, Нәҗибә радиолага пластинка куйды.

Алар һәркайсы үз хыялларына чумып, Батыр Закировны тыңладылар. Алсу яктылык таралган бүлмәдә тел очларыннан тибрәп чыккан һинд җырының иркә авазлары, гарәп көенең дәртле аһәңнәре, итальян моңының йомшак дулкыннары диңгез кебек чайпалды. Моңның һәр бизәге, сүзнең һәр авазы хәзер икесе өчен дә аерым мәгънәгә ия иде.

Музыка тәэсирендә Нәҗибәнең дә кабара башлаган ачуы басылган булса кирәк, нәүмизләнеп утырган бокалын кулына алды һәм эчемлеккә авызын тидерде. Аннары көлемсерәп кунагына:

— Әйдә, без дә гашыйклар төсле кыланыйк инде, күтәр бокалыңны! Синең уңышны юмый булмас, — диде.

— Син тыйнак булгач, мин дә җыйнак булам, яныма да китермим хәмерне. Аңа хиреслегем зур түгел.

— Әдәпсез булсам, гадәтсезләнер идеңме?

— Кызык сез! Ягымлы сүзләр дә ишетәсегез килә, әйтә башласак, шик, икеләнү чиренә сабышасыз.

— Иблисләнүчеләр артык күп. Ә син шартына карап җайлашасыңмы? Каушап калмаска өйрәндеңме?

— Кеше ич мин. Дәртсез — дивана, гыйшыксыз — багана. Егетләргә килешә ул. Авыру булсам, елар идем, гашыйк булу сайрата. Тик юкка тынычсызланасың. Чакыруыңа да үкенәсең, ахры. Җимеш ашыйсы килгәнгә, чәчәкне өзү минем башыма да килгәне юк, кермәс тә.

Нәҗибә кызыксынып каш астыннан Айбулатка карады да шәрабен эчеп җибәрде. Айбулат та бокалын бушатты. Хуҗа аларны тагын тутырды. Аның карашы, сүзләр кылычын уйнатып алгач, сизелерлек ягымлылана төшкән иде. Айбулатка ул үсендеребрәк карый башлады. Бокаллар да, чәнечке-кашыклар да таныш юлда күбрәк урала башлады. Бүлмә һавасы да җылынарак төшкән сыман булды, Нәҗибә халатының путасын чишеп, аны диван аркасына атты.

— Син кайчандыр тиз ага идең, — диде ул. — Тау елгасы кебек. Тау елгасы сикерә-сикерә йөгереп диңгезгә төшеп югалган шикелле, тиз туктадың да. Синең файдага сөйләми ич бу. Уен, бары тик шаяру гына. Мин бу очракта җирәбәгә чыккан кыз булганмындыр?..

— Күз күреп тә буй җитмәсә, нишләргә кушар идең? — диде Айбулат.— Минемчә, үз гаебеңне тикшерсәң, кешенекен күрергә вакыт калмый.

— Үзең турында нәрсә дә булса сөйлә әле? — диде кыз назланып.— Мотор төзү заводыннан соң милиция. Кискен борылыш түгелме икән бу?

— Кешегә шулай тоелуы да мөмкин, — диде Айбулат. — Тик милициягә эшкә керүем бик үк гаҗәп нәрсә түгел. Бәлки торшерны сүндерербез? Каминнан да якты төшә ич.

Бүлмә тагын да караңгыланды. Айбулат галстугын чишеп кәнәфи аркасына элде. Электр камины һаваны мамыкландырып җибәргән иде. Ничә еллар буе хәтереннән чыкмаган, хыялында инде әллә нинди кыяфәтләргә кереп Айбулат белән бергә киләчәккә атлаган, төшләренә кереп йөдәткән Нәҗибә кул сузымы җирдә утыра иде. Төштәгедән аермалы буларак, тотыйм дисә, гаип булмаячак, ун елдан соң да, илле елдан соң да шушы төнге күрешү һәр икесенең күңелендә сакланачак. Әгәр бу гәп күгәрчен кебек гөрләшеп бергә яшәячәк гомернең оеткысы гамәлендә булса, Байчуринга нигә үз эченә бикләнергә яки кирәкмәгәнне сайрарга?

— Беләсеңме, — диде Айбулат, — кешенең үз-үзен саклау инстинкты шул кадәр көчле ки, ул беркемгә дә ахыргача бар дөньясын ачып салмый. Бәлки үзенең бик үк әүлия булмавын фаш итәсе килмидер, иеме? Алай дисәң, берәү дә камиллеккә ия түгел. Ояла, кыенсына дисәк, кай арада чамадан ашып тәртәдән чыга ич. Әллә үзен бизәбрәк, идеаллаштырыбрак күрсәтсә, җәмгыятьтә югарырак урын биләячәкме? Ләкин бу вакытлыча гына мөмкин. Шуңа карамастан, кеше рәхәтләнеп үзен булдыклы, намуслы, мөрәүвәтле герой рәвешендә таныта башлый. Мондый икейөзлелекне күралмыйм. Матур ялганга караганда аяусыз хакыйкатьне хуштрак саныйм.

Айбулатның бу сүзләре кызның бәгырен көйдереп алгандай булды. Нәрсә, белеп сукалыймы бу, кыек атып туры тидерәме? Айбулатның икейөзлелек турында искә алуы Нәҗибә хәтереннән икенче бер кешене калкытып чыгарды. Көяз мыеклы, дулкын чәчле, киң җилкәле егетне. Нәҗибә гадәттәге гамьсезлеге белән аңа киного чакырырга ирек куйды. Аккош күленә барып көймәдә йөзделәр, сәнгать музеенда рәсемнәрне тамаша итеп йөрделәр. Күңелен яулап алган егет белән гомер аяк басмаган стадионга футбол ярышын карарга да барды Нәҗибә. Аннары туган көн уздырдылар. Үзенең чибәрлегенә артык ышандымы, егетнең ихласлыгына ул шикләнмәде. Артыграгын да рөхсәт итте. Көннәрнең берендә исә егетнең өйләнгән ир-бала атасы булуын белде. Хурлану, нәфрәтләнү тойгыларын эченә йотса да, шуннан соң нык кына үзгәрде Нәҗибә. Кешедән мәкер эзли башлады. Үзе дә үчлегә әйләнде.

Моннан соң инде ул алдатмады, киресенчә, үзе алдарга өйрәнде. Тыштан исә көләч, уйнак кыз булып кала бирде.

Айбулат сүзләре аны беразга гына икеләндерде, аннары ышанычлы төстә ул үзен-үзе кулга алды.

Алар яңадан мәхәббәт турында сөйләшә башладылар. Нәҗибә табынга тагын бернечә сыра шешәсе һәм ликер алып килде.

— Бай яшисең! — диде Айбулат.

— Сый-хөрмәт — хуҗаның йөз аклыгы.

Айбулат Нәҗибәнең камин яктысында алсуга манылып күренгән муен, түшләренә, беленер-беленмәс сипкелләренә, сыгылмалы гәүдәсенә карап туя алмый иде. Кыз исә әллә чынлап та эсселәде, әллә инде егетне тәмам иласлэндерергә теләде — халат канатларын ачып ук җибәрде. Икенче шешәне башлаганга, Айбулат моны эчемлек галәмәте дип кабул итте. Егет үзе дә ярыйсы ук кызарга өлгергән иде инде.

— Нигә кешене тоттыгыз соң инде? — диде Нәҗибә Айбулат нәрсә җавап бирсә дә исе китмәячәген аңлаткан төстә.

— Шактый.

— Көмешкә компания белән кул сузганнармыни?

— Көмешкә генә түгел. Универмагтагы бер кош менә фототасма аркасында килеп капты.

— Сизәсеңме, без болай да күбрәк сүз белән мавыгабыз ич, — диде Нәҗибә, кунакчыл хуҗа роленә кереп. — Күтәрик!

— Минем нәрсәләр әйтә алачагым сина билгеле инде. Үзгәрмәдем. Син минем өчен дөньяда иң матур, иң акыллы, иң сөйкемле кыз!

Бүлмәгә тәрәзәдән якты шәүлә төшә башлаган иде инде. Егет сүзләре бокаллар чыңында күмелеп калды. Каминны сүндергәч, Айбулат кыз янына күчеп утырды. Дәү куллары белән аны кочып алды да кайнар сулышын Нәҗибәнеке белән кушты. Кыз зәгыйфь кенә каршылык күрсәтте дә Айбулат ихтыярына буйсынды. Егет моны мәхәббәтенә җавап бирү дип аңлады, йөрәге кысылды. Менә ул үзенә ни булганына хисап бирә алмый башлады. Нәҗибәнең маңгаен, муенын, иңбашларын үпте... Хуҗасыз калган радиоладагы пластинка уйналып бетеп, автомат туктагыч хәрәкәткә килми калганлыктан, чыжылдап әйләнә бирде...

*

* *

— Гайнуллиннар кая китте икән? — дип сорады Вилданов күрше картыннан.

— Җәмил дәваланам дип больницага кереп ятты. Сеңелесе өйдә торырга яратмый. Ата-аналары авылда аның, кунакка киткәннәр иде. Кеме буласыз соң, наный? Бер дә танымыйм үзегезне.

Сержант урамда калган, Касыйм үзе исә гади киемнән иде. Шуңа күрә кемлеген белгертмәскә булды. Бәлки Җәмилнең сеңелесе аңлы рәвештә өйдә утырмыйдыр? «Талчыбык» дигән бәндәкәй бәлки шулдыр? Димәк, абыйсы кисәткән, «кунаклар» килү мөмкинлеген белә. Тиешенчә әзерләнеп тә куйгандыр, тентесәләр дә берни тапмаслар. Хәзер дә Җәмил кушканнарны үтәп йөрүе мөмкин. Әгәр әлеге кардәшләренә дә Касыймнан алда барып өлгерсә?

— Миңа апасының адресын алу кирәк иде, — диде Касыйм. Рат ураммы, Тар ураммы шунда?

— Галиямә? Вахитов ыстансасы янында тора ул. Урамын белмим. Нигә әйткәне бар инде, истә калмаган, энем. Һе, һе, кара инде.

— Апасының фамилиясен әйтә алмассызмы соң? — дип эндәште тагын Касыйм.

— Юк, иренекенә күчте шул ул. Ире Хәсип атлы. Кранда эшли, елга портында. Үтә кече күңелле. Әмма Җәмил бик үз итми аларны.

Иөрешмиләр. Апасы әллә нигә бер анасының хәлен белешергә килеп китүен генә әйтмәсәң, бүпчи юк. Җизнәсе бик күркәм кеше үзе. Кем килде дип әйтим соң, оланкаем, үзләренә?

— Равил диярсез. Ярый, рәхмәт сезгә. Таба алмасам, яңадан әйләнермен әле.

Җәмилнең сеңелесен ректә калдыру хәтәр дип уйлады Вилданов. Ил кин, төннәр караңгы. Сержантны калдырып китәргә кирәк.

— Формадан булуың эшне боза бит әле, әллә кайдан күзгә бәрелә сең, — диде ул юлдашына. — Монда эш без уйлаганча барып чыкмады. Хуҗалар өйдә юк. Сиңа Җәмил Гайнуллин сеңелесенең кайтуын көтәргә туры килер. Бүлеккә озатырсың. Милиционер күргәч, син абайлаганчы ук өркеп койрыгын боруы бар, бер кырыйдан гына тәрәзәләренә ут алганны күзәтеп тор.

Касыйм Вилданов узгынчы машинага утырып яңадан милиция бүлегенә кайткач, сатучы Хәят Галиеваны сорау алырга чакырды. Көянтә кашлы көяз хатын зәңгәр күзләрен әле һаман һавалы ялтырата иде.

— Сез киреләнеп торган арада бик күп нәрсәне ачтык,— диде Касыйм аңа.— Инспектор Зиннәтевага Гайнуллинны «кавалерым гына» дигәнсез икән. Ә менә бу язу хәйләне кире кага бит.

Инспектор Вилданов Галиевага универмагта кулга төшерелгән хатны күрсәтте. Хәят корама кәгазьдәге язуны таныды. Сер бирмәскә тырышса да, бу аңа авыр тәэсир иткәнлеге сизелеп тора иде. Һушын алыр өчен Касыйм өстәде:

— Бу хатка каршы язган җавабыгыз да милициягә исән-имин килеп керде бит! Чынлыкта безне Гайнуллинның фототасма урлап универмагка китерүе, сезнең сатып торуыгыз бик үк кызыксындырмый да,— диде Касыйм бу фактның әһәмиятен юри киметеп. Бер-берсенә тоташкан кашларын уып, кысык күзләрен тагын да кыса төшеп, Хәятның буялган салам чәчләренә, лакланган тырнакларына карап алды да үзенең аңсызлыгы аркасында гына ятьмәгә кергән балык турында фикер йөрткән сыман дәвам итте: — Фототасма — чуртан янындагы ташбаш кына. Җәмил Гайнуллин заводтан бүтән асыл нәрсәләр урлаган, менә кайда ул чуртан! Моның өчен Җәмилкәең кызган табада куырылмый калмас! Әйе, әгәр юньле кавалер икән, нигә сезнең иминлекне кайгыртмаган соң ул?

Хәятның гаҗәпләнүе инде чыраена ук чыккан иде. Касыйм, дөрес юлга басуын сизеп, һөҗүмен көчәйтте:

— Үзе алны-артны карамый сызган, җан дусты теләсә нишләсен икән! Егет булarak әйтәм: сөйгән кызымны, мин булсам, упкын ярында ташлап калдырмас идем. Бәлки яратмыйдыр?

Инспектор Вилданов, Хәятка уйланырга вакыт биреп, туктап торды. Шул арада өстәл тартмасын актарып, Корниловаңың фоторәсемен алды да тавышын сер ачкан төсле әкренәйтеп:

— Менә бу чибәркәй — Лена исемле, — диде. — Җәмил белән бергә эшли. Гайнуллинның миңа ошаган бердәнбер ягы — кызлар сайлауда нечкә зәвыккә ия булуы. Көнләшәм. Сезгә дә ачкычны таба алган. Әгәр мин сезнең кебек чибәрне карата алсам, үземне җиде кат күккә ашкан кебек хис иткән булыр идем.

Хәят, көлемсерәп Касыймга бер генә күз салды да, фоторәсемгә төбәлде. Менә кем икән көндәшем дип уйлый иде ул үзенең беркатлылыгын битәрләп. Касыйм исә тартылган җәягә бушарга ирек бирмәде, ин ихлас тавыш белән, Хәятның уйларын алдан ук чамалап, яңа ук атты:

— Тик Җәмил бу матуркайга да өйләнмәячәк!

Галиева башын күтәреп Вилдановка карады.

— Тагын да асылрак кошка — бер инженерга күз салып йөри ул. Бүген ул кыз да юкка чыккан. Асыл мал саткан акчаны кесәгә тутырып, бергәләп качканнар, ахры. Бәлки әле ерак та китмәгәннәрдер,

Җәмилнең Вахитов станциясе ягындагы апаларында качып яталардыр? Адреслары ничек әле?

Яцаклары бурлаттай кызарып чыккан Галиева:

— Арт урамда. Йорты исемдә калмаган, егерме дүртме, утыз дүртме шунда, — дип ярып салды.

Ашыга-ашыга беркетмә яза башлаган Вилданов аптыраган төстә башын күтәрде дә янә бер сорау бирде:

— Әгәр Гайнуллин асыл малдан килгән сәмәнне фототасма сатудан җыелган сумма дисә, нишләрбез икән?

— Андый малны зур суммага чәлдергән дисез түгелме соң?

— Хәйран гына сыптырган, — дип раслады инспектор.

— Мин ана мең ярымлык кына сатып бирдем ич.

Касыйм:

— Ә-ә-ә, әйе шул,— дигәләп, шуны да белештермәвенә кәефе киткәндәй башын селкеде.

Инспектор Вилданов Идел буе районындагы участок инспекторы белән, буяулы капкалары, өй кыеклары, челтәрле кәрнизләре һәм шәһәр өчен сәеррәк булган тынлыгы белән авылны хәтерләткән урамга барып керделәр. Хәят сүзе буенча башта егерме дүртенче өйнең капкасын шакыдылар. Хуҗа кранчы Хәсипнең йортын күрсәтә башлагач, Вилданов аның үзенең дә баруын үтенде. Пүнәтәй сыйфатында тагын бер кешене чакырып, Җәмилнең хатында телгә алынган апасы өенә килеп керделәр. Телевизор алдында утырган Хәсип белән Галиягә Касыйм:

— Сезнең келәтме, абзармы бар, ахры, шуны карап чыкмый булмас, — диде.

— Анда тавыклар гына ич безнең, — диде Галия. — Бер ягында утын, башны да тыгарлык түгел.

— Җәмил кайниш белән дуслык та чамалы, житмәсә, — дип өстәде хуҗа. — Ул да безне урап уза, без дә еш барып йөдәтмибез.

— Нишләп алай? Якын туганнар ич сез.

— Характерлар туры килми, — дип елмайды Хәсип. — Икебезнең дә үз туксаны туксан. Аның белән сөйләшергә белемем житеп бетмәсә, кирелегем бәрәкәтле. Кайнишнең мона җене чыга!

Утынлыкка чыннан да борын тыгарлык түгел иде. Утны яндыруга тавык кетәгендә дәррәү ыгы-зыгы купты. Вакытсыз бәреп кергән әрсез кунаклардан коты алынган көзге чебешләр кунакчадан очып төшкәч, тузан күтәрелде, дуамал этәч ду кытаклый башлады. Тынычлыкларын бозарга бернинди нигез күрмәгән хуҗалар да кетәкне тикшермәкче булган Касыймны өнәмәде:

— Монда тавык тизәгеннән гайре берни юк, буялып кына бетәрсез, — дип кисәттеләр.

— Теге сандыкта нәрсә ул? — дип сорады Вилданов.

— Чебешләргә алган фураж.

— Сандыкны бушатып карарбыз. Ишегалдына җәяргә бирәр нәрсә юкмы?

Кәефе кырылган Галия өйдән полиэтилен җәймә алып чыкты. Сандыкны шуның өстенә аудардылар. Аның төбеннән ике йозак белән бер дерматин капчык килеп чыкты.

— Боларын да тавык ашыймы?

Таныклар да, Галия белән Хәсип тә гаҗәпләнә калганнар иде.

— Беренче тапкыр күрәм, — диде Галия. — Фураж капчыгында килде микән ни? Сандыкка бушатканда абайламадым боларны.

— Алар абага чәчәге кабып йоткан булган, — дип шаяртты Касыйм. — Шуңа күренмәгәннәр. Өегездә дә шулай берәр нәрсә мутланып посып ятмасын. Бу арада гына Җәмил килгәне юкмы?

— Юк.

— Кунак җыйганыгыз да юкмы?

— Бар, — диде Хәсип. — Җәмил минем мотоциклга утырып килергә дә чыккан иде дә, әмма, ниндидер эше искә төшкәч, юлда кире борылды.

— Кайчан булды бу?

— Сентябрь азакларында.

— Менә нәрсә,— диде Касыйм.— Өегездә тентү ясап тормыйм, намуслы кешеләр булуыгызга ышанам. Әмма үзегез бүген бар җирегезне карап чыгыгыз. Җәмилнең йөзегезне кызартырлык тагын бер кучтәнәче табылса, менә шушы телефон буенча безгә хәбәр итәрсез. Мәшәкатьләгән өчен гафу үтенәм. Күрәсез, бушка гына түгел үзе.

Касыйм йозакка һәм дерматин капчыкка акт төзеп, таныклардан кул куйдырткач, өенә кайтырга булды. Җәмилнең күршесе сүзләрен искә алып, Хәсипнең квартирын тентемәскә булды ул. Белеп һәм дөрес әйткән булырга тиеш. Ә хәзер капчыкны продукция төрү цехындагыларга, йозакларны җыештыручы Алексеевага күрсәтергә кирәк. Тик Касыйм моны иртәгәгә калдырды.

*

* *

Айбулат Байчурин кояшның беренче нурлары җир өстенә төшкәч кенә күзләрен йомды, әмма йокыга китә алмады. Үз тормышында тагын бер бик әһәмиятле борылыш ясалды дип уйлады ул. Нәҗибәнең маңгаеннан тагын бер үпте дә, аны уятмаска тырышып, сак кына торды һәм юынырга китте. Краннан кайнар су ага башлагач, кинәт ниятен үзгәртеп, ваннада коенырга булды. Җылы суга муеннан күмелеп кереп ятты да рәхәтлектән кинәнеп күзләрен йомды. Шәплеге тиңсез иде! Ылыслы сабын, мунчала да, чиста сөлге дә кул астында гына. Вакыты да иркенрәк булсачы! Әмма сәгать, ярышка чыккан спортчы кебек, алга кызу чаба иде. Бераздан Айбулат, яңа туган бала кебек җиңеләеп, ваннадан чыкты.

Аның бу чупылдатуына Нәҗибә дә уянган иде.

— Син бөтенләй үз өеңдәге кебек, — диде ул көлемсерәп.

— Сәерме?

— Әйе, — диде Нәҗибә назлы караш белән. — Чәйлисеңме?

— Ашыгам. Эш арасында берәр җиргә керермен әле. Я, мин киттем. Барасы җирең юктыр ич? — Нәҗибәнең сораулы карашын күреп, Айбулат аңлатып куйды: — Әгәр бер-ике сәгатькә бушый алсам, яңадан әйләнеп килмәкче булам. Загска гариза илтеп бирер идек?

— Эштән бүген генә кайттың ич әле. Төнге дүрттә генә. Бармасаң да ярыйдыр, ял итәргә хакың юкмыни?

Әйе, өлкән инспектор Байчуринның да башкалар шикелле эштән соң ял итәргә хокукы бар иде. Нәҗибәнең бәлки, бүгенге көнне бергә үткәрәсе, әллә кайларга чыгып китәсе киләдер. Мондый гадәти булмаган төннән соң бар дөньяны онытып сәхрә чигеп йөрүгә ни җитә? Яшь ич әле алар, берәүләр әле олыгайгач та, гадәти ял көннәрендә дә берсен дә калдырмый. Мари урманнарына кадәр барып җитәләр, кәрзинкәрзин җиләк, тырыс тутырып гөмбәсен дә җыеп кайталар. Үпкә киереп саф һаваны бер сулавы ни тора! Айбулат исә башка вакытта да моның берсенә дә өлгерми. Эш сәгате нормаланмаган. Еш кына төнгә калып та кайта. Чөнки гадәти генә хезмәт түгел аның. Эшченең эш сәгате станогы янына килеп баскач, бухгалтерныкы — өстәле артына килеп утыргач кына башлана. Ә милиционерныкы — үз фатирыннан чыккач ук.

Менә хәзер дә, Нәҗибә тәкъдименә бик колак саласы килсә дә, инспектор гашыйк егет омтылышын җиңеп чыкты.

— Бүген ярамый,— диде ул.— Көмеш «Эш»ен ябыйк инде.

— Әллә баш каракны да кулга төшердегезме?

— Бүген кулга алырбыз, ахры. Безнең күзәтү астында, ышанычлы жирдә утыра ул.

Нәжибә чәч тараган жиреннән Айбулатны күзәтә иде. Җавабын ишеткәч, иренено кыстырган брошкасын алды да йөзен егетенә таба борып:

— Чынлапмы?— дип сузды. Чәче белән эшен бетергәч, әйтергәме, юкмы дигән кебегрәк кыяфәттә уйланып торды да, дәвам итте:— Беләсеңме, әти безнең өйләнешүебезгә ризалык биргәнче, бер шарт куячак бит. Үти алырсыңмы икән?

— Синеңчә, үтәргә кирәкме?

— Әйе. Бу аның өчен хәлиткеч нәрсә. Бәлки безнең өчен дә шулайдыр. Мин аның бердәнбер үтенечен кире кага алмыйм. Я болай, я тегеләй, диячәк ул.

— Булачак кайнатаның ихтыярына каршы килеп булмас, алайса,— диде Айбулат елмаеп.— Тик без конкретрак итеп мин өйләнеп килгәч сөйләшербез, ярыймы?

— Ярар.

Айбулат кулын чигәсенә куеп баш иде дә бүлмәдән чыгып китте. Көнчыгыш як болытлар белән капланган, әмма аның уртасындагы ачыклыктан тансык нурлар көлтәсе жиргә коела иде. Кичкә таба жил чыгар, куәтле яңгыр булыр, ахры, дип уйлады Байчурин.

Милиция бүлегенә ул көндәгедән бераз соңрак, әмма барыбер эш сәгате башланганчы ук килеп житте.

— Сезне тагын бер уныш белән котларга мөмкин дип ишеттем,— диде майор Айбулатны күрүгә.— Нишләп өйгә хәбәр итмәдегез?

— Соң иде, Даниэль Соломонович. Уңайсызландым.

— Көймәң комга терәлә башласа, соң дип тормыйсың тагын. Ярар, ярар, акланма,— диде ул сүз кыстырырга талпынган Айбулатны туктатып.— Вилданов та авызына су капканмыни, дөньяда барлыгын да белгертми. Мәшәкате бергә, туе аерым, кара син бу акыллы башларны!

Юрамалый кыздыруына караганда, майор Винерның күңеле күтәренке иде. Айбулат аңа төнлә соң гына тәмамланган операциянең нәтиҗәләрен сөйләп бирде.

— Степан Муллин чималны кайдан алганлыгын да белдегезме?

— Юк әле,— диде Айбулат.

— Аңа килә торган хат-хәбәрләргә арест салдырган идем. Нәрсәдер жибәргәннәр, киңәшмәдән соң почтага барып кара.— ЖАБ башлыгы кабинетына инспекторлар җыйнала башлады. Иртәнге биш минутлык якынлашып килә иде.

— Ярар, дәвам итегез,— диде Винер Айбулатка.— Бүген Сафиуллинга керәсебез бар. Мин аңа соңгы уңышлар турында доклад биреп чыгыйм әле. Министрлыкка шалтырату да зыян итмәс, полковник вәгъдәдә торганны ярата.

Винер житез хәрәкәт белән соры костюмын сыпыргалап бүлмәдән чыгып китте. Беравыктан аның тавышы Сафиуллин кабинетында яңгырый иде инде.

— Иптәш подполковник, булдыра егетләр,— дип, Винер соңгы нәтиҗәләрне санап чыкты.— Үзегез беләсез, бу арада мин әле монда, әле тегендә, әле министрлыкта мәшәкатьләнеп йөреп, көмешчеләрне эзләүдә юньләп катнашмадым. Җинаятьне өлкән инспектор Байчурин оператив төркеме тикшерә. Шулай итеп Байчурин тагын бер кат үзенең каты төеннәрне дә чишәргә сәләтле икәнлеген раслады. Тәҗрибәле, сабыр, төптән уйлый. Кандидатура дөрес сайланган дип әйтәсем килә.

— Вакытында ерып чыксалар, Байчурин белән Вилдановның икесен бүләккә тәкъдим итәрбез. Министрлык фондыннан. Тик Байчурин

салмаграк егет, ахры, миңа күләгәсен дә күрсәтмәде, киңәшеп эшләргә яратмый дип әйтикме?

— Юк, юк, иптәш подполковник,— дип каршы төште Винер.— Ул просто яхшы атланып йөрүне сөйми. Шуның өстенә, субординация сакларга да ярата. Миннән узып кирәсе килмәгәндер. Бу начар гадәтмени?

— Хәйләкәрлек сездә, Даниэль Соломонович!— дип елмайды Сафиуллин.— Биш кешегә җитәрлек!!

— Бәлки аны вакытлыча дип түгел, бөтенләйгә билгеләргәдер? — диде Винер киңәшкән төстә.— Байчурин чын мәгънәсендә эзләре суынганчы ук җинаять арты җинаять ачып кына тора.

— Яшьрәк түгелме?

— Акыл сакал чыкканны көтми.

— Уйлашырбыз. Соңрак бергә керегез.

Киңәшмә тәмамлануга Айбулат Винер әйткән почта бүлегенә юл тотты. Декабристлар урамында хәрәкәтнең кызган чагы иде: машиналар икешәр сафка тезелеп чаба. Байчурин комташ, кирпеч төягән үзбушаткычларны, троллейбус, автобусларны уза алмый аптырады. Трампаркка җиткәч кенә машиналар ташкыны икегә аерылды — яртысы тегермән ягына таба, сулга борылды. Айбулат җиңел сулап тизлекне арттыра төште, бүлектә буш машина торганга, рульгә үзе генә утырган иде. Асфальтка сумала эремәсендәге вак таш сибелгәнгә, тәгәрмәчләр күңелле шыбырдап тәгәри, юлның ике ягы буйлап тезелгән биек-биек тирәкләр, усаклар тоташ яшел агым булып артка йөгерә. Менә трамвай юлы да артта калды, бер катлы авылча өйләр башланды. Ниһаять, менә ул зур таш йортның бер почмагын биләгән почта бүлеге.

Степан Муллинга адресланган хаттан Айбулат ике гадәттән тыш нәрсә тапты: беренчедән, хат чамадан тыш кыска; икенчедән, аның авторы адресны башка кешедән тутырткан.

Машинасына чыгып утыргач, Айбулат берничә генә юлдан торган хатны ике-өч тапкыр әйләндереп-тулгандырып карады. Кайбер хәрефләре таныш та кебек үзе. Кем язуына охшаган соң ул?

«Степан абый!

Бурычыңны без әлек сөйләшкән җиргә шушы шимбәдә үк китереп бир әле. Озаграк көтәргә чама юк, янам. Сәлам белән артист дустың... 7/X. Хуш.»

Сырланган имзасын һич тә танырлык түгел иде.

Майор Винер киңәшен истә тоткан Айбулат Степан Муллин өендә янадан тентү ясарга карар бирде. Өлкән инспектор бу юлы бүлмәләрне дә, инде бер мәртәбә тентегән келәтне, утын әвеслеген дә ашыкмыйча карады. Чормаларына менеп төште, идән асларына күз салды, бакчаларын айкап чыкты, стеналарына каккалап колак салды. Тик күпме генә жентекләп казынса да, һичнинди химикат, хат-мазар таба алмады.

Иң ахырда аның кулына фотоальбом килеп эләкте. Башта ук шуңа игътибар итмәвенә гаҗәпләнеп, Байчурин һәр рәсемне озаклап күздән кичерде, төркемләп төшкәннәрне хәтта лупа белән дә карады. Арадан берсе аны сөендерә куйды. Завод идарәсе алдындагы эскәмиягә биш ир кеше кысылышып утырганнар. Степан янәшәсендә генә Җаббар Гыйбадуллинның тутырган тавык кебек тулы йөзе балкып тора иде!

Муллинның өйдә очраган кызы Айбулат әле яңа гына почтадан алып чыккан хатның кемнән булуын да, фоторәсемдәге кешеләрне дә белмим дип җавап бирде. Байчурин фоторәсемне милиция бүлегенә алып кайтты.

Үз кабинетына килеп керү белән Айбулат инде байтактан җыйналган беркетмә, экспертиза белешмәләрен, фоторәсемнәр, хатларны тәр-

типкә китерергә тотынды. Бу эшкә ул почтадан алып кайткан хат почеркына охшаш язуны табу өмете белән керешкән иде. Больницадан Җәмил Гайнуллин язган хатны лупа белән аеруча озак карады. Ике хатның язу рәвешләре бер-берсенә охшаган да, юк та төсле тоелды. Өлкән инспектор аларны һәм Зөбәер Габдуллин, каравылчы Җаббар Гыйбадуллин, сатучы Хәят Галиеваларның язу үрнәкләрен дә алып, эксперт белән киңәшергә китте.

Эчке эшләр бүлегенә кайтуга, Айбулат изоляторда ятып зарыккан Степан Муллинны кабинетына чакыртып алды. Уртачадан калкурак буйлы, коңгырт чәчле, очлы иякле картның озынча йөзе суырыла төшкән кебек иде. Коңгырт сакал-мыегы да тәртеп чыгарга өлгергән. Тупас тукымадан тегелгән кара зәңгәр чалбары, вак шакмаклы соры күлмәге тагын да бөгәрләнә төшкән.

— Көмеш китерәсе егетне тагын бер тасвирлагыз әле?— диде аңа Айбулат.

— Егерме-егерме өч яшьләрдә булу кирәк. Уртача буйлы, ябык. Кара тутлы, кылыч борынлы. Уң күз төбендә миңе бар.

— Иреннәре, тавышы, ияге нинди?

— Ирене юка, тавышы нечкә сыман.

— Нәрсә кигән иде?

— Соры кримплен костюмнан булса кирәк.

Айбулат Степан Муллинның юри чыңга ялганны кушып тасвирлавын сизеп алды. Озак гәпләшергә вакыты юк иде, шуңа күрә ул карталарын ачып уйнарга булды.

— Егетнең калын иренле, ак чырайлы, матур тавышлы булуын беләсез ич. Битендә миң-фәләннең заты юк. Артист кебек чибәр. Юри буташтырып утыруыгызны суд хөкем иткәндә искә алачак. Зыяны кемгә тияр? Уйлагыз.

Байчурин инде берничә том төпләрлек булып җыелган документлар арасыннан ике хатны өстәл өстенә чыгарып куйды.

— Акчаны нигә товарны алгач ук түләмәдегез?— диде карашы белән Муллинны бораулап.

— Китермәде әле.— Муллин төксе генә сакал-мыегын капшап куйды.

— Бәлки «артист» үз гаебен күптән таныгандыр инде. Ә сез, абзыкаем, яшергән булып, үзегезгә баз казып утырасыз. Адрес бирүегезне дә әйтмәдегез. Ул мескен Степан абыйсына тилмереп язып ятты!— дип, Айбулат эксперт тикшергән хатларны Муллинга күрсәтте.— Монда кулын үзгәртеп маташкан.

Гайнуллинның хатын һәм эксперт актын укыгач, Степан Муллин мәче-тычкан уенын дәвам итүдән баш тартырга мәҗбүр булды.

— Мине аның белән Җаббар Гыйбадуллин таныштырды, Җаббарны заводта эшләгән чактан бирле белә идем,— дип, Гайнуллин турында белгәннәрен сөйли башлады.

Көзгече Степан Муллиннан сорау алу беркетмәсен илләре янына тегеп ятканда, бүлмәгә Касыйм килеп керде һәм исәнләшкәч:

— Менә, тагын да яңаракларын алып кайттым,— дип, берничә беркетмә һәм акт сузды.— Беләсеңме, Гайнуллин артыграк бөгеп ташлаган бит! «Тар урам» дип язган булса, без аңа бәлки ышаныр һәм шул тирәне капшап азапланыр идек. Артык бөксәң, таяк та сына. Аның да хәйләсе эшкә ашмады. Шикләндек тә таптык. Арт урам икән! Апаларында тентү ясадым, ике йозак белән бер дерматин капчык таптым. Төрү цехында капчыкны таныдылар. Йозакларны Алексеева көмеш секциясенеке дип раслады.

— Йозакларда бармак эзләре юк идеме?

— Юк.

— Йозак кына эшне хәл итми,— диде Касыйм төксе генә.— Ачыклыйсы бар әле...

Айбулат бик сирәк, аеруча дулкынланган, эче пошкан һәм борчылган чакларда гына тарта иде. Менә хәзер дә ул папирос кабызды, аннары телефоннан Уфага шалтыратты. Күрше республика җинаятьләрне ачу бүлекчәсенең инде Байчуринга таныш инспекторы сөйләшә башлады:

— Техник фәннәр кандидаты Рәфикъ Гатауллинны күреп аңлаштык. Ул Казанда яшәүче Гайния Хаҗиеваны яхшы белә. Яраткан кешесе икән. Тик моннан ун ел чамасы элек һәлакәткә очравы аркасында, аңа өйләнә алмаган. Бүтән берәү белән тормыш корырга мәҗбүр булган. Алло, мине ишетәсезме?

— Ие, ие, дәвам итегез,— диде Айбулат.

— Хаҗиеваның баласы тууын белгәч үк, аңа ярдәм итәргә карар биргән һәм ай саен иллешәр тәңкә җибәреп тора башлаган. Гатауллиннар кысынкы яшәми, шуңа күрә юмартлыгы бик гаҗәп түгел. Гайнияне яраткан, әле дә ярата, әмма бер гаилә коргач, аны җимерергә базмаган. Гатауллин баланың үзеннән булмаска мөмкинлеген дә истә тота, тик бу аның Хаҗиевага карата җылы мөнәсәбәтен үзгәртмәгән. Рәфикъ моннан тугыз ел элек Казанга барып килгән, Гайния белән дә күрешкән. Бәлки алар аннан соң да очрашкалап торганнардыр, Гатауллин барысын да әйтеп бетермәскә дә мөмкин. Сорау алу беркетмәсен авиапочта белән җибәрербез, үзегез карарсыз. Канәгатьләндермәсә, шалтыратырсыз. Тагын ачыкларбыз. Рәфикъ Гатауллин ышанычлы кеше. Хаҗиевага бернинди дәгъвасы юк. Хәтта аның өчен борчыла да башлады төсле.

— Рәхмәт. Безне бер мәшәкатьле бәладән коткардыгыз,— диде Айбулат һәм канәгатьләнгән төстә трубканы куйды.

Шул чак кабинетка майор Винер башын тыгып карады да бусаганы атлап узды:

— Ә-ә-ә, югалган кеше пәйда булган,— диде ул Касыймны күреп.

— Вилданов көмеш эшен ачыклый торган дәлил алып кайткан.— диде Айбулат.— Йозакларны тапкан да, таныткан да.

— Булдырган, котлыйм. Байчурин, әйдә, Сафиуллин көтә безне.

— Лена Корнилова белән нишлим, аны күрә алмадым бит әле,— диде Касыйм чыгарга кузгалган Айбулатка.

— Кулга алырбыз. Хәзер спектакль куюо кирәкмәс инде. Аннары Гайнуллинны дару исләре иснәүдән коткарырга барырбыз. «Исле монда»,— дип зарлана икән.

*
* *

Майор Винер белән Айбулат Байчурин килеп кергәндә подполковник Сафиуллин шәһәр картасын карап тора иде.

— Утырыгыз,— диде ул, үзе дә әйләнмәле урындыгына килеп урнашкач. Винерга карап көлемсерәде дә әйтте:— Конвой астында алып кердеңме егетне? Без аңа нинди җаваплы эш тапшырдык, ник бер отчет биреп чыксын Байчурин.

Подполковникның болай да түгәрәк йөзе бер мәлгә генә тагын җәелеп алды, аннары ул җитдиләнеп Айбулатка күз йөгертте дә, галстугын бушатты, көлсу төс керә башлаган чәчләрен тарады һәм, сөйли башлавыгызны көтәм дигән сыман, кеҗүчеләргә баш какты.

— Мин Даниэль Соломонович сезгә доклад биреп барадыр, дип уйлыйм,— диде Айбулат акланып.

— Әйе, ул кыскача таныштырды. Дәлилләр ышанычлымы соң?

— Шиксез. Кичә Касыйм көмеш секциясенең йозакларын да табып кайтты.

— Өметле егет, алайса, Вилданов?— дип сорады подполковник.— Әле яңа гына эшли башлаган кеше өчен начар түгел, ә? Алмаш үсә, димәк?

Сафиуллин бу сүзләрне Винерга карап әйткәнлектән, Айбулат дәшмәде. Әмма подполковникның аның фикерен дә беләсе килгән икән.

— Ничек уйлыйсың, әйбәт инспектор чыгармы Вилдановтан, иптәш Байчурин?

— Әрсезлеге бар, чыгарга тиеш.

Сафиуллин әйләнмәле урындыгының терсәкләренә таянып бер уңга, бер сулга борылгалап тирбәлеп алды да тагын Айбулатка карады.

— Сезнең бүлекчәдә булдыклы кадрлар үсеп чыкса, шатлык эчкә сыймас иде,— диде ул.— Тәҗрибә җыйганнары китә менә. Сез көмеш геройларын эзләп мәш килгәндә, Даниэль Соломонович безнең белән кендеген өзеп бетерә язды. Оча сөекле начальнигыгыз!

Айбулат өчен бу хәбәр аяз көнне күк күкрәү кебек яңалык иде. Сигез елдан бирле белә ул майор Винерны. Шуның бишесен турыдан-туры аның кул астында хезмәт итте. Кызу канлылыгы бар. Әмма кызып китсә дә, сүгенә белми үзе, ачу кумый. Тәҗрибәсен юмарт уртаклашты, инспекторларын куркыныч астына куюдан уттан сакланган кебек сакланды...

— Кая оча?— диде Айбулат әле Сафиуллинга, әле Винерга карап.

— Билгеле инде, кошлар төсле җылы якка түгел,— дип көлде подполковник.— Бүтән шәһәргә күчә Даниэль Соломонович. Тагын да җаваплырак хезмәткә. Үз урынына менә сине куярга тәкъдим итте. Ничек соң, башкарып чыгып булырмы?

«Уйнап әйтәме, чынлапмы?» — дип уйлады Айбулат тагын да көтелмәгәнрәк тәкъдимгә аптырап. Район кадәр районга җавап бирү турында бара ич сүз. Җитмәсә, исеме район гына булса да, күрше республикаларның башкалаларыннан да зуррак бит ул, халкы да шактый күбрәк. Нигә инде шаярткан булып, кешене уңайсыз хәлгә куярга?

— Даниэль Соломоновичка ышанычы өчен рәхмәт,— диде Айбулат.— Тик бездә миңа караганда күбрәк, озаграк эшләгән тәҗрибәлерәк иптәшләр дә бар.

— Даниэль Соломонович нәкъ менә сезне бу постка иң кулай кеше дип саный,— диде Сафиуллин.— Җинаятьләрне ачу буенча да бүлекчәдә инде байтактан бирле беренче урынны тотасыз. Соңгы уңышларыгыз гына да теләсә нинди мактауга лаек. Мин дә канат чыгарган кошка очарлык киңлек кирәк дип исәплим.

— Белмим. Кинәт әйтеп хәйран калдырдыгыз әле.

— Бизмәнгә салып торырга вакытыбыз юк. Даниэль Соломонович ашыга, бүген үк араны өзмәкче. Боерырга туры килә ул чакта. Тотынып кара, безгә үз кадрларыбызны үстерү кадерлерәк. Районны беләсең, барыбыз да булышырбыз. Даниэль Соломонович, алыш-биреште башлагыз. Байчуринга яңа вазифасының нидән гыйбарәт икәнен үзегез аңлатырсыз инде. Алыш-биреш тәмамлангач, бергәләп миңа керерсез.

Өлкән инспектор Байчурин бер дә уйламаганда менә шулай югарырак баскычка сикерде. Моңа ул сөенергә дә, көенергә дә белмәде. Яңа эшнең дәрәҗәсе белән бергә мең төрле мәшәкатен дә үз өстенә алырга кирәк иде. Хәер, озак баш ватырга вакыты да тимәде, Сафиуллин кабинетыннан чыккач ук аңа ҖАБ сейфларындагы папкалар белән таныша башларга туры килде. Даниэль Соломонович белән менә шул эш өстендә утырганда Шәмсия шалтыратып, аның тиз генә Җәмил Гайнуллин яткан больницага килеп житүен үтенде.

*
* *

— Алло, алло, Зөбәрҗәт... Алло, Зөбәрҗәт... Мин — Кашкарый, мин — Кашкарый...

Трубкада район эчке эшләр бүлеге дежурныеның егетләрчә тавышы ишетелгәч, өлкән инспектор Байчурин аңа больницадан качкан җинаятьче Җәмил Гайнуллинның тышкы кыяфәтен тасвирлап бирде.

Хәзер инде ул биш минут эчендә вокзаллардагы милиционерларның, автоинспекция постларының кисәтелеп куелачагына шикләнми иде. Тик Җәмил Гайнуллинны кулга алу, барыбер, Айбулат өстендә калачак. Райкомнан кайту белән Касыймны ияртеп больницага килгән иде дә бит менә, ычкындырдылар кошны. Көтелмәгән бәла сагалап торган икән. Хәзер инде барысын да төптән уйлап, яңа планнар корып хәрәкәт итәргә кирәк. Беренче кая барырга тиеш Гайнуллин? Үз өенә кайтмаячак, билгеле. Җаббар, Зөбәер, Хәят Галиевалар да исәптән төшеп кала. Өйләрен күзәтү астында тоталардыр дип шикләнәчәк. Апалары белән тату түгел, больница киеменнән анда хәтле бару уңайсыз да — артык ерак. Башка якын туганы юк. Әһә, аңа беренче нәүбәттә яңа кием юнәтү кирәк ич! Бәлки ул «Талчыбыккай»ына сәфәр тотар? Шул фәрештәнең бүген тагын килеп егетне кисәткән булуы да, алдан ук кием әзерләп торуы да мөмкин ич! Кем соң ул «Талчыбык?» Әллә Лена Корниловамы икән? Иректә ич әле ул чибәркәй. Тик хәзер эштә булырга тиеш. Бүлеккә кайтып җиткәч үк шуны белешер заводтан Айбулат. Сулар тагын болганды бит әле болай булгач!

Өлкән инспектор Гайнуллин асылынып киткән машинаны эзләп тору файдасыз икәнен төшенә иде. Чөнки бу елгыр егет ничек ябышып менсә, шулай ук шома гына төшеп тә калачак. Шофер сизмәячәк тә. Шуңа күрә юл уңаендагы урамнарга күз сала-сала туп-туры милиция бүлегенә кайтты. Монда аңа Әзербайҗан Эчке эшләр министрлыгыннан сугылган телеграмманы китереп тоттырдылар.

«СӘФИ АБДУЛЛАЕВ СПЕКУЛЯЦИЯ БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНҮДӘ ШИКЛӘНЕЛӘ, МАХСУС ИСӘПТӘ ТОТЫЛА. АҢА КАГЫЛГАН МАТЕРИАЛЛАР БЕЛӘН БЕЗНЕ ДӘ ТАНЫШТЫРУЫГЫЗНЫ ҮТЕНӘБЕЗ, ИНСПЕКТОРНЫ КОМАНДИРОВКАГА ҖИБӘРӘ АЛМАССЫЗМЫ?» дип язылган сүзләрне укыгач, Айбулат канәгать төстә елмаеп куйды.

Ул кабинетына кергәнче үк үз телефонының яман таләпчән шалтыравын ишетте. Ишектән керүгә трубканы алды. Энесе искә төшергән икән.

— Бүген өйгә кайтасыңмы?— дип сорады ул абыйсыннан.

Айбулат энесен, аның янына килеп утырган әнкәсен күз алдына китерде. Телефонны әле яңарак кына керткәнгә, әнкәсе үзе аның белән эш итәргә кыенсына иде. Әмма шалтыратырга тотынсалар, килеп колак салмый калмый.

— Кайтам. Үзеңнең кем белән сөйләшкәнеңне бәләсеңме?— дип елмайды телеграмма укыгач кәефе күтәрелә төшкән Айбулат.— Районның җинаятьләрне ачу бүлекчәсе начальнигы белән! Менә шулай, абыең синең кебек туп тибеп кенә йөрми ул! Начальник!!

— Бер сәгатьлек солтанмы?— дип мыскыллады энесе. Даниэль Соломонович былтыр ялга киткәндә Айбулатның аның урынында калып торуын белә иде ул.

— Бу юлы бөтенләйгә охшый. Бүген яңалык күп җыелды әле. Кичкә таба итәкләрне җыеп бетереп булса, мәҗлескә барам. Даниэль Соломонович белән саубуллашабыз. Өйгә җиденчедә үк кайтырмын. Кунагым да булыр, ахры. Кара аны, малай, бүлмәне тәртипкә сал. Кунак хатын-кыз затыннан. Аңладыңмы? Көтегез.

— Бакудан телеграмма бар,— диде энесе.— Зыятдин абый «көтәм» дигән.

— Шәп эшләгән. Кунак алып кайтам, ишеттеңме?

Соңгы сүзләрне әнкәсе өчен әйтте Айбулат. Кунак дигән үе да трубканы алгач кына башына килде. Иртә белән башкача планлаштырган иде. Җәмил Гайнуллинны кулга алырлар да, вакыты иркенәер, янәсе. Төштән соң, бушый төшкәч, Нәҗибәне барып алыр да загска гариза кертеп бирерләр. Аннары, бәлки Аккош күле тирәсенә китеп ял итәрләр. Әмма эшкә килү белән программасына үзгәрешләр керә башлады. Ишекле-түрле йөргәндә Винер:

— Әйдә, араны өзик тизрәк,— дип ашыктырды.— Мәҗлескә дә әзерләнәсем бар ич әле. Сиңа әйттемме, «Ширбәт» кафесы белән килештем. Сигездә җыелабыз. Сафиуллин да киләчәк.

— Кафе ничәдә ябыла?

— Тугызда. Унга кадәр утырырга сөйләштем.— дип күз кысып куйды майор шаян кыяфәттә.

— Юмартлана башлаганда гына китеп баруыгыз кызганыч,— дип көлде Айбулат.

Хәзер менә шушы үзгәрешкә җайланырга кирәк. Даниэль Соломонович оештырган мәҗлескә Нәҗибәне дә алып барырга ярамый иде. Бары хезмәттәшләрен генә чакырды Винер. Загстан чыккач ук Айбулат кафега сыйланырга китеп барса, Нәҗибәнең үпкәләве бар. Шуңа күрә, вакыты кысан булса да, кызны өйләренә чакырырга кирәк тапты. Әнкәсе дә булачак киленен күрә торсын. Бәлки Нәҗибә дә кызыксынадыр? Танышырлар, чәйләп алырлар. Димәк, Зыятдин телеграмма да сугарга өлгергән! Егет! Кунакчыл булырга охшый. Бәлки Бакуга да парлап барыргадыр? «Һаваларда оча ике аккош...» Менә бусы, ичмасам, идея: туй сәяхәте! Хәер, эшендәге үзгәреш аңа тиз генә җыенырга ирек бирмәс әле. Бәлки командировкага сорарга дыр? Сылтавы да чыкты лабаса!

Айбулат, үзен татлы уйлардан аерылырга мәҗбүр итеп, Гайнуллин хакында баш вата башлады. Хәзер үк бүтән инспекторларны да эшкә җигеп, аның бөтен таныш-белешләрен ачыкларга, һәммәсенең өенә күз салып чыгарга кирәк иде. Шушы карар белән Айбулат Винер кабинетына кереп китте.

— Көтәм, көтәм сине, күренмисең дә. Алыш-биреше төгәлләргә кирәк ич инде,— дип каршылады аны ҖАБ башлыгы.— Түрә итәбез дигәч әллә тәкәбберләнеп тә киттеңме?!

— Тапкансыз бит, Даниэль Соломонич, эшегезне кемгә сылап китәргә! — диде Айбулат эче пошкан кыяфәттә.— Минем баш белән район масштабында...

— Ишеттем, ишеттем, туктат!— диде Винер — Мескенләнмә. Көрәк кечкенә булса да, тирәкне ега. Менә мин дә үземне даһи санамыйм. Шерлок Холмс та түгел. Шулай да бөтен бер шәһәрнең иминлеген кайгыртуны өскә алырга туры киләчәк. Авыр йөкне ат тарта, авыр эшне — ирләр. Менә, боерык та әзер.

Айбулат Даниэль Соломонович кулындагы кәгазьне алып укыды. Үзен ҖАБ башлыгы итеп билгеләү турында приказ басылган икән.

— Котлыйм, Айбулат дускай! — диде Винер. Өлкән инспектор штатлану галәмәте күрсәтмәгәч, өстәде:— Борынының салындырма. Гайнуллин качканга аһ орасыңмы? Заводта аның иптәшләрен барларга да, күршеләреннән сорашырга да кешеләр җибәрдем инде. Хафизов белән Слесарев китте. Ничек сыпыртты соң ул?

Айбулат больницада булган хәлне сөйләгән арада Зиннәтева да кайтып җитте.

— Касыйм аякка басты,— диде ул.— Хәл җыя калды.

Зиннәтева шул арада өлкән инспектор өстәлгә куйган кәгазьне караштырып та өлгерде. Андагы боерыкны укыгач, ирексездән Айбулатка йөгерек караш ташлап алды. Ошый иде кызга Байчурин. Бергә эшләү дәверендә Айбулат тикшерә торган җинаятьне ачуда катнашса, Шәмсия үзен ышанычлырак сизә, канатланыбрак йөри иде. Егетнең шомырттай күзләре генә моны күрмәде. Әллә күреп тә күрмәмешкә салынды шунда. Ә бу боерык исә аларны тагын да ераклаштырырга гына мөмкин иде...

Айбулат «Тасманур»ның унөченче цехына шалтыратып белешкәч, Шәмсиягә:

— Озакламый Лена Корнилованың эш сәгате тәгәлләнә, заводка барып кулга ал,— диде.— «Талчыбыккай» шул түгел микән? Мин хәзер өйләренә барам. Гайнуллинның аларга килеп яшеренүе дә ихтимал.

Шәмсияне бер милиционер белән машинага утыртып заводка озаткач, Байчурин папирос кабызды һәм, яңа фаразлар уйлый-уйлый, Торнаяз урамы буйлап атлады, нәни скверга кереп, көзге купшылыгы белән күзне иркәләгән, куе хуш исләре белән борынны кытыклаган чәчәкләр түтәленә карап узды, каршыдагы кинотеатр игъланнарына күз салды. Әмма аның күңел күзе боларның берсен дә күрми иде.

...Байчурин бүлектән машина алып, Лена Корнилованың өенә күз салып чыгу нияте белән, Бишбалтага китте. Әгәр ул «Талчыбык» булып чыкса, тентергә соңга калдылар инде. Яшерәсе әйберне күптән яшергәннәрдер. Җәмил Гайнуллин андый гына киңәшне бирми калмас.

Сәгать көндезге өчләр чамасы иде. Кисәк-кисәк исеп куйган җилдән агач башлары чайкалгалый, яфраклар шыбырдаша. Иртән үк явасы сизелгән яңгырның беренче тамчылары машина тәрәзәләренә куна башлады. Коңгырт-көрән төстәге «Москвич» Торнаяз урамы буйлап бара-бара күрше район биләмәләренә килеп керде. Күзенә ышыкка йөгерешкән кешеләр чалынгач, Айбулатның йөрәге тагын да тынычсызрак тибә башлады: Гайнуллинның койма аркылы чыгып качканына нәкъ ике сәгать иде инде. Тотуын тотарлар, мәшәкате генә артты менә. «Талчыбыккай»ны фаш итә торган дәлилләр дә тапса әгәр! Алдагы троллейбус, автофургоннар туктады, әмма аларны урап узарлык ара калмаган иде. Ярдәмгә алган инспектор Харрасовны аптырашка салып, Айбулат инде сибәли башлаган яңгыр астына чыгып басты. Тротуардан машиналар ташкыны тыгылган якка күз салды. Бәрелешкәннәр, ахры. Нинди җир соң әле бу, алда «Идел» кинотеатрының ишектәрәзә пыялалары ялтырый түгелме?

Айбулат бүгенге төнне әнә шул кинотеатр артындагы йортларның берсендә уздыруын, чирек кенә минутка да керфек какмаган булуын кылт итеп исенә төшерде һәм уй-фикерләренең дә нәкъ менә шунлыктан сүлпән агуын чамалап алды. Хыялында тагын сөйгәненең сихри сурәте җанлана башлады. Озын керфекләр астындагы зур коңгырт күзләреннән кояштан килгән кебек җылылык бәрелеп торгандай тоелды. Кынага буялган чәчләре астындагы якты йөзе караңгы күк гөмбәзе уртасындагы тулган ай кебек нур сибәргә тотынды. Яңгыравык тавышы көмештәй чылтырап үзенә дәшә торган иркә авазларга әйләнде...

Айбулатның миендә яшен яшенләдемени — ул уйлар агышын кинәт өзеп, машинага кереп утырды да шоферга, «Идел» кинотеатры артындагы бер йортка кагыла китәргә кирәк дип, тротуар аша әйләнергә юл күрсәтте. Харрасовка машинада көтеп торырга кушып, үзе йөгерә-йөгерә баскычтан күтәрелде. Әмма Нәҗибә ишеге төбенә килеп җиткәч, кыңгырау төймәсенә басарга сузылган кулын кире төшереп, үзенә дә хисап бирмәстән, кесәсеннән тентүләргә барганда гына тыгып чыга торган универсаль ачкычлар бәйләмен алды һәм шуларның берсен яратып, тавышсыз-тынсыз ишекне ачты.

Калын келәм җәелгән коридорга кергәч, һаваның бөркү булуыннан Айбулат бүлмәдә камин янып торуын чамалады. Тәрәзә калын пәрдәләр белән капланганга, бүлмә ишеге төбенә килеп баскан Айбулат башта диванда уйнаган якты шәүләнең ни икәнен дә аңламый торды. Бары тик дивандагы серле сыннарны җәтерәк шәйләп, чәчләре пумала кебек таралган хатын-кызның таныш тавышы чырылдап яңгырап киткәч кенә бу күренеш Айбулатның аңына барып житте.

Ул арада аһылдау тавышы яңгырады. Һәр сигналга бик тиз реакция ясый алу сәләтенә ия булган Айбулат үзенә куркыныч янавын күзгә күренмәс нерв җепселләре белән сизеп, кухня ягына тайпылды— шул авыкта ук ул иңбашында үткен чәнчү тоеп алды. Кискен хәрәкәт белән уң кулын, йөрәгенә төбәлеп тә, Айбулатның вакытында тайпылып калуы аркасында, иңбашын гына сыдырып үткән хәнҗәргә сузды. Ул арада һөҗүм итүче, аны суырып алып, яңадан кизәнде. Әмма Байчурин тәҗрибәле көрәшче иде. Яшен тизлегендә үлем белән янаган беләкне ике куллап эләктереп алды да, самбо алымы кулланып, күз ачып йомганчы дошманын идәнгә сузып салды. Ятьмәгә эләккән балык сыман әле һаман тыпырчынып маташкан адәмнең кулын тагын да каера төште. Тегесе һаман бирешергә теләмәгәч, Айбулат аның башын чәченнән эләктереп, таш стенага орды. Аннары каршылык күрсәтүдән туктаган дошманның чалбар каешын суырып алып, каерылган кулларын бәйләргә кереште. Ләкин ул шул мизгелдә үк башына ниндидер каты нәрсә бәрелүен тоеп тынсыз калды, тик ярым караңгыда өй хуҗасының иягенә соңгы көче белән сугарга да өлгерде...

Айбулат исен җыеп як-ягына карана башлаганда бүлмәдә үле тынлык хөкем сөрә иде. Сул як иңбашыннан җиң буйлап җылы кан саркып төшкән. Ул, хәл алгач, башын тотып аягына басты, тәрәзә буена барып пәрдәләрне ачты да көрәш барган ишек төбенә күз салды: финка тотып һөҗүм итүче, хәзер салам көлтәсе сыман бусагада яткан ир Җәмил Гайнуллин иде. Айбулат тәрәзне ачып, ишегалдына ук кереп туктаган милиция машинасына карап:

— Харрасов, унөченче фатирга мен әле!— дип кычкырды.

Аның тавышына, Айбулатның кулы җиңелчә генә кагылуга да егылып, башы белән таш стенаны сөзгән Нәҗибә дә күзен ачты.

Әллә пычак җәрәхәте, әллә Нәҗибә туфлиенең кадак үкчәсе хәлен алды — Айбулат инспектор Харрасовның фатирны тентүен томан аша гына күзәтте. Иптәше беренче ярдәмне күрсәткәч, медпунктка китик дигән тәкъдимен ишетергә дә теләмәде.

Ярты сәгатьтән машина коеп торган яңгыр астында милиция бүлегенә юл алды. Җәмил Гайнуллинның битлек кигән кебек хәрәкәтсез калган йөзенә тере төс керә башлаган иде инде. Нәҗибә исә Харрасов тентү уздырган арада кунакка барырга җыенгандай киенеп-ясанып та өлгерде. Үче кайнап торган хәлдә дә Айбулат аның юка, зәңгәр төстәге күбәләк җиңле нейлон күлмәгенең, сары агач муенсаларының үзенә килешеп торуын күрми кала алмады. Байчурин Харрасов тентүне тәмамлап акт яза башлаганда гына Нәҗибәнең Гыйбадуллина фамилиясендә булуын беренче мәртәбә ишеткән кеше кебек исе китеп күзен ачты.

— Димәк, атаң Җаббарның миңа бер шарты бар? — диде Айбулат.

Нәҗибә дәшмәде. Айбулатның да бүтән сорау бирергә яки нәфрәтләнергә дәрте сүнгән иде инде. Ул хәтта Нәҗибә Гыйбадуллинаны бүлеккә алып кергәндә милиция машинасында эшләүче шоферның елтыр күзле шук малае шатланып:

— Менә, менә ул апа! Сары йозаклы сумкасы да бар. Шушы апа әйтте ич инде миңа пожарникларны!— дип кычкырганда да борылып карамады.

Бу арыганлыктан да, яраланып хәл китүдән дә түгел, якты хыялларының кара сөремгә күмелүеннән, идеал итеп йөрткән гүзәл фәрештәсенең ямьле кабыкка төренгән иблис булып чыгуыннан иде. Коеп яуган яңгыр Айбулатның бәхетле гаилә кору турындагы бөтен матур теләкләрен, ашкынулы омтылышларын гүя мәңгегә үзе белән юып, агызып кара җир астына алып китте. Һәрхәлдә, ул үзе менә шундыйрак уйларга күмелеп атлый иде.

*
* *

Айбулатлар кайтып җиткәндә, Лена Корнилова кулга алынган иде инде. Гайнуллиннар төркемен коридорда каршылаган инспектор Шәмсия Зиннәтева яра турында ишетү белән куркуга төште һәм чиста бинтлар алып Байчурин кабинетына килеп керде. Егетнең ай-ваена карамыйча, күлмәк, майкасын чишендерде. Яра бик тирән түгел, финка иңбаш мускулын гына кисеп үткән иде. Күлмәк, костюм җиңнәренең юешләнүенә караганда шактый кан аккан булса кирәк. Шәмсия нечкә кашларын күтәреп, күк күзләрен тутырып Айбулатның агарыныбрак киткән түгәрәк йөзенә карады да, төгәл, җитез хәрәкәтләр белән яра тирәсенә йод сөртеп, кысып бәйләде. Аның нәфис куллары бинтны сүтә-сүтә култык астына кереп, калак сөякләренә орынып киткәндә егетнең битләренә алсулык йөгерде. Иягенә мәзәк сызыклар сызылган, тар борынлы, маңгае нәни генә алгарак чыгып торган коңгырт чәчле сылу кыз алдында бүлмәдә ялангач басып торуыннан уңайсызланды. Шәмсия исә, шул арада кайдан табып өлгергәндер, Айбулатка яраклы чиста күлмәк, костюм китереп тоттырды. Якындагы кафедан йөгереп кенә бер стакан кофе да алып кереп өстәленә куйды. Кайчаннан бирле бергә эшләп тә Шәмсиягә рәсми хезмәттәше буларак кына карап килгән өлкән инспектор хәзер аның кешелегенә, кайгыртучанлыгына сокланмый булдыра алмады. Без һәр вакыт шулай: якында яткан алтынны күрми, ерактагы ялтыравыкка кызыгабыз, дип уйлады ул, җылы карашы белән Шәмсиягә рәхмәтен белгертеп.

Кайнар кофе тәненә җылы керткәч, Айбулат подполковник Сафиуллинга Җәмил Гайнуллинның тотылуы, инспектор Касыйм Вилдановның җиңелчә травма алуы, Әзербәйҗанның Эчке эшләр министрлыгыннан телеграмма килүе турында хәбәр итте. Үзенең яралануын ләм-мим телгә алмады. Өйгә кайтарып җибәрер дип курыкты. Урланган көмеш нитраты әле һаман табылмаган, Айбулатның эшне җиренә җиткереп бетерәсе килә иде.

Җәмил Гайнуллиннан сорау алырга әзерләнгәндә уйлары тагын Нәҗибәгә әйләнеп кайтты. Нигә бер дә шикләнмәгән икән ул кызыйдан? Нигә көмеш җинаяте турында сораштырулары сагайтмаган? Унҗиде яшьлек егет кебек мәхәббәттән күзе томаланганмы әллә? Каравылчы Җаббар Гыйбадуллин фаш ителгәч тә Нәҗибәнең фамилиясенә генә булса да игътибар итмәгән бит! Ни өчен?

Айбулат бергә укыганда ук Нәҗибәнең ата-анасы Тәтештән ерак түгел авылларның берсендә яшәвен белгән иде. Соңыннан аңа бу турыда сорашырга туры килмәде. Кечке мәктәптә укыганда Нәҗибә заводның тулай торагында яшәде, бу юлы очрашканда инде Айбулатны Бишбалта уртасындагы үз фатирында кунак итте. Җаббар Гыйбадуллин исә шәһәрнең бүтән районында, кырыйда үз йорты белән торучы кеше иде. Фамилиягә килгәндә, Казанда Гыйбадуллиннар йөзләгән ләбаса, ни дип шикләнергә тиеш иде соң өлкән инспектор?

Җәмил Гайнуллин Айбулат кабинетына кергәч, бер ноктага карап өнсез утыра бирде. Тонык ак чыраенда кан тамчысы калмаган төсле,

калын иреннәре тагын да салына төшкән, сакал-мыек, төк урыннары зәңгәрләнеп тора.

— Каракның кулы озын, законныкы тагын да озынрак,— дип башлады сүзен Айбулат.— Тәүбә итәр вакыт җитте менә. Дөресен сөйләүдән дә отышлырак юл юк сезгә.

«Белмим»— бер сүз дип уйлады Җәмил. «Беләм»— ике сүз. Ике генә дә түгел, ике мең сүз. Бер сава башласалар, мең генә дә булмас. Барысын да кире кагарга кирәк. Белмимнең беләге авыртмый.

— Лена Корнилова, Зөбәер Габдуллиннар, тагын унбишләп кеше күрсәтмәләре менә монда,— диде Айбулат, бүселеп торган папкаларны күрсәтеп.— Зөбәер дә, Җаббар абзый да җинаятьне фаш иттеләр. Калай сатуыгызны бөтен авыл белә.

Гайнуллинның чигә тамырлары бүртеп чыкты, башы чыңлый башлады, хәзер инде Айбулат тавышы үзе эшли торган цехтагы насос гөрелтесе кебек бөтен бүлмәне каплап алгандай булды, тизрәк тышка, тынычка, саф һавага чыгасы килде.

Ниһаять, Җәмилнең колаклары шаулаудан туктады, уй-фикерләре ачык бер эзгә төште.

— Зөбәер, Җаббар абзый күрсәтмәләре белән танышыйм әле?— дип сорады ул Айбулаттан.

— Я алар сөйләгәннән артыгын ычкындырырмын дип куркасызмы? Хәйләкәр! Сезгә, гражданин Гайнуллин, үз хатагызны күрсәтим булмаса.— Айбулат «Талчыбыккай»га дип язган язуны укырга мөмкинлек бирде.— Таныйсызмы?

— Тик ятмагансыз,— диде Җәмил тагы да кәефе ныграк кырылуын яшермәстән.— Безне җыеп утырткан өчен нинди калҗа тияр икән сезгә?

— Без закон сагында. Я, нәрсәдән башлыйсыз?

Җәмил фототасма, спирт, калай урлавын өлешчә танырга туры киләчәген ачык төшенде. Колагын кызганып башын кистермәс ич инде. Вак караклык өчен генә гүргә кертмәсләр дип исәпләде. Әмма Айбулатның исе китмәгән төстә «Уклар аттым ай көмешкә...» дип тәрткеле җыр көйләве аны тәмам шабыр тиргә салды. Байчурин көйләгәндә Җәмилдән күзен алмады, наян гына каш та сикертеп куйды. Гайнуллинга идән чайкала, урындыклар әйләнә, җир тетри сыман тоелды. Шул чак коридордагы аяк тавышларын ишеткән Байчурин кабинет ишеген ачты да:

— Шәмсия, монда керегез әле,— дип, кемнедер бүлмәгә чакырды.

Кече лейтенант формасын кигән йөзе таныш хатын-кызны күргәч, Җәмил тагын да аптырый төште.

— Шәфкать туташын таныйсызмы?— диде Айбулат аңа.— Инспектор Зиннәтева уникенче больницада сезнең тирәдә кызык өчен генә йөрмәде. Дәлил кирәкме? Менә алар: бусы — «Талчыбыккай» хаты, үз җавабыңны укыдың да инде.

Милиция кулына үзе компас тоттырган икән ләбаса! Суга төшкән балта кебек батачак хәзер! Ә бит үзен тәҗрибәле карак дип исәпли башлаган иде ул. Җәзасы җиңел булмас, чәперләр.

Айбулат аның җавап хатын селкеп мактаган итенде:

— Оста иҗат иткәнсез моны! Рат урам дигән җире генә дә ни тора. Тик без ул башваткычларны чиштек. Арт урамдагы җизнәгез келәте дә серен ачты. Алма сатучы дустыгыз Сәфи Абдуллаев исә күрше бүлмәдә утыра. Сезнең белән кавышуны зарыгып көтә. Эшен бетерә язган иде инде, аэропортта туктатып арест салдык. Азапланып йөрмәсен дидек.

Җәмилнең эченә йөгергән сыкы суык йөрәген дә өшеткән, канын да катырган төсле иде — сулышы кысылды, болай да ак йөзе акшар төсенә керде. Аны кояшлы хөр дөнья белән бәйләп торган кыллар әйтер-

сең шартлап өзелде дә, Җәмил хәзер төпсез упкынга очып төшеп бара иде.

— Дәшмәвеңнең әһәмияте су буенда суга сусау шикелле генә, гражданин Гайнуллин,— диде Айбулат инспектор Зиннәтева чыгып киткәч.— Суд өчен материаллар болай да җитәрлек. Мине кайбер детальләр генә кызыксындыра.

Айбулатның бу сүзләреннән соң Җәмил исәнгерәгән хәленнән бераз айный төште, эчендәге бимазалы бушлык та җилдә киерелгән җилкән кебек тула башлады. Өмет дигән ут кабыну иде бу. Гүя таяк белән суккандай башын иңгерәткән сискәндергеч сүзләрдән соң Җәмилнең таркау гына ага башлаган уйлары яңа сукмак сапты: әгәр машинасын корбан итсә? Дөнья малы — дуңгыз каны. Капкыннан ычкынуы кадерле. Кеше закон өчен яшәми, закон кеше өчен языла. Аны төрлечә чыгарырга мөмкин. Бозарга ярамаса, әйләнеп узарга була. Гозерләп сораса, бәлки тикшерүләрен туктатырлар, җинаятьне томаларлар?

— Инспекторлар җитәрлек казынган,— диде Җәмил Айбулатка.— Әмма җиһанны бер сез генә пакьли алмассыз.

— Нәрсә тәкъдим итәр идегез соң безгә?

— Үземә кагылганны гына әйтәм: әгәр мине чистартсаң, өр-яңа «Жигули»гә утырырсың!

— Әһә, беркетмәгә теркик әле моны. Ришвәт өчен махсус статья каралган.

Айбулат алдындагы кәгазьгә чынлап та нидер язарга тотынгач, Җәмил иреннәрен чәйни башлап кычкырды:

— Языгыз, яз! Кул гына куймам. Ник самолет вәгъдә итте димисез шунда! Көндәштән ачу алырга кирәк ич инде!!

— «Талчыбыккаең» Нәҗибә Гыйбадуллина, димәк? — диде Байчурин тыныч кына. Тыштан тынычлык сакласа да, бу аңа бик җиңел бирелмәде.— Әйтәсең килмәсә, хаты буенча эксперт ача инде аны. Озакламый хәбәр дә итәр. Валентин Николаевның ни өчен илле кап пленканың унысын гына чәлдерүе миңа кызык менә.

— Әй, шул җебегәнне!— диде Җәмил сүзнең башка якка борылуыннан соң бер селкенеп алып.— Имеш, барын бергә кузгату хәтәр, бүлеп-бүлеп кенә кирәк. Тәвәккәлләгән көнендә генә калдырып эшләткәннәр, тагы шыр җибәргән, Янәсе, заводтан халык мыжгыган вакытта сыптыру хәвефсез. Аулак чакта курыккан, иртәгәсен барыбер элэктергәннәр үзен. Җитмәсә, ул сузып йөргән арада куштаннар калган кырык капны табып алган.

Айбулат көлемсерәп сорады:

— Я, көмеш нитратына күчик инде. Машинага ничек төядегез?

Яшереп маташу файдасыз дип уйлаган Җәмил көттереп җавап бирде:

— Мин биреп тордым, Зөбәер таслап урнаштырды.

— Турыдан-туры складтан төядегезме?

— Складны үзем генә бастым. Йозагын бәреп төшердем дә, көмеш капларын җиденче цех янынннан алып килгән уфалла арбага төядем. Аннары яңа корыла торган бина эченә ташыдым. Механика цехы чүплегенә яшергән пленканы да шунда китердем. Спиртны туп-туры машинага чыгарып куйдым.

— Калайны кем төяде?

— Зөбәер үзе. Автокранны идарә итә белә икән.

— Җаббар Гыйбадуллин капкадан чыгарганда машинагызны карап та тормаган. Сезне ничек таный иде соң?

— Алдан сөйләшенгәнчә, аңа кул фонаре белән сигнал бирәм, юл ачык булса, ул да шулай җавап кайтара иде,— диде Җәмил. Икеләнүен җиңеп, үзе дә сорау бирде:— Көмешнең утынлыкта икәнен ничек

ачыкладыгыз? Хуҗалар да, тирә-күрше дә берни сизмәгән шикелле иде ич үзе.

— Эшең шул булгач, остарасың инде.

— Бөтен утынны чыгарып бетердегезме?— диде Җәмил тагы да кызыксына биреп.

— Туры килде,— диде Айбулат керфеген дә какмыйча.

Җәмил канәгатьләнеп көлемсерәде:

— Бушка тир түккәнсез. Утынлыкның арттагы ике тактасы алына иде аның.

Димәк, көмеш әле дә шунда торырга тиеш! Сорау алуга тыштан бик исе китмәгән сыман кыланса да, Айбулат чынлыкта аңа зур әһәмият бирә иде. Әнә шул сүзләрне ишетер өчен тырышты да ул. Теләгенә иреште ич менә! Юк, гражданин Гайнуллин, безнең тәкъдиргә бушка тир түгү язылмаган.

— Хәзер үк машина белән арт урамга кит,— диде ул телефоннан Шәмсиягә.— Җәмилнең җизнәләренә барып, утынлыктагы көмеш нитратын алып кайтыгыз. Сарайның арткы яктагы ике тактасы куба торган икән, шуннан алыгыз.

Байчуринның канәгать төстә ялтыраган күзләренә карап, телефоннан әйткәннәрен ишеткәч кенә Гайнуллин үзенең нинди хата җибәрүен аңлап алды. Тик соң иде инде. Телефон трубкасын куйган Байчурин яңа сорауларын бирә башлады.

Гайнуллин белән тагын ике сәгатьләп әңгәмә корып утырып, Байчурин озын гына беркетмә язды. Ул арада инспектор Харрасов «Талчыбык» язуы белән Нәҗибә Гыйбадуллина кулының охшашлыгын тикшергән эксперт актын алып кайтты. Байчурин хәзер инде үзендә нәфрәт уяткан инженер кыздан сорау алырга теләмәде. Заводның кадрлар бүлегеннән аның бернинди аспирантура-фәләндә дә укымавын белеште дә, калганын Зиннәтева тикшерер әле дип, кул селтәде. Шулай да, Гайнуллинны изоляторга илтеп япканда, ялгызы гына аерым камерада утырган кыз янына кереп, аяк өсте генә берничә сүз алышты:

— Шуны гына беләсем килә,— диде Айбулат,— барысын да аңлы рәвештә эшләдеңме?

— Караңгыда кергән кешенең кем икәнлеген каян белим?

— Ә элегрәк?

— Кыю, перспективалы кешеләр ошагач, нишлим?— диде Нәҗибә тамчы да уңайсызлану сиздермәстән.— Җәмил мутлыгы, фәлән итәрбез, төгән итәрбез дигән хыяллары белән һушны алды. Аннары синең йолдызыңның да югары күтәрелә башлавына күзем төште.

— Аның караклыгын белә идеңме?

— Әллә шуннан шикләнәсезме?

Айбулат аның гөнаһсыз төстә биргән соравыннан үзенең нинди зәһәр юха елан белән бәйләнешкә кергән булуын бөтен тирәнлеге белән аңлады һәм ачулы гына:

— Әйе, «Талчыбыккай!» — диде дә кырт борылып камерадан чыгып китте.

## Әхмәт Рәшитов

# ТОРМЫШ ӘЛИФБАСЫ

ПОЭМА

### Ирләр исеме белән

Сау булыгыз инде, әкияттәге
Каф тавының зәңгәр кыялары!
Сау булыгыз инде, бала чакның
Чынга ашмый калган хыяллары!
Иң беренче сөю ялкыннары,
Кыз куенында үткән беренче төн —
Сау булыгыз инде!
Сез — үткәндә.
Аерылуы сездән, әйе, читен.
Без гомернең яңа баскычында,
Башка гамьнәр бездә, башка җырлар,
Очынсак та сезне сагынып кайчак,
Чабулардан тотып тора еллар.
Безнең буын бүген ир уртасы —
Акыл теше, димәк, чыкты күптән,
Дуамаллык түгел, аек акыл —
Безнең эшне нәтиҗәле иткән.
Нух көймәсен хәтерләтә дөнья,
Җилкәненә хәтәр җилләр өрә.
Сыналабыз суга бата-бата,
Сыналабыз утка керә-керә.
Без бит ирләр! Горурлык та бардыр,
Масаю да бардыр бу исемнән.
Баһадирлар — ирләр токымыннан,
Пәйгамбәрләр — ирләр җенесеннән.
Гаилә һәм ил язмышы өчен
Җаваплылык тою түгел тиккә.
Парламентлар мөнбәреннән торып,
Хөкем чыгарабыз кешелеккә.
Бәхет эзлибез без яшәешнең
Куе чытырманы арасыннан.
Зур миссия безгә йөкләтелгән
Табигать һәм тарих тарафыннан.

Безнең антлар йөрәк түрләрендә,
Безнең уйлар постта көн-төн уяу.
Ахыргача тора алырбызмы?—
Тормыш куя сорау арты сорау.
Ир икәнсең, я, әйт, үтәдеңме
Борынгыдан килгән йолаларны:
Йорт салдыңмы?.. Агач үстердеңме?..
Нәселең дәвам итәр кешең бармы?

## Гаилә күренешләре

●

— Нәрсә шул кадәр авызың ердың?
— Малай туды бит... Ма-лай!..

*Трамвайда колакка чалынган сөйләшүдән.*

Бер юаныч кынадырмы шунда,
Котылгысыз көннән дәвадырмы?—
Калдырасы килә җир йөзендә
Үзең төсле җисми дәвамыңны.
Бер утырып уйланасың кайчак,
Уйланасың... үзең сизмисең дә:
Васыятьләр әле язасы бар —
Әманәтең мирас булыр кемгә?
Шәҗәреңне кемнәр дәвам итәр?—
Җавап кирәкмәгән сорау түгел.
Бик яшертен генә гомер буе
Соңгы көнгә әзерләнә күңел.
Бездән соң да кояш-йолдызларның,
Җирнең, суның җирдә каласы бар.
Кешелекнең әле миллион еллар
Киләчәккә карап барасы бар.
Әле күпме күрелмәгән офык,
Әле күпме ачылмаган серләр,
Бәхетсезлек... Бәхет... Афәт... Өмет...
Җиргә әле һаман кирәк ирләр.
Игенчеләр кирәк, диңгезчеләр,
Шахтер, шагыйрь, йолдыз санаучылар...
Көн белән төн алышынып тора —
Җирнең әле Җирдә каласы бар.
Изге утны — мәңге яшәү утын
Алгы көнгә кемнәр алып барыр?
Уйланасың... Үзең сизмисең дә:
Нәсел агачында ныкмы тамыр?
Кыз табалар — ана булсын өчен,
Җиргә кабат ирләр тусын өчен.
Ә ирләрнең һаман — никтер алай?—
Телләрендә бер сүз:— Малай... Малай...
Мәхәббәтне, көчне мирас итеп
Саклап барыр өчен еллар аша,
Үҗәтләнеп җиргә малай баса —
Җиргә басса малай — ир ләбаса!

•

«Искәндәр дигән малаебыз бүген көне буе елады. Башта аны уллыкка алмакчылар иде дә...»

*Балалар йорты тәрбиячесеннән ишеткән сүз.*

Елап кына чыкса икән кояш,
Елап кына тынса икән җаның,
Елап кына җиңеп булса икән
Ачы хакыйкатен бу дөньяның.
Көннәр буе көтте...
Тәрәзәгә
Карый-карый керфекләре талды...
Нәүмизләнеп көтте... Әмма бүген
Чәлпәрәмә килде хыяллары.
Өч көн элек аркасыннан сөеп,
Конфет биргән абый белән апа
Ни өчендер бүген аңа таба
Борылып та карамады хәтта.
Аларга бит Марат кирәк булган,
Ә хыялың синең — төшең генә.
Өмет сүнде... Алар бүгеннән соң
Әти-әни... Марат өчен генә.
Конфетлары Марат өчен генә,
Уенчыклар... «Алыйк!..» дисен генә.
Аның өчен назлар-иркәләүләр...
Бөтенесе аның өчен генә.
«Мин кем!» дигән сыман бик ирәеп,
Җитәкләшеп... әнә, китте Марат...
Утыз пар күз, нидер өмет итеп,
Нәүмизләнеп арттан калды карап.
Баштарак ул ышанмаган иде.
Аннан чабып, күрми артны-алны,
Почмактагы гөлләр арасына
Чүмәште дә... кинәт... аваз салды.
Үкси-үкси озак елады ул...
Юаттылар: «Син бит үскән егет...
Монда да бит сиңа яхшы...»— диеп.
(Мөлдерәмә күздә сүнде өмет!)
Монда яхшы: яшьтәшләре белән
Уйнамыйча калган көне сирәк.
Кулда — мәми...
Ләкин әни кирәк...
Күлмәк тәти...—
Ләкин әти кирәк.
Уенчыклар матур, телисеңме,
Сикер дә мен — атлан агач атка.
Тәрбияче апа әйтми торып,
Менеп ятма ләкин караватка.
Монда кызык. Ләкин Искәндәргә
Ике җәпле үткен пәке кирәк...
Кесә кирәк таш тутырыр өчен,
Иң мөһиме ләкин — әти кирәк.
Аның хәтта почык борыныннан
Үбеп ала торган әти кирәк,

Арт ягына авырттырмый гына
Сугып ала торган эти кирәк.
Дөнья! Дөнья! Күк йөзендә аяз,
Законнар бар җирдә, хәкимнәр бар.
Яу кырында ире башын салган
Хатыннар юк... Нигә ятимнәр бар?
Гомер үтәр — яра онытылыр,
Кояш көләр күктә, исәр җилләр.
Җилдән туган диеп хурламагыз —
Алай килми җиргә асыл ирләр.
Җилдән туамыни җилдән җитез
Корабларда галәм гизүчеләр,
Бәхет өчен шәһәр төзүчеләр,
Икмәк өчен камыр изүчеләр.
Усал телләр әйтсен — уфтанмагыз.
Яшәү гүзәл барыбер — ата таңнар.
Уфтансыннар сез дөньяга килгәч,
Күкрәк сөтен сезгә кызганганнар.
Уфтансыннар сезнең «әт-тә» дигән
Татлы сүздән мәхрүм калган ирләр.
Сез барыбер илдә ир булырсыз,
Барыбер сез илдә — баһадирлар.

●

— Парин, мин хатынның чибәреннән сайлап маташмадым. Күңел тыныч. Гы-гы-гы!

*Бер күршем еш кына шулай мактана.*

«Коридорга чыгып тәтәтәмсең?!
Хатын хәтерен саклыйм дисеңдер...
Башыңа да менеп биер әле,
Бик үсендер әле, үсендер...
Мин шаяртам. Кичер»!
Бу шул — күршем.
Кайтып килә төнге «гүләйт»тән.
Әзрәк салмыш. Кайсы чибәрнеңдер
Хушбуйларын үзенә ияртkән.
Азмыни соң төнге күбәләкләр —
Кәртинкәгә тезеп куярлык.
Мәкәрҗәгә барып йөрисе юк —
Казанда да буа буарлык.
Тормыш җайлы,
Малны таба белә.
Хатын уңган...— тагын ни кирәк?!
Малайлары рояль дыңгырдата,
Кызы «инглизчә сиптерә».
Тыныч заманнарга шөкер итеп,
Калышмаска теләп кешедән,
Ул, баш ватмый гына, шөгыльләнә
Төшемле һәм җиңел эш белән.
Атна саен өе тулы кунак
(Чакыргалый кайчак безне дә).

Ә бер килеп керсәң өйләренә,
Чыгып китәм димә тиз генә.
Ул гарнитур... Сервиз...
— Махсус заказ!..
Ул келәмнәр...
— Кайтты чит илдән!..
Башлый гына күрмә... Дәштең исә,
Бер сүз булыр һаман гел телдә.

Ә хатыны ләм-мим. Һаман боек.
Күзләрендә никтер ымсу юк.
Нигә анда күңелләрне айкап
Елатырлык тирән моңсулык?!
Дүрт стена кысасына кереп
Сулган, ахры, яшьлек, өмет, йөз.
Ул бит бары ире хозурында
Кирәк чакта дежур хатын-кыз.
Һәм ул түзә. Түзми кая барсын?!—
Бозга каткан инде итәге.
Бәхетлесез, диләр, сердәшләре —
Бәхеткә соң шулар җитәме?!
«Жигули»да һаман җигүле дә,
Бергә булыр өчен... вакыт юк!..
Алтын-көмеш тә бар, өлеш тә бар,
Ефәк-бәрхет тә бар... бәхет юк.

●

Алар аерылыштылар. Ире аны хыянәттә гаепләде.

*Суд хроникасыннан.*

Керфек очларына йолдыз кунган,
Ә төн үтә... Үтә йокысыз...
Юк, төн түгел — яшьлек үтә бугай,
Тартышалар уйда ике сүз:
«Сөям» — «Сөймим»...
Гомер буе бер сыныкны бүлеп,
Бер чишмәнең суын эчәргә
Меңләп вәгъдә биргән иде егет,
Күрешкәндә айлы кичләрдә.
Туй узса да, туннар тузмаган бит —
Гел яшә дә яшә гөрләшеп.
Әле кайчан гына әйбәт иде —
Үтәсең дәмени, и яшьлек?!
Китәсең дәмени соң, мәхәббәт,
Язмыш ярларында калдырып?!
Көндәлек гамь, мәшәкатьләр белән
Бөтенесен утка яндырып?!
Керфек очларына йолдыз кунган,
Кайда соң сез, зөфаф кичләре,
Татлы талгынлыкта сүнгән төннәр,
Тәнгә эссе салган хисләрең?!
...Кайтты бүген.
Кыштыр-кыштыр йөрде,
Нидер барлап, нидер исәплә.

Көндәгечә әзрәк салмыш иде —
Барып ауды аннан түшәккә.
Ни җылы сүз... Ни бер назлы караш...
Ә ул аны бүген нигәдер
Бик сагынып көткән иде эштән —
Аңламады шуны сөйгәне.
Стенага танау терәгән дә
Хырлап йоклый (йокы күрмиме?!)
Ир — ир икән, хатын хозурында
Арка җылытыр өчен ирмени?!
...Тәрәзәгә карап ай да арган,
Черем итә әнә йолдызлар.
Ә төн үтә... Үтәр яшьлеге дә,
Назга туймаганга җан сызлап.
Уйдан кичә бөтен үткәннәре —
Ерактагы татлы мизгелләр.
Искә төшә чит-ят комплиментлар,
Искә төшә чая-сизгерләр,
Аяк терәп карышса да акыл,
Йөриләр бит һаман күз атып,
Йөрәк сандыгына яшерелгән
Тылсымлы шул хисне кузгатып.
Искә төшә кемдер тәкъдим иткән
Умырзая... Затлы бүләкләр...
Тик киная белән аңлатылган
Күңелгә хуш матур теләкләр
Искә төшә...

●

«Малаем өйдән куып чыгарды.
Инде кая барыйм?..»

*75 яшьлек карчыкның редакциягә язган хатыннан.*

Кәфенлегең күптән әзер инде —
Әҗәл генә никтер соңлап йөри.
Ана, ана! Күпме газап күреп,
Инде шушы хәлгә төштеңмени?!
Кысыр еллар ишек шакыганда,
Иртә таңнан кырга чыгып чапкан,
Сабыена сынык ризык тапкан
Ул син түгел идеңмени, ана?!
Кеше булсын диеп, яна-яна
ВУЗга озатканда өмет белән,
Соңгы тиенеңне өзеп биргән
Ул син түгел идеңмени, ана?!
Улың доктор булды. Хәзер аңа
Хөрмәт белән карый бөтенесе.
Шуңа сөенеп туялмаган кеше
Ул син түгел идеңмени, ана?!
Ә ул хатлар язды:
«Эшем уңды...
Казанга кил...» диде —
Һәм син... килдең...

Оныгыңны кулга алып сөйдең...
Болай булыр диеп уйладыңмы?!
Яшәдең бит бары аның өчен...
Башта әйбәт иде. Улың гына:
«Ташла авыл гадәтләрен»,— диеп
Ычкындыра иде кайчагында.
Син заманча өйгә килеп кердең
Намазлыгың, наданлыгың белән,
Аерылып изге кануннардан —
Нигез ташларыннан, туган җирдән.
Синең өчен монда ят иде шул
Кием, ризык, сүзләр, гореф-гадәт!..
«Баш катырдың буш киңәшләр белән»
Таләп итеп киленеңнән әдәп.
Ул синеке түгел иде инде
(Ничек кенә рәнҗе, ела, даула),
Муен борылганга борылган баш —
Хатын ире булган синең бала.
«Авыл, авыл...» Гомер буе авыл
Синең өчен сафлык иле иде.
Килен исә ныгрgetak итеп әйтте,
«Бар, авылда, кортка, чере...»— диде.
Ничә тапкыр аэропорттан урап
Кире кайттың.
Авыл түренә соң,
«Миһырбансыз бала үстердем»,— дип
Ни йөз белән кайтып күренәсең.
Их, атасы исән булса икән!
Шул сугыш шул...
Сугыш харап итте...
Бер өйрәтер иде малаена
Ир булырга ничек кирәклеге.

●

«И бу яшьләр!.. Бала үстерүдән куркалар...»
*Әбиләр сөйләшүеннән.*

Нур сирпелә сыман күзләреннән —
Сөйкемле соң татар карчыклары.
Өс-башы пакь, сүзе тыйнак булыр,
Көлемсери күк җыерчыклары.
Һәркем киткәч, өйдә эшләр беткәч,
Тоташтырып сүзнең очын очка,
Хәл алырга диеп җыелалар
Ишек төбендәге утыргычка.
Сара әби монда яңа кеше,
Ул кунакка килгән төпчегенә,
Җиде улы аның — җиде җимеш —
Җидесенә карап җиде сөенә.
Җыештырган булды.
Ә көн озын.
Кала кала инде — җиңел бар да:

Аннан карап торды тәрәзәдән
Ишегалдындагы агачларга.
Чордашларын күреп, шунда чыкты —
Китте сүзләр, китте сорашулар:
— Ипекәйләр быел ничек уңды?
— Корымыймы таллар, чишмә-сулар?..
Якташлар да монда байтак икән —
Чәйгә чакыралар кыстый-кыстый.
Мөслимнеке берсе. Кат-кат әйтә:
— Керми калма берүк... пажалысты...
Яңаралар иске хатирәләр,
Тагын әллә ниләр искә төшә.
Тормыш — шөкер!
Сара әбинең тик
Бер нәрсәгә генә эче поша.
Төпчек улы һаман өйләнмәгән —
Һәм ул кат-кат шуны телгә ала:
— Әйбәт кызлар җирдә беткәнмени?
Һәм уфтана аннан:— Бала... бала.
Әбиләре кочагына поскан
Баг алмасы кебек сабыйларга
Карый да ул эчтән сызлап куя:
Күңләшүе күчә моңга-зарга.
Оныклары буйга җитеп килә,
Сөйдермиләр хәзер элеккечә.
«Төпчегемнең улын күрсәм бер...»— дип,
Нәзер әйтте инде әллә ничә.
Хөкемнәре кыска әбиләрнең:
Тормыш шундый җитеш! Имин еллар...
Өй тутырып бала үстермәгәч,
Бу дөньяның нинди кызыгы бар?!

## Заманага мирас

Куя язмыш сорау арты сорау —
Юк әле, юк тулы җавап биргән.
Югыйсә бит, газиз аналардан
Без мәхәббәт булып туган җиргә.
Туган яшәешкә дәвам булып,
Омтылабыз тоташ камиллеккә,
Ирләр, ирләр, дибез эре генә —
Кемнәр соң без — ирләр ахыр чиктә?!
Җан сөйгәннәр, дөрес, кайчак безне
Ил тоткасы диеп атый әле.
Без малайлар өчен һәр нәрсәне
Эшли ала торган әти әле.
Ләкин... Ләкин... һәрчак көчлеме без,
Юмартмы без назга-иркәләргә?
Авыр йөкне иңнән алып ташлап,
Салмыйбызмы нәфис җилкәләргә?
Һәр даим без батыр, намуслымы?
Безнең хакта түгелмени җырлар:
«Куркакларны дөнья күп үрчетте,
Кайда соң сез, кайда, мушкетерлар?!»
Кайда соң син, мсье Д'артаньян, һәй!

Дульсинея, уят Дон Кихотны —
Рыцарьларны сагына хатын-кызлар,
Аларга хас шул илаһи утны.
Мүкләнгән ир — ул ирмени инде
Ни хатын, ни Ватан карашында!
Шуңа мәллә казына кайберәүләр
Колба-ретorталар арасында.
Яңа токым homo sapienes дип,
Баш ваталар. Әйе, бик мөмкин эш,
Безгә алмаш булып туса җиргә
Ниндидер бер Нейтрон Протонович.
Хет тимердән, хет камырдан яса —
Аталардан күчкән геннар канда.
Электродлар ябыштырып кына
Ия булырбызмы яңа аңга?!
Омтылабыз һаман камиллеккә —
Башы аның ләкин табигатьтән.
Мәңге дәвам итәр кешелеккә
Хас шул акыл, шул көч, шул хис, шул тән.
Шуңа күрә әнә ирләр туа —
Шуңа гашыйк гомер язына без;
Я илаһи күккә ашабыз без,
Я гөнаһлы җирдә казынабыз.
Стандарт уй һәм стандарт кием
Әле бездә... Бер көн алар тузар.
Дульсинея, уят Дон Кихотны —
Рыцарьларны сагына хатын-кызлар.
Альфонс һәм Нероннарны түгел —
Ирләр бары ирләр булсын өчен,
Җир йөзендә яшәү һәм мәхәббәт
Байрак кебек балкып торсын өчен
Рыцарьларны сагына хатын-кызлар.
Дульсинея, уят Дон Кихотны.
Дөрләтсеннәр ирләр Прометейдан
Безгә күчкән шул илаһи утны —
Яшәү утын. Аны йөрәкләрдә
Киләчәккә алып барасы бар.
Сәгадәтле таңнар каршысында
Көрәшләрдә әле янасы бар.
Кояшыбыз баер — гомернең ул
Офыгына җитә инде менә.
Җавап бирәсе бар тормыш куйган
Сорауларның иң-иң мөһименә.
Җавап эзләп яшәү серләренә,
Гомер чишмәләре ага, ага.
Васыятьләр әле язасы бар —
Нинди мирас калыр заманага?!

1977

## Хәй Вахит

# ИКЕ КИЛЕН-КИЛЕНДӘШ[1]

КОМЕДИЯ, ИКЕ КИСӘКТӘ

Онытылмас дустым, талантлы артист һәм режиссер Рәфгать Бикчәнтәевнең якты истәлегенә багышлана.

**Автор.**

КАТНАШАЛАР:

Саҗидә — фермада сыер савучы кыз.
Шәрифҗан — колхоз председателе, урта яшьләрдә.
Камилә — фермада сыер савучы. Тол хатын.
Гаделша — олы яшьтә. Колхозчы.
Хәерниса — Гаделшаның хатыны.
Сәүбән — Гаделшаның олы малае. Инженер.
Разия — Сәүбәннең хатыны. Югары юридик белемле.
Рәүф — Гаделшаның уртанчы малае. Колхозда төзүчеләр бригадиры.
Әнәс — Гаделшаның кече малае, сигезенче классны тәмамлап йөргән чагы.
Бибигайшә — Гаделшаның бертуган сеңлесе.
Гыймран — Бибигайшәнең ире.
Сәхипҗамал — Саҗидәнең әнисе.
Кәримулла — урта яшьләрдә. Күрше район колхозыннан.

Вакыйга безнең көннәрдә авылда бара.

## *БЕРЕНЧЕ КИСӘК*

### БЕРЕНЧЕ КАРТИНА

Авыл тау сыртына җәелеп утырган. Ерактан сызылып таң атып килә. Беренче әтәч башлаган хорга башкалары кушыла, сыер, сарык мөңгерәүләре өстәлә, кайдадыр эт өреп куя — авыл йокысыннан уяна. Без Гаделшаның ишегалдын төсмерли башлыйбыз. Бер якта алты почмаклы өйнең стенасы, тәрәзәләре, өйалды. Каршы якта рәшәткә белән әйләндереп алынган бакча. Бакча түрендә мунча. Безгә аның алгы ягы, ишеге, баскычы күренә. Лапас белән янәшә нәзек бүрәнәләрдән салынган келәт. Лапаста Гаделшаның эш урыны.

Гаделша таңнан ук торып чыккан. Өйалдында Хәерниса күренә. Кулында чиләк белән тастымал.

**Хәерниса** *(келәттә йоклаган килененә генә ишетелерлек итеп).* Килен!.. Разия килен! Әле уянмадыңмыни? Сыер савылмаган. Көтүең соңга калмасын дим, килен! *(Үзе Гаделшага күз төшереп ала, иреннән шүрләбрәк куя, ахры. Шулай да ялгыш төшергән булып ку-*

[1] Пьеса, 1975 елда язылып, 1976 елда Татар дәүләт академия театрында куела башлады, бу театр сәхнәсендә инде йөздән артык уйналды. Әсәр шулай ук Минзәлә һәм Салават театрларында уйналып килә. 1977 елда бу әсәрне РСФСР Культура министрлыгы русчага тәрҗемә иттерде.

*лындагы чиләген җиргә ыргыта. Чиләк шалтыр-шылтыр килеп тәгәри).*

Г а д е л ш а *(хатынының бу кыланышларыннан канәгать түгел).* Үзең генә саусаң кулың калырмы?

Х ә е р н и с а. Мин күп сауган инде. Шушы яшемә җитеп килен хезмәте күргәнем юк. Өч малай үстереп. Бөтен эш үз өстемдә. Без килен булып төшкәч, унике кешегә хезмәт иттек. Ирләр торганчы дөнья эшен башкарып куяр идек.

Г а д е л ш а. Ишә идең инде ишәк чумарын.

Х ә е р н и с а. Килен!..

Г а д е л ш а. Яшь кеше, йокысы туймагандыр. Таң тишегеннән торырга күнекмәгән ул шәһәр халкы.

Х ә е р н и с а. Күнегер. Килен!..

Г а д е л ш а. Җитәр дим!

Келәттән Разия тавышы ишетелә.

Р а з и я. Хәзер, әнкәй, хәзер.

Х ә е р н и с а. Уяндыңдамыни, килен? Йоклар идең әле, яшь чакта йокы тәмле була ул. Сыерын да савармын, боерган булса, көтүен дә үзем генә куармын.

Р а з и я. Юк, юк. Үзем, үзем.

Г а д е л ш а. Кунакка кайткан дип тә тормыйсың.

Разия келәттән чыга. Йокысыннан айнып та өлгермәгән, кулында стакан.

Р а з и я. Хәерле иртә.

Х ә е р н и с а. Анысы нәрсәгә кирәк булды тагын? Стаканы дим?

Р а з и я. Сыер саварга дидең бит.

Х ә е р н и с а *(авыз эченнән мыгырдана).* Сабырлык бирсен ходаем.

*(Разиядан стаканны алып кулына чиләк тоттыра).* Мәле, бездә сыерны чиләккә савалар, килен.

Р а з и я лапаска сыер саварга кереп китә.

Г а д е л ш а. Сак була күр анда, тибә күрмәсен.

Урамнан С ә х и п җ а м а л к е р ә. Борчулы.

Г а д е л ш а. Хәерле иртә, Сәхипҗамал.

С ә х и п җ а м а л. Хәерле генә була күрсен. Хәерниса! Төн буе күземә йокы кермәде. Саҗидә һаман да күренми.

Х ә е р н и с а. Юкка борчыласың, Сәхипҗамал. Казан шәһәре күршедә генә түгел лә.

С ә х и п җ а м а л. Киңәшмәләре өченче көн үк беткән. Кайтып җитәрлеге бар иде инде.

Х ә е р н и с а. Айрапланы очмагандыр.

С ә х и п җ а м а л. Үзе юк, ә яман хәбәре кайтып җитте.

Х ә е р н и с а. Ходаем икән!

С ә х и п җ а м а л. Казанда сезнең Рәүфегез белән очрашканнар.

Г а д е л ш а. Рәүф?

Х ә е р н и с а. Алган эшебезне тәмамлап киләбез дигән хәбәре бар иде. Кайтып килә икән, алайса... Очрашсалар — шул гаеп булдымы?! Күршеләр, бергә үстеләр, араларында дуслык та бар бугай.

С ә х и п җ а м а л. Әйтергә тел әйләнми, гостиницада номер алып бергә кунып яталар ди.

Х ә е р н и с а. Рәүф беләнме?

Г а д е л ш а. Булмас. Саҗидә андый бала түгел.

С ә х и п җ а м а л. Камилә сөйләгән. Ул да Казанда иде. Үзем күрдем дип әйтә ди.

Хәерниса. Саескан Камиләсеме? Бигрәк кешесенә туры килгән икән. Аның авызына эләксә.

Сәхипҗамал. Нишлим, телеграмма сугыйммы, телефоннан сөйләшимме?.. Ай, Саҗидә, Саҗидә, башсыз, нәрсә уйлап кергәндер егет белән бер номерга. Нәселдә булмаганны. Кайтып кеше күзенә ничек күренер... Камилә янына кагылыйм булмаса...

Урамга чыгып китә.

Хәерниса. Ай, кыз кешегә бер дә килешә торган эш түгел.

Гаделша. Егет кешегә килешәме?

Хәерниса. Егет кеше егет кеше инде ул.

Өйгә кереп китәләр. Беркавым ишегалдында берәү дә калмый. Бераздан арт капкадан Рәүф белән Саҗидә күренә. Юлдан килешләре. Рәүфнең ике кулында ике чемодан, беләкләренә, муенына тартмалар, төргәкләр аскан. Саҗидә туктала.

Рәүф. Әйдә, нәрсә туктадың?

Саҗидә. Мин туры үзебезгә.

Рәүф. Кер әле.

Саҗидә. Кермим.

Рәүф. Сүзем бетмәде.

Саҗидә. Минем бетте.

Рәүф. Саҗидә дим!

Саҗидә. Кермим.

Рәүф. Керәсең. Тапшырасы бүләгем бар. *(Чемоданын ачарга җыена).*

Саҗидә. Мәшәкатьләнмә.

Рәүф. Сиңа атап алынган бүләк.

Саҗидә. Ул ни дигән сүз тагын?! *(Чемоданны ачтырмый, өстенә үк утыра).*

Рәүф. Ышан, мин ихлас күңелемнән. Беләсең килсә, мин аны синең өчен алудан бигрәк, үзем өчен алдым. Сиңа бүләк эзләве — үзе бер рәхәт булды.

Саҗидә. Рәүф, үпкәләмә, мин синең бүләгеңне ала алмыйм.

Рәүф. Син аны башта кара, бәлки ошатырсың.

Саҗидә. Ошаса да ала алмыйм.

Рәүф. Костюм! Үзең теләгән.

Саҗидә. Булачак хатыныңа кидертерсең.

Рәүф. Минем булачак хатыным — син. Биргән вәгъдәбез бар.

Саҗидә. Вәгъдәңне боздың, Рәүф.

Рәүф. Ах, Саҗидә, Саҗидәкәй, өзмә үзәгемне. Ничек яратканымны, өзгәләнеп сагынганымны беләсең.

Саҗидә. Алай бик сагына торган кеше айлар буена ташлап чыгып китми ул.

Рәүф. Күңел ачарга түгел, эш артыннан китәм.

Саҗидә. Эш үзебезнең колхозда да бетмәгән.

Рәүф. Үзебезнең колхозда? *(Көлемсери).* Мин бер айда бер еллыкны сугып алып кайтам. Монда кем бирә аны миңа?

Саҗидә. Бар нәрсәне дә акчага сатып алып булмый, Рәүф. Акчадан өстен нәрсәләр дә бар бу дөньяда.

Рәүф. Бозма кәефемне, Саҗидә. Ял итәргә кайттым.

Саҗидә. Әйе, баеп кайттың. Кесә тулы акча, чемодан тулы мал! Һәркемгә бүләк, ярты авылны сыйлаячаксың.

Рәүф. Кулымнан килә.

Саҗидә. Тик кешеләр күзенә ничек туры карый аласыңдыр.

Рәүф. Нинди кешеләрнең?

С а җ и д ә. Син күрше районнарда шабаш кылып йөргәндә, колхозыңдагы бар эшнең авырлыгын үз җилкәләрендә күтәреп барган кешеләрнең.

Р ә ү ф. Бәгырьгә кадыйсың.

С а җ и д ә. Миңа кадалса да ярыймы? Синең өчен миңа оят.

Р ә ү ф. Ә син оялма. Рәүфеңне һәр җирдә мактыйлар, кулыннан килмәгән эш юк.

С а җ и д ә. Сине туган колхозыңда мактасыннар.

Р ә ү ф. Читкә китеп эшләп йөрим икән, бәлки икебез өчен дә, алдагы көнебез өчен тырышамдыр.

С а җ и д ә. Юк, Рәүф, безнең интереслар башка.

Р ә ү ф. Менә нәрсә, аласыңмы бүләкне?

С а җ и д ә. Шабашник акчасына алынган бүләкне киеп йөри алмыйм.

Р ә ү ф. Тот та әйт инде, алайса, яратмыйм диген. Шул минутта ук араны өзәбез.

С а җ и д ә. Яратам мин сине.

Р ә ү ф. Яраткан кеше шулай эшлиме?

С а җ и д ә. Намусыңны сатып йөрүеңне яратмыйм.

Р ә ү ф. Аңламасаң да аңламассың икән. Кире беткән. Их, җүләр мин. Бер номерда икәү генә калгач, синең белән икенче төрлерәк сөйләшергә кирәк булган икән.

С а җ и д ә. Ничек?!

Р ә ү ф. Хәзер кешегә сөйләсәң, кеше ышанмас. Көләрләр.

С а җ и д ә. Синнән.

Р ә ү ф. Миннән шул. Булдыксыз дип. Бер номерда икәү генә кал да, икең ике почмакта йокла, имеш.

С а җ и д ә *(ярсып)*. Нәрсә-ә-ә?! Мин синең белән бүтән сөйләшергә дә теләмим! *(Капкага юнәлә)*.

Р ә ү ф. Саҗидә, гафу ит.

С а җ и д ә. Түбәнләнмә.

Р ә ү ф. Алайса, бар, бар! Үкенерсең әле.

С а җ и д ә. Бәлки үкенермен, әмма үзгәрмәм.

Р ә ү ф. Үзсүзлелек синдә җитәрлек инде ул.

С а җ и д ә. Үз сүзе булмаган кешене җенем сөйми. Кызганыч кеше.

Р ә ү ф. Синең урыында берәү булса...

С а җ и д ә. Әнә шул берәүләрне эзлә. Миңа ышанып ялгышкансың.

Р ә ү ф. Бер-беребезгә ышанып без икебез дә ялгыштык.

С а җ и д ә. Моннан соң ялгышмаска тырышырбыз. *(Чыгып китә)*.

Р ә ү ф. Бар, бар!..

Өйалды баскычында Хәерниса белән Гаделша күренә.
Тавышка, киерелә-киерелә, мунча алачыгыннан Әнәс чыга.

Х ә е р н и с а. И-и, Рәүф кайткан ич.

Рәүф авызындагы тәмәкесен тиз генә яшерә. Гаделша моны күрмәмешкә салына.

Р ә ү ф. Исәнме, әнкәй! Әти, исәнме! *(Гаделша кул бирми, эш урынына юнәлә)*.

Ә н ә с. Абый! *(Йөгереп килеп муенына асылына)*.

Р ә ү ф. Әни, менә нәрсә алдым сиңа. *(Бер чемоданнан шәл алып энисенең җилкәсенә сала)*.

Х ә е р н и с а. Ай, рәхмәт кенә яугыры.

Р ә ү ф. Мәгез әле, алып куегыз.

Төенчекләрне әнисенә бирә тора, ә әнисе аларны Әнәскә тапшырып бара. Әнәс исә аларны өй эченә ташый тора. Рәүфнең күзе әледән-әле этисендә: күрәме, янәсе.

Рәүф. Тот! *(Рюкзагыннан баян алып энесенә суза).*

Әнәс *(алмакчы иде, туктала).* Ай, кулны юмаган килеш ярармы? *(Кулларын чалбарына сөрткәндәй итә дә, уч төбеннән тузанны өреп, кадерләп кенә баянны ала, сөенеченнән нишләргә дә белми).* Рәхмәт, абый. *(Баянны сузып җибәрә).* Абый кайтты, баеп кайтты! Эти, күрдеңме, абый нәрсә алып кайткан.

Хәерниса. Белеп алдыңмы? Укуына комачауламасын.

Әнәс. Абыйлар белми алмыйлар, яшәсен безнең абыйлар!

Лапас эченнән бер кулына чиләк тотып Разия чыга. Икенче беләген тастымал белән ураган.

Разия. Ятсына. Ярты сөтен генә бирде.

Хәерниса. Ярар, көтүдән кайткач үзем савармын.

Рәүф. Җиңги, исәнме? *(Исәнләшә),* Кулыңа ни булды?

Разия. Сөте беләк буенча ага.

Барысы да шаркылдап көлә. Әнәс баянда туш уйный.

Хәерниса. Килен, бар, арт капкадан гына куып чыгар үзләрен. Алып китәрләр. *(Алып керим дип чиләкне алса, чиләк буш. Аударып ук күрсәтә).* Ә сөтең кайда?

Разия. Тибеп аударды.

Хәерниса. Хәерле каза булсын.

Разия лапаска юнәлә, хайваннарны көтүгә куа.

Разия *(йомшак кына итеп).* Көтүгә! Арт капкадан гына көтүгә! Әйдә, әйдә, кузгалыгыз. Сарык, сарык! Сыер, сыер!

Хәерниса *(түзеп тора алмыйча).* Ай, аллам икән, хайванны шулай куалар димени! *(Чыбык алып, дөнья туздырып үзе куа башлый).* Вәс, вәс! Пүчә, пүчә! Пүчә дим, бәдбәхет! *(Өйгә юнәлә).* Сабырлык бирсен ходаем.

Юл өстендәге чемоданнарны алып кереп китә.

Гаделша *(малаен чакыра. Кырыс).* Рәүф!

Рәүф этисе янына килә, үзе дә сизмәстән, кесәсеннән папирос чыгара, ялгышканын аңлап алгач, кире салмакчы була, әмма Гаделшаның үткен күзе моны күреп өлгерә.

Гаделша. Тарт, тарт. Яшереп тартырга яраганны.

Рәүф дәшмичә генә этисенә папирос тәкъдим итә. Гаделша аңа күз кырые белән генә карап ала да, үз кесәсеннән үз папиросын алып авызына каба. Рәүф зажигалка чыгара. Гаделша тагын папиросын үз шырпысы белән кабыза.

Гаделша. Я, мактан!

Рәүф. Мастерской, гараж төзедек. Договор буенча тиешле акчасын алып...

Гаделша. Сүз ул турыда түгел.

Пауза.

Рәүф. Кунарына урын булмады.

Гаделша. Син шуңа сөендең инде, оятыңны югалткан нәмәрсә. Ой, Рәүф, ошамыйсың син миңа. Кемгә охшап үсәсеңдер.

Рәүф. Син инде эти, бигрәк... Әллә нәрсәләр уйлый башладың.

Гаделша. Мин нәрсә, менә башкалар ни уйлар. Бигрәк тә кыз бала турында.

Рәүф. Уйласалар!.. Минем вөҗданым саф.

Гаделша. Акыл бар синдә, бар. Акылсызлык эшли торган акыл, Җүнсез!

Шул чакта бакча аша гына Шәрифҗан керә. Түгәрәкләнеп килә башлаган урта яшьләрдәге колхоз председателе. Үзенә күрсәтелә торган хөрмәтнең кадерен белеп яши, кеше белән йөрәген ачып сөйләшә торган гадәте бар. Күңеле күтәренке. Шат. Исәнләшә.

Шәрифҗан. Акча капчыгы да кайткан икән.

Рәүф. Исәнме, Шәрифҗан абый.

Гаделша. Иртәләгәнсең.

Шәрифҗан. Йокы качты бүген.

Гаделша. Нәрсә, исәрләнгәнсең, димме?

Шәрифҗан. Күзең очлы. Бар, бар, күңелдә нәрсәдер бар. Тантана бар.

Гаделша. Иртә таңнан ук?

Шәрифҗан. Эшләр шулайга табанрак китеп тора.

Гаделша. Ягъни мәсәлән?

Шәрифҗан. Мәсәлән, ягъни! *(Тәмәке кабыза).*

Гаделша. Нәрсәдән икән ул, тантана дим?

Шәрифҗан. Кысма. Сиңа барысын да белергә кирәк. *(Капкадан кергән Сәхипҗамалны күреп).* Ә-ә, Сәхипҗамал. Сезгә керген идем, берегез дә юк, кайда йөрисез?! Синнән сөенче, Сәхипҗамал.

Сәхипҗамал *(шикләнеп кала).* Әллә берәр...

Шәрифҗан. Сөенче, сөенче! Шатлык! Үзең генә бел! Сиңа да шатлык, безгә дә горурлык.

Сәхипҗамал. Шул кадәр горурланырлык нәрсә булыр икән ул?

Шәрифҗан. Ашыкма. Вакыты җиткәч белерсең. Бәхетле ана булып чыктың син, Сәхипҗамал. Нинди кыз үстердең бит. Күз өстендәге кашыбыз.

Сәхипҗамал. Төшеп калганнардан түгел анысы.

Шәриф. Саҗидә колхозыбызның мактанычы. Кайттымы? Әйт әле үзенә, Шәрифҗан абыең чакыра диген. Сүзем бар. Кисәтеп куярга телим. Моннан соң аңа үзен гел контроль астында тотарга кирәк. Яшьлегенә бирелеп, андый-мондый ярамаган шуклык эшләп ташламасын. Кеше белән сөйләшкәндә дә уйлап кына, артыгын ычкындырмыйча гына... Җаваплылык сизеп.

Сәүбән балыктан кайта. Кулында кармагы, чиләге. Аңа Гыймран да ияргән.

Гыймран. Кызык булмыйча, көтүне «Жигули» белән... *(Шәрифҗанны күреп, ярты сүзендә туктап кала).* Исәнмесез, иптәш председатель.

Шәрифҗан. Хәерле иртә. Күрдеңме, Сәүбән, авыл кая табан бара. «Жигули»га утырып көтү көтә! Ә син ташлап киттең. Юк, кул бирмим мин сиңа, исәнләшүен исәнләшәм, әмма кул бирмичә генә. Туган колхозын ташлап киткән адәм — якын күршем булса да — минем шәхси дошманым. Менә Гыймран ичмаса! Ничә ел читтә йөрсә дә кире әйләнеп кайтты. Аңа ике кулымны бирьюлы!

Гыймран. Туган туфрак тарта. Ни генә әйтсәң дә, үз колхозың.

Шәрифҗан. Менә бу ирләр сүзе. Юк, Гаделша ага, малайларың үзеңә охшамады. Колхозны сөендергәннәре юк диярлек. *(Рәүфкә ишарәләп).* Монысы этисе һөнәрен өйрәнеп алды да республика буенча акча сугып йөри. Кулы алтын, югары класслы оста. *(Сәүбәнгә).* Ә монысы, кесәсенә диплом салды да, Уфага тайды... Уйла, Сәүбән, уйла, синнән дә ирләр сүзе көтәбез. Синең кебек инженерлар кирәк хәзер авылга. Академиклар кирәк.

Гыймран *(Рәүф янына килеп җилкәсенә кага. Үзенә генә ишеттереп).* Ах сине! Үткен булып чыктың да соң, каене. Барыбыздан да уздырып җибәрдең. Без ул кадәр үк булдыра алмадык. Молодец, шу-

лай кирәк ул. Ни кыйланса шул килешә өйләнмәгән егеткә. Номер алып, менә дигән кыз белән...

Р ә ү ф *(якасыннан ала).* Мин җизни дип тормам, айкап та җибәрермен!

Г ы й м р а н. Әй син, чамалап! Берәү аны мактап ята...

Ш ә р и ф җ а н *(ишетеп калды).* Ни булган?

Г ы й м р а н. Юк ла. Рәүф белән Сәҗидә... Бер номерда...

Ш ә р и ф җ а н. Сәҗидә?

Г а д е л ш а. Һай!.. Чыбыксыз телефон эшли дә башлаган. Безнең авылның капкаларында да колак бардыр.

Ш ә р и ф җ а н. Бер номерда кунганнар диденме?

Г ы й м р а н. Күпмегә алдым, шуңа саттым гына. Көтү куганда Бибигайшә ишетеп кайткан.

Ш ә р и ф җ а н. Сәхипҗамал, кайда Сәҗидәң?

С ә х и п җ а м а л. Кайтып җитмәде әле.

Ш ә р и ф җ а н. Кайчан кайта?

С ә х и п җ а м а л. Я-а, шул хәтле төпченмәсәң!

Ш ә р и ф җ а н. Сәхипҗамал! Мин белергә тиеш. Һәр адымын, һәр сулышын...

С ә х и п җ а м а л. Ул кадәр, колхоз председателе булдым дигәч тә. Әллә тагын яшьләрне колхоз карары белән генә йөртер идеңме? Кайчан кайтса да сиңа барыбер түгелме? Кияүгә алырлык малаең юк.

Ш ә р и ф җ а н. Барыбер түгел шул. Кияү генәме, монда зуррак мәсьәлә бар дип торам ләбаса. Сөенеч дигәнем көенечкә әйләнмәсен. Кайчан кайта?

С ә х и п җ а м а л. Әнә Рәүфтән сора.

Х ә е р н и с а. Өендә Сәҗидәң, өендә. Кайтты. Бер җире дә ашалмаган. Нәрсәгә шулай дөнья куптарасыздыр.

Ш ә р и ф җ а н *(күршедәге йортка ишетелерлек итеп кычкыра).* Сәҗидә! Кер әле монда! Хәзер үк!.. Ә сез нәрсәгә җыйналдыгыз әле? Аю биетмиләр. Барыгыз, бар, эшегездә булыгыз. Дөньяга фаш итә торган хәбәр түгел. Вакыты җиткәч ишетерсез. Гаделша ага, сиңа калсаң да ярый.

Р ә ү ф. Миңа да ярый торгандыр дип беләм.

Ш ә р и ф җ а н. Сиңа мәҗбүри.

Шәрифҗан, Сәхипҗамал, Гаделша, Рәүфтән башкалар кайсы кая юнәлә, әмма берсе дә бөтенләй үк чыгып китми, я өйалдыннан, я ишек артына посып тыңлап тора. Мунча алачыгыннан Әнәс чыга, Шәрифҗан аны да куа.

Ш ә р и ф җ а н. Син дә бар әле, бар. Йокыңны туйдыр.

Ә н ә с кире кереп китә. Сәҗидә күренә.

С ә җ и д ә. Нәрсәгә кирәк булдым, Шәрифҗан абый? Фермага җыена идем.

Ш ә р и ф җ а н. Кайттыңмы? Анда гостиницадагы бер номерга кәҗә белән бүрене ябып куйганнар дип ишеттем. Шул хәбәр дөресме?

С ә җ и д ә. Кайсыбыз кәҗә дә, кайсыбыз бүредер әле.

Ш ә р и ф җ а н. Дөрес икән. *(Рәүф белән Сәҗидәне читкә алып).* Менә нәрсә, булмады ул хәл.

Р ә ү ф *(Сәҗидәгә төбәп).* Ничек инде булмасын. Минем янда калмыйча кем янында калды соң ул.

Ш ә р и ф җ а н. Калмады дим. Кызның яманатын чыгармакчы буласыңмы?

Р ә ү ф. Мин булганны әйтәм. Үз күзем белән күргәнне, үз кулларым белән...

Ш ә р и ф җ а н. Сындырырга кирәк синең ул кулларыңны!

Р ә ү ф. Сәҗидәнең минем янда калганын күрүче булды шул.
Ш ә р и ф җ а н. Кем?
Р ә ү ф. Саескан Камиләсе.
Ш ә р и ф җ а н. Ул нишләп йөри анда?
Р ә ү ф. Әҗәткә акча алып китте.
Ш ә р и ф җ а н. Камилә? *(Башына ябышып).* Булдыргансыз икән, алайса. Гайбәтегез бөтен авылга тарала икән инде. *(Сәҗидәгә).* Нишләдең син, нәрсә уйладың? Шушындый вакытта.
С а җ и д ә. Вакытына ни булган?
Ш ә р и ф җ а н. Депутатлыкка кандидатлар күрсәтү барамы?
С а җ и д ә. Барса соң.
Ш ә р и ф җ а н. Кандидат итеп сине күрсәтеп куйсалар ни диярсең?
С а җ и д ә. Беткән иде лаеклы кешеләр.
Ш ә р и ф җ а н. Лаеклы кешеләр күп. Менә сине дә лаеклы дип таптык. Үзем беренче булып тәкъдим иттем. Башкалар күтәреп алдылар.
С а җ и д ә. Сорамадым, тәкъдим итмәгез иде. Мин гаеплеме?
Ш ә р и ф җ а н. Синең шулай яхшы эшләгәнеңә, тырыш, актив, принципиаль булганыңа, өметле булганыңа, кем, мин гаеплеме әллә?!
С а җ и д ә. Әле соң түгел, сызып ташлагыз.
Ш ә р и ф җ а н. Соң шул инде. Характеристикаларың югарыга китте. Ах, сынаттың кызый, сынаттың. Вакытының туры килеп торуын кара син аның. Кирәк бит, нәкъ менә бүген! Моңарчы шундый әдәпле, инсафлы гына йөргән кеше. Ә бүген... Бүре белән бер номерда...
С а җ и д ә, Сезнең миңа ышанмаска хакыгыз юк.
Ш ә р и ф җ а н. Мин ышанам. Синең турыда мин бертөрле дә начарлык уйламыйм. Ә башкалар? Кеше бит ул сөйли, авызын томалап куеп булмый. Бер гайбәт таралса...

Шул чакта урам яктан К а м и л ә килеп керә.

Ш ә р и ф җ а н. Әнә, үзе!
К а м и л ә. Исәнмесез, барыгыз да. *(Сәҗидәгә).* Кайттыгыз дамы? Ха-ха!.. Шәрифҗан абый, хәерле иртә!
Ш ә р и ф җ а н. Нихәл, Камилә?
К а м и л ә. Кәнсәләргә килгәнегезне көтеп тормадым инде. Сездә йомышым бар, иптәш председатель, жалоба китердем. *(Кесәсеннән эзләнә).* Кая куйдым соң? Ә, менә икән. Язып бирсәң ышанычлырак. Телдән генә әйткән бер колактан керә, икенчесеннән чыгып китә. Кәнсәләргә китеримме, әллә монда гына биримме?
Ш ә р и ф җ а н. Тагын кем өстеннән?
К а м и л ә. Анда барысы да бәйнә-бәйнә язылган.
Ш ә р и ф җ а н. Өлгердең дә? Ай, Камилә, кайчан туктыйсың инде бу жалобалар биреп йөрүеңнән? Берәрсен әләкләмәсәң, тамагың туймыймы соң?
К а м и л ә. Йоклый алмыйм.
Ш ә р и ф җ а н. Китер. *(Ала да, карап та тормый, кесәсенә тыгып куя).*
К а м и л ә. Җавабына кайчан килим?
Ш ә р и ф җ а н. Әйтермен. *(Каршында Хәернисаны күреп).* Эшләргә комачаулыйсыз! Барыгыз әле, бар!
Х ә е р н и с а. Әйдә, Камилә, өйгә уз. *(Камиләне өйгә алып кереп китә).*
Ш ә р и ф җ а н. Нинди гадәттер ул яшьләр эшенә тыгылу. *(Рәүф белән Сәҗидәне читкәрәк алып).* Пычаксыз суйдыгыз. Шушындый

фокус күрсәтерсез дип уйламаган идем. Бигрәк тә, Сәҗидә, синә ышанычым зур иде.

Р ә у ф. Шәрифҗан абый, сез чамадан чыкмагыз. Ул нинди фокус, нинди ышанмау?! Сәҗидә минем күз тотып йөргән кызым, өйләнешергә җыенабыз.

Ш ә р и ф җ а н *(үз колакларына үзе ышанмый. Йөзе ук яктырып китте).* Өйләнешергә? Кабатла әле тагын, кабатла, нәрсә дидең? Туй итәргә сөйләштегезме? У-у, болай булгач котылдык. Өстемнән авыр йөк төшкәндәй булды. Туй! Бердәнбер чара — туй итәргә. Кайчан?

С ә җ и д ә. Кызыл кар яугач.

Ш ә р и ф җ а н. Ике көннән! Җыеныгыз, әзерләнегез!

С ә х и п җ а м а л. Чү, Шәрифҗан, әтисез бала дигәч тә, монда әнисе бар әле.

Ш ә р и ф җ а н. Сәхипҗамал, сезнең үзегез өчен кайгыртам.

С ә х и п җ а м а л. Син күбрәк үзең өчен борчыласың шикелле.

Ш ә р и ф җ а н. Яшермим, үзем өчен дә тырышам. Минем шулай: үзем өчен тырышуым — колхоз өчен тырышу. Колхозыңда үз депутатың булсын әле, начармыни! Хөкүмәттә үз кешең, колхоз вәкиле утыра дигән сүз. Берәр әйбер кирәк булдымы, министрга аны гына җибәрәсең. Аңларга кирәк, алдынгылардан булмасак, Верховный Советта урын бирерләр идеме? Ихтирам күрсәтәләр, уңышларны исәпкә алалар. Туй!

Моңарчы яшеренеп тыңлап торган бар кеше дәррәү кубып поскан урыннарыннан чыгалар.

Г ы й м р а н. Бәрәкалла! Туй!

Х ә е р н и с а. Ай ходаем, ничек болай кисәктән генә?

С ә у б ә н. Без әле кунакка гына кайткан җирдән туй мәҗлесенә эләктекмени?

Шул чакта Г а й ш ә килеп керә.

Г а й ш ә. Әй дим, син чәй эчәргә кайтасыңмы инде?

Г ы й м р а н. Чәй? Мәй эчәр көннәр җитте. Туй итәбез, сый-хөрмәтеңне әзерли башла.

Р ә у ф *(Сәҗидә янына килә).* Сәҗидә, син нәрсә дисең?

С а җ и д ә. Мәхәббәтсез өйләнешә торган заман түгел хәзер.

Р ә у ф. Мәхәббәтсез? Минме яратмыйм сине, минме?

С а җ и д ә. Шабашниклыкны өстен күргән кешедә нинди ярату булсын?!

Р ә у ф *(кабынып китә. Сер бирми).* Алаймыни? Ярый! Мин дә шулай дим шул, председательгә депутат кирәк булган өчен генә теләсә кемгә өйләнергә.

С а җ и д ә. Теләсә кемгә?

Ш ә р и ф җ а н. Ниткән сүз ул. Бергә уйнап үстегез, бергә укырга йөрдегез. Стена күршеләр. Тагын ни кирәк?!

С а җ и д ә. Мәхәббәт кирәк.

Ш ә р и ф җ а н. Бергә тора башлагач анысы да булыр.

С а җ и д ә. Ә миңа тора башлаганчы ук кирәк.

С ә х и п җ а м а л *(кызына).* Я, син! Олылар алдында әдәплерәк кылан.

Кешеләр ике төркемгә бүленәләр. Гаделша семьясы Рәуфне урап алган, калганнары Сәҗидә тирәсендә. Үгетлиләр, кысрыклыйлар.

Ш ә р и ф җ а н *(ишек алды уртасында бүкән өстенә менеп баса).* Менә нәрсә, бер-берегезгә үпкәләшкәнсез икән, онытырга вакыт.

С а җ и д ә. Аны оныту өчен айлар гына җитмәстер.

Ш ә р и ф җ а н. Айлар? Атна да юк. Ике көннән туй!

С а җ и д ә. Мин аңа ышанмыйм!

Р ә ү ф. Ышанмыйсың? Миңа? Ничә ел озатып йөрдем, ничә тапкыр үбештек.

С а җ и д ә. Барысын да үзең үк җимереп ташладың.

Ш ә р и ф җ а н. Туктагыз дим! Син нәрсә, уен эш дип беләсеңме, бөтен авыл, бөтен район синең өчен тавыш бирергә тиеш. Уйлыйсыңмы син шул хакта? Гомергә бер килә торган язмыш бу. Анда да бәхетле кешеләргә генә эләгә. Халык ышанычының нинди зур ихтирам икәнен беләсеңме син? Килешегез, башка чара юк.

С а җ и д ә. Шәрифҗан абый, сез мине ирексезләмәгез, мин үземне мәҗбүр итә алмыйм.

Р ә ү ф *(кызып китеп)*. О-һо! Ишеттегезме, нәрсә диде? Юк, сез ишеттегезме?! Мин аны мәҗбүр итәм, имеш. Ха-ха-ха! Болай булгач инде сөйләшеп торасы да юк. Рәхмәт, күрше, ачыктан-ачык әйтеп салганыңа. Ә минем өчен борчылма. Үз язмышымны табармын. Карар кылдым инде: бөтенләйгә авылдан китәм. Уфага! Менә абыйларга ияреп. Бетмәс әле дөньяда кызлар.

Г а д е л ш а. Хәл иттеңдәме инде? Әти-әниеңнең ризалыгын алырга да кирәк тапмадың, ә? Дөньяда кызлар эзләргә чыгып киткән кешенең булганы юк иде әле безнең нәселдә.

Р ә ү ф. Әти...

Г а д е л ш а, Дәшмә. Язмышың монда синең. Монда өйләнәсең.

Ш ә р и ф җ а н. Ике көннән үк!

Г а д е л ш а. Әйе, ике көннән!

Р ә ү ф. Әти, син мине ирексезләп өйләндерә дә алырсың, ә аны миңа чыгарга мәҗбүр итә алмыйсың.

Г а д е л ш а *(ялварып)*. Сәхипҗамал!

С ә х и п җ а м а л *(үтенеп)*. Кызым, синең сүзеңне көтәбез.

Ш ә р и ф җ а н. Саҗидә, күгәрченем!

С а җ и д ә. Әгәр дә инде кемнәрнеңдер авызын томалау өчен генә дисез икән, күз буяу өчен... Ярар, нишләмәк кирәк, карышып торып булмас, мин риза.

Ш ә р и ф җ а н. Менә шулай, акыллы бит ул.

Ишек алдында тантаналы гауга күтәрелә.

Г ы й м р а н. Риза, риза!

Г а й ш ә. Кыз риза!

Ш ә р и ф җ а н. Кыз да риза, егет тә риза.

Г ы й м р а н. Туй!

Р ә ү ф *(тагын Саҗидә янына килә)*. Нәрсә дидең?

С а җ и д ә. Ишеттең ич.

Р ә ү ф. Колакларыма ышанмыйм.

С а җ и д ә. Гомуми эш өчен шулай кирәк булгач.

Р ә ү ф. Шуның өчен генә?

С а җ и д ә. Ә башкача ничек булсын?

Р ә ү ф *(киреләнә)*. Өйләнмим! *(Әтисе муен тамырыннан тотып алгач)*. Ярый, ярый, өйләнәм, өйләнәм. Әмма онытма, аерылышырга туры килсә, колхоз идарәсенә йөгерде юк.

С а җ и д ә. Син йөгермәсәң, мин йөгермәм.

Р ә ү ф. Андый-мондый депутат итеп сайлый калсалар, минем өстән баш булмаска. Семьяда мин хуҗа.

С а җ и д ә. Семьяда тигезлек булыр.

Р ә ү ф. Минем сүз — ир сүзе.

С а җ и д ә. Минеке — хатын сүзе.

Р ә ү ф. Мин баш.

С а җ и д ә. Дилбегә минем кулда.

Р ә ү ф. Акчаны мин тотам.

С а җ и д ә. Акча синеке, кассир — мин.

Рәүф. Әгәр башка кешегә күзең төшсә, шул көнне үк китә аласың. Мин сиңа ирек бирәм.

Саҗидә. Андый ирекне миннән ала алмассың.

Энәс. Их-ма! Абый өйләнә, миңа да чират җитә!

Тавышлар. Туй итәбез!

— Туй!

Бары да әсәрләнгән. Кумәк җыр, күмәк бию башлана.

— Табыныңа сый-хөрмәтне
Мул итеп әзерләп куй.
Сал ачысын, сал татлысын,
Бөрлегәннәре белән,
Кушылабыз кодаларның
Бер дигәннәре белән.

Кызы сандугач икән дә,
Егете лачын икән!
Үпкәләп-ярсып йөрсә дә,
Яратуы чын икән.

Кызыбыз сандугач булса,
Егете бөркет икән.
Яшь чагында антлар эчеп,
Вәгъдәләр беркет икән.

— Туй итәбез! Туй!
— Табыныңа сый-хөрмәтне
Мул итеп әзерләп куй.
Куй ачысын, куй татлысын,
Бөрлегәннәре белән,
Кушылабыз кодаларның
Бер дигәннәре белән.

Ут сүнә. Музыка дәвам итә. Ут шунда ук кабына.

## ИКЕНЧЕ КАРТИНА

Ике-өч көн вакыт узган. Бакчада алмагач төбендәге өстәл артында Хәерниса утыра. Кайнана килененә эшне кушып кына тора.

Хәерниса. Килен, олы килен, самаварыңны өстәлгә утырт.

Разия. Хәзер, әнкәй. *(Өйгә кереп китә).*

Хәерниса. Бу көннәрне күрергә дә насыйп булыр икән. Баедым киленнәргә, биргәненә шөкер.

Разия самовар күтәреп чыга. Өстәлгә утырта.

Хәерниса. Менә шулай, шаулап торсын. Чәйнектә кайнаган суны эчеп, эч күпертер хәл юк. Инде бар, әзерләнгән ризыкларны подносы белән алып чык. *(Разия китә. Хәерниса самавар капкачын күтәреп, чүпрәк белән дүрт-биш йомырканы самавар суына тыга да, капкачын ябып куя. Разия поднос белән ризыклар алып чыга).* Ай, рәхмәт. Инде, килен, казан астына ягып җибәр. Аннан токмач кисәрсең. Аннан соң...

Гаделша камыт күтәреп кайта.

Разия. Ярый, ярый, әнкәй. *(Өйгә кереп китә).*

Гаделша. Бу туйның бетәсе булмады. Кемнәрне чакырасың тагын?

Хәерниса. Үз кешеләребез генә. Гыймран киявне.

Гаделша. Гыймран? Өч көн мәҗлес уздырып, берсеннән дә калдырмадык, җитеп тормасмы?

Хәерниса. Син катнашмый тор, ярыймы. Өч көн буе туй бара, ә никах укытканыбыз юк.

Гаделша. Гыймраннан укытмакчы буласыңмы? Шул алкоголиктан.

Хәерниса. Алкоголик булмаган мулланы табып кара син хәзер. Тәүфыйкка утырды инде ул. Мөфтигә кул биргән. Тәүбәгә килгән. Үзбәкләрдә дүрт ел мулла булып йөрде.

Гаделша. Дуңгыз тавыкка әверелгән дисәләр ышанырмын, әмма Гыймранның төзәлүенә...

Хәерниса. Бар әле син, бар, аяк астында чуалып йөрмә. Әтисе, сине кәнсәләргә чакырганнар иде.

Гаделша. Кәнсәләргә? Нәрсәгә икән?

Хәерниса. Тиз килсен диделәр.

Гаделша *(китәргә җыена)*. Шуны бел, рөхсәтем юк.

Хәерниса. Синнән сорап торырмын менә. Үз өемдә үз көем.

Капкада Гыймран күренә.

Гыймран. Әссәләмәгаләйкем!

Гаделша. Вәгаләй! *(Чыгып китә).*

Хәерниса. Әйдә, хәзрәт, әйдә, түрдән уз. Әйдә, кияү, озакка сузма. Кеше-фәлән югында...

Гыймран өстәл янына килә. Башы авырта, күрәсең. Хәерниса кулыннан озын сөлгене алып, чалма итеп урый.

Гыймран. Гаделша кайнагайны озатуың әйбәт булды. Аның да белмәве хәерлерәк. Баш китәрлек эш. Депутатка никах укыганны сизеп алсалар...

Хәерниса. Беркем дә сизмәс, боерган булса.

Гыймран. Хәер, шул әйткәнгә риза булсаң.

Хәерниса. Савап булыр.

Гыймран. Саваптан бераүнең дә тун теккәне юк әле.

Хәерниса. Буш итмәм. Әнә чуар тавык.

Гыймран. Китап тояклы хайванны мәгъкуль күрә күрүен.

Хәерниса. Сарык өмет итәр идеңме әллә тагын? Тамагыңа тыгылыр. Әле укый беләсеңдерме-юктырмы?

Гыймран. Юк ла, үз кешедән аламмы соң?

Хәерниса. Әйдә, әйдә, бәхилләтермен, башла.

Гыймран. Ике як та ризадыр бит инде?

Хәерниса. Риза булмыйча.

Гыймран. Аллага тапшырып башладым, алайса. *(Эченнән укый башлый).*

Разия *(өйдән)*. Әнкәй!

Хәерниса. Ни бар? *(Өйгә кереп китә).*

Гыймран *(укуыннан туктап башын тота)*. Ярыла.

Келәт артыннан Гаделша чыга. Кулында сумка. Хатынының хәйләсен аңлаган карт, кәнсәләргә бармаган. Өстәлнең икенче башына килеп утыра. Сумкасыннан пиво алып, Гыймранны кызыктырып тәмләп эчә башлый. Бер шешә аракыны да өстәлгә чыгарып куя.

Гаделша. Синең белән, кияү, сөйләшеп утырырга да вакыт тими.

Гыймран *(кызыгып-кызыгып пивога күз төшерә, әмма сорарга базмый)*. Кыздыра. Сусатты... *(Чәй эчә).* Без үзебез электрда кайнатабыз. Ни әйтсәң дә самаварга җитми инде.

Гаделша *(пиво эчә)*. Кара бу ләззәтне. Бәрәкалла. Бирим дигән колына, чыгарып куяр юлына. Куеп тор әле ул чәеңне. Сусаганны аны менә нәрсә баса.

Гыймран. Миңа килешер микән соң?

Гаделша. Сиңа килешә инде ул, сиңа.

Гыймран. Белмим шул.

Хәерниса *(ачык тәрәзәдән кычкыра).* Килен! Йомырка пешкәндер дә инде. Алып бир үзләренә.

Разия чыга. Самавар капкачын күтәреп, чүпрәктәге йомыркаларны ала. Моны күреп Гаделша әллә чыннан, әллә хәйлә корып ах-вах итә башлый.

Гаделша. Бу ниткән эш инде бу? Безнең Хәернисаның шул булыр инде аның. Теге чакта да өч сум югалгач, әй эзлибез, әй эзлибез, актармаган җир калмады. Аш ашаганда кастрюль төбеннән килеп чыкмасынмы. Лавровый лист дип салган. Менә хәзер тагын. Кара инде бу эшне. Хәтере булмаса да булмас икән. Һай, билләһи! Тапкан чүпрәк!

Гыймран. Нәрсә булды соң, кайнагай?

Гаделша. Соң, йомырканы бит, йомырканы, самавар суына... аяк чолгавычына салып пешергән.

Гыймран. Ә? Аяк чолгавы? Портянка? Самавар эчендә? *(Кулындагы чынаягын төшереп ук җибәрә. Күңеле болгана, укшый башлый).*

Гаделша. Тастымал дип бутагандыр инде.

Гыймран. А-ы, кайнагай, у-у!.. Салып бир әле. Бир әле... ы-ы... Тизрәк!..

Гаделша чәшкәне тутырып аракы сала. Гыймран ала да эчеп тә бетерә. Аннан бераз тынычлана.

Хәерниса *(тәрәзәдән кычкыра).* Кияү, башладыңмы?

Гаделша. Башлады, башлады. *(Тагын чәшкәләргә аракы агыза).* Тот, укшуың басылсын.

Гыймран. Син үзең дә.

Күтәреләр. Гыймранга җитә кала, җырлап ук җибәрә.

Иөгерә үрдәк күл күрсә,
Ике күзен сөртә-сөртә
Сүзе бетми бер күрсә.

Гаделша *(кулында чүпрәк).* И-и, дөрестән дә тастымал булган икән лә.

Өйдән Хәерниса килеп чыга. Мондагы хәлне күреп өнсез кала.

Хәерниса. Әстәгъфирулла!

Гаделша. Аста Гарифулла.

Хәерниса. Бу ни эшең, хәзрәт?!

Гыймран.

Дөнья куласа,
Бер әйләнә, бер баса.
Яки син аңа басасың,
Яки ул сиңа баса.
Кул кулны юа диләрме,
Ике кул битне юа.
Без шулай дөнья куабыз,
Дөньясы безне куа.

Хәерниса. Шул булдымы башлавың?!

Гаделша. Бетереп киләбез инде.

Хәерниса *(агачлар арасыннан бу күренешне фотога төшереп барган Әнәсне күреп ала).* Синең нишләвең тагын?

Әнәс. Никах мәҗлесен истәлеккә калдырам.

Гыймран. Нишләп бу кадәр яратам икән мин сине, дәү апай. *(Беләгеннән тотып әйләндерә башлый).*

Хәерниса *(иренә).* Синең эшең, җүнсез. Мунчага кертеп, бикләп куеп укытасым калган икән аны.

Гыймран. Кайне, кечкенә кайне, тарт әле шул гармуныңның колагын! *(Хәернисаны әйләндерә-әйләндерә бии).*

Дөнья куласа,
Бер әйләнә, бер баса.
Урта кайнем туенда
Басып калыйм булмаса.

Хәернисаны котыртып Гаделша да биергә тотына. Хәерниса ычкына алмый. Капкадан Сәҗидә белән Камилә кайтып керә. Мондагы хәлне күреп җанланып китәләр. Камилә биючеләргә үк катнаша.

Бас әле, бас, кодагый,
Бие әле, кодача.
Бер әйләнеп биегәннән
Гөнаһ булмый ләбаса!

Хәерниса *(Гыймран белән Гаделшадан ычкынып).* Дәрьяхтан сөрелгән нәмәрсәләр.

Камилә. Абау, Хәерниса апа, нәрсәбез килешмәде?

Хәерниса тузынып өйгә юнәлә. Аның артыннан Камилә белән Гыймран, Гаделша да иярә. Бирегә Сәҗидә белән Разия гына кала.

Сәҗидә. Разия апа, бер утырып серләшә дә алганыбыз юк. Киңәшәсем килә иде. Бу Рәүф белән нишләргә дә белмим.

Разия. Рәүфкә ни булган?

Сәҗидә. Мин дигәнчә түгел.

Разия. Син бигрәк, Сәҗидә. Беренче көннән үк иреңне кулга алмакчы буласыңмы?

Сәҗидә. Мин аны өйләнешкәнче үк кулга алырга теләдем. Әгәр дә тыңламаса, кияүгә чыкмам дигән сүзем дә бар иде.

Разия. Ә син сүзеңнән кире кайтма.

Сәҗидә. Менә бит, уйламаганда-көтмәгәндә туй ясаттылар.

Разия. Туйда утырдың, кияүгә чыкмадың түгелме соң?

Сәҗидә. Ай, аны син дә сизгәнсең икән.

Разия. Арагызда нидер бар. Көйләнеп кенә китә алмыйсыз.

Сәҗидә. Крылов мәсәлендәге кебек. Беребез җиргә, икенчебез күккә тарта. Мин аның үз колхозын ташлап, читтә эшләп йөрүенә риза түгел.

Разия. Мин дә риза булмас идем. Берең депутат бул, икенчең шабашниклыкта йөр, имеш. Адәм көлкесе, кеше ни сөйләмәс.

Сәҗидә. Җир ярылса, җир тишегенә кер дә кит.

Разия. Мал артыннан куам дигәч тә...

Сәҗидә. Кемгә кирәк аның малы?! Хәзер мал җыеп түгел, хезмәттән ямь табып яшиләр. Бергә-бергә эшләп йөрүләре нинди күңелле булыр иде.

Разия. Кемгә охшап шулай булгандыр. Әткәй дә андый түгел, абыйлары да.

Сәҗидә. Тазалыгына, чибәрлегенә масая.

Разия. Аңа калса, син дә чибәр дә бит...

Сәҗидә. Кулыннан килмәгән эше юк, шуңа азына.

Разия. Ирне ир иткән дә хатын, чир иткән дә хатын, дигәннәр. Син аның ул гадәтенә юл куйма. Нык тор.

Сәҗидә. Торуын нык торам да, куркып та куям шул. Арттырып җибәрмәгәем дим. Түзәр түзәр дә, бер ачуы ташып китсә, тотар да тәртәгә тибәр. Аннан терсәгеңне тешләргә бик теләрсең дә...

Р а з и я. Аңа ук җибәрмәбез.

С а җ и д ә. Ярсып китсә.

Р а з и я. Беләсеңме, без аны бергәләп акылга утыртырга тиеш.

С а җ и д ә. Ай, туганым апа, икебез бер сүздә булсак.

Р а з и я. Булабыз.

С а җ и д ә. Аның йоклаган намусын уятырга кирәк.

Р а з и я. Тезгенне тота бел, ычкындырма.

С а җ и д ә. Үз дигәнемне итмәсәм...

Р а з и я. Итәбез!

С а җ и д ә. Туганым апа, алайса, мин сиңа ышанам. Ярдәм кирәк булса...

Р а з и я. Ышан!

С а җ и д ә. Ике килен-килендәш?

Р а з и я. Ике килен-килендәш.

И к е с е б е р г ә:
Икесендә бер киңәш!
Кирәк булса, берсен-берсе
Аклый да белер алар,
Саклый да белер алар,
Яклый да белер алар.
Ике килен-килендәш,
Икесендә бер киңәш!

Капкада Рәүф күренә.

Р ә ү ф. Саҗидә, кулга су салып тор әле.

Саҗидә чүмеч белән су алып килә. Разия табыннан нидер алып өйгә кереп китә.

Р ә ү ф. Туй вакытында да фермадан кайтып кермисең. Бер караңгыдан икенче караңгыга хәтле.

С а җ и д ә. Минем эшне кем эшләсен.

Р ә ү ф. Өч көн ял тиеш.

С а җ и д ә. Тиеш нәрсәләр күп булыр ул.

Аулаграк урынга алып килгәч, Рәүф, Саҗидәнең чүмечен бүкән өстенә алып куя да, үзен көчләп кочакларга, битеннән, чәченнән, муеннарыннан комсызланып үбәргә керешә. Бу шулкадәр көтмәгәндә эшләнә ки, Саҗидә югалып кала, карышса да, Рәүф кочагыннан тиз генә ычкына алмый.

С а җ и д ә *(тыны кысылып)*. Җибәр! Кычкырам!

Р ә ү ф. Әйдә печәнлеккә!

С а җ и д ә. Нием калган анда?

Р ә ү ф. Тавыклар йомырка салгандыр, җыеп төш.

С а җ и д ә. Акылыңны җуйма! *(Өстен-башын рәтләмәкче була).*

Р ә ү ф *(тагын кысрыклый)*. Саҗидә дим!

С а җ и д ә. Бу ни эшләвең?

Р ә ү ф. Син минем хатыным! Мин синең ирең!

С а җ и д ә. Каян килеп?!

Р ә ү ф. Туй итмәдекме?!

С а җ и д ә. Ул бит гайбәтчеләрнең авызын томалар өчен, күз буяр өчен генә эшләнде. Минем сиңа кияүгә чыкканым юк. Без ирле-хатынлы түгел.

Р ә ү ф *(башын йомарлап тота)*. О-ой! Бел аны, урамга чыгып кычкырам!

С а җ и д ә. Кычкыр.

Р ә ү ф. Шаркылдап көлсеннәр дисеңме? Синең көлүең дә җиткән.

С а җ и д ә. Минем синнән көлгәнем юк, Рәүф.

Р ә ү ф. Ә бу нәрсә?! Бергә йокламыйсың да. Кич булдымы, үз өеңә кереп китәсең.

С а җ и д ә. Әнинең үзенә генә күңелсез.

Р ә ү ф. Миңа менә бик күңелле. Син сандык өстендә, мин койкада ялгызым. Кара бу хурлыкны! Мәсхәрә! Өйләнде Рәүф! Кәләш алды. Хатынына кагылырга да хакы юк.

С а җ и д ә. Көчле мәхәббәт юк икән, чәчемнән сыйпарга да, күзләремнән үбәргә дә ирек бирмәм. Үлсәң үләргә, әмма мәхәббәтсез үбешергә ярамый, дигән Чернышевский.

Р ә ү ф. Чернышевский? Кайсы? Ә, тегеме? Кызганыч, үзе белән очрашырга туры килмәде. Сөйләшеп карар идем мин аның белән. Ә безнең эш башка. Өч көн туй иттек, мәҗлес уздырдык. Котладылар, бүләкләр бирделәр. Тигез гомер, татулык теләделәр. Яшь бала теләделәр.

С а җ и д ә. Ә нәрсә үзгәрде?

Р ә ү ф. Ничек үзгәрмәсен ди.

С а җ и д ә. Туй бетүгә ташлап китәргә җыенасың түгелме?

Р ә ү ф. Дөнья куам. Синең өчен дә куам. Җәфәккә төрәм әле мин сине, Саҗидә. Алтынга күмәм. *(Саҗидәнең бармагына алтын балдак кидертмәкче).*

С а җ и д ә *(кидертми).* Бирәү бар бит инде.

Р ә ү ф. Хәзер Казанда өчәрне кияләр. *(Балдакны ыргытмакчы була да, кесәсенә салып куя).* Авылны макта, шәһәрдә тор дигәннәр. Менә акча җыям да Казанның уртасыннан өч бүлмәле коопиративный квартира сатып алам. Машина алам.

С а җ и д ә. Машинадан соң нәрсә алырсың икән?

Р ә ү ф. Сатсыннар гына, вертолет алам!

С а җ и д ә. О! Вертолеттан соң?

Р ә ү ф. Һава шары!

С а җ и д ә. Шартлар бит ул, Рәүф.

Р ә ү ф. Сине дә үземнән калдырмыйм. Берең анда, берең монда яшәмәбез.

С а җ и д ә. Мине дә шабашниклыкка?

Р ә ү ф. Ял итеп кенә йөрерсең. Китап укып, мәхәббәт романнары...

С а җ и д ә. Мин сыер саварга яратам шул.

Р ә ү ф. Кирәк икән, өч-дүрт сыер алып бирермен, сава бир.

С а җ и д ә. Эх, Рәүф, аңламасаң да аңламассың икән.

Р ә ү ф. Гомер буе фермада эшләрсеңме? Акчасы шактый да... Авыр эш.

С а җ и д ә. Җиңел түгел. Соң, Рәүф, син үзең дә авыл малае бит. Колхоз сине кеше итте. Укытты, һөнәргә өйрәтте. Мондый һөнәр белән үзебезнең колхозда да менә дигән итеп яшәргә була. Син шабашниклыкта йөрисең, ә колхоз төзүчеләрне читтән чакыра. Горурлыгың, намусың кайда синең, Рәүф!?

Музыка башлана.

Р ә ү ф.
Багышладым сиңа язмышымны,
Белмәсәм дә аның азагын.
Мең мәртәбә күтәрергә әзер
Артык яратуның газабын.

Б е р г ә:
Башка язмыш миңа кирәкми,
Телгәләмә алай йөрәкне.

С а җ и д ә.
Өстеңдәге зәңгәр күлмәгеңнең
Зәңгәрлеген кояш ашаган.
Безнең болай гомер итүебез
Аерым торуларга охшаган.

Б е р г ә:
Күзләремә шулай карама,
Тоз саласың йөрәк ярама.

К а м и л ә *(килә).* Әй сез, пар күгәрченнәр! *(Көйләп).* Икегез, икегезнең битегез, икегез дә пар килгәнсез, тигез гомер итегез. *(Сер итеп кенә).* Кияү өегез кайда булды? Кайда йоклыйсыз?

Р ә ү ф. Нәрсә, Камилә апа, әллә безнең уртага кереп ятмакчы буласыңмы?

К а м и л ә. Кит, әдәпсез. Шушы ирләр... Барысы да бер чыбыктан сөрелгән. *(Күзе түтәлдә).* Карагыз бу нәнекәйләремне. Игезәкләрмени. *(Түтәлдән ике кыяр өзеп ала).* Закускага кирәк була, тегеңә.

Капкада Кәримулла күренә. Каршына өйдән Хәернисa чыга. Гыйльман килә.

Х ә е р н и с а. Әйдәгез, әйдә. Камилә, ирең килде.

К а м и л ә. Нишләп ирем булсын ди. Квартирантым гына ич ул. Квартирга керткән бер кешене иргә саный башласаң, счет төймәсе җитмәс. Болын кадәр өйдә бер үзем нишләмәк кирәк. Җан бирә башласаң авызыңа су салыр кешең юк. Иптәш булыр дип кертәм инде шунда.

Х ә е р н и с а. Үзең тагын гел ир затыннан кертәсең. Югыйсә, укытучы кызлар да була.

К а м и л ә. Тәмәке исен яратам.

Г ы й м р а н. И-и, Кәримулла тәмәке тартмый.

К а м и л ә. Тартмаса, мыегы мәһабәт. Җеннәр куркытырга.

Рәүф белән Кәримулла сөйләшә башлыйлар. Яннарына Гыймран килеп җитә.

Х ә е р н и с а. Камилә, мә, кыяр ал. Дүрт-бишне генә.

К а м и л ә. Урлап алдым инде.

Х ә е р н и с а. Ничәне урладың соң?

К а м и л ә. Икене.

Х ә е р н и с а. Алайса, мә, өчне генә бирәм.

Түтәлдән өзеп алып Камиләгә кыярлар бирә. Камилә аларны Кәримулланың кесәсенә сала.

К ә р и м у л л а. Күттерeп кенә йөрисең, бригадир. Синекеләр беркөн үк кайтып җиттеләр.

Р ә ү ф. Казанда йомыш килеп чыкты.

Г ы й м р а н. Әйе, йомыш йомышлап йөргән ул гостиницада...

Р ә ү ф *(кисәтеп).* Гыймран абый!

К ә р и м у л л а. Ничек соң, Рәүф, юллар уңдымы?

Р ә ү ф. Ярыйсы. Зарланырлык түгел. Егетләр дә канәгать. Килешкәнне бирделәр.

К ә р и м у л л а. Без дә монда бер эш башларга тәвәккәлләп торабыз әле.

Р ә ү ф. Ишеттем, сөт комплексы салырга җыенасыз икән.

К ә р и м у л л а. Договор кесәдә инде.

Р ә ү ф. Өлгер үзең.

К ә р и м у л л а. Гадәтне беләсең, тимерне кызуында сугарга яратам.

Г ы й м р а н. Әйе, кызганда сугарга кирәк. Әйдәгез, юыйк!

Р ә ү ф. Җитәр инде сиңа. *(Кәримуллага).* Эш нәрсәгә терәлде соң? Осталар җитмиме әллә?

К ә р и м у л л а. Нәкъ өстенә бастың, энекәш, җитми. Вакыт үтә. Колхозның үз егетләре кайсы кая таралып беткән. Договор кесәдә, срогы күрсәтелгән, ә кеше җитми, синең кебек остам юк. Тәкъдим ясарга килдем. Әйдә, миңа.

Р ә ү ф. Кул астында эшләргә күнекмәгән.

К ә р и м у л л а. Кул астында түгел, минем белән бертигез. Миңа күпме, сиңа да шул кадәр.

Г ы й м р а н. Тыңла син аны, кайне, тыңла. Уңарсың.

Р ә ү ф. Уйлап карарга була.

Г ы й м р а н. Нәрсә уйлап торырга. Юабыз!

К ә р и м у л л а. Өч айда «Жигули»га утыртам мин сине.

Р ә ү ф. «Жигули»лык кына үземдә дә рәт бар ла минем.

К ә р и м у л л а. Артыгы кесәңне тишәр мәллә? Я, ризамы?

Р ә ү ф. Миңа ярап бетәр микән? Сиңа килешә ул, читтән килеп эшлисең. Мин бит шушы авылныкы. Үз колхозыбызда договор белән эшләү әллә ничегрәк. Халыктан уңайсыз. Әткәйдән дә... Болай да инде...

К ә р и м у л л а. Булса соң? Анда да, монда да колхозга эшлибез. Хөкүмәткә. Күңел ачарга чакырмыйм. Бер караңгыдан икенче караңгыга хәтле бил бөгәргә. Тәртипне беләсең, минутын да бушка югалтты юк.

Г ы й м р а н. Әйдә, кайне, икеләнеп торма. Хезмәт кайда да почетта ул.

К ә р и м у л л а. Шабашник диләр дә... Бездән башка төзеп карасыннар әнә. Колхозчыларың алынса да, алар эленке-салынкы кузгалганчы, без эшләп арган булабыз. Без бер айда бастырып куйганны алар ел буена.

Г ы й м р а н. Әйттең сүз. Өч-дүрт ел диген.

Р ә ү ф. Бригадаңда кемнәр?

К ә р и м у л л а. Кемнәр дип... Ике студент. Үзебезнең авылныкылар. Казанда укыйлар. Бер аспирант, ике кандидат. Сыналганнар. Ученый халык, акча дигәндә чиркәү салырга әзер.

Р ә ү ф *(кулын уып)*. Болай тәкъдимең кызыклы... Шулай да, белмим әле, егетләр, хатын да чыгымлап тора.

Г ы й м р а н. Хатын? Соң, хатының, әлбәттә, карышыр. Син бит читкә чыгып эшлисең. Нинди хатынның туйдан соң ук ирен читкә чыгарып җибәрәсе килсен. Ә Кәримулла сиңа үз авылыңда эшләргә тәкъдим итә. Үз өеңдә, хатының янында.

К ә р и м у л л а. Ашарга да расход чыкмый. Чистагон белән аласың.

Г ы й м р а н. Әйдә, кайне, ике дә уйлама. Өйләндең, башка чыгасың булыр. Төп йортта калырга әнә энең үсеп килә.

К ә р и м у л л а. Я, кул суктыкмы?

Р ә ү ф. Договорны күрсәт әле. *(Алып карый.)* Әйе... Иртәгә җавабын бирермен.

Г ы й м р а н. Их, мине чакырсалар, уйлап торыр идемме?

К ә р и м у л л а. Син нәрсәгә?... Коръән укытмыйм, сөннәткә утырту яшеннән узганмын.

Г ы й м р а н. Алай димә... Камилә белән икегезгә никах укырга кирәгем чыкмагае.

К ә р и м у л л а. Рәүф, мин сиңа ышанам!

Р ә ү ф. Килешербез!

Г ы й м р а н. Вәт шабашниклар!

Музыка.

Г ы й м р а н. Табыш итү хараммыни
Мөхәммәт өммәтенә.
Ни бар җирдә тиңләшерлек
Акчаның кодрәтенә?!

Б е р г ә: Их-ма, шабаш!
Акча бездә — кунак түгел,
Акча безгә — юлдаш!

К ә р и м у л л а. Кесәләрең калын булса,
Күңелкәйләр үсәләр.
Караңгы төнең яктыра
Калын булса кесәләр!

**Бергә:** Их-ма, шабаш!
Дөньяларын гөрләтергә
Яралган бу баш!

**Рәүф.** Тотынса безнең егетләр,
Сызгансалар җиңнәрен,
Читтән генә карап торсын
Әкияттәге җеннәрең.

**Бергә:** Их-ма, шабаш!
Уйнап тора безнең кулда
Агач, тимер, таш!
Их-ма, шабаш!

Бию.

Гыймран. Җилле булды бу. Киттек миңа, юабыз! Мин кабарга юнәтә торам. Сез кибеткә кагылыгыз.

Кәримулла. Үз заводыңныкы гына юкмыни?

Гыймран. Ремонтка япкан идем. Туй арасында кул җитешмәде. Озакламагыз, кибете ябылмасын.

Китәләр, шул чакта капка төбенә җиңел машина килеп туктый. Сәүбән белән Шәрифҗан керә.

Хәерниса. Кунакка кайттым дигәч тә, председатель машинасына утырып йөрмәсәң.

Сәүбән. Үзе төшерми.

Шәрифҗан. Ю-ук, мин сине колхозда кал дип кыстамыйм. Үзе теләмәгән кешенең кирәге юк миңа. Син киңәш кенә бир. Фикереңне әйт, инженер фикерен.

Сәүбән. Ул кадәр зур төзелеш турында...

Шәрифҗан. Зур булмаса, синнән киңәш сорар идемме? Булгач булгач, булсын инде. Сөт фабрикасы салырга исәплибез. Үзе бер комбинат. Алар тәкъдим иткән типовой проектны күрдең. Аның безгә ошамаган якларын да аңлаттым. Хәзер синең фикерең кирәк.

Сәүбән. Уйламыйча гына...

Шәрифҗан. Ә син уйла. Уйла, мин ашыктырмыйм.

Хәерниса. Шәрифҗан күрше, кил, утыр әле. Үзең котыртып җибәргән туйда рәхәтләнеп утыра да алмадың. Баш кода булып утырасы кеше.

Шәрифҗан. Бушап буламы? Туй башлануга чакыртып алдылар бит. *(Өстәл артына утыра).* Расходы зур булачак. Шул шабашникларның чырайларын күрмәс өчен әллә ниләр бирер идем, тик аларсыз булмый! Тизрәк төзеп бетерергә кирәк. Ә ул халык акча күрсә, җәһәннәм шайтанына әверелә инде. Аларга түлисе акчага тагын бер библиотека салып булыр иде. Менә бит ул үз төзүчеләреңнең, үз инженерларыңның булмавы нишләтә. Барыгыз да ташлап китәсез бит.

Хәерниса. Бик зурдан купмадык инде. Хәлдән килгәнчә генә.

Шәрифҗан. Зурысы алтын туйларын үткәргәндә булыр.

Камилә *(өстәл янына килә).* Шәрифҗан абый, исәнме?

Шәрифҗан. Исәнме, Камилә.

Камилә *(председатель алдына ризыклар куеп).* Мин һаман да көтәм.

Шәрифҗан. Нәрсә көтәсең, Камилә?

Камилә. Жалобама җавап көтәм.

Шәрифҗан. Көт, көт. Жалобаны тикшерми калдыра торган гадәтебез юк.

Камилә. Озакка китмәдеме дим.

Шәрифҗан. Әниеңнән дә тиз генә тумагансыңдыр.

К а м и л ә. Ялгыштым, ахры. Күрәсең, сразы райкомга язарга кирәк булгандыр.

Ш ә р и ф җ а н. Син нәрсә?! Тәмле ризыкның тәмен бозарга килдеңме?

К а м и л ә. Ризык кына түгел, минем нервларым бозылып бетте инде. Әле дә түзәм, берәү булса...

Ш ә р и ф җ а н. Берәү булса тырышып эшләп күрсәтер иде. Нормаңны үтәгәнең бармы?

К а м и л ә. Ул үләтләрдән нәрсә аласың. Сыер димәсәң хәтере калыр. Кәҗә дә алардан күбрәк сөт бирә хәзерге заманда. Җыен чуттан чыккан миңа эләкте. Исемлектән төшеп калган нәрсәләр.

Ш ә р и ф җ а н *(сагаеп кына).* Менә нәрсә, Камилә, телеңне тыя белмәсәң! *(Өстәл артыннан торып ук китә. Үзен кулга алырга тырыша).* Сезнең белән башың Себер китәр! *(Бераз йөренгәч.)* Жалобаң тикшерелде.

К а м и л ә. Кем тикшерде? Саҗидәме? Тапкансыз кемгә тапшырырга.

Ш ә р и ф җ а н. Алдынгы сыер савучы. Депутатлыкка кандидат.

К а м и л ә. Аңа тудырылган шартлар миңа да тудырылса... Сыерларның бер дигәннәре анда. Комбикорма да — күпме кирәк — аңа. Башкасы да... Аның урынында булсам, мин дә алдынгылыкны бирмәс идем.

Ш ә р и ф җ а н. Оятың юк синең, Камилә. Саҗидәнең фермадан чыкмый эшләгәне күз алдыңда. Ә син, ничә карама...

К а м и л ә. Тол хатын шулай күзгә күбрәк чалына инде ул. Әзрәк кенә кыеграк бастыңмы...

Ш ә р и ф җ а н. Ә син кыек басмаска тырыш.

К а м и л ә. Эх, бер бәхеткәйләрең булмаса булмый икән. Иң җүнсезләре миңа эләгә. Сыерларымнан да уңмадым, ирләремнән дә. *(Кире әйләнеп килеп.)* Үпкәләштән булмасын, Шәрифҗан абый, мин моны болай гына калдырмыйм. Райкомга язам.

Ш ә р и ф җ а н. Югал! Югал күземнән!

Ишегалдында уңайсыз тынлык урнаша. Күбесе өйгә кереп китә. Камилә дә күздән югала. Бераздан Шәрифҗан янына Саҗидә килә.

Ш ә р и ф җ а н. Тикшерүнең актын бүген үк идарәгә кертеп чык. Өчегез дә кул куйган булсын.

С а җ и д ә. Без акт язып тормадык.

Ш ә р и ф җ а н. Язмыйча булмас. Ишеттең, ничек яный.

С а җ и д ә. Ул хаклы.

Ш ә р и ф җ а н. Нәрсә?!

С а җ и д ә. Шәрифҗан абый, Камиләнең жалобасы дөрес. Иң начар сыерлар барысы да аңа бирелгән.

Ш ә р и ф җ а н *(үзен кулда тотарга тырышып).* Син дә шуны кабатлыйсыңмы? Камиләнең сөйләнүе әле бер хәл, менә синең!.. Чәчләрең үрә торыр! Инфарк алырсың сезнең белән! *(Бераздан ярсуын баса төшкәч).* Шуның өчен җибәрдемме мин сине? Кляузникны яклап, минем дәрәҗәне төшерергә.

С а җ и д ә. Хаклы булмасагыз да, мин сезне якларга тиеш идемме?

Ш ә р и ф җ а н. Мине түгел, колхоз председателен. Ышанган идем мин сиңа.

С а җ и д ә. Мин дөреслекне яклыйм.

Ш ә р и ф җ а н. Мин атаң башын яклыйммы?

С а җ и д ә. Шәрифҗан абый, кайда жалоба булса, тикшерергә мине җибәрәсез.

Ш ә р и ф җ а н. Син депутат. Синең сүзең закон. Дәүләт кешесе. Халык хезмәтчесе. Менә күрсәт хезмәтеңне халыкка.

С а җ и д ә. Аңламадым: халыккамы, сезгәме?

Ш ә р и ф җ а н. Колхозга.

С а җ и д ә. Беренчедән, мин әле депутат түгел.

Ш ә р и ф җ а н. Булмасаң, булырсың. Сайланмаслык кешеләрне кандидат итеп күрсәтмибез без. *(Каршына урын күрсәтә.)* Утыр әле. Кем сине үстерде, кем күтәрде?

С а җ и д ә. Халык.

Ш ә р и ф җ а н. Соң, кем әйтә халык түгел дип. Әлбәттә, халык. Сүз дә юк. Шулай да? Халык күп бит ул. Кандидатура күрсәткәндә синең исемеңне беренче булып кем атады? Менә мин. Шәрифҗан абыең. Дөрес, башкалар күтәреп алдылар. Әмма дә ләкин беренче булып мин авыз ачтым, синең исемең минем авыздан чыкты. Менә шулай, Саҗидә акыллым. Аңлаган кешегә аңларлык, син минем депутат.

С а җ и д ә *(аягына баса)*. Шәрифҗан абый! *(Бераздан.)* Камилә минем турыда да дөрес әйтә. Сыерларның иң яхшылары миндә. Кормасы да, башкасы да. Кирәкми миңа аерым шарт тудыру.

Ш ә р и ф җ а н. Тудырсаң да ярамый, тудырмасаң да.

С а җ и д ә. Бергә эшләгән иптәшләремнән оят.

Ш ә р и ф җ а н. Ә менә миңа оят түгел. Яхшы сыерларга да хөрмәт кирәк. Теләсә кемгә тапшырып булмый.

С а җ и д ә. Сыерга хөрмәт, ә кешегә?

Ш ә р и ф җ а н. Кешесенә карап.

С а җ и д ә. Менә шул, Шәрифҗан абый, минем өчен генә аерым шарт тудырмагыз. Бөтенебезгә дә тигез булсын.

Ш ә р и ф җ а н. Син депутат буласы кеше. Төрле кешеләр белән очрашырга туры килер. Президиумда утырырсың. Һәр адымың күз алдында булачак. Эшеңдә дә башкалардан аерылып торырга, алдынгы булырга тиешсең. Синнән үрнәк алачаклар.

С а җ и д ә. Мин үз көчем белән ирешергә телим.

Ш ә р и ф җ а н. Шулаймыни? Мин тагын сине икенче эшкә, җиңелрәккә, югарыракка күтәрергә кирәк булыр дип йөри идем. Лабораториягәме, мөдирлеккәме. Ә сиңа дөреслек, тигезлек кирәк икән. Ярый. Үзеңә үпкәләрсең. *(Кычкыра.)* Камилә!

Камилә шундук килеп җитә. Председательнең боерыгын көтә. Шәрифҗан өстәлгә килеп чәшкә тутырып аракы сала да күтәреп эчә. Закуска каба. Шуннан соң гына Саҗидәгә борыла.

Ш ә р и ф җ а н. Бүгеннән башлап, алайса, Камилә сыерларын син алырсың. Шарты белән.

С а җ и д ә *(аптырап кала)*. Ничек инде?

Ш ә р и ф җ а н. Нәрсә ничек?

С а җ и д ә. Кисәктән генә.

Ш ә р и ф җ а н. Үз теләгең.

С а җ и д ә. Мин үз сыерларыма ияләшкән идем инде. Алар да миңа ияләштеләр.

Ш ә р и ф җ а н. Зыян юк, болары да ияләшер.

Ишегалдындагылар берәм-берәм бергә җыйналалар. Гаделша да якыная.

Ш ә р и ф җ а н. Ә, Камилә, сиңа...

К а м и л ә. Әйе, Шәрифҗан абый.

Ш ә р и ф җ а н. Сиңа аның сыерлары.

К а м и л ә. Саҗидә группасы?

Ш ә р и ф җ а н. Ферма мөдиренә әйтегез, Шәрифҗан абый шулай кушты диегез.

Камилә. Алмаштырырга! Минем урынга Сажидә, Сажидә урынына мин. Шәрифжан абый, болай булгач, бәлки депутатлыкка да?

Шәрифжан. Жалобаларны күбрәк язсаң, син булырсың. Ашың бик тәмле булды, Хәерниса апа. Бүген тамактан башка ризык үтмәстер.

Чыгып китә. Ишегалдындагылар бар да аптырап кала. Берәү дә сүз дәшми.

Пәрдә.

## *ИКЕНЧЕ КИСӘК*

### ӨЧЕНЧЕ КАРТИНА

Көн кичкә авышкан. Капкадан Рәуф кайтып керә. Мунчага күз төшерә. Сөенече эченә сыймый.

Рәуф. Әни! Разия җиңги! Сажидә!

Өй тәрәзәсеннән Хәерниса, өйалдында Сажидә күренә.

Хәерниса. Ни бар, ут каптымы әллә?

Рәүф. Әни җаныем, мунча яктыгызмыни?

Хәерниса. Яктык, яктык, өлгерә торгандыр да инде.

Рәүф. Тизрәк кыймылдагыз. Ашыгам.

Хәерниса. Куырма ул кадәр! *(Тәрәзәдән югала. Шунда ук өй алдында күренә).* Сажидә килен, карап чык, томаларга вакыт түгелме икән?

Сажидә. Хәзер карармын, әнкәй.

Рәүф. Кара, кара, берәүләрнең кече килене.

Хәерниса. Суы кайнарланып җиттеме икән? Беренчесенә үзе гез керерсез.

Сажидә *(Рәуфнең үзенә генә).* Бу ни эшең?

Рәүф. Нәрсәдер арка кычытып тора.

Сажидә. Егетлек түгел бу, Рәуф.

Рәүф. Арка юарга да ярамагач, нәрсәгә өйләндем соң мин?

Рәүфнең кәефе шәп, авызы ерылган. Өйгә кереп китә.

Разия. Мунча? Ах, мунча. Борчылма, бер хәйләсен табарбыз. *(Китә).*

Лапаста Гаделша күренә. Камыт төзәтә. Сажидә мунчага кереп китә. Ул бер кереп, бер чыгып, мунча карап йөри. Су ташый.

Хәерниса. Мин боларны һич кенә дә аңлап бетерә алмыйм әле. Сажидә белән Рәүфне әйтүем. Кияү өе дә булмады, ахры.

Гаделша. Башка сөйләшер сүзең юкмы соң?

Хәерниса. Йокларга кодагыйга кереп китәләр. Бергә яталармы икән?

Гаделша. Синнән сорап торырлар. Инде тагын кайда, ничек йоклаганнарын да тикшереп йөрмәсәң. Тыгылма яшьләр арасына. Үз эшләрен үзләре белерләр.

Хәерниса. Аерым яткач ул ни була.

Гаделша. Син үзең дә миннән аерым йоклыйсың ич.

Хәерниса. Безнең инде телгә алырлык калмаган.

Гаделша. Әнә мунча ягылды. Мунчага бергә кергәч, тагын ни кирәк.

Х ә е р н и с а. Әле кергәннәре юк.

Г а д е л ш а. Ягылгач керерләр. Томалаганда аң карагыз, исле була күрмәсен.

Х ә е р н и с а. Катнашма хатын-кыз эшенә.

Г а д е л ш а. Синнән өйрәндем.

Гыймран белән Сәүбән өйдән чыга. Гыймранның кулында сәгать. Төзәтергә утыра. Коралы: чүкеч-келәшчә.

Г ы й м р а н. Менә син инженер, зарплатаң күпме? Синең ай буе эшләгәнеңне мин ике-өч көндә сугып алам. Һөнәр әйбәт минем. Менә Гаделша кайнагайныкы төслерәк. Әнә ул колхозга камыт-ыңгырчак, арба-чана, тырма-сәнәк төзәтә. Ә мин колхозчыларга хезмәт күрсәтәм. Кемдә радио-телевизор ватыла, кемдә газ көйсезләнә...

Г а д е л ш а. Эшләмәгән эше юк, кинәндергән төше юк.

Г ы й м р а н. Кем чакырса шуңа барасың.

Г а д е л ш а. Кем күбрәк түли.

Г ы й м р а н. Бушка селкенеп йөрергә мин! Ә менә син, кайнагай, дөрес эшлим дисеңме? *(Сәүбәнгә сөйли).* Ул да кай чакта аерым кешеләргә эшли. Тәрәзә рамымы шунда, өстәл-урындыкмы. Ә акча алмый, рәхмәткә эшли, янәсе. Дарымга. *(Гаделшаның үзенә.)* Син безнең профессиянең бәясен төшерәсең, һөнәрне кимсетәсең. Син акча алмагач, миңа ничегрәк?

Г а д е л ш а. Синең һөнәр түгел, кәсеп дип атала. Шабашник син.

Г ы й м р а н. Ә менә, кайнагай, синең профессия үлеп бара. Синең һөнәрнең киләчәге юк. Атлар бетә, машина заманасы. Минем замана.

С ә ү б ә н. Кайдан өйрәндең син, җизни, техникага? Укымадың да шикелле.

Г а д е л ш а. Каян килгән өйрәнү ди ул. Чамалый инде шунда, барысыннан да аз-маз, аннан-моннан. Химиясен дә...

Г ы й м р а н. Ә менә анысын үзләштереп булмады.

Г а д е л ш а. Самогонны яхшы куасың дим.

Г ы й м р а н. Тссс! Әкренрәк син, кайнагай. Башны төрмәгә илтеп тыгарсың. Кирәк чагы була. Берәр әйбер юнәтим дисәң дә алдан йөри торганы булсын. Куян тотарга да эт кирәк. Былтыр әнә, Бибигайшәне Кавказга алып бардым. Быел Кырымда ял итәргә исәп. Хәзер халык ялга чыктымы — көньякка агыла. Синең, кайнагай, булганың бармы ул якта?

Г а д е л ш а. Бар. Бер мәртәбә генә. Севастопольдә. Фашистларны куганда.

С а җ и д ә. Син, Гыймран җизни, үзеңне әткәй белән чагыштырма. Әткәй колхозга эшли, ә син үз кесәңә.

Г ы й м р а н. Усал булыр, ахры, бу киленебез, усал булыр. Разия килен төсле җайлы булмастыр бу.

С а җ и д ә. Кешесенә карап. Безнең йорт хәзер бөтен авылга күренеп тора. Күзгә каршындагы кебек.

Г ы й м р а н. Син депутат булгач күренер инде. Мин сезнең семья члены түгел. Аерым торам.

С а җ и д ә. Барыбер — җизни.

Г ы й м р а н. Җизнине хөрмәт итәргә кирәк.

С а җ и д ә. Никах укып йөргән өченме, сөннәткә утыртып?

Г ы й м р а н. Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз дигәннәр. *(Төзәтә торгач, сәгатьнең пружинасы зыңгылдап ычкына.)*

С а җ и д ә. Җитте сиңа паразит булып яшәргә. Безнең колхозда мулла-мәзин штаты юк.

Гыймран. Ниткән мулла?! Кеше сорагач, сүз тыңлап кына. Үлем-җитем була, күмәргә кирәк, чакыргач ничек бармый каласың. Мин дә синең шикелле, килен, халык хезмәтчесе. Без икебез дә халыкка хезмәт итәбез.

Гаделша. Тапты чагыштырырга! Син агу чәчеп йөрисең, кияү, кеше агулап.

Хәерниса *(мунча карап чыга, башында бүрек)*. Саҗидә, килен! Рәүф! Мунча өлгерде. Бик парлы, бик әйбәт булган. Барыгыз, кереп чыгыгыз. Ашыкмагыз, рәхәтләнеп юыныгыз.

Рәүф *(өйдән сумка тотып чыга)*. Саҗидә, әйдә. Мин күлмәкләрне алдым. Мунчала-сабын анда бардыр.

Саҗидә *(югалып кала)*. Тукта, сөлге кирәк булыр. *(Өйгә кереп китмәкче.)*

Рәүф. Алдым, анысын да алдым. *(Сумкасын күрсәтә.)* Менә.

Мунчага юнәлә. Саҗидә урыныннан кузгалмый. Хәерниса боларны бик игътибар белән күзәтә. Шул чакта өйалдына ашыгып Разия килеп чыга.

Разия. Саҗидә! Саҗидә, син кайда?

Саҗидә. Монда мин, монда.

Разия. Онытып торам икән, сине фермага чакырганнар иде.

Саҗидә. Кайчан?

Разия. Күптән түгел. Бер малайны йөгерткәннәр. Әйтергә кушты. Нәрсәдер булган, ахры, анда. Кайсыдыр авырган диме.

Саҗидә. Ни генә булды икән?

Разия. Зинһар тизрәк килә күрсен дигәннәр.

Саҗидә. Харап икән. Йөгерергә туры килә инде, алайса. Кара, мунчага кереп булмадымыни инде? Ярар, эссесе калса, соңыннан гына юынып чыгармын. *(Капкага йөгерә. Туктала).* Рәүф, син мине көтеп торма инде. Кызу чагында кереп чык. *(Урамга чыгып китә.)*

Хәерниса *(Гаделшага шыпырт кына)*. Әйтмәдемме мин сиңа!

Рәүф бер сүз әйтә алмыйча авызын ачып кала. Аннан кулындагы сумкасын җиргә күтәреп бәрә дә, Разия каршысына килеп баса. Текәлеп аңа карап тора.

Рәүф.
Ике килен-килендәш,
Икесендә бер киңәш?

Хәерниса. Я, нәрсә булса да аңладыңмы?

Гаделша. Нәрсәсен аңламаска. Киленне фермага чакыртып алдылар. Ашыгыч эш килеп чыккандыр.

Хәерниса. Әй, синең белән сөйләшеп торган мин җүләр.

Гаделша. Анысына кул куям.

Рәүф. Барыгыз, керегез мунчага, кем чираты!

Хәерниса. Бибигайшә! Кияү! Барыгыз. Үземә беренче мунча ярамый, башыма каба.

Гыймран белән Гайшә мунчага юнәләләр.

Хәерниса. Яңа себерке кирәк булса, келәттә. Кияү ике себеркеләп чабынырга ярата ул. *(Гаделша белән өйгә кереп китә.)*

Гыймран. Келәттә дидеме?

Гайшә. Әйдә, берсе җитмәгән тагын. *(Ирен мунчага алып кереп китә.)*

Разия. Нәрсә, Рәүф, җырлыйсың килдеме әллә?

Рәүф. Җылыйсым килә.

Разия. Кызык булыр иде ир кешенең үкереп җылаганын тыңлаулары.

Р ә ү ф. Көтмәгез, анысы булмас. Ә менә мин сезне, ике килен-килендәш, кызган табага бастырмасам!

Р а з и я. Ничек булыр икән ул?

Р ә ү ф. Голодовка игълан итәм. Ашаудан баш тартам. Бүгеннән башлап авызыма бер тәгам ризык капмыйм. Менә шул чакта карап карарбыз.

Р а з и я. Озакка барыр микән ул?

Р ә ү ф. Кирәк булса ай буена.

Р а з и я. Әй, бичара, бөтенләй хәлдән таячаксың икән. Коры сөяккә әйләнәчәксең. Ул чакта кемгә кирәгең калыр соң?

Р ә ү ф. Скелетка әйләнсәм дә, аның өчен барыбер түгелмени?

Р а з и я. Шабашник булып йөрергә көчең калмас дим.

Шул чакта Әнәс мәктәптән кайта. Портфелен ачык тәрәзә аша гына өй эченә ыргыта.

Ә н ә с. Нәрсә, Сәҗидә җиңгине фермага чакыртып алдылармыни? Шәп булган, мунчага керергә иптәш юк дип тора идем, арка юарга. Абый, бергә керәбез.

Р ә ү ф. Синең беләнме? Шул гына калды!

Ә н ә с. Нигә, гел икәү керә идек ич. Моңарчы яраганны моннан соң нишләп ярамас икән?

Р ә ү ф. Әнәс! Яхшы чакта телеңне тый! Юкса, үземә үзем ышанмыйм! *(Капкага юнәлә.)*

Ә н ә с. Абау, котырган бу! Псих!

Р а з и я. Хатының кайткач, кая китте, дип сораса, нәрсә дияргә?

Р ә ү ф. Сорамас.

Р а з и я. Әгәр сораса?

Р ә ү ф. Дүрт ягым кыйбла!

Р а з и я. Ярар, дүрт якка чыгып китте диярмен.

Рәүф тузынып урамга чыгып китә. Разия Рәүф ташлап калдырган сумканы алып өйгә юнәлә.

Ә н ә с. Нәрсә пешердегез, эчемдә бүреләр улый. *(Өйгә кереп китә. Шул чакта мунча ишеге ачылып, анда Гыйльмранның башы күренә. Ишегалдында берәү дә булмагач, ярты тиклем үк чыга. Ялангач. Тирә-якны күзәтә.)*

Г а й ш ә т а в ы ш ы. Нишли инде?

Г ы й м р а н. Булмый бу себерке белән генә, чыбыкка әйләнеп беткән. Яңалары келәттә дидеме?

Г а й ш ә т а в ы ш ы. Мә, ичмасам, җәймә бөркән.

Ак җәймә бөркәнеп Гыймран мунчадан чыга да, як-ягына карангалап, келәткә йөгерә. Менә ул аннан каен себеркесен тотып чыга. Ләкин нәкъ шул вакытта капкадан Камилә килеп керә. Гыймран шунда келәт алдындагы мичкә артында посып калырга мәҗбүр була.

К а м и л ә *(ярсыган)*. Әй, кайсыгыз өйдә?

Х ә е р н и с а *(чыга)*. Кем ул, синме, Камилә?

К а м и л ә. Кайда йомран?

Х ә е р н и с а. Нинди йомран?

К а м и л ә. Киявегез. Сездә диделәр.

Х ә е р н и с а. Гыймранны әйтәсеңмени?

К а м и л ә. Йомран. Кайда нәрсә күрсә, шуны үз оясына ташучы.

Х ә е р н и с а. Мунчада алар, мунчада.

К а м и л ә. Мунчасыннан өстерәп чыгам. *(Мунчага табан юнәлә.)*

Х ә е р н и с а. Чү, нишләвең?! Ул анда юынып ята. Тукта дим! Шәп-шәрә ир янына...

К а м и л э. Шэп-шэрэ ирлэрне күрмэгэнме? *(Мунча ишеген дөбердэтэ.)* Әй, йомран, чык. Вакытым юк. Ач ишегеңне дим! Ачык икэн ич. Монда берэү дэ юк. *(Хэернисага бармак яный да мунчага кереп ук китэ. Өйдэгелэр бу гаугага аптырап ишегалдына чыгалар. Камилэ мунчадан эйлэнеп чыга.)*

К а м и л э. Монда юк. Кайда ул?

Х э е р н и с а. Ничек булмасын, лэүкэ астында качып калганмы эллэ?

К а м и л э. Карадым. Бөтен җирне актарып чыктым. Анда хатыны гына.

Х э е р н и с а. Нэрсэгэ дип шул кадэр ярсыйсың, ни булды соң?

К а м и л э. Өч мэртэбэ телевизорымны төзэтеп китте. Төзэткэн саен бер тавык та бер савыт. Ә эшенең рэте юк. Белэ ничек төзэтергэ кирэген, бер атнага гына чыдарлык итеп. Тагын чакырсыннар тегене. Тагын куйсыннар бер тавык та бер савытны. Якасыннан алырмын дип килгэн идем. Ничава, элэгер эле. Түзэрлегем калмады, өенэ кереп үз телевизорын алып чыгам.

Х э е р н и с а. Алай ярамас, Камилэ.

К а м и л э. Аңа ярыймы тол хатынны алдап йөрергэ?

Х э е р н и с а. Өе бикледер.

К а м и л э. Тэрэзэсен ватып керэм.

Х э е р н и с а. Синнэн булыр да.

Г а д е л ш а. Үзеңне гаеплэрлэр.

К а м и л э. Газны төзэтэ, радионы ватып китэ. Радионы төзэтэ, сэгатьне ватып китэ. Чамалый. Барысы да төзек булса йомранны кем чакыра. Мошенник! Халтурщик! Аферист! Судка бирэм. Шуны авылдан кудырмасам.

Артык чыдап тора алмый, Гыймран яшеренгэн җиреннэн чыгарга була.

Г ы й м р а н. Кемне судка бирэсең? Кем аферист?

Х э е р н и с а. Эстэгъфирулла!

Ишегалдындагылар Гыймранны шул хэлендэ күреп, кайсы сискэнеп китэ, кайсы көлэргэ тотына.

Х э е р н и с а. Ай ходаем, кияү, синме бу? Нишлэп болай йөрүең?

К а м и л э. Миннэн качып калмакчы булгандыр.

Г ы й м р а н. Син нэрсэ тавыш күтэреп намуслы кешегэ яла ягып йөрисең? Нинди гаебем бар, тоттыңмы?

К а м и л э. Тотылмаган карак карак түгел дисеңме? Ашыкма, бер элэгерсең эле.

Г ы й м р а н. Колхозның энэсенэ дэ тимим. *(Кулындагы ике себеркенең берсен Камилэгэ ыргыта. Камилэ аны тотып ала.)*

К а м и л э. На кой черт сиңа энэ, арбасы белэн төяп кайтмагач.

Г ы й м р а н. Ишеттегезме, шаһит булыгыз, үзен судка бирэм.

К а м и л э. Бирермен мин! Бэбэгеңне чукып алырмын. *(Себерке белэн айкана).*

Г ы й м р а н. Аның телевизорының лампасы бозылганга Гыймран гаепле булган.

К а м и л э. Кулыңнан килерлек булмагач, нигэ тотынасың?

Г ы й м р а н. Синең белэн бэйлэнгэн мин җүлэр. Февраль!

К а м и л э. Нэрсэ диде? Мыскыллавымы? Ни дигэн сүз ул февраль?

Г ы й м р а н. Тулы түгел дигэн сүз.

К а м и л э. Ах, шулаймыни эле... Мультфильм!

Гыймран себеркесен күтәреп Камилә өстенә килә башлаган иде, җәймәсе сүтелеп, тәненнән шуышып төшә башлады. Камилә дә себеркесен күтәрә. Кылычлар белән сугышалармыни, себеркеләр белән фехтование башлана. Гыймран Камиләдән котылу өчен ишегалдында йөгереп йөри. Камилә аның артыннан калмый, җәймәсен тартып төшермәкче була. Гыймран камыт алып, шуның белән сакланмакчы. Камилә камытны Гыймранның муенына киертеп куя. Аннан ике себерке белән аркасын чаба башлый. Мунча кертә. Икесе дә тәмам аргач кына туктыйлар.

Гыймран. Нәрсә җыйналдыгыз, таптылар цирк!

Камилә. Телевизор төзәтелгән булсын. Бүген кич татарча спектакль. Синең аркада карамый калмам.

Гаделша. Бер тавык та бер савытың бармы соң?

Камилә. Моңарчы ашаганын да костырам әле мин аның. Әйдә, үземнән калдырмыйм.

Гаделша. Шушы килешме, урам буйлап?

Камилә. Индиядән килгән турист диярләр.

*(Мунчадан Гайшә чыга. Киенгән. Кулында Гыймранның костюмнары).*

Гайшә. Әйдә, кер.

Гыймран. Чәнчелеп китсен мунчасы.

Гаделша. Монда гына, ишегалдында гына керттеләр аны мунчага. Бик кызуы әлакте, җан тирләре чыккандыр.

Гыймран *(ак җәймәсе өстеннән костюмын кия-кия).* Мине алай җиңел генә әләктерә алмаслар.

Гаделша. Син балык кебек, тотылгач та кулдан шуып чыгасың.

Гыймран. Гыймран диләр аны.

Урамнан Шәрифҗан керә.

Шәрифҗан. Нәрсә шул кадәр тавышлана бу күршеләр дисәм, Камилә белән Гыймран монда икән.

Гыймран коелып төшә, ярты киенгән хәлдә лапаска йөгермәкче була. Әмма хатыны аны мунчага өстери. Аннан икәүләшеп үз өйләренә йөгерәләр. Алар артыннан Шәрифҗан гаҗәпләнеп карап кала.

Шәрифҗан. Бу ниткән әкәмәт тагын?

Камилә. Шәрифҗан абый, үзегезнең керүегез шәп булды. Сезнең янга да сугылырмын дип чыккан идем.

Шәрифҗан. Тыңлыйм сине, Камилә.

Камилә. Иптәш председатель, ишеттегезме, алдынгылыкны яулап алдым бит.

Шәрифҗан. Ишетмәскә, бөтен авыл шаулый. Барысы да синең турыда гына сөйлиләр.

Камилә. Бер ярым норма бирдем. Мин сауган сөт елга булып ага. Мактаулы Сәҗидәгез ярты норма белән утырып калды. Бүгеннән беренчелек минем кулда.

Шәрифҗан. Синең кулда, нык тота күр.

Камилә. Телләрендә Камилә дә Камилә иде. Камилә начар эшли, Камилә артта сөйрәлә... Менә хәзер күрсеннәр инде!

Шәрифҗан. Күрдек инде, Камилә, синнән дә булдыклы кешебез юк икән. Бер көн дигәндә ничек әйләндереп салдың.

Камилә. Җыелыш кайчан була? Сәҗидәне ярышка чакырам. Депутатның үзен.

Шәрифҗан. Курыкмас микән синең белән ярышырга.

Камилә. Шәрифҗан абый, әйтегез әле, кем хәзер бездә алдынгы, Сәҗидәме, минме?

Шәрифҗан. Син булмыйча, син, Камилә, син. Безнең мактанычыбыз.

Камилә. Шулай булгач, газетта нишләп аның рәсеме, минеке түгел?

Шәрифҗан. Ул депутатлыкка кандидат.

К а м и л ә. Ә ни өчен ул кандидат? Мин түгел? Бездә депутатлыкка алдынгыларны сайлыйлар. Уйлагыз, уйла, иптәш председатель, үзегез уңайсыз хәлдә калмагыз. Әле соң түгел. Югыйсә бит, минем киреләнеп куюым да бар. Йөрерсез аннан ялынып. Уйлагыз, уйла.

Ш ә р и ф җ а н. Камилә, депутатлыкны сорап алмыйлар.

К а м и л ә. Беләм, Шәрифҗан абый, җан кисәгем, бик яхшы беләм. Эш күрсәтеп алалар. Шуңа күрә дә менә норманы бер ярым иттереп арттырып үтәдем.

Г а д е л ш а. Сәҗидә сыерларын алгач.

К а м и л ә. Колхозда синеке-минеке юк ул, Гаделша абзый. Ирләрне генә без тегесе синеке, монысы минеке дип үзебезгә бәйләп куябыз. Ә сыерлар... кичә аныкы иде, бүген минеке.

Г а д е л ш а. Менә син үз сыерларыңны әйбәтләп тәрбияләп иде дә, узып кит идең. Аннан мактансаң да булыр иде.

К а м и л ә. Мин мактанмыйм, фактны әйтәм. Сорау куям: кем депутат булырга тиеш, алдынгы сыер савучымы, әллә артта сөйрәлүчеме?

Г а д е л ш а. Камилә, нигә син кеше көлдерәсең. Кандидат итеп күрсәтсәләр дә, синең өчен берәү дә тавыш бирмәячәк.

К а м и л ә. Тол хатын булган өченме?

Г а д е л ш а. Камилә булган өчен.

К а м и л ә. Киленең өчен йөрәгең әрни икән, үзенә әйт, бәйләнмә миңа.

Г а д е л ш а. Сәҗидә урынында булсам, бирер идем мин сиңа үз сыерларымны! Күрә алмас идең син аларны, җилкә чокырыңны күрә алмаган шикелле.

К а м и л ә. Инде Камиләнең җилкә чокыры да ошамый башладымыни?

Г а д е л ш а. Аның турындамыни сүз?

К а м и л ә. Аның турында. Күргәнең бармы синең Камиләнең җилкә чокырын, күрсәткәнем бармы?! Тол хатын дигәч тә.

Г а д е л ш а. Шуның белән сыерларын алмаштырып ята бит, ай, Сәҗидә.

К а м и л ә. Председатель кушкач нишли ала?! Бездә председатель сүзе закон. Шәрифҗан абый сүзе. Ул безнең атабыз. Аның дәрәҗәсе белән авыз чайкарга юл куймабыз!.. Шуңар борчылам: печән өлгереп килә, озакламас урак өсте дә килеп җитәр, нишләрбез икән, Шәрифҗан абый? Ул сөт фабрикасын да быел салдырып бетерә алсак шәп булыр иде.

Ш ә р и ф җ а н. Син ул кадәр үк борчылма инде, Камилә. Сәламәтлегеңә зыян килмәсен.

К а м и л ә. Тәртип ягын да ныгытасы бар. Мин әле уйлап йөрим, безгә җыйнаулашып бер сөйләшеп алырга кирәк булмасмы?

Ш ә р и ф җ а н. Кайда дип уйлыйсың?

К а м и л ә. Әйтик, партия оешмасында, коммунистларны җыйнап.

Ш ә р и ф җ а н. Минем белгәнемчә, син партия члены түгел бугай.

К а м и л ә. Я колхоз идарәсендә.

Ш ә р и ф җ а н. Син идарә члены да түгел.

К а м и л ә. Әй-й, ул турыда уйлап тора торган чакмыни? Агитмасса эше аксый, культуралы ял итүне дә оештырырга кирәк. Стенгазетаның чираттагы номерын чыгарырга вакыт.

Ш ә р и ф җ а н. Синең уңышларны күрсәтергә дисеңме?

К а м и л ә. Куйчы, Шәрифҗан абый. Үзем турында кайгыртаммыни?! Менә монда *(күкрәгенә күрсәтә)* йөрәк тыныч түгел. Олы юлга чыктык. Син инде дилбегәне бушата күрмә. Безгә хәзер сынатырга ярамый.

Шәрифҗан. Болай булгач сынатмыйбыз инде. Камилә булып Камилә шулай эш өчен янып йөри башласын да.

Гаделша. Сыер дуласа аттан да яман, диләр иде аны.

Камилә. Ишетмәдем, нәрсә диден, Гаделша абый?

Гаделша. Ишетмәвең хәерлерәк. *(Өйгә кереп китә.)*

Хәерниса, Бигрәк эшем кешесе булып киткәнсең, Камилә.

Камилә. Халык ышанычын акламаска ярыймы?!

Капкага юнәлә. Саҗидә белән очраша. Бер-берсенә карашып торалар. Камилә башын югары тотып чыгып китә.

Шәрифҗан. Нихәл, барамы?

Саҗидә. Тәгәри.

Шәрифҗан. Бик авыр түгелме?

Саҗидә. Җиңелне эзләмим.

Шәрифҗан. Иртүк торулары читендер инде яшь киленгә.

Саҗидә. Сәламәтлеккә файдасы зур диләр.

Шәрифҗан. Нормаң да тулмый, ахры?

Саҗидә. Көрәшергә стимул бар. Җиңелне җиңүгә караганда авырны җиңүе кызыграк.

Шәрифҗан. Үзе ни тора, ә?

Саҗидә. Үзе ни тора.

Шәрифҗан. Бик авырга килә башласа, җегәрлегең бетсә дим, килерсең. Бәлки уйлап карармын.

Саҗидә. Бетмәс дип ышанам. Килергә туры килмәстер.

Шәрифҗан. Характер ба-ар!

Бирелә Шәрифҗан белән Сәүбән генә кала.

Шәрифҗан. Сәүбән!

Сәүбән. Әйе.

Шәрифҗан. Җыен әйдә, бүген таңда сазанлы күлгә алып барам үзеңне.

Сәүбән. Син балык тотып, вакыт әрәм итүчеләрне кешегә дә санамый идең бугай, Шәрифҗан абый.

Шәрифҗан. Ул бит балык дигән булып, яр буенда эштән качып яткан эшлексезләрне. Ә син башка, балыгын да тотасың, эшеңнең дә остасы.

Сәүбән. Я, я, Шәрифҗан абый, салпы якка салам кыстырма, турысын гына әйт тә бир. Минем күңелне табар өчен генә төн йокыңны корбан итмәссеңдер. Сазанлы күл өчен мин нәрсә эшләргә тиеш булачакмын?

Шәрифҗан. Сизеп торасың, ә? Гаделша малае шул. Кил әле, туган, карап чык әле шушы проектны. Ахрысы, синсез чыкмады бу эш. Алар тәкъдим иткән ошамый миңа, төзүче булмасам да күреп торам, алай булмый. Аңлатып карадым, үгетләп карадым, юк, үз туксаннары туксан. Миңа иҗат итү кирәк, фантазия, ә аларга тизрәк төзелеп кенә бетсен. Эштер-өштер саласы да, акча төяп таясы. Ә безгә гомер бакый шушы авылда каласы. Ныклап эшкә керешкәнче, сызгалап бир, туган. Син бит профессионал, өйрәт шул наданнарны.

Сәүбән. Кай арада? Ә сазанлы күл?

Шәрифҗан. Күл качмас, төзәттем дип өстәлгә салуыңа, сазан безнеке. Эшлә. Үз колхозыңа. Савап булыр. *(Китә).*

Эңгер-меңгер куера. Сәүбән тәрәзәдән төшкән ут яктысына якыная. Разия чыга.

Разия. Нәрсә ул?

Сәүбән. Юк, болай гына.

Разия. Чертеж? Ит фабрикасы, сөт елгасы?

Сәүбән. Бер фикер кылгән иде.

Р а з и я. Әкренләп җәтмәгә эләгеп барам, диген.

С ә ү б ә н. Нинди җәтмәгә?

Р а з и я. Колхоз председателе корган җәтмәгә.

С ә ү б ә н. Кара син бу тынлыкны. Ә һавасы, һавасы! Бер сулавы ни тора! Каймак эчкән кебек.

Р а з и я. Ипи манып ашарлык.

С ә ү б ә н. Күкрәкләр киңәеп китте.

Р а з и я. Менә хәзер шушы минутта Мәскәүдә, я Казанда тормыш гөрли. Балерина аяк бармагы очында әйләнә, концерт залларында җырчылар. Ә авылда нәрсә? Тынлык, һава?

С ә ү б ә н. Әнә телевизор, кер дә борып җибәр. Бөтен дөнья күз алдыңа килеп басар.

Р а з и я. Алышынган бу кеше. Алмаштырганнар моны. Шикләнеп йөри идем аны. Сиңа, иптәш, председатель җене кагылган. Минем турыда уйлыйсыңмы? Мин нишләрмен авылда? Стаканга сыер савам. Белемем буенча юрист. Кая монда миңа эш?

С ә ү б ә н. Калабыз дип әйтмәдем бит әле.

Р а з и я. Беләм мин сине, дәшми йөрисең-йөрисең дә... Бац!

С ә ү б ә н. Прокуратурада эш булмасмы, я мәктәптә укытырга.

Р а з и я. Кара моны, инде хәл итеп тә куйган.

С ә ү б ә н. Юк ла, үзең сорагач кына әйтүем. Разия, бераз йоклап алам да, балыкка төшәм. Уятырсың, яме. *(Келәткә кереп китә. Разия уйланып кала).*

Р а з и я.
Ак чәчәкләр җыйдым болыннарда,
Бирермен дип сиңа бәйләмен.
Бар гомеремне сиңа багышладым,
Язмышымны сиңа бәйләдем.

Бердәнберем, кадерлем!
Күңелемдәген күрә алсаң гына
Ал кулымнан гөлләр бәйләмен.

Сүнмәс нурга күмдең бар дөньямны,
Ачып бирдең җирнең бар ямен.
Синең белән булган минутларым —
Иң сагынып көткән бәйрәмем.

Бердәнберем, кадерлем!
Өметемне аклый алсаң гына
Ал кулымнан гөлләр бәйләмен.

Ачык тәрәзәдән Саҗидә күренә.

С а җ и д ә. Туганым апа, бу ир белән хатын арасындагы яратышу ничек була соң? Гел бергә булгач, бер-береңнән туеп бетмисеңме?

Р а з и я. Кемдә ничектер?

С а җ и д ә. Ә сездә?

Р а з и я. Торган саен якыная гына барасың. Бер тән, бер җан кебек.

С а җ и д ә. Шул кадәр дә көчле булыр микән.

Р а з и я. Ышанасыңмы, аның үзен генә түгел, ул яраткан әйберләрне ярата башлыйсың. Элек мин шигырь укырга бик ихлас түгел идем, ә хәзер кулыма шигырь керсә, аерыла алмыйм.

С а җ и д ә. Сәүбән абый шигырь ятраткангамы?

Р а з и я. Ул яраткан ашны ярата башладым. Аңа ошаган җырларны ошатам.

С а җ и д ә. Безнең дә Рәүф белән шулай булыр микән?

Р а з и я. Аның дуслары — миңа да дус. Аның хыялы — минем өчен дә изге.

**С а җ и д ә.** Икең дә бер теләк, бер омтылыш белән яшәү — зур бәхеттер ул. Безгә дә килерме ул көн?

*Разия җырының аһәңе һаман да ишетелеп тора иде. Саҗидә дә Разия җырына кушыла.*

**Р а з и я.**
Уйларымны аңлый алсаң гына
Ал кулымнан гөлләр бәйләмен.

**С а җ и д ә.** Була китаплар, кат-кат укыйсың, укыган саен моңарчы күрелмәгән яклары ачыла бара. Әйбәт китап шикелле син, Разия апа. Менә уку кешене ничек күтәрә.

**Р а з и я.** Синең үзеңә дә укырга керергә кирәк, Саҗидә. Читтән торып булса да.

**С а җ и д ә.** Ниятем быел керергә иде. Булдыра алсам.

**Р а з и я.** Тырышсаң булыр.

**С а җ и д ә.** Фермадагы эшем дә болайрак булып китте. Кайчакта уйлап та куям, нигә дип ризалык бирдем бу депутатлыкка. Халык ышанычын аклый алмасам нишләрмен.

**Р а з и я.** Син дә акламасаң.

**С а җ и д ә.** Алай димә. Планнар елдан-ел арта бара. Бер урында гына таптанырга ярамый хәзер. Ярышка чыккач, берәүнең дә җиңелеп каласы килми.

**Р а з и я.** Камыр изеп куйган идем, әчер микән?

**С а җ и д ә.** Нишләттең?

**Р а з и я.** Суга он тугладым да...

**С а җ и д ә.** Чүпрә салдыңмы соң?

**Р а з и я.** Чүпрә дә кирәкмени?

*Көлешәләр. Капкада Рәүф күренә.*

**Р ә ү ф.** Кирәк түгел чүпрә, чүпрәсез күперә.

**Р а з и я.** Рәүфнең ачуы.

**Р ә ү ф.** Ике килен-килендәш?

*Музыка башлана.*

**Р ә ү ф.**
Ике килен-килендәш,
Икесендә бер киңәш.
Үз иренә якын килми,
Менә, җиңги, сиңа әйтәм,
Кочакларга иренгәч.

**Р а з и я.**
Салып кайту килешерме,
Рәүф, синең кебеккә?

**Р ә ү ф.**
Ни кыланса шул килешә,
Менә, җиңги, сиңа әйтәм,
Өйләнмәгән егеткә.

**Р а з и я.**
Туйлар ясадың түгелме,
Ни сөйлисең, акылсыз.

**Р ә ү ф.**
Көндезен Рәүф өйләнгән,
Менә, җиңги, сиңа әйтәм,
Төн җиттеме — хатынсыз.

*Р а з и я керен китә.*

**С а җ и д ә.** Бу эшең генә җитмәгән иде. Ашыйсың киләме, эчәсеңме?

**Р ә ү ф.** Кычкырышасым килә.

**С а җ и д ә.** Кайда йөрдең?

**Р ә ү ф.** Иркле кош кайда очмас. Танцада. Кунак кыз килгән. Ай, матурлыгы, чукынчык.

**С а җ и д ә.** Биегәч-биегәч озатырга иде.

Р ә ү ф. Анысын гына беләбез.

С а җ и д ә. Нишләп иртә кайттың, кунак кыз куна кертмәдемени?

Р ә ү ф. Иртәгә, боерган булса, иртәгә!

С а җ и д ә. Әткәй сизә күрмәсен, бар, кереп ят.

Р ә ү ф. Урын җәйдеңме?

С а җ и д ә. Җәелгән.

Р ә ү ф . Кайда?

С а җ и д ә. Әниләрдә.

Р ә ү ф *(кабынып).* Кунак кыз янына китәм!

С а җ и д ә. Үз иркең.

Р ә ү ф. Көнләшә дә белмисең.

С а җ и д ә. Ирем түгел лә.

Р ә ү ф. Кемең, кем мин сиңа?

С а җ и д ә. Йөкләмә. Менә салып кайткансың. Хәзер сине күзәт, кулдан ычкындырма, тәрбиялә. Аз иде кайгым.

Р ә ү ф *(көлә).* Өстәмә йөкләмә? Бер үзеңә егерме биш баш сыер да, бер баш ир?.. Салдым. Синең өчен йөрәк әрни. Сине кызганам.

С а җ и д ә. Аңламадым. Горурланам дисәң аңлар идем.

Р ә ү ф. Камилә булып Камиләдән дә көлдергәч. Синнән генә көлми ул, миннән дә көлә. Безнең семьядан көлә. Үз сыерларыңны кире ал!

С а җ и д ә. Боларын кемгә?

Р ә ү ф. Анысы синең эш түгел. Камилә үзе карасын.

С а җ и д ә. Камиләгә ярый, Саҗидәгә ярамыймы? Эшнең ояты юк. Ул сыерларны да адәм рәтенә кертергә кирәк.

Р ә ү ф. Менә сине дөрестән дә аңлавы кыен.

С а җ и д ә. Ә син башың белән генә уйлама, намусың белән дә уйлап кара, бәлкем аңларсың.

Р ә ү ф. Әзрәк кенә үзең турында да кайгыртырга ярыйдыр. Нигә кирәк булды депутатлыкка ризалык бирергә? Менә җигел инде. Берәр эш чыкса — сиңа килерләр. Жалоба булса — сиңа, ярдәм кирәк булса — сиңа. Барысын да тикшер, үз эшеңне дә, аларныкын да. Тикмәгә генә депутатны хезмәтче димиләр.

С а җ и д ә . Халык хезмәтчесе.

Р ә ү ф. Барыбер рәхмәт әйтүче булмас, ә зарланучысы табылыр. Председатель белән булышуларың тагын! Ташны башка бәрсәң дә, башны ташка бәрсәң дә, баш ярыла. Ул председатель, ни әйтсә дә анықы дөрес, аныкы өстен.

С а җ и д ә. Өстеннәр белән алышырга яратам.

Р ә ү ф. Ой, характер да соң!

С а җ и д ә. Сиңа характерсыз хатын кирәк идемени?

Р ә ү ф. Ялгышмадым микән мин сиңа өйләнеп.

С а җ и д ә. Ай, терсәкне тешләп булса! Мин дә ялгыштым, ахры, сиңа ышанып.

Р ә ү ф. Терсәкне тешләп булмый икән шул.

С а җ и д ә. Ә без, әйдә, бер-беребезнекен тешләшик.

Этә-этә Рәүфне үз өйләренә йокларга кертеп җибәрә. Беркавым ишегалдында берәү дә юк. Капкада Камилә белән Кәримулла күренә. Камиләне бөтенләй танып булмаслык. Мини юбкадан. Мөмкин кадәр яшь күренергә тырышып, затлыдан гына киенгән. Үзен-үзе тотышында көязлек, мөлаемлык, нәзбереклек. Әдәпле, инсафлы, йомшак кына итеп сөйләшә.

К а м и л ә. Белмим инде синең белән нишләргә дә. Аптыраган.

К ә р и м у л л а. Ә син уйлап та бирмә. Тилмереп әйткән сүзләремә колак сал. Карышуыңны ташла.

К а м и л ә. Сезгә ышансаң.

К ә р и м у л л а. Кемгә ул сезгә?

К а м и л ә. Ирләргә.

Кәримулла. Ю-ук, син башка ирләргә ышанма, син миңа гына ышан.

Камилә. Хатының булмаса икән.

Кәримулла. Хатын? Кайда ул хатын?! Моннан йөз чакрымда. Авылда, йорт карый. Минем еллар буе аның янына кайтканым юк. Фактически әйтсәм, тол ир мин. Ялгыз башым. Фактически — минем хатыным син.

Камилә. Килеп чыкса.

Кәримулла. Килми. Өйне, балаларны ташлап кая чыгып йөрсен. Ул турыда уеңа да кертмә. Юкка карышасың, Камиләкәй. Гомер ике килми, заяга уздырмыйк.

Камилә. Ай, Кәримулла, сизеп торам, харап итәсең син мине.

Кәримулла. Итәм! Бал кашыгына салам да кабып йотам мин сине.

Камилә. Тамагыңа тыгылсам?

Кәримулла. Үләм икән, синең өчен китәм бу дөньядан.

Дуэт башлана.

Камилә.
Минә инде ничә еллар
Күңелемдә йөри антым.
Антымны боздыра язды
Шушы мыеклы квартирантым.

Бергә:
Өздереп, һай, өздереп карамачы күзләремә,
Укларың, һай, укларың кадамачы үзәгемә.
Сиңа бәлки ул берни дә түгелдер дә,
Ә минем, һай, ә минем үзәгемне өзә генә.

Камилә.
Нишләсәм дә онытa алмыйм
Янымда мыек барын.
Кырдырып ташлатыр идем
Бу ирләрнең кара мыекларын.

Бергә:
Өздереп, һай, өздереп карамачы күзләремә,
Укларың, һай, укларың кадамачы үзәгемә.
Сиңа бәлки ул берни дә түгелдер дә,
Ә минем, һай, ә минем үзәгемне өзә генә.

Кунаклар каршына өйдән хуҗалар чыга.

Камилә. Хәерле кич.

Кәримулла. Сәлам бирдек!

Камилә. Йөрергә чыккан җирдән сезгә дә кагылдык. Миннән башка ике аягының берсен дә атламый.

Кәримулла. Гаделша абый, Рәүф өйдәме?

Гаделша. Белмим.

Кәримулла *(сызгыра)*. Рәүф!

Рәүф күренә.

Кәримулла. Рәүф, ике көнең узды, җавабыңны әйт.

Рәүф *(Саҗидәгә күз төшереп алгач)*. Сүзеңнән кире кайтмадыңмы?

Кәримулла. Ике сөйли торган адәм түгел Кәримулла.

Рәүф. Шарты да шул әйткәнеңчәме?

Кәримулла. Кәримулланың сүзе бер булыр.

Рәүф. Алайса, мин риза.

Кәримулла. Кулыңны! *(Кул бирешәләр)*. Минем егетләр җыйналып калдылар. Безгә дә анда булырга кирәк. Сөйләшәсен сөйләшеп, килешәсен килешеп алырбыз. Иртәгәдән тотынабыз.

Гаделша. Ничек каерырга беләләр.

Кәримулла. Без, Гаделша ага, эшли дә беләбез. Куш син безгә: нәрсә салырга, кайчан өлгертергә, әйт: бер елдан диген — бер елдан өлгертәбез. Әйт: бер айдан — бер айдан әзер булыр. Ничек эшлибез, кайчан эшлибез — анысы безнең эш. Шабаш!

Гаделша. Җыен килмешәк, җиделәтә, унлата артык итеп каералар.

Камилә. Нишләп әле син, Гаделша абый, аңа ят кеше итеп карыйсың? Әгәр дә без туй итеп куйсак? Кәримулла, мыекбаем, әйдә, шуларга ачу итеп, тотабыз да өйләнешеп ташлыйбыз.

Кәримулла. Өйләнәм. Колхозыгызга керәм.

Камилә. Иртәгә үк!

Кәримулла. Ю-ук, туй итәргә акча кирәк. Башта төзибез, акча алабыз, аннан соң...

Гаделша. Койрыкны сыртка салабыз? Акылың алтын. Мут егет син, Кәримулла. Исемең үк өметле түгел, мулла дип бетә.

Камилә. Колхозыбызда байлык җитәрлек, бер договор төзегәннән генә коргаксымас әле.

Хәернисa. Кәримулланы җибәрәсең килми, Камилә. Синдә ир кайгысы.

Камилә. Нишләп җибәрәсем килсен. Аз булса да ай саен квартир акчасы кереп тора.

Хәернисa. Бер башың, кая куеп бетерәсеңдер ул акчаны.

Камилә. Бөтен тапканны шушы уймак авыз йота да бара. Тәмле ашарга, матур киенергә яратам.

Хәернисa. Тагын нәрсә яратасың?

Камилә. Квартирант кертергә.

Гаделша *(малаена)*. Хәл иттеңмени инде? Атаң белән киңәшеп тә тормадың?

Рәүф. Мин нәрсә, председатель хәл иткән.

Гаделша. Ә син ир булсаң үз сүзеңне үзең әйт. Юк, диген, үз колхозымныкын үз бригадам белән мин үзем төзим, договорсыз-нисез, намуслы хезмәт белән диген. Менә шул җавабың булыр. Председательгә дә, шабашникка да. Менә шул чакта авыл урамнарыннан күкрәгеңне киереп йөри алырсың, авылдашларыңның күзләренә туры карап.

Кәримулла. Минем Рәүф өчен кайгыртып йөрүем. Акчалы эш чыгып торганда.

Сәүбән. Йөзгә кызыллык китерә торган акчаны мин аны!

Рәүф. Шулай, без акча эшлик дисәк, йөз кызарырга тиеш. Ә синең кызармый. Зарплата көйләнгән, ай башында аванс, уртасында получка, көне-сәгате билгеле.

Гаделша. Армиядән кайтканны бирле колхозыңны сөендергәнең булдымы? Ә хәзер... Уйласаң гына да чәчең үрә торыр. Үз авылында үзе шабашник.

Рәүф. Әти, кесә тутырып акча алып кайткач уйланырсың.

Гаделша. Акча? Әниеңнең күпме көче керде бу колхозга, атаңның күпме тире тамды. Хәзер килеп син шул мираска кул сузасыңмы? Үз колхозыңны каезларга керешәсең, сине үстергән, әпәй ашаткан туган авылыңны таларга тотындыңмы? Оятың ук юк икән.

Хәернисa. Атасы, ул кадәр кызма әле.

Гаделша. Карт көнебездә шушы хурлыкны күрергә үстердекме без аны?

Хәернисa. Атасы дим!

Гаделша. Кем малае дигәндә Гаделша малае диләр. Дөньяга чыгарлыгымны калдырмады.

Рәүф. Кеше әйберенә кул салмаган, ул кадәр хурланырга.

Гаделша. Карак, ичмаса, яшеренеп урлый, ә син көпә-көндез, ачыктан-ачык.
Хәерниса. Гаделша!
Гаделша. Күземә күренмәсен! Чыгып кит минем йортымнан!
Хәерниса. Үз балаңны...
Гаделша. Намусын сатып йөрүче минем балам түгел!
Рәүф. Ярый, эти. Бикләнгән капканы ватып кермәм. Әйдә, хатын, җыйна әйберләрне.
Саҗидә. Мине кумыйлар.
Рәүф. Каласыңмы?
Саҗидә. Калам.

*Рәүф Кәримуллалар белән китә.*

*Пәрдә.*

## ДҮРТЕНЧЕ КАРТИНА

*Күпмедер көннәр узган. Өйлә вакыты. Гаделша эш урынында. Әнәсне үз һөнәренә өйрәтә. Урамнан Камилә керә. Ишегалдын әйләнеп чыга.*

Гаделша. Нәрсә тыз-быз йөрисең, Камилә. Кем кирәк?
Камилә. Кем кирәген үзем дә белмим. Синең киленең Саҗидә. Куып җитеп килә бит. Нормасын тутырган. Ә минем кими дә кими.
Гаделша. Җиткермә.
Камилә. Сыерлары да аның яклы. Мине санламыйлар, тол хатын итеп карыйлар. Нишлим, хур булам, ахры.
Гаделша. Итәгеңә ут каптымыни?
Камилә. Кияүгә бирер шәһәр егетенә чыкмады, ичмасам. Китәр иде дә, котылган булыр идем. Үзе кайда икән?

*Өйгә кереп китә. Урамнан Гыймран керә. Ул да борчулы.*

Гыймран. Гаделша кайнагай, кәнсәләргә чакырталар, районнан следователь килгән ди. Нигә кирәк булдым икән?
Әнәс. Билгеле инде, сорау алырга.
Гыймран. Нәрсә өчен?
Гаделша. Нәрсә өчен булса да синдә җитәрлек.
Гыймран. Кайсы өчен икән?
Гаделша. Менә шулай дип сора.
Әнәс. Кеше алдап, никах укып...
Гыймран. Телеңне тый! Кемгә укыган, кем күргән?
Әнәс. Менә мин. Фотога төшереп барганны оныттыңмыни?
Гыймран. Ах, җен әвәләгән нәмәрсә! *(Куа. Шунда Камиләне күреп ала).* Ә сиңа нәрсә кирәк?
Камилә. Син түгел. *(Саҗидәләргә юнәлә).*
Гыймран *(Әнәскә).* Саҗидә җиңгәңә дә бала китерәсең. Үзем батам икән, аны да батырам.
Гаделша. Аның ни гаебе бар?

*Шәрифҗан керә. Камилә нәрсәрән. Гыймран чыгып китә.*

Шәрифҗан. Саҗидә кайтмадымы? Гаделша ага, сизәсеңме, эшләр кая табан китте? Колхозыбызга кешеләр кире кайта. Элек китәләр дип алҗый идек, хәзер кайталар.
Гаделша. Кем кайта бит.
Шәрифҗан. Менә улың Сәүбән. Инженер! Үзе генә дә түгел, югары белемле хатын нәртеп кайтты.
Гаделша. Кайталар. Колхоз баегач Гыймран да кайтты әйләнеп. Шабашниклар да килә. Балга җыйналган чебеннәр төсле.

*Өйгә юнәләләр. Председательне Камилә алып кала.*

Камилә. Шәрифҗан абый!

Ш ә р и ф җ а н. Ни бар?

К а м и л ә. Үзегезгә генә әйтер сүзем бар.

Ш ә р и ф җ а н. Я?

К а м и л ә. Эшләр хөрти, Шәрифҗан абый. Саҗидәне ничек тә коткарып калырга кирәк. Югарыда белеп алсалар, депутатлыкка үткәрмәсләр.

Ш ә р и ф җ а н. Соң?

К а м и л ә. Никах укыткан.

Ш ә р и ф җ а н. Шуннан?

К а м и л ә. Алар ирле-хатынлы да түгел икән. Су коенганда берсе алдында берсе чишенми. Мунчага да бергә кергәннәре юк. Йоклаганда да...

Ш ә р и ф җ а н. Стоп! Аларның кайда, ничек йоклаганында синең ни эшең бар?!

К а м и л ә. Туй итүләре дә ялган булган. Шикләнгән идем аны, үзләре бер-берсенә каршы, үзләре өйләнешәләр, бу ни эш дип аптыраган идем.

Ш ә р и ф җ а н. Алай. Өйләнешмәгәннәр дисеңме?

К а м и л ә. Өйләнешмәгәннәр.

Ш ә р и ф җ а н. Соң, алайса никах та укылмаган булып чыга. Өйләнешмәгән кеше никах укытамыни?

К а м и л ә *(сүз әйтә алмый тора).* Ә? Ә-ә. Шулай булып чыга икән шул. Кара син аны, юкка гына борчылып йөрим икән, Шәрифҗан абый.

Ш ә р и ф җ а н. Әйе шул, Камилә, юкка гына борчылып йөргәнсең. Әйтә киләм ләбаса ул кадәр борчылма дип.

К а м и л ә. Кайтыйм, алайса. *(Чыгарга юнәлә. Үз алдына.)* Буталып беттем, каһәр суккыры.

Ш ә р и ф җ а н *(кискен).* Камилә! *(Камилә шунда ук туктап, тынып кала. Куырылып төшә. Көтә).* Ташла бу гадәтеңне, Камилә. Болганчык суда балык тотарга яратасың. Әнә эшеңне кара. Сыерларың сөтне киметә. Саҗидә куып җитеп килә үзеңне, узып та китәр.

К а м и л ә. Саҗидә ул сыерларның телен белә. Әллә сихерли дә инде шунда.

Ш ә р и ф җ а н. Телен түгел, һәркайсының фигылен, характерларын, ничек ашатырга кирәген белә.

Чыгып китә. Камилә аның артыннан иярә. Арт капкадан Гыймран белән Гайшә керә. Одеалга төреп нәрсәдер күтәргәннәр. Ишегалдында Камиләне күреп, лапас эчендә яшеренеп торалар. Камилә чыгып киткәч кенә поскан урыннарыннан чыгалар.

Г ы й м р а н *(як-ягына карана).* Кая яшерергә соң? Бар әле, берсен чакырып чык.

Г а й ш ә. Кайсын, Хәерниса җиңгинеме?

Г ы й м р а н. Анысы безнең кеше түгел. Разиясын. *(Өйалдында Разия үзе күренә).* Разия, матур килен, кил әле, кил. Менә шушыны яшереп куярга кирәк.

Р а з и я. Нәрсә соң бу?

Г ы й м р а н. Шул инде. Теге нәрсә. Өч сортка аерып чыгара торганы.

Р а з и я. Әллә?

Г ы й м р а н. Әйе, үзе. Кибетнекен генә ничек җиткереп бетерәсең.

Р а з и я. Самогон аппараты?

Г ы й м р а н. Шыпырт. Сизә күрмәсеннәр. Аерата Саҗидә киленнән сак бул.

Р а з и я. Мин яшериммени?

Гыймран. Иң ышанычлы кешебез син инде, килен.
Гайшә. Идән астына төшереп куй. Берәр нәрсә белән томалап.

Өйалдында Гаделша белән Хәерниса күренә.

Гыймран. Кәнсәләргә чакырталар. Күрсәтеп язучы булгандыр. Белер хәл юк, өйгә тенту керсә.
Гайшә. Сезгә кереп берәү дә эзләп йөрмәс. Сездән шикләнмиләр.
Гыймран. Следователь килгән ди.
Разия. Следователь? Мин булам инде ул следователь. *(Өстендәге плащын сала. Прокуратура эшчесе киеменнән кала).*
Гыймран *(телсез кала. Тотлыга).* Ә... Ә-ә... ни... ни...
Разия. Прокуратурага эшкә кердем.
Гыймран. Пр... пр.. пр-пр-прркарур? *(Авып төшә).*
Хәерниса *(өйалдыннан йөгереп төшә).* Кияү, ни булды? Нишләдең?
Гаделша. Күрмисеңмени, паралич сукты.
Гайшә. Гыймран дим, сиңа әйтәм!
Гыймран. А-а... Ә-ә...
Хәерниса. Харап эш. Нишлик, доктор чакыртыйк мәллә?
Гайшә. Паралич сукты дисеңме?
Гаделша. Сукмый ни, сугар да. Җинаятемне яшерәм дип, следовательнең үз кулына китереп тоттыр әле.
Гайшә. Бетте баш.
Әнәс. Калды муен сузылып.
Гыймран *(үзенә-үзе ярсып).* Син следовательме? Син чакыртыңмы? Ә мин... үз кулым белән китереп бирдемме моны? Самогон кайнатам, мине кулга алыгыз дип килдемме?
Гаделша. Паралич булмады бу. Акылына зәгыйфьлек килде.
Хәерниса. Сиңа көләргә булсын.
Гаделша. Кем көлә? Кияү хәзер башын җүләргә салып кына котыла ала. Җүләргә суд юк.
Гыймран. Ах, мин ахмак.
Гаделша. Менә, менә.
Гыймран. Маһы бирдем. Берәү дә эләктерә алмый иде. Элеккәч тә шуып чыга идем.
Гаделша. Балык кебек.
Гайшә. Әй, тиле баш, тиле баш. Җебегән. Кемгә биреп яшертә бит. Менә утырырсың инде.
Гыймран. Кайда?
Гайшә. Урыныи табарлар. Тәрәзәсенә аркылы тимер кадаклаган номерларда.
Гыймран. Ә син передача ташырсың.

Капкада Сәҗидә күренә.

Гыймран *(теш арасыннан).* Ике килен-килендәш!
Гайшә *(түзынып).* Уңдык без килennәрдән.
Гыймран. Каптык без киленнәргә.
Гаделша *(горурланып).* Ах, безнең киленнәр!
Гыймран. Инде кечесе кемне алып кайтыр?
Әнәс. Судьяга өйләнәм.
Гыймран. Шулай, безгә судья гына җитми. Закон чыгаручы бар, прокурор бар. Судья да булса, судны үз өебездә генә ясарга кала.
Әнәс. Гаепләнүче дә бар.
Гыймран. Башта исбат итәргә кирәк әле.

Энәс. Ә мин нәрсәгә дип фотога төшереп бардым?

Гыймран. Өметсез үк икәнсең.

Гайшә. Я, бетерегез инде. *(Разия алдына килеп тезләнә.)* Ят кешеләр түгел. Бер юлга гына гафу итегез. Кем ялгышмый. Бутагандыр.

Гаделша. Бутаган? Песок урынына тоз салып эчми.

Гыймран *(еламсырап).* Разия килен, акыллым, инде миңа нишләргә?

Разия. Канцеляриягә барырга.

Гыймран. Следователь монда ич.

Разия. Мин дә хәзер барып җитәм.

Гыймран. Үз кешеләр ләбаса, Разия кадерлем, бармыйча гына булмасмы дигән идем.

Разия. Булмас, кадерле җизнәкәй.

Гыймран. Ә моны? Аппаратны әйтәм.

Разия. Алып барасың.

Гыймран. Урам буенча? *(Гайшәгә.)* Күтәр!

Гайшә. Үзең күтәр.

Гыймран. Апай, бәхил бул. *(Аппаратны күтәреп урам буйлап китә.)* Сау булыгыз, туган-үскән җирләр!..

Гаделша. Разия, бу усал кайнаналар өчен дә юкмы шунда берәр статья?

Хәерниса. Ни сөйләнә? Гомер иткән хатыныңны илтеп тыгар идеңме рәшәткә артына?

Гаделша. Унбиш тәүлеккә генә. Акылга утыртырлык итеп кенә.

Разия. Безнең әнкәйгә нишләп статья булсын. Безнең әнкәй бит ул.

Хәерниса. Менә закон кешесе ни әйтә.

Гаделша. Элекке заман булса киленнәреңнең җелеген суырыр идең син. Замана үзгәрде.

Хәерниса. Телеңне тый дим.

Разия су чиләкләре ала.

Хәерниса. Абау, кая барасың, килен?

Разия. Суга.

Хәерниса *(аның кулыннан чиләк-көянтәне алып).* Кирәкмәс, килен. Син болай да арып кайтасың. Үзем, үзем. Әнә радиосы да гимнастерка ясарга куша.

Гаделша *(төзәтеп).* Гимнастика!

Хәерниса. Ярар, син өйрәтеп утырма, күп ясыйм мин аны — гимнастны. Иртә таңнан кара төнгә кадәр.

Суга китә. Урамнан Камилә керә. Саҗидә аның янында тоткарлана.

Камилә. Саҗидә, сине эзлим.

Саҗидә. Син үзең дә миңа кирәк идең.

Камилә. Зинһар, хур итмә. Куып җитеп киләсең, узып та китәрсең. Ә мин кеше күзенә ничек күренермен. Сыерларымны кире бир. Үзеңнекеләрне үзеңә ал.

Саҗидә. Тынычлан әле. Хәлең ничек?

Камилә. Тегенең хатыны килеп төште. Квартирантымның.

Саҗидә. Ишеткән идем.

Камилә. Чая нәрсә, күзеңә керергә тора. Үзе кебек үк, мыегы гына юк.

Саҗидә. Ни булды соң?

Камилә. Ни булсын, куып чыгарырсыңмы? Кичтән икесенә бергә урын җәеп йоклаттым. Иртән мунча ягып керттем.

С а җ и д ә. Икесен дә.

К а м и л ә. Мунчаны тышкы яктан бикләп алып, керосин сибеп, ут төртеп яндырыйм микән әллә дигән идем дә, тыелып калдым инде. Бу ирләрне атасы гына эт ата торган мылтык белән.

С а җ и д ә. Төкер. Чибәрлегең бар, үткенлегең.

К а м и л ә. Үз сыерларыңны үзеңә аласыңмы?

С а җ и д ә. Камилә, менә мин нәрсә уйлап торам әле. Кайбер колхозларда икешәр смена белән эшләүчеләр бар. Без дә шул методка күчсәк, ә? Илле баш сыерны бергәләп карасак?

К а м и л ә. Икәү бергәме?

С а җ и д ә. Ә ник, эшли алмабызмы әллә. Бер-беребезгә булыша-булыша.

К а м и л ә. Син миңа булышмакчы? Камиләгә?.. Ә мин сиңа яла ягарга теләдем.

С а җ и д ә. Якмагансың ич.

К а м и л ә. Ышанмадылар. Хәзер килеп бергә эшләргә тәкъдим итәсең. Булышырга. Буксирга алырга. Әй, җаным, әй, Сәҗидәкәй, изге җандыр син. Фәрештәдер. Берәү булса минем белән сөйләшеп тә тормас иде.

С а җ и д ә. Нишләп инде.

К а м и л ә. Үзеңнән күпме көлеп йөрдем.

С а җ и д ә. Син шаярмыйча яши аласыңмыни?!

К а м и л ә. Җүнсез мин. Шушы яшемә җитеп акыл кермәде. *(Күзен сөртә).*

С а җ и д ә. Я, нәрсә дисең?

К а м и л ә. Эшлибез, ник эшләмәскә? Синең белән булсакмы, билләһи дип әйтәм, районда гына түгел, республикада алдынгылыкны бирмибез. Киттем. Теге шабашникны куып чыгарам. Ә шулай да кызганыч, мыегы шәп иде.

Камилә чыгып китә. Сәҗидә Разия белән очраша.

С а җ и д ә. Туганым апа, нишлим? Ничек акылга китерим бу Рәуфне? Күпме аңлатып карадым, ялварып карадым, һич кенә дә эзгә төшереп булмый. Һаман да үз кирелеген куа. Әткәй сүзен дә алга алмады. Нишлим?

Р а з и я. Аерыл.

С а җ и д ә *(монысын ук көтмәгән иде).* Ә?

Р а з и я. Бүген үк!

С а җ и д ә. Аерылырга? Мөмкин түгел.

Р а з и я. Мөмкин!

С а җ и д ә. Булдыра алмыйм.

Р а з и я. Булдырырсың.

С а җ и д ә. Аннан башка яшәргәме? Яратам шул мин аны.

Р а з и я. Ятратканга күрә дә аерылырга кирәк.

С а җ и д ә. Юк, юк, әйтмә дә...

Р а з и я *(капка төбендә керергә базмыйча торган Рәуфне күреп ала. Шыпырт кына).* Рәуф кайткан. *(Кычкырып).* Сәҗидә, уйлап эшләвеңме бу, ирдән аерылып йөрүне уен эш дип беләсеңме?

С а җ и д ә *(хәйләне аңлап).* Үгетләмә, Разия апа. Хәл иттем инде. Аерылам. Гаризасын да яздым. Башка чарам калмады.

Р а з и я. Мондый чакта җиде мәртәбә үлчәргә кирәк дигәннәр.

С а җ и д ә. Җитмеш мәртәбә үлчәдем. Булмый, бергә торып булмый.

Р а з и я. Үзе белән тагын бер тапкыр сөйләшеп карасаң, соңгы мәртәбә. Бәлки ялгышканын аңлар.

Сажидә. Күп сөйләштем инде.
Разия. Әллә үзем сөйләшеп карыйммы?
Сажидә. Мәшәкатьләнмә. Барыбер тыңлый торган түгел.
Разия. Икмәкне дә бер киссәң кире ябыштырып булмый.
Сажидә. Безнең киселде инде.
Разия. Бер дә кызганмыйсыңмыни соң?
Сажидә. Үзе гаепле. Үзенә үпкәләсен. *(Өйгә кереп китә).*
Рәүф. Туктагыз! Ике килен-килендәш! Бу ни эшегез сезнең?
Разия. Абау, син мондамыни?
Рәүф. Җиңги, ничек болай була инде бу? Тора да башламаган килеш.
Разия. Әй, аерылса тагын, икенчене табарсың.
Рәүф. Ничек икенчене?
Разия. Беткәнмени дөньяда кызлар.
Рәүф. Дөньяда икенче Сажидә юк.
Разия. Булыр әле.
Рәүф. Булмаган да, булмас та. Юк, моңа юл куярга ярамый. Беләм мин аны, бер хәл итсә, кире кайта торганнардан түгел. Җиңги жаным, ирек бирмә. Яратам, үлеп яратам мин аны.
Разия. Яратасың? Ярату шулай буламыни? Нинди хурлыкларга төшермәкче буласың син аны?! Намусыңны акчага сатып. Кем син? Кем баласы? Кая тәгәрисең? Шул турыда уйлап карар идең, әткәй әйтмешли, башыңа тай типмәгән булса.

Рәүф нишдидер карарга килеп урамга чыгып китә. Өйдән Сажидә чыга. Шул чакта урамнан Шәрифҗан керә.

Шәрифҗан. Килендәшләргә сәлам!
Разия, Сажидә *(бергә).* Сәлам, Шәрифҗан абый!
Шәрифҗан. Я, кайтып җиттеңме, Сажидә, юл уңдымы?
Сажидә. Уңмаган кая.
Шәрифҗан. Башкармага кердеңме, үзен күрдеңме?
Сажидә. Кердем, күрдем. Молоковоз мәсьәләсендә гадел булырга кирәк ди.
Шәрифҗан. Ә син?
Сажидә. Мин дә аның фикерен куәтләдем.
Шәрифҗан. Менә рәхмәт, молодчина!
Сажидә. Безнең болай да ике молоковозыбыз бар, күршеләргә бирү гадел булыр дидем.
Шәрифҗан. Нәрсә?! Молоковозны күршеләргә бирдереп кайттым дисеңме?
Сажидә. Әйе.
Шәрифҗан. Сиңа ышанган мин җүләр, үзем барган булсам, алып кайта идем. Менә шушы детсад белән эшләп кара инде син. Нишләргә сезнең белән, кая барырга?
Сажидә *(беренче мәртәбә председательгә тавыш күтәреп).* Мин сезгә детсад түгел, иптәш Мортазин! Мин хөкүмәт кешесе. Мәсьәләне үз каланчабыздан гына карап хәл итәргә безнең хакыбыз юк.
Шәрифҗан. Каланчадан карап утырырга мин пожарник түгел, миңа сөт тапшырырга кирәк, сөт әчи.
Разия. Шәрифҗан абый, минемчә дә Сажидә дөрес эшләгән. Ул мәсьәләгә киңрәк, хуҗаларча карый.
Шәрифҗан. Хуҗалыкны безгә калдырып тор инде син. Катлаулы тармак, читтән торып хәлфә булып булмый, гражданин следователь.

Р а з и я. Мин эш урынында следователь, ә хәзер, шушы авыл килене буларак, шуны әйтәм: үз кешеләрегезне оештырмыйча, шабашниклар белән договор төзергә ашыккансыз.

Ш ә р и ф җ а н. Тимерне кызуында сугарга яратам.

С а җ и д ә. Идарә членнары белән киңәшләшмичә.

Ш ә р и ф җ а н. Эш көтми.

С а җ и д ә. Проект-сметада күрсәтелгәннән берничә мәртәбә артык түләргә килешкәнсез.

Ш ә р и ф җ а н. Беренчедән, проект баштагыдан күп тапкырлар киңәйтелде. Икенчедән, ул халыкны шабашник диләр, син биргәнгә генә риза буламы?

Р а з и я. Колхоз милкен үз белдеге белән тарату беркемгә дә рөхсәт ителми, Шәрифҗан абый, хәтта колхоз председателенә дә.

С а җ и д ә. Шабашниклар белән араны өзәргә кирәк.

Ш ә р и ф җ а н. Ә миңа төзергә кирәк.

С а җ и д ә. Юк, бу дөрес түгел, мин моны болай гына калдыра алмыйм.

Ш ә р и ф җ а н. Дөресе кайда, барып әләкләшүдәме?

С а җ и д ә. Әләкләшә торган гадәтем юк. Эш аңа барып җиткәнче, идарә членнарын җыеп, колхоз файдасыннан чыгып хәл итәргә кирәк. Аннан, фабриканы салып бетерсәк, молоковозның да кирәге калмый. Сөт продуктларын хөкүмәт бездән үзе килеп алачак.

Ш ә р и ф җ а н. Карап торам-торам да мин сиңа, килен, горурланып та куям, сине үз депутатым итеп бер дә ялгышмаганмын.

Р а з и я. Ул халык депутаты, Шәрифҗан абый.

Ш ә р и ф җ а н. Кем әйтә халыкныкы түгел дип, әлбәттә, халыкныкы. Ә халык кем соң ул, халык мәнә без ул.

Шулчак Рәүф К ә р и м у л л а н ы алып керә.

К ә р и м у л л а. Кая өстерисең?

Р ә ү ф. Әйдә әле, эш башланганчы председатель белән киңәшеп алыйк әле. *(Кәримулла ышана, портфеленнән эш кәгазьләрен чыгара башлый).* Шәрифҗан абый, иптәш председатель! Ни дисәң дә, бу төзелешне шабашникларга биреп эшләтү дөрес түгел. Нәрсә, безнең үзебезнең эшләрлек кешеләребез юкмы әллә, үзебез булдыра алмыйбызмы? Халыктан оят. Хурлык. Менә шул, шабашниклар белән төзегән договорны юкка чыгарыгыз. Төзүчеләр бригадасын үзем оештырам. Сөт комплексын үзем төзеп бирәм.

Ш ә р и ф җ а н. Менә чын колхозчы сүзен ишетәм.

Р ә ү ф *(Кәримуллага).* Кая, чыгар әле договорны.

К ә р и м у л л а. Ертып ташлар идең бугай.

Р ә ү ф. Юк, син аны үзең ертачаксың!

К ә р и м у л л а. Шаярма. Договор хәзер закон көченә кергән. Аны суд та юкка чыгара алмый.

Р ә ү ф. Суд? Минем судым үзем белән. *(Якасыннан ала).* Бирәсеңме-юкмы?

К ә р и м у л л а. Ярдәм! Коткарыгыз!

С а җ и д ә. Рәүф!

К ә р и м у л л а. Разия ханым! Иптәш следователь, күреп торасыз... Прокурорга язам!

Р ә ү ф. Прокурорга? Әйдә, бигрәк тә шәп булыр. Шунда берьюлы аңлатып та бирерсең. Өченче ел «Таң» колхозында егетләрең дүртәр мең алды, ә син үз кесәңә сигезне салдың.

Кәримулла. Чү, син! Нишләвең?

Рәүф. Ах, прокуратурага бармыйбызмыни?

Кәримулла. Шаярдым гына.

Рәүф. Ярый, прокурорга бармыйбыз. Егетләреңә генә чишәм. Алар сине моның өчен...

Кәримулла. Рәүф энем!..

Рәүф. Хәзер дә махинация корырга маташасың.

Кәримулла. Алла хакы өчен!

Рәүф. Чыгар договорны.

Кәримулла. Көпә-көндез талау бу. Пычаксыз сую. *(Кесәсеннән договорны алып бирә).*

Рәүф. Председательгә бир... Ә, юк, үзең ертып ташла. *(Кәримулла договорны ерта).* Инде бар, дүрт ягың кыйбла. *(Кәримулла янап чыгып китә).*

Шәрифҗан *(кочагын җәеп Рәүфкә килә).* Коткардың. Колхоз исеменнән олы рәхмәт сиңа.

Рәүф туп-туры Сәҗидә каршына атлый, алдына тезләнә. Бу вакытта ишегалдында кеше шактый җыйналган була инде.

Рәүф. Язмышка мең рәхмәт, күршеләр булганбыз. Әгәр дә башка авылда, башка районда туып, сине очрата алмаган булсам, көннәрем болай нурлы, шатлыгым бу кадәр тулы булмас иде. Яратам мин сине, Сәҗидә. Чык миңа кияүгә!

Камилә. Бәрәч! Үз хатынына өйләнергә тели түгелме соң бу бәндә?

Хәерниса *(Гаделшага).* Әйтмәдемме мин сиңа?

Шәрифҗан. Туй итәбез, туй!

Хәерниса. Бер иткән идек бугай инде.

Шәрифҗан. Тагын итәбез. Боларга өч тапкыр итсәң дә артык түгел.

Камилә. Ура! Рәүф үз хатынына өйләнә.

Сәҗидә. Сәҗидә үз иренә кияүгә чыга.

Музыка.

Пәрдә

# ГАДЕЛЛЕК ҺӘМ ИРЕК ҖЫРЧЫСЫ

**Үзем үлсәм, исемем үчәр, кабрем сыйпап җилләр исәр,**
**Якын күргән дусларымның бәгырьләрен кайгы кисәр...**

Бу юлларны язган көрәшче шагыйрь Билал Назыйм исеменең бүген дә хөрмәт белән яд ителүен, әсәрләренең яңа буыннар күңелендә урын табуын әйтү кирәктер. Аның югарыдагы шигыре дә, байтак бүтән әсәрләре дә инде күптән халык җырына әйләнгән. Дастаннары сөеп укыла, ирек һәм гаделлек өчен көрәшкә рухландыра, тормыш юлы исә ил бәхете өчен яшәү өлгесе булып хезмәт итә.

Билал Назыйм Шәркый Төркстанның Голҗа шәһәрендә туган, атасыннан укырга-язарга өйрәнгән, мәдрәсәдә белем алган. Гарәп, фарсы телләрен үзләштергән һәм шәрык шигърияте белән мавыккан. Фирдәүси дастаннары, Г. Хәйям робагыйлары, Сәгъди хикмәтләре, Җәми касыйдәләре, Хафиз газәлләре, Нәваи лирикасы белән танышу аны кулына каләм алырга этәргән. Егерме җиде яшендә инде ул үз әсәрләреннән «Газәлият» җыентыгы төзегән һәм шөһрәт казанып өлгергән.

Билал Назыйм феодализм эскәнҗәсе кыскан, ислам дине хорафатлары аңны богаулаган, чит ил баскыннары башбаштаклык иткән бер дәвердә яши һәм иҗат итә. Шагыйрь замандашларының авыр хәленә ачынып:

**Салым түли алмаган халык үз баласын сатты,**
**Түрәләр булды аждаһа, уйгырларга афәт чәчте,**
**Уйгырлар малын ашап туймады губернатор,**
**Ки бер йөз ничә ел кылган золымы хәттин ашты,**

— дип язды.

Менә шул газапларга чыдый алмаган халык 1864—1867 елларда баш күтәрә. Билал Назыйм да атасы белән бергә кулына корал алып манҗурларга, җирле феодалларга каршы көрәшүчеләр сафына баса. Сугышта атасы һәлак була, үзе яралана. Кузгалыш җиңеп чыккач, ул укыту, кулъязмалар күчерү белән шөгыльләнә, күп сәяхәт итә, халык иҗатын җыя һәм эпик, лирик әсәрләрен иҗат итә башлый.

Халыкның бай шигъри иҗатын рухына сеңдерү, шәрыкның бөек шагыйрьләре иҗатына таяну һәм тормыш эчендә кайнау Б. Назыймга тирән эчтәлекле, озын гомерле әсәрләр тудырырга мөмкинлек бирә.

Б. Назыйм газәлләренең күпчелеге мәхәббәткә багышланган. Әмма аның лирикасы бүтәннәрнекеннән нык кына аерыла. Күпләр мәхәббәтне ходайга һәм ахирәткә баглы гына күзалласа, Б. Назыйм иҗатында исә тормышны сөю, мәхәббәтне бер кешенең икенче кешегә омтылышы итеп сурәтләү, кешенең үз бәхете өчен көрәшергә тиешлеген исбатлау төп урынны ала. Мәхәббәт кешене рухландыра, аңа көч бирә торган нәрсә итеп карала. Б. Назыйм үз газәлләрендә заманының актуаль мәсьәләләрен дә күтәрде. Ул социаль гаделлек, шәхес иреге тарафдары була — олы җанлылыкны үрнәк итеп, байлар һәм руханиларның ачкүз, ялкау, икейөзлелеген фаш итә, хезмәт ияләрен яклый.

1876 елда иҗат иткән «Кытайларга каршы изге сугыш» дастанында шагыйрь XIX гасырның икенче яртысында Шәркый Төркстандагы чит ил басып алучыларына каршы азатлык сугышын гәүдәләндерә. Әсәрнең геройлары — авторның замандашлары, фикердәш һәм көрәштәшләре иде. Дастанда дунганнәрнең баш күтәрүе, уйгырлар белән берләшеп уртак дошманга каршы торулары һәм җиңүләре, соңрак исә үзара ызгышып, көрәшкә зыян китерүләре реалистларча күрсәтелә. Б. Назыйм үзе шаһит булган вакыйгаларны сурәтли, кытайлылар изүе астында халыкның җәфа чигүен гәүдәләндерә һәм көрәшкә өнди.

«Чаңмуза Йосыфхан» сатирик поэмасында исә дин әһелләре фаш ителә. Үзен хаҗи дип игълан иткән Йосыфханның икейөзле, кәкре куллы булуы, тәкәбберлеге һәм намуссызлыгы ачыла.

Б. Назыйм иҗаты күләме ягыннан зур түгел, әмма күтәргән мәсьәләләре, новаторлыгы җәһәтеннән зур игътибарга лаек. Мәсәлән, аның «Нәзегем» повесте уйгыр әдәбиятындагы беренче проза әсәре булып тора. Автор монда 1818—1820 еллардагы Җиһангир хаҗи җитәкчелегендәге кузгалышны, аны бастыру фаҗигаләрен гәүдәләндерүне бурыч итеп куя.

Баш күтәрүдә катнашкан ирләрне кырып бетергәч, басып алучылар хатын-кызларны читкә сата һәм калмыкларга көчләп кияүгә бирә башлыйлар. Нәзегем дә шул язмышка дучар ителә. Ирен һәм баласын манҗурлар үтерә. Нәзегем язмышка буйсынмаска карар бирә һәм әсирлектән ике тапкыр кача. Әсәрдә Ватанны, туган халыкны сөю, ирек өчен көрәш мотивлары үзәккә куелган, халыклар дуслыгы гәүдәләндерелгән.

Шагыйрьнең иҗади палитрасы бик бай. Ул төрле сурәтләү чараларын иркен файдалана, тормыш сөючән рухы, прогресска омтылышы белән укучы күңелен әсир итә. Музыка белән мавыгып, шагыйрь үз газәлләренә, Нәваи һәм Фөзүли әсәрләренә көйләр чыгара.

Шагыйрь манҗур-кытай басып алучыларының шәфкатьсез золымын татый һәм шуның аркасында 1882 елда аңа Или төбәгеннән качып баручы уйгырларга ияреп, Россиягә китәргә туры килә. Яркәнт шәһәрендә яши башлаган шагыйрь 1900 елда вафат була.

Б. Назыйм иҗаты — XIX гасыр уйгыр әдәбиятының иң югары ноктасы. Үз халкы арасында аның әсәрләрен белмәгән һәм җырламаган кешене табу читен. Шагыйрьнең «Кытайларга каршы газават», «Чаңмуза Йосыфхан» дастаннары, «Нәзегем» повесте Казанда нәшер ителгән һәм татар укучыларына да мәгълүм булган. Бу әсәрләр кайбер татар зыялыларын уйгырлар язмышы белән якыннанрак кызыксынырга этәргән. Н. Яушев, З. Бәшири, Г. Монасыйповлар соңрак үзләре дә уйгырлар турында мәкаләләр һәм әсәрләр язганнар. Н. Исәнбәт исә бала чагында укыган «Нәзегем» повестенең кайбер шигъри юлларын әле дә бик яхшы хәтерли.

**ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ.**

## Уйгыр шагыйре Билал Назыйм газәлләре

●

Аһ, гамәлгә ашмады күңел хыялларым минем,
Тамды яшь урнына күздән җиргә каннарым минем.

Мәңгелектән үк язылгандыр шушы язмыш миңа,
Әверелә көз фаслына яп-якты язларым минем.

Дусларым салды күңелгә көн дә мең төрле газап,
Калмады оят йөземдә, гәүдәдә хәлем минем.

Мин янам гыйшык утында нәкъ сәмәндәр[1] кук булып,
Калмады каным, корып бетте тамырларым минем.

Дивана булдым күреп айдай йөзен бер көнне мин,
Житте күкнең гөмбәзенә шунда аһ-зарым минем.

Шул пәри йөзгә багышладым тәнем, җаным тәмам,
Җан ни ул! — булсын фида аңарга иманым минем.

Бар кеше тели үзенә хур кызы төсле җанаш,
Шул пәри йөзле гүзәл тик хур вә гыйльманым[2] минем.

Ул зифа буйлы гүзәлем булса ханәмдә әгәр,
Иң матур җәннәт булыр җимрек бу абзарым минем.

●

Кашыңны кап-кара диләр,
Йөзеңдә нур яна, диләр,
Әгәр гыйшкыңда җан бирсәм,
Шәһит булды, дияр ирләр.

Барыр юлың туры булсын,
Кызыл гөл юлдашың булсын,
Синең күк назлы бер ярга
Минем күк бер колың булсын.

Илеңнең бакчасында син
Ачылган гончәсе гөлнең,
Ачылган гөлне мактарга
Минем күк былбылың булсын.

Көмеш икән касәләрең,
Синең чәйнекләрең алтын,
Хан урдасында һәр вакыт
Йөрер урның, юлың булсын.

Йөгертеп бер килим, дисәң,
Әгәр сайлап гарәп атын,
Назыймның гәүдәсе сиңа
Ат өстендә җулың[3] булсын!

●

Надан белән дус булма, вөҗданы юктыр,
Дусын сатар җай килсә, иманы юктыр,
Наданнарның уе һәр вакыт бозыктыр,
Бөтен кылган эше гел ялганчылыктыр.

Ирек куйсаң, наданнар эшләр барын да,
Акылын сатар, гел мәкер булыр аңында,
Көлке итәр җиһанның халкы алдында,
Ни кылса кылыр, һич уйлап тору юктыр.

---

[1] Сәмәндәр — әкиятләрдә ут эчендә яшәүче, кәлтә еланга охшаш җан иясе.
[2] Гыйльман — җәннәт егете.
[3] Җул — ат өстенә ябыла торган җәймә, япма.

Наданнан кач, Назыйм, кылма аңа дуслык,
Дуслык кылсаң, булырсың син үзең бозык,
Наданнарга ишек ачма, бикне тот нык,
Наданнарда гыйшык һәм мәхәббәт юктыр.

●

Бул бәхил, әй йөзе аем, бул бәхил,
Бул бәхил, әй зифа буем, бул бәхил!

Бул бәхил, әй якты күңелем, бул бәхил,
Бул бәхил, әй назлы гөлем, бул бәхил!

Бул бәхил, әй бәгъре катым, бул бәхил,
Бул бәхил, әй барча халкым, бул бәхил!

Бул бәхил, әй барча гашыйк, бул бәхил,
Бул бәхил, әй тугры дуслык, бул бәхил!

Бул бәхил, изге адәмнәр, бул бәхил,
Бул бәхил, дәрвиш ирәннәр, бул бәхил!

Бул бәхил, әй барча солтан, бул бәхил,
Бул бәхил, бар ир-арыслан, бул бәхил!

Бул бәхил, әй барча заман, бул бәхил!
Бул бәхил, әй барча дастан, бул бәхил!

Бул бәхил, барча бәхетле, бул бәхил,
Бул бәхил, бар мәрхәмәтле, бул бәхил!

Бул бәхил, барча терекләр, бул бәхил,
Бул бәхил, бар саф йөрәкләр, бул бәхил!

Барча яшьләр һәм олуглар, бул бәхил,
Бул бәхил, барча оруглар, бул бәхил!

Дивана булды Билал гыйшкы аша,
Бул бәхил, әй барча галәм, бул бәхил!

**Уйгырчадан ӘХМӘТ ИСХАК тәрҗемәләре.**

Абдулла Сәләхетдинов

# СЫНАТМАС СОМОВЛАР



Федор карт ул көнне юлдан күзен алмады. Улларының кайтуын көтте. Гаҗәеп бер хис иде аның күңелендә. Әйтерсең балалары бик тә җаваплы имтихан тапшырырга киткәннәр һәм бу сынауны үтә алсалар, алар белән бергә бабайның өенә шатлык керер, бәйрәм килер.

Үзенең генә тыз-быз йөрүе җитмәгән, карчыгына да тынгылык бирми. Иркен өй эченең әле бер почмагыннан, әле икенче ягыннан тамакны кырып кына тора картың:

— Самаварың әзерме, анасы?

— Куйдым инде, куйдым.

— Ризыкларыңны өстәлгә чыгар, малайлар кайтып керүгә табының түгәрәк торсын. Кара аны, йөгереп йөрергә калмасын эшең!..

Мария Александровна, мич тирәсендә кайнаша-кайнаша, ризасызлык белдереп сөйләнә:

— И ходаем, печән өстендә каныккан кигәвен булдың лабаса... Бетмәде шул мыжыклыгың.

— Нәрсә каркылдыйсың син анда? — Карт, җилтерәп, мич аралыгына килеп керә. — Өстәлгә балыңны чыгар да, кәбестә пирогын көйдермә. Бөкрене күрсәтергә дә күп алмам мин сиңа!..

Картның бу сүзләре кысыр болыт кына, әлбәттә. Шуңа күрә Мария Александровна аңа карап кеткелди генә.

— Суга алмаган авыр күтәрер дигәннәр — дөрес икән.

Ул арада ишек ачылды. Бусагада картның өлкән улы күренде. Түзмәгән Анатолий, күрше авылдан килеп җиткән. Борчыла, дулкынлана шул — туган бит! Әнекәшләрен сораша:

— Кайтып җитмәделәрме әле?

— Юк, улым, — диде Федор карт. — Әйдә, түрдән уз!

Сап-сары итеп юылган идәнгә басарга кыймады Анатолий — итекләрен ишек төбендә салып, әчкә үтте. Карт аның урындык алып утырганын тыныч кына көтеп торды. Аннары улы янынарак килде:

— Әйт әле, Толя, анда ниләр сорашалар?

— Кайда? — дип сорады улы, аңламаганга салышты.

— Райкомда инде... Партиягә кабул иткәндә.

Анатолий көлемсерәп кенә әтисенә карады. Карт, авызы белән кош тотарга әзерләнгәндәй, аның җавабын көтә иде.

— Сорауларның төрлесе була, эти. Иң мөһиме — эшеңә карыйлар.

— Эшеңә дисең?.. — Федор карт, уйчан карашын улына төбәп, сакалын сыпырып куйды. — Алайса, тулы тәртип, Толя. Эш дигәндә, безнекеләр сер бирә торганнардан түгел. Сынатмый Сомовлар!.. Сынатмый! — дип кабатлады ул һәм Анатолий янына утырды.— Безнең нәсел шундый, улым, кендеге белән җиргә береккән. Эш дигәндә җиңел куллы. Моны барысы да белә...

Арттырмый да, киметми дә Федор карт, дөресен әйтә. Авылда Сомовларны белмәгән, хезмәтләре өчен ихтирам итмәгән кеше юк. Барысы да зурлый аларны. Совхоз идарәсе урнашкан бина яныннан узганда, зур стендларга күзең төшми калмый. Шуларның берсеннән — «БЕЗНЕҢ ВЕТЕРАННАР» дип язылганыннан — күзләрен кысыбрак рәсемгә төшкән карт карап тора. Астына эре-эре хәрефләр белән: «Федор Никитич Сомов» дип язылган. Шуның янәшәсендә генә совхозның Мактау тактасы. Анысында Анатолий Сомов рәсеме. Сигезьеллык мәктәп бинасында «Алар бездә укыдылар. Производство алдынгылары» дигән хөрмәт почмагында тагын ике Сомов: Коля белән Ваня.

Федор карт, үз өендә утырган килеш, хыялы белән шуларны карап авыл буйлап узды. Аннары район үзәгенә юл алды. Анда, матур поселокның үзәк мәйданы түрендә, хөрмәт флагы җилферди. Аны производствода зур җиңү яулаган кешеләр хөрмәтенә күтәрәләр. Флагштокка беркетелгән кызыл тактада фамилияләр гел алмашынып тора. Сомовлар анда да еш күренә. Хөрмәт флагы аларның әле берсен, әле икенчесен зурлап җилферди.

Картның ул флагның җәйге җилдә талпынуын, кызыл коштай очынуын күзәтеп торганы бар. Сомовларның берәрсе хөрмәтенә җилфердәгән чакта, ул флагтан Федор Никитичның күңеленә ниндидер җылы нур бөркелә сыман. Андый рәхәт минутларны бик еш кичерә карт. Хәзер дә менә, тәрәзәдән урамга караган килеш, еракта җилфердәгән хөрмәт флагын күз алдына китерә шикелле. Аны бөтен район күреп тора, әлбәттә. Кемне зурлап балкый дисең ул кызыл нур?.. Сомов Анатолий хөрмәтенә! Юк, бер аны гына олылап түгел, бөтен Сомовлар нәселен зурлап җилферди кызыл флаг! Карт аны шулай күзаллый, шулай булырга тиеш дип саный...

*

* *

Нәкъ шушы минутларда райком бюросы бара иде. «Красный партизан» совхозының партоешма секретаре сүзен йомгаклап куйды:

— Без бүген өч бертуган Сомовларны партия сафларына тәкъдим итәбез. Бу мәсьәләне җыелышта тикшердек. Коммунистлар бертавыштан хуплады. Сомовларны барыбыз да бик яхшы беләбез. Совхоз коммунистлары исеменнән зур ышаныч белән әйтә алам, иптәшләр: Сомовлар — хуҗалыгыбызның алдынгы механизаторлары, төп таянычлары. Ә партия сафына баскач, алар партоешмабызның активы, терәге булырлар.

Райком бюросы членнары алдыннан өч туган үтте. Арысландай ир-егетләр. Алардан биографияләрен сөйләүне үтенделәр, әлбәттә. Сомовларның һәркайсы бик кыска итеп, өч-дүрт җөмлә белән җавап бирде. Егетләрнең уртак биографиясендә туган җирне яраткан, Федор карт әйтмешли, «шул җиргә кендекләре белән береккән» кешеләрнең язмышы гәүдәләнде. Болар — буразнада маңгай тирен җәлләми торган игенчеләр, куәтле техниканы эшкә җиккән оста механизаторлар. Алар өчесе дә сүзне этиләреннән башлады.

... Федор Никитич Сомов гомерен туган авылы кырларында, фермаларында, көтүлекләрендә үткәрде. Колхозда игенен дә икте, малтуарын да карады. Заманында матур атлар үстерде. Сыртлары елкылдап торыр иде малкайларның! Баскан урыннарында тупырдарлар иде! Монысы инде бик күптәнге хатирә, сугышка кадәре үк булган хәлләр. Фронтка күпме озатты ул атларны Федор Никитич — йөзләп! Канлы зилзилә үтеп, еракта гөрселдәгән туп тавышлары тынгачтын, аңа дуңгыз фермасын тапшырдылар. Ул чакта бит зоотехнигы-ветеринары да юк иде. Ата-баба тәҗрибәсе белән эшләргә туры килде. Үзе мөдир дә, дуңгыз караучы да. Һай, авыр да булды соң ул чаклар! Ни азыгы такы-токы, ни каралты-курасы рәтле түгел. Шундыйда да түгәрәк борыннарны күпләп үстерде Федор Никитич. Хатыны Мария Александровна фермада да картының уң кулы булды. Сугыш елларының мәшәкатен бергә күтәргән иңнәр тыныч көннәр хезмәтенең авырлыгын да җиңде. Икесен дә «Бөек Ватан сугышы чорында фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләделәр. Уртак эшләрен тигез олылау иде бу, лаеклы хөрмәт иде. Шуннан соң инде күпме еллар үтте дә, күпме сулар акты — ә Федор карт һаман фермада. Хезмәте буенча каравылчы булып исәпләнә, ләкин башкарып йөргән эшләре — санап бетергесез! Кайчан карама — балтасы белән чүкече кулында булыр. Кушканны көтмәс, хакын сорамас. Бер ферманың ишеген төзәтеп алыр, икенчесендә тәрәзә рамнарын ныгытыр. Кулы белгәнгә, күңеле теләгәнгә шөгыль бетә димени фермада! Мөдирнең җаны тыныч.

— Федор Никитич барында борчылырга урын юк,— дип, ферма башлыгы аның нәләр эшләвен саный.— Ветеринарга булышчы, зоотехникка ярдәмче ул. Үземнең уң кулым. Бөтен совхозның фермада күз-колагы.

Династия башлыгының хезмәтен шулай бәялиләр.

Ә өендә?.. Федор Никитичның өендә тугыз бала үсте. Канат яргач оядан очкан кошлар шикелле, төрлесе-төрле якларга таралды. Ә дүрт улы туган җирдә оя корып калды. Эштә, әтиләре кебек үк, ялыгуны белмиләр, кушканны көтмиләр. Берәр шөгыльгә керешкәннәр икән инде — очламый тынмаслар. Кечкенәдән шулай башладылар. Ояда ни күрсә, очышта шул була дигәндәй, туган йорттагы тырышлыклары кайда да юлдаш үзләренә. Солдат хезмәтендә булдылар — командирларыннан ата-анага рәхмәт хатлары явып торды.

* * *

Федор Никитич, пыялалы зур шкафны ачып, бер төргәк алды. Аны чишеп җибәрүе булды — өстәл өсте Мактау грамоталары, рәхмәт сүзләре язылган телеграммалар һәм хатлар белән тулды, карт шулар арасыннан берсен алды да:

— Әйт әле, Анатолий, моны нинди хезмәтең өчен язганнар иде безгә? — дип сорады.

— Нәрсәсен әйтеп торасың инде аның, әти. — Анатолий бармаклары белән өстәлгә чиерткәләп утыра. — Танкист идем бит мин, анысын беләсең. Йөртүче-механик. Бер өйрәнү вакытында югалып калмадым, шуңа яздылар...

Анатолий солдат чакларын искә төшерде. Үзе «югалып калмаган» өйрәнүләрне хәтерләде. Көз көне булды бит әле ул? Әйе, сентябрь урталары иде. Яфракларга алтын йөгергән чак. Ул хезмәт иткән төбәктә елның бу вакыты бик яңгырлы була. Өйрәнүләр башланган чакта да өзлексез сибәләп торды. Ә рота командиры моңа сөенде.

Куктән яңгыр түгел, куаныч явамыни — болытларга карый да күңеленләдәге уйларын әйтә:

— Танкның ниндилеген, танкистның кемлеген шундый чакта белеп була инде, егетләр! — ди.— Сынатсагыз — рота йөзенә кызыллык, алдынгы булсагыз — ротага дан, бөтен дивизиягә дан. Шулай тора әш. Хәрби осталыкка сынау бу яңгыр...

Өйрәнүләр беренче көннән үк аеруча киеренке башланды. Йөртүче-механигы Анатолий Сомов булган танк экипажына елга кичәргә, каршы як ярга чыгып, «һөҗүмгә» барырга приказ бирелде.

— Алга! — танк командирының тавышы шлемофонда яңгырады.— Кузгалдык, Толя... Полный газ!..

Кисәк ыргылып киткән танк, яр буйлап килде дә, күрсәтелгән урында борылып, суга керде. Елга артык тирән түгел, ләкин каршы якта яр бик текә иде. Ажгырып килгән машина кинәт тукталып калды. Мотор сүнде.

— Нәрсә булды, Сомов? — шлемофонда рота командирының тавышы яңгырады. Рация буенча сөйләшә иде ул. Каян күреп өлгергән дә, ни арада элемтә урнаштырган. — Сездән сорыйм, Сомов! Нигә тукталдыгыз?..

Анатолий эндәшмәде. Иреннәрен тешләп, күзләрен кыса төшеп,— монысы инде этисенә охшаган гадәт, — ул каршыдагы ярга карап торды. Әллә ни биек тә түгел үзе... Ләкин бик текә. Бу урынның махсус сайланган булуы да ихтимал иде. Нишләр, янәсе, танк йөртүче Анатолий Сомов? Үтә алырмы табигый киртәне, әллә аптырап торырмы?.. Уза алмаса... рота йөзенә кызыллык! Командир шулай диде бит. Елганы кичү өчен бүтән урын эзләсәң — вакыт оттырасың! Юк, ничек тә шушыннан үтәргә кирәк! Җаен табарга! Танк белән бәрдереп карасаң, ничек булыр икән?

Машинаны артка чигендерә дә механик, тулы газ биреп, алга ыргыла. Үкереп, су баганалары күтәреп барган танк, маңгай бронясы белән яр кырыена килеп бәрелә, дерелдәп киткәндәй була. Ләкин өскә күтәрелеп китә алмый. Анатолий Сомов ярның умырылып төшүен күреп ала да шул ук маневрны яңадан кабатлый. Корыч танк өстенә яр ишелеп төшкәндәй — шыбырдап таш-ком коела. Тузан-туфрак өермәсе күтәрелә. Һәм шул өермә эченнән танк килеп чыга да яр естенә ыргыла. Механик шунда гына аңлап ала: ясалма киртә булган лабаса бу! Табигать тирәлегенә шул кадәр оста итеп корылган ул, баштарак хәтта кыяга ук охшап күренде.

Танк яр өстенә күтәрелеп җитүгә, рота командирының тавышы янә ишетелде:

— Тапкырлыгыгыз өчен рәхмәт белдерәм, иптәш Сомов!..

— Советлар Союзына хезмәт итәм! — Анатолийның тавышы көр. Машинасы сынатмады. Үзе дә аптырап-каушап калмады.

Рота өйрәнүләрдән кайткач, командование аның әти-әнисенә рәхмәт хаты яза. Картларның башы күккә тигән. «Туган илгә шундый тырыш, эшчән һәм кыю солдат үстереп җибәрүегез өчен Сезгә, Федор Никитич, һәм Сезгә, Мария Александровна, бик зур рәхмәт!» дип ерактан зурлап, исемеңне атап, хат язсыннар әле. Улларын дөрес тәрбияләгәннәр булып чыга бит инде бу. Күңелгә куаныч өсти торган хәл!.. Ата-ана йөрәген җилкендерә торган хәбәр!..

Шуннан соң Анатолийны партия сафына кабул иттеләр. Рекомендация бирүчеләрнең берсе механикның осталыгын, өйрәнүләр вакытында да «югалып калмавын» сөйләде. Аңа сорау бирделәр:

— Әйтегез әле, иптәш Сомов, яр буендагы киртәнең ясалма икәнен белдегезме?

— Белмәдем, — диде механик. — Бу урыннар миңа таныш ту-

гел бит. Аннары ул бик оста яраклаштырып корылган иде. Табигый киртә дип уйладым мин аны.

— Ә танкыгыз туктап калгач, нинди хис кичердегез?

Анатолий чак кына уйланып торды.

— Рота командирын күз алдыма китердем. Аның сүзләре искә төште. Подразделениебез йөзенә кызыллык төшерүче булмасам гына икән, дип уйладым. Яшен шикелле, бик тиз үтте бу фикер. Шундук салкын кан белән уйларга керештем... Мөмкинлекләрне чамаладым...

Бүтән сорау бирүче булмады.

— Коммунистлар партиясе сафына кабул ителүегез белән котлыйм, иптәш Сомов! — политбүлек начальнигы аның кулын солдатларча каты итеп кысты.

Армиядән шундый чыныгу үтеп кайткан Анатолий Зәй ГРЭСын төзүдә дә эшләгән. Анда да рәсеме Мактау тактасында булган. Квартирага ордер алырга чакырганнар Сомовны, ә ул эштән китәргә үтенеп гариза язган. Нигә дисәң...

— Үзем Зәйдә, күңелем туган авылымда иде, — дип искә төшерә ул чакларны Анатолий. — Тәки тартты туган җир, кайтарды да үзенә беректереп куйды.

Әтисе аның бу сүзләрен хуплап башын селки:

— Нәселебезнең кендеге җиргә береккәнгә күрә шулай ул, Толя!

Федор карт бәлкем хаклыдыр. Аның улы сабый чактан үзенә таныш һәм газиз булган кырларда тагын да дәртләнебрәк эшли. Бер елны район сабанчылары ярышында беренчелекне яулаган. Аннары республика күләмендә икенче урынга чыга. Шул ярышта җиңү истәлеге — ау мылтыгы — өй алдында әле дә эленеп тора.

Хәзер ул — совхозның ремонт мастерскоенда механик. Һәр машинаның гөрләп эшләве өчен җаваплы кеше. Кирәк чагында аларны дәвалаучы да. Төрле маркадагы тракторларны, комбайннарны — барысын да карарга, «диагноз» куярга туры килә. Ялгышмый Анатолий Сомов, машинаның кайда нинди «чире» барын тиз һәм төгәл билгели.

— Машинаның йөрәге — мотор, аның ничек эшләвенә колак салу белән, кай төшендә төзексезлек барын белергә була...

Бу сүзләрне ул тыныч кына әйтә. Гүя ки, шундый осталык аңа үзеннән-үзе килгән һәм ул аны гадәти хәлгә саный. Ә бит механик техниканы шул дәрәҗәдә белсен өчен күпме теоретик уку кирәк тә, нинди зур тәҗрибә хуҗасы булу шарт,— моны ул үзе генә чамалый торгандыр.

Тыйнак кеше Анатолий. Хәер, Сомовларның барысы да шундыйлар.

Совхозга Т-150 маркалы яңа трактор кайтарылган иде. Аңа утырырга, буразнага алып чыгарга кеше юк. Механизаторлар җитешми. Кемдер әйткәнне көтмәс бит инде механик — куәтле тракторны кырга үзе алып чыкты. Туңга сөрү вакыты иде, сменага икешәр норма эшләде.

— Механик абруен күтәрдең син болай, Анатолий Федорович, — дип сөенечен белдерде совхоз директоры. — Хәзер инде башка механизаторлардан да шундый ук эш көтә алабыз...

Яңа тракторга хуҗа табылгач, механик тракторның башкасына — К-700 маркалысына күчеп утырды. Анысын да җырлата-гөрләтә. Серен белгәч, машиналарның барысы да кыр киңлекләрен шаулата.

Бүтәннәре дә аңардан ким түгел. Яшь ягыннан аңа энекәш булсалар да, эш ягыннан тиңдәшләр.

Александр «Алтай» тракторында эшли иде. Үч иткәндәй, кылны кырыкка ярырлык бер чакта, моторны алмаштырырга кирәк булды.

Колакка ятышсыз шакылдаулар ишетелә башлады үзеннән. Механизатор тракторны туктатты. Булышырдай кешеләр барысы да кырда — ярдәмгә исәп тотып булмый. Механик абыйсы килмәкче иде дә, Саша үзе риза булмады.

— Шул куәтле тракторны туктатып, ремонтка ябышсаң, гөнаһ булыр, абый. Үзем генә ерып чыгармын, борчылма!..

Федор картның икенче улы бер ялгызы мотор алыштырырга керешге. Ремонтчылар бригадасы эшләгәндә дә дүрт-биш көнгә сузыла торган бу эшне Александр тиз тотты. Өченче тәүлек тула дигәндә, кичкә табан, «Алтай»ның яңа йөрәге тибә башлады. Механизатор аның тигез гөрелтесенә колак салып торды да:

— Болай булгач, киттек кырга, дускай! — дип, кабинага сикереп менде һәм тракторны басуга алып чыкты. Кырда очрашып, Анатолий аңардан:

— Нихәл, энекәш, «Алтай» булдырамы? — дип сорады.

— Бүген норма ярым гына булды, — диде Александр. Үз эшеннән канәгать түгел иде, күрәсең. Иртәгесен, туңга сөрүдә ике норма үтәп, механик абыйсына баш бармагын күрсәтте:

— «Алтай» әйбәт эшли башлады...

Шундый ул — Федор картның икенче улы.

Ә өченчесе — Николай — республика күләмендәге премиягә лаек булган механизатор. Кукуруз игү звеносында эшләгән. Яшел массаны бик әйбәт үстергәннәр: 75 гектарның һәркайсыннан дүртәр йөз центнер алынган.

Тракторга моннан унике ел элек утырган Николай. Төпләнәсе җирен тиз генә сайламады — бер ара читтә дә йөреп карады. Профессиясе һәркайда кирәкле бит, эшнең төшемлеләрендә дә булган, акчаны кесә тутырып алган. Ләкин егетнең күңеле туган якны сагына. Авылга әйләнеп кайта Николай. Туган йорт бусагасыннан үтүгә, әтисенә әйтә:

— Басу һавасы, арыш исе кирәк икән миңа, әти. Алары да кайдадыр читтә түгел, менә шушында, үз кырларыбызда булсын. Шуны аңлап кайттым, бүтән кыбырсыйсым юк...

Әй, Федор Никитичның шул чактагы куануларын күрсәң икән! Кая басканын белмәде. Күңеле йомшап китте. Читтән кайткан улының аркасыннан сөя-сөя, үзенең бик тантаналы чакларда гына әйтә торган сүзләрен кабатлады:

— Адәм баласының ике әнкәсе бар, улым: берсе — тудырган-үстергән әнкә, икенчесе — кешегә ризык биргән, аны туендырган җирана. Туган якларында ул икеләтә кадерле. Шуны аңласаң, сиңа җирдән дә изгерәк нәрсә булмаячак...

Кем белсен, Николайны бәлки чынлап та шушы тойгы дәртләндерә торгандыр. Менә ничәнче ел инде ул, туган кырларында җилкенеп, авылдашлары әйтмешли, «умыртып» эшли.

Былтыргы яз аның да осталыгын сынап алды. Кайчан диген бит — чәчү кызып киткән чагында, вакытның һәр минуты кадерле көннәрдә. Шулай әйбәт кенә эшләп йөри иде — тракторы киреләнә башламасынмы! Тизлек алыштыргыч тартмада нидер шалтырарга тотынды. Машина белән алыш-биреше булган кешеләр моның ни икәнен бик яхшы беләләр инде. Тартманы ачарга, теге шалтыр-шолтыр килгән урынны төзәтергә кирәк,— башка бернинди юл юк. Зур эш, шактый озакка сузыла торган ремонт бу.Коля моңа төнгә каршы тотынды. Фаралар яктысында тизлекләр тартмасын сүтеп ташлады. Нәрсәләрнедер юды, чистартты, ниндидер детальләрне алмаштырды. Җәйге төн кыска булса да, җитез куллар күп эш башкарырга өлгерә икән! Кояш күтәрелә башлаганда, Коляның тракторы инде, авылдан чыгып, басуга таба китте. Бераздан ул культивацияләү эшенә дә керешге.

Чебешне кѳзен саныйлар дигәндәй, аның хезмәтен дә уңыш бәйрәмнәре үткәч бәяләделәр. Егеткә акчалата бүләк тә, истәлекле әйберләр дә бирелде. Совхозның үзәк авылында үткәрелгән тантанадан бер кочак бүләк күтәреп кайтты ул. Нәкъ шул кичне аның күкрәгендә «Тугызынчы бишьеллык ударнигы» дигән значок балкыды.

Улына бирелгән бу бүләкне Федор карт башта, саллымы икән дигәндәй, учына салып торды, аннары кытыршы бармаклары белән капшап карады. Бераздан, значокны Николайның күкрәгенә беркетеп, аңа читтән күз салды.

— Бѳтенләй сабыйларча кыланасың инде, атасы, — дип канәгатьсезлек белдерде Мария Александровна. — Я, әйт инде миңа, тәти күргән сабыйдан кай җирең артык?..

Карт моны ишетмәмешкә салышты.

— Килешә, улым, бик килешә бу сиңа, — дип сѳйләнә-сѳйләнә, Николайга якынлашты. — Геройга охшата үзеңне. Икмәктер менә!..

— Рәхмәт, әти!

Федор Никитич янә улының аркасыннан какты:

— Молодец, Коля! Зуррагын алырга да насыйп булсын!.. Эшләсәң, бирерләр. Медален дә, орденын да бирерләр.

Шул ук кѳнне Николай мѳгезле эре терлекләр ѳчен җитештерелгән комплекста эшли башлады. Монда ул зур чүмечле экскаватор белән идарә итә. Машиналарга азык тѳяп тора.

— Сомов килгәннән бирле кинәндек, — диләр терлекчеләр. — Тѳягеч машина гел ватыла иде. Хәзер, тфү, күз тимәсен, һәр вакыт тѳзек.

— Николай кулында ватылмас ул! — дип ѳсти икенчесе, һәм ул да моны зур ышаныч белән әйтә.

— Алар барысы да шундыйлар, — дип нәтиҗә ясый ферма мѳдире. — Техниканы беләләр, авыл хезмәтен яраталар. Андыйлар кулында машина да көндәм була. Бер сүз белән әйткәндә, Сомовлар нәселе...

Сомовлар нәселе!.. Ферма мѳдире әлеге сүзләрен әйткәч, мин уйлана калдым. Революциягә кадәрге чорда Рәсәй җирендә аксѳякләр аз булмаган. Алар үзләренең чыгышлары, нәселләре белән кукрайганнар. Ә чынлыкта бу «асыл затларның» тамыры черек булган. Алар илгә — таяныч, халыкка — терәк була алмаганнар. Ә бүгенге Сомовлар нәселе?.. Чын күңелдән игенче хезмәтен яраткан, бәхетен маңгай тирен түгеп авыл җирендә тапкан гади кешеләр нәселе — авылга таяныч, бѳтен илгә терәк! Аның тамыры нык. Ул үзенең бѳтен барлыгы белән җиргә береккән, хезмәткә тоташкан. Безнең Совет дәүләте нәкъ менә шундый игенче һәм эшче династияләрне хѳрмәтли дә инде. Сомовлар гаиләсенә совхозда, районда күрсәтелә торган хѳрмәт һәм ихтирам — шуның билгесе бит!

Федор картның дүртенче улы Ваня да абыйлары эзеннән китте — механизатор булды. Тѳпчек малай ул, арада иң яше, шулай да Сомовлар гвардиясендә үз урынын табарга ѳлгергән инде. Мәктәптә укыганда ук техника җене кагылган иде үзенә. Трактор, комбайннар тирәсендә мәш килеп йѳрде. Абыйлары да читкә тибәрмәде — беренче остазлары булдылар. Парта арасыннан чыгуга, тракторга утырды Ваня. Беренче елны ук, абыйлары шикелле, үз дигәнен булдыра алуын күрсәтте. Авыл хуҗалыгы машиналарын ѳйрәнде, агротехника нигезләре белән таныша башлады.

Хәзерге заман авыл хуҗалыгы производствосының бер үзенчәлеге бар: механизатор кеше агротехника алымнарын белергә, ә агроном исә механизация мѳмкинлекләре белән яхшы таныш булырга тиеш. Шушы ике нәрсә бергә кушылган чакта гына игенче хезмәте нәтиҗәле була. Ваня шуны аңлап эшкә башлады. Игенче хезмәтенә ул

механизатор күзлегеннән генә түгел, җир серен белүче кеше буларак та карый. Өлкән абыйларыннан аерылыбрак торгаи сыйфаты да шулдыр, мөгаен.

Тракторда эшли башлаган елны туңга сөрүдә Иван Сомов көн саен норма ярым үтәп барды. Аның яхшы эшләве турында партком һәм совхоз дирекциясе әти-әнисенә хат яздылар, рәхмәт белдерделәр. Картлар шуңа сөенә дә. Балаларының армия сафындагы хезмәте өчен дә, туган авыл кырларында дәртләнеп эшләве өчен дә гел рәхмәт сүзе ишетеп тору күңелләрен эретә, куандыра. Ләкин Федор карт хәсрәт килгәндә дә, шатлыгы ташып торган чакта да сер бирә торганнардан түгел. Улларының удар хезмәте өчен рәхмәт белдереп язылган хатларны кулында тоткан килеш ике генә сүз әйтә:

— Сомовларча бу!..

Берчак аның бу сүзләрен Анатолий ишетеп торды һәм, Иванга ишарәләп, шаяртып алды:

— Ваняны өйләндерсәң дә була инде, әти. Солдат буткасын авыз итеп кайтты. Егетлеген эштә раслады.

Әтисе аңа көлемсерәп кенә карады да ярып салды җавапны:

— Өчне үткәргәнне, тагын бер туй гына уздырырбыз инде, Анатолий Федорович. Шулаймы, анасы?..

— Иртәгә килен төшерсә дә риза, — дип килеште Мария Александровна. — Дүртенче кодагый кем булыр менә — шунысын тизрәк беләсе иде.

— Анысын чамалыйбыз инде чамалавын...

Федор карт сүзен әйтеп бетермәде.

Район үзәге Зәйгә табан сузылган юлларга карап, шуларны уйлады, шуларны күздән кичерде ул көнне Федор Никитич. Уллары кайтеп кергәндә, өйдә табын корылган, җиз самавар пар бөркеп утыра иде. Анатолий да китмәгән — көткән.

— Ничек, балалар? — дип төбәде аларга түземсез карашын Федор Никитич.

— Котла, әти: өчебезне дә партиягә кабул иттеләр.

Федор бабай түргә кереп утырды.

— Мине, партиясез большевикны, тыңлагыз, улларым...

Дүрт егет аңа текәлде. Ә карт әйтер сүзен дә онытып җибәрде, ахрысы, чыланган күзләрен сөртә башлады.

— Мин бик бәхетле кеше бүген, балакайларым!.. Бик бәхетле!.. Рәхмәт сезгә... Шундый булган өчен рәхмәт!..— диде ул һәм йомшак кына тавыш белән өстәп куйды: — Беркайчан да сынатмагыз, балалар!..

Уллары — типсә тимер өзәрдәй егетләр — гаиләдә инде күптән девиз булып әверелгән сүз белән җавап бирделәр:

— Сомовлар сынатмас, әти!..

Федор карт күзләрендә җемелдәгән шатлык яше аралаш елмайды. Уллары нинди бит аның, күрче: дүрт солдат, дүрт игенче, дүрт коммунист! Замана мәшәкатьләрен үз иңнәренә күтәргән кешеләр.

**У. Белялов,**
тарих фәннәре кандидаты

# ИР АСЫЛЫ — ИЛГӘ ТАЯНЫЧ

Элле инде тарихны өйрәнүче булганга, музейларда йөрергә яратам — үткән чорлардан сакланып калган һәр экспонат, әйбер яки фоторәсем миңа бик кадерле. Озаграк карап торсам, алар җанланып китәләр кебек.

Татарстан Дәүләт музеенда йөргән көннәрнең берендә зур гына фото янында тукталып калдым. Рәсемдә таныш кешеләр: хезмәтләре белән тарихка кереп калган дәүләт эшлеклеләре, партиябезнең күренекле җитәкчеләре. Араларында якташларыбыз да бар. Шуларның берсе — заманында Татарстан республикасының Халык Комиссарлары Советын җитәкләгән Хаҗи Заһидулла улы Габидуллин. Кыю һәм тәвәккәл кеше, зирәк акыллы дәүләт эшлеклесе, киң эрудицияле галим.

Бик күп мәкаләләрен, речьләрен, докладларын, фәнни хезмәтләрен укыганым бар. Ә үзе, барыннан да элек, иң гади бер кешедер кебек. Чыннан да, нинди булды икән соң ул?

Шул ук стенд янына шактый калку буйлы бер карт килеп басты. Йөреше-кыяфәте белән хәрбиләрне хәтерләтә: төз гәүдә, хәрәкәтләре җиңел һәм төгәл. Ул да мин карап торган рәсемгә текәлде.

— Беләсезме, биредә минем яшьлек дустым бар. Шуның белән очрашырга киләм мин бу залга...

— Танышыйк булмаса, — дип аңа кул суздым, исемемне әйттем.

— Мин Петухов булам, — диде карт. — Михаил Васильевич дип тә зурлыйлар. Үзем отставкадагы офицер. Тумышым белән Көнгәр ягыннан. Ишеткәнегез бармы?..

— Көнгәр ягыннан?.. Димәк, сез Хаҗи Габидуллинның якташы.

— Якташы да, классташы да. Бер класста укыдык без Хаҗиәгъзам белән. Тулы исеме шулай иде аның.

Сүз бик тиз ялганып китте һәм беребез дә аны өзәргә ашыкмадык. Хәтере шәп икән картның. Икәүләшеп Хаҗи Габидуллинның тормыш юлын күңелдән кичердек.

— Кечкенәдән үк таза, зирәк малай иде Хаҗиәгъзам, — дип башлады сүзне Петухов. — Сережа Седов белән бер партада утырдылар.

Дүрт классלы шәһәр училищесында. Хаҗиәгъзам — өлгер, кыю, шук. Коңгырт күзләре сине үтәли күрә сыман. Ачулы чагында ул күзләргә чалынмаска тырыш — көйдереп алуы ихтимал. Ләкин бу ут борчасы беркемне дә урынсызга рәнҗетмәде. Малайлар арасында һәркайчан калай әтәчләр дә була бит. Безнең класста да бар иде алар. Тәнәфес вакытларында шулар үзләреннән кечкенәләргә каныга, аларны кыерсыта. Мондый чакларда инде Хаҗиәгъзам чәчрәп чыгар, нәниләрне һич рәнҗеттермәс иде. Абыйсын да хәтерлим: сугыш чукмары инде! Кулы кая төшкәнен белми. Ә монысы, кечкенәрәк булса да, төптән уйлап эшли. Үз дигәнен булдырмый калмас, инанган фикереннән кайтмас. Ихтыяр көче зур иде. Ул ничектер берчакны хәтта өч-дүрт көн укырга килмәде. Малай, һичшиксез, ниндидер гаделсезлеккә каршы протест белдерергә уйлаган булса кирәк. Кыюрак укучылар бездә моны шулай эшли иде.

Без, Хаҗиәгъзамның классташлары, сирәк булса да аларның өенә барып йөрдек. Аның әтисе — Заһидулла ага — мулла иде. Дин башлыгының йортына рус малайларының килеп йөрүен мәхәллә халкы хупламагандыр, билгеле. Тик Заһидулла абзый безгә караңгы чырай күрсәтмәде. Хәер, бик үк ачылып китмәде кебек. Русча сөйләшүе — тел тидергесез иде: матур, дөрес! Гарәп-фарсы телләрен дә су урынына эчә дип сөйләделәр. Укымышлы кеше булган, күрәсең. Өйләренә татарча гәзитләр дә, русча басмалар да килә иде. Улларын да шәһәр училищесына русча укырга кертте. Шулай да Хаҗиәгъзам белән әтисе арасында ниндидер упкын бар иде шикелле. Малай соңга таба тикмәгә генә әтисе йортын ташлап китмәгәндер.

Шул, өч-дүрт көн дәрескә килмәгән Хаҗиәгъзамны әтисе класска алып керде.

— Иптәшләрең алдында тезлән!.. Тезлән дә гафу үтен! — дип таләп итте мулла.

Хаҗиәгъзам аның кимсеткеч әмерен үтәргә уйламый да. Без дә, тезләнә генә күрмәсен дип, ут йотып утырабыз. Чөнки кем алдында булса да бил бөгүне җенебез сөйми, аны хурлыкка, куркаклыкка саныйбыз.

— Тезләнмим! — Хаҗиәгъзам, иреннәрен кысып, мөгаллим өстәле янында басып торуында булды. Күзләре уттай яна. Әтисенә ачу белән карый, әмма ярсуын эчкә йота.— Тезләнмим! — дип кабатлады ул. Барыбыз да җиңел сулап куйдык. Әйттеме, сүзендә тора инде безнең Хаҗиәгъзам. Әтисе дә аны тезләндерә алмаячагын аңлады, тавышын йомшарта төште:

— Иптәшләреңнән гафу үтен!..

— Алар алдында гаебем юк минем!

Шулай ярып кына салды малай. Укытучы аңа урынына утырырга кушты.

Бу вакыйгадан соң аның күңелендә нинди үзгәреш булгандыр — әзеп әйтүе кыен. Тик ул җаны-тәне белән укуга ябышты. Яхшы укыды. Сочинениеләрне шул хәтле матур итеп яза торган иде — әдәбият укытучыбыз Михаил Ефимович Дьяконов барыбызга да аның эшләрен үрнәк итеп күрсәтә килде.

— Әдәбиятны уйлап укырга кирәк, туганкайлар, — дип сөйләргә ярата иде ул. — Күңел ачу өчен генә китап актарып утырмагыз. Сочинение язганда да башны нык эшләтү шарт. Моңа әнә Габидуллиннан өйрәнергә була. Ятлаганын түгел, аңлаганын яза ул...

Күп укый иде Хаҗиәгъзам. Пушкин, Некрасов шигырьләрен яттан сөйли башласа — авызыңны ачып тыңлыйсың. Тарих китапларын да кулдан төшермәде. Бу фәнне безгә Надежда Васильевна Федосова укытты. Император хәзрәтләре дип авыз суларын корыта торган

кеше түгел, киң карашлы акыллы укытучы иде. Патшалар, тәхетләр турында сөйләгәндә көлемсерәп кенә:

— Искә алыгыз, туганкайлар: Рим императорларын тәхеткә ходай утырткан да булсын ди... Ә кем бәреп төшергән аларны?.. Шул турыда уйлангаларга кирәк лаbаса, — дип читләтеп кенә булса да безгә акны-караны аңлатырга тырыша иде. Күрәсең, Надежда Васильевна тарихны тудыручы көчләрнең патшалар булмавын төшендерергә теләгәндер. Хаҗиәгъзамны бик тә якын итте ул. Аңа өйдәге китапханәсеннән алып укырга да рөхсәт итте. Бу бәхет һәркемгә дә тими иде.

Михаил Васильевичның бу сүзләре күз алдыма икенче бер күренешне китереп бастырды.

1926 елның январь көннәре. Салкын кич. Казандагы эшче клубларының берсендә алма төшәрлек тә урын юк. Зур предприятиенең коммунистлары, комсомоллары, партиясез эшчеләре җыелышка кергәннәр. Клуб эче ялт итеп тора. Шәһәрдә яңа электр станциясе эшли башлаган, аңа Татарстан республикасының III еллыгы исеме бирелгән. Күп дигәндә унлы лампа яндырып яшәгән төбәктә электр станциясе хәтле зур предприятиенең ходка җибәрелүе, билгеле инде, һәркемне куандыра.

Трибунада озын буйлы, мәһабәт гәүдәле, ачык йөзле ир кеше. Яше утызлардан артык булмас. Ул Совет илен индустрияләштерү турында сөйли. Большевиклар партиясенең XIV съезды бу өлкәдә гаҗәеп зур перспективалар билгеләгән. Эшчеләр клубы трибунасыннан шул хакта ялкынланып сөйләүче оратор әле күптән түгел генә Мәскәүдән кайткан. Татарстан коммунистлары аны — Хаҗи Заһидулла улы Габидуллинны — шул съездга делегат итеп сайлаганнар. Бүген ул — республиканың Халык Комиссарлары Советы Председателе — Казан эшчеләренә, партия һәм совет активына ил һәм Татарстан хәл итәргә тиешле бурычларны аңлата.

Ораторның фикерләре тыелгысыз чишмә булып агыла. Русча сөйли, акцент дигән нәрсәнең эзе дә юк. Катлаулы мәсьәләләрне дә гади итеп аңлата белүе, ил экономикасы үсешен, Татарстанда промышленность хәлен анализлавы — барысы да тыңлаучыларны әсир итә. Үткен күзләре бүгенгене генә түгел, илнең һәм республиканың киләчәген дә күрә шикелле.

Әйе, егерме җиде яшендә үк Татарстан кебек зур автономияле республиканың хөкүмәт башлыгы дәрәҗәсенә күтәрелү өчен оештыра белү таланты да, политик карашларның киңлеге дә, тарихны сиземләү дә, халыкның тормышын һәм рухи халәтен аңлау да кирәк булгандыр, әлбәттә.

Петухов үз хикәясен дәвам иттерә:

— Көнгәр шәһәр училищесын без 1914 елда тәмамладык. Июнь башында аттестатлар тапшырдылар. Төрлебез төрле якка таралыштык. Шуннан соң Хаҗиәгъзам белән тагын ике тапкыр очрашу насыйп булды.

Унсигезенче елны үзегез дә чамалыйсыздыр инде: җилле-давыллы, күкрәүле-яшенле чак. Мин тимер юлда эшли идем. Хаҗиәгъзам да шул тирәдә — товар конторасы эшчесе...

Әйе, бу елларда ул тимер юлчылар белән чыннан да якыннан аралаша. Тормыш иптәше Зәйнәп ханым бу хакта миңа нәрсә яза: «Хаҗи үзенең яшьлек елларында төшкән фотоларын бик кадерләп саклый иде. Тимер юлчы формасы киеп төшкән рәсеме аның өчен аеруча кадерле булды, чөнки ул — Көнгәрдә яшерен революцион эш алып барган тимер юлчылар арасында йөргән көннәрнең истәлеге. Шул ук елларның ядкаре булып кызыл тышлы партизан кенәгәсе дә саклансды...»

Социаль гаделсезлеккә каршы көрәшү теләге Хаҗи Габидуллинны социал-демократларның яшерен түгәрәгенә китерә. Ул тимер юл эшчеләре арасында большевистик матбугат органы — «Голос самого рабочего» газетасын тарата, аларга социал-демократларның карашын аңлата. Татар эшчеләренә туган телләрендә, русларга русча сөйли.

— Аның большевиклар белән якынлыгы сизелә иде, — дип тагын ялгап алып китте Петухов. — Унсигезенче елның июль аенда без комсомоллардан сугышчан отрядлар оештырдык. Хәвефле чак иде бит — әзер торырга кирәк булды. Беркөнне Хаҗиәгъзам безгә килеп керде. Мәктәп елларын, классташларны ,укытучыларыбызны искә алдык. Революция давылы төрлебезне төрле якка тараткан иде. Хаҗиәгъзам, сүз арасында гына итеп, комсомол отрядлары турында сорашты. Мин аңа ышана идем — нибарын сөйләдем. Ул бик сөенде. «Отрядларыгызны ныгытуда без дә булышырбыз», диде. Без дигәне большевиклар оешмасы булырга тиеш. Моны мин соңрак кына аңладым. Үз тормышы хакында сораша башлагач:

— Әти йортыннан киттем мин, — диде.

— Нигә, сыешып булмадымыни?

— Яңа дөнья иске йортка сыймый икән шул, — диде Хаҗиәгъзам. Бу мизгелдә ул бик җитди иде.

— Ә абыең? Ул кайда?

— Ул безнең кыр чәчәге түгел...

1916 елда солдатка алынгач, прапорщиклар мәктәбендә дә Хаҗи революцион эшен дәвам иттерә. Сусаган җир яңгыр көткәндәй, солдатлар күңеле хаклык сүзен ишетергә зар-интизар булып беткән. Андый сүзне бары тик большевиклар гына әйтә. Габидуллин аларның исеменнән сөйли, солдатларга җир, ирек, солых турында аңлата, бу мәсьәләләргә Ленинның карашын төшендерә. Әлбәттә, мондый «көфер» сүзләр ачыктан-ачык сөйләнми. Әмма алар тиздән шытым бирәчәк туфракка төшәләр.

Февраль революциясеннән соң прапорщик Габидуллин Көңгәр шәһәр советы члены итеп сайлана. 1917 елның 7 апрелендә аның большевиклар партиясенә керүе рәсмиләштерелә. Россия өстендә революция давыллары дулаган көннәрдә ул Төмән якларында сугышчан эш башкарып йөри. Аны мөселман хезмәтчәннәре арасында аңлату эшләре алып бару өчен җибәрәләр. Бу вакытта Хаҗи Габидуллин партиянең губерна комитеты члены да була. Димәк, сабакташы Михаил Петухов белән икенче тапкыр очрашкан чакта инде ул көрәштә чыныккан, идеологик эштә тәҗрибә тупларга өлгергән большевик-революционер итеп саналырга хаклы. Чәй янында сөйләшеп утырганда, Хаҗи Габидуллин сабакташының да күңел кылларын чирткәләп карый:

— Большевикларга мөнәсәбәтең ничегрәк, Миша? — дип сорый ул. — Ни уйласаң да дөресен әйт, миннән шикләнмә.

Михаил Петухов шактый уйланып торганнан соң гына фикерен әйтә:

— Дөньяны яңартучылар шулар булмасмы икән дип уйлыйм. Дөресрәге, өметләнәм.

Габидуллин аңа дустанә карап елмая:

— Төтенең туры чыга, Миша. Дөньяны яңартыр төп көч — большевиклар. Син ялгышмыйсың. Тик өметләнергә генә түгел, инанырга кирәк моңа. Күреп торам, җаның большевиклар ягында. Партиягә керергә вакыт сиңа.

Ул, рәхмәт әйтеп, өстәл янынңан тора да, Михаилның әнисе белән саубуллашып, урамга атлый. Сабакташы аны озата чыга. Хаҗиның өстендә тимер юлчылар формасы: кара пинжәк-чалбар. Пинжәк яка-

сына җете-кызыл петлицалар тегелгән. Ак металл төймәләре елык-елык итә.

Яратып кия бу форманы Хаҗи.

— Кигәнең әшче киеме булгач, башың да әшче хәсрәте белән тула икән, сабакташ. Я, ярый, мин әйткәнне онытма... Хуш!..

— Хуш, Хаҗиәгъзам! Тагын көрешергә насыйп булсын!

Ә сабакташларның кабат очрашуы тиз генә булмый. Гражданнар сугышының утлы өермәсе Хаҗи Габидуллинны илнең төрле якларында йөртте. Аңа берсеннән-берсе катлаулырак, җаваплырак эшләр йөклиләр.

Мәгълүм ки, 1918 ел җәендә революция һәм Совет властеның язмышы Көнчыгыш фронтта хәл ителә иде. В. И. Ленин нәкъ шул хәтәр чакта: «Хәзер революциянең бөтен язмышы бер картага салынган: бу — Казан — Урал — Самара фронтында чехословакларны тизрәк җиңүгә ирешү. Бөтенесе шуңа бәйләнгән», дип язды.

Шундый авыр көннәрдә партия Габидуллинны Казанда эшләргә җибәрә. Август аенда исә Казанга чехлар керә. Алар партия һәм совет активистларын кырырга керешәләр. Мулланур Вахитов һәлак ителә. Габидуллин да кулга алына һәм төрмәгә утыртыла. Тоткыннарның гомере кыл өстендә була. Кызыл Армия частьләренең Казанны тиз азат итүе генә бик күпләрне үлемнән коткарып кала.

Хаҗи Габидуллинның шуннан соңгы язмышы Кызыл Армия белән бәйле. Унсигезенче елның сентябрендә аны Астрахань шәһәрендәге Икенче Мөселман полкының командиры итеп җибәрәләр. Бу хәрби часть ак казаклардан торган дивизиягә каршы канлы бәрелешләрдә катнаша. Тигезсез сугышларда Габидуллин тәҗрибәле һәм талантлы командир буларак танылa. Полк командирының шәхси батырлыгы һәм үрнәге сугышчыларны канлы бәрелешләрдә дошманны җиңәргә рухландыра. 1919 елда инде аны атлы полкның хәрби комиссары итеп билгеләләр. Озакламый, ул чакта данлыклы булган 11 нче Петроград дивизиясенә дә комиссар итеп Хаҗи Габидуллин җибәрелә. Ә егерменче елдан ул Казандагы кавалерия курсларында комиссар була, сугышчылар арасында идея-политик эш алып бара.

Егерменче ел ахырында яулардан хәтәррәк булып ачлык килә, һәр тарафта — сугыш калдырган җимерекләр, хәрабәләр. Шуларга тагын яшеренеп яткан сыйнфый дошманнарның мәкерле эшләре өстәлә. Алар социалистик дәүләтнең милкенә кул сузалар, талау һәм үтерүләр белән шөгыльләнәләр. Совет власте органнары сыйнфый дошманнарның бу явыз эшләренә каршы кискен көрәш алып барырга мәҗбүр. Мондый шартларда милициягә аеруча җаваплы эшләр башкарырга туры килә. Партиянең Татарстан өлкә комитеты республика милициясен ныгыту, аңа җитәкчелекне яхшырту турында кайгырта. Габидуллинны да, Кызыл Армия сафыннан кайтарып, ТАССР милиция начальнигы итеп билгеләләр. Бер үк вакытта аның кандидатурасы Татарстан АССР Эчке эшләр Халык Комиссарының урынбасары итеп тә раслана. Бу җаваплы эшләрне ул иң авыр вакытларда — 1924 елга кадәр башкара.

— Аның белән өченче тапкыр очрашуым да шушы чорда, дөресе, 1921 елда булды, — ди Петухов. — Мин тимер юлның тәэминат бүлегендә эшли идем. Телеграмма бирергә дип телеграфистлар бүлмәсенә керсәм, ни күрим: Хаҗиәгъзам тора. Өстендә озын шинель, башында йолдызлы шлем, ягъни буденновка.

— Кайлардан җил ташлады болай?

— Татарстан республикасыннан, Миша. Мин шунда хәзер... Өстемдә шинель булгач, хәрби кеше инде мин. Ә хәрбиләр, үзегез беләсез, ни эшләп йөргәннәрен сер итеп сакларга өйрәнгәннәр. Телеграмма бирергә кердем менә. Казанга кайтып барышым.

Егерменче-егерме дүртенче еллар арасында Хаҗи Заһидуллович республикада барган зур эшләрнең үзәгендә кайнаган. Аның бу эшчәнлеге партия характеристикасында менә ничек бәяләнә: «Оста җитәкче, эшне бөтен киңлегендә колачлый ала һәм аны башкару өчен кирәк булганның барысын да үти... Киң карашлы, иптәшләренә мөнәсәбәттә принципиаль... Энергияле һәм үз сүзендә торучан...»

Эчке эшләр Халык Комиссариатында эшләгән чагында Хаҗи Габидуллин ТАССР дәүләт органнары һәм төрле идарәләрнең эшчәнлегенә багышланган зур доклад әзерләгән. Анда республика оешмаларының һәм җирле органнарның, шулай ук комиссариатларның хокуклары һәм бурычлары төгәл билгеләнә. Бу хезмәтендә Хаҗи Габидуллин дәүләт эшлеклесе һәм галим буларак ачыла.

Бу, әлбәттә, республиканың җитәкче органнары тарафыннан тиешенчә бәяләнә. Партиянең V Татарстан өлкә конференциясе 1922 елда ук инде Хаҗи Габидуллинны РКП (б)ның өлкә комитеты члены итеп сайлый. Ә 1924 елның апрелендә ул Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы Председателе итеп билгеләнә.

Мәгълүм булганча, ул елларда республикабызның партия һәм совет органнарына, хуҗалык һәм культура үсешенең төп мәсьәләләрен хәл итү белән беррәттән, идеологик көрәш фронтында да зур эш алып барырга — бер яктан бөекдержавачыл шовинизмга, икенче тарафтан җирле буржуаз милләтчелеккә каршы көрәшергә туры килә. Шул ук вакытта солтангалиевчеләр һәм республика партия оешмасындагы «уң» һәм «сул» группалар да баш калкыталар. Шушындый кискен көрәштә Габидуллин милли мәсьәләдә ленинчыл принципларны тормышка ашыра. 1923 елның 20 июлендә, мәсәлән, өлкә киңәшмәсендә ул, конкрет фактларга таянып, Солтангалиевнең партиягә һәм советка каршы эшчәнлеген фаш итә. Тарихка күз салып, аның 1918 елда ук инде «рус оешмасыннан» аерылырга һәм сепаратистик милли-буржуа партия булдырырга омтылуын раслый. Бу ымсынуларның чын битлеген ачып, Х. З. Габидуллин Татарстан коммунистларын «уң» һәм «сул» тайпылышларга каршы бердәм көрәшкә чакыра.

Совнарком председателе (1924—1927 еллар) бер үк вакытта республикада оештырылган Экономик киңәшмәнең рәисе вазифаларын да үти. Аның утырышларында тикшерү өчен Татарстан промышленностен һәм авыл хуҗалыгын үстерүнең төп проблемаларын куя, шул мәсьәләләр буенча хәлне җентекле өйрәнеп төпле уйланылган, фәнни нигезләнгән докладлар әзерли. Барлык бүтән чыгышлары һәм отчетларында да ул республиканың ул чактагы экономик хәлен тирән анализлый, хуҗалык һәм культура төзелешенең көн үзәгендә торган бурычларын төгәл билгели, Татарстанны индустриальләштерү, аның промышленностен яңартып кору перспективаларын ача. Х. З. Габидуллин җитәкчелегендә төзелгән беренче перспектив план буенча Зеленодольскида шпал әзерләү һәм агач эшкәртү предприятиесе, Бөгелмә кантонында гудрон заводы, Казанда суыткыч комбинат салына. Аларның һәркайсына, нигез ташлары белән бергә, Совнарком председателенең энергиясе дә салынган.

Республика тарихында сер түгел, нәкъ шул елларда кайбер «белгечләр» Бондюг химия заводын ябарга да маташалар. 1926—27 нче елларда СССР һәм РСФСР хөкүмәтләренең югары органнарында ул чакта илдә иң зурлардан саналган Бондюг химия заводын ябуның экономик һәм политик яктан хата булачагын исбатлый. Заводны саклап калырга гына түгел, киңәйтергә, үзгәртеп корырга карар кабул ителә.

Хаҗи Габидуллинның «Татарстан җиде елда (1920—1927)» дигән

фәнни хезмәтендә Совет властеның беренче унъеллыгында Татарстанда социалистик төзелеш тарихының иң мөһим этаплары чагыла.

Совнарком председателе республиканың культура, әдәбият, фән эшлеклеләре белән якыннан аралашып, аларның иҗади эшенә конкрет булышып тора. Тормыш иптәше Зәйнәп ханым бу хакта болай искә төшерә: «Күренекле әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовка ул бик игътибарлы һәм ихтирамлы иде. Язучы Кырымда яшәгән чакта аның хәлен белешеп торды. Ул чакта татарлардан беренче булып профессор дәрәҗәсе алган Мөхетдин абзый Корбангалиев белән алар дуслар иде. Хәтерлим, Мөхетдин абзый бездә еш булды. Татарча куе итеп ясалган чәй эчә-эчә, озын кичләр буена сөйләшеп утыралар, бәхәсләшеп тә китәләр... Казанга А. В. Луначарский килгән чакта Габидуллин аны зур ихтирам күрсәтеп каршылый. Соңыннан алар Мәскәүдә бик еш очрашып торалар. Хаҗи Семашко белән дә аралашып яшәде. Шунысы үзенчәлекле, аның бөтен дуслары үзеннән өлкәннәр иде».

1925 елда Хаҗи Габидуллин партиянең XIV съездына делегат булып бара. 1925—29 нчы елларда ул — Бөтенсоюз Үзәк Башкарма комитеты члены, ВЦИК Президиумы членлыгына кандидат. 1927 елның октябрендә Партия Үзәк Комитеты аны Мәскәүгә чакыртып ала. Илебез башкаласында ул хөкүмәт аппаратында эшли — РСФСР Совнаркомы члены була. Утызынчы елдан башлап исә Кызыл профессура институтында өч ел укый, аннары РСФСР Мәгариф Халык Комиссариатының университетлар һәм фән учреждениеләре идарәсе начальнигы итеп билгеләнә. Бу хезмәтендә Хаҗи Габидуллин шактый озак вакытлар Мәгариф Халык Комиссары урынбасары Н. К. Крупская җитәкчелегендә эшли. Бу турыда З. А. Габидуллина истәлекләреннән берничә юл китерик: «Комиссариатта Надежда Константиновна безнең Хаҗины аналарча яратып, «улым» дип йөртте. Крупская ул вакытта Архангельское дигән урында дачада яшәде һәм кадерле Ильич турында истәлекләрен язды. Аның һәр минуты исәпле булганга күрә, Хаҗи Идарә эшләре буенча еш кына шунда бара, Надежда Константиновна белән киңәшә торган иде. Көзме, кыш көнеме — кайчан барып кайтса да ,безнең өйдә чәчәк атып утырган гөл пәйда була торган иде. Бу — Надежда Константиновнаның Хаҗига даими ихтирам билгесе булды».

1936 елның февраль аенда Хаҗи РСФСР Мәгариф Халык Комиссариатының өлкәннәр өчен мәктәпләр идарәсе начальнигы итеп билгеләнгәч, Надежда Константиновна, бу эшкә югары бәя биреп, аның тарихи әһәмиятен, дәүләткүләм зарурилыгын, политик мәгънәсен яхшы аңлап, Габидуллинга махсус хат белән мөрәҗәгать итә: «...Моның мәгънәсе шунда ки, бу эшкә иң зур фәнни көчләр тартыла, алар массалар белән тыгызрак бәйләнешкә керергә омтылалар. Фәннәр академиясе, мәсәлән, беренчеләрдән булып, популяр китаплар язу кебек эшкә алына. Бу — заманыбызның иң яхшы билгесе. Безнең Советлар илендә массаларны белем белән коралландыруга булышу — галимнәр өчен намус эше... Мин үземнең шушы фронттагы бөтен тәҗрибәмне Сезгә эшегездә булышуга юнәлдерергә йөкләмә алам».

Хаҗи Габидуллин бу Идарәдә дә җиң сызганып эшли. Тагын Зәйнәп ханымның истәлегенә күз салыйк: «Хаҗиның язу өстәлендә калган фәнни хезмәт — шактый күләмле тарих дәреслеге нәкъ менә өлкәннәр мәктәпләре өчен әзерләнгән булырга тиеш. Бу дәреслекне өч кеше язды шикелле. Берсе профессор Кокин, икенче авторы Хаҗи, өченчесен әйтә алмыйм. Тик шунысы хәтеремдә, дәреслекне язу эшен аларга Үзәк Комитет тапшырды. Авторларга дәреслекне яңа уку елына кадәр төгәлләргә кушылды. Моның өчен аларга бөтен мөмкинлек-

лəр тудырылды. Галимнəр Мəскəү янындагы ял йортында — Абрамцевода һəм Большевода эшлəделəр...»

Бу чорда Хаҗи Габидуллин гаять киң колачлы эш алып бара. Башта Көнчыгыш хезмəт иялəренең Коммунистик университетында кафедра җитəкчесе була. 1934—1937 нче елларда Мəскəү дəүлəт университетында эшли: колониаль һəм бəйле иллəрнең яңа тарихы кафедрасында мөдир. Ə профессорлык дəрəҗəсен ул 1933 елда ук ала. Үзəк нəшриятларның берсендə А. Аршаруни белəн берлектə язылган монографиясе — «Россиядə панисламизм һəм пантюркизм очерклары» дип исемлəнгəн китабы чыга (1931). Бу хезмəттə элеге «изм»-нарның сыйнфый асылы, реакцион нигезе фаш ителə. Коммунистлар партиясенең пантюркизмга һəм солтангалиевчелеккə каршы көрəше күрсəтелə. 1936 елда Х. З. Габидуллинның тагын бер хезмəте — «Младотурецкая революция» дигəн күлəмле китабы басылып чыга. Бу монографиясендə тарихчы галим Оттоман империясендəге иҗтимагый-экономик мөнəсəбəтлəрне, Төркиядəге революцион хəрəкəтнең тарихын анализлый һəм империализмның мəкерле эшлəрен фаш итə.

1934 елда Истамбул шəһəрендə төрки теллəре белгечлəренең Бөтендөнья Конгрессы үткəрелə. Совет галимнəренең аңа катнашкан делегациясен Х. З. Габидуллин җитəкли. Анда ул империалистик дəүлəтлəрнең Көнчыгыш иллəренə карата колониаль политика үткəрүлəрен фаш иткəн ялкынлы речь сөйли.

«Конгресска безнең илдəн өч кеше барды, — дип искə төшерə Зəйнəп ханым. — Алар академик Самойлович, академик Каблуков һəм Хаҗи иде. Делегация Төркиядəн кайткан көнне үк, кич белəн, безнең квартирада галимнəр җыелды. Мəҗлестə А. С. Бубнов та бар иде. Сүз, əлбəттə, Конгресста күтəрелгəн мəсьəлəлəр тирəсендə йөрде... Аннары август аенда безнең илдə булачак тарихчылар конгрессына əзерлек хакында сөйлəштелəр. Бу бик җитди эш иде. Чит иллəрдəн бик күп галимнəр килергə тиеш икəн. Аларны каршылау, Конгрессны оештыру мəшəкатьлəренең зур өлеше безнең Хаҗига йөклəнде...»

Тарихның үзең яшəгəн чорын өйрəнү гаять четерекле эш. Моны башкаручы галим зирəк тə, белемле дə, кыю да булырга тиеш. Хаҗи Габидуллин нəкъ менə шундый сыйфатларга ия булган галим. Аның дəүлəт эшлеклесе булуы — галимлегенə, галимлеге дəүлəт эшлəрен алып баруга ярдəм итə.

Аның музейдагы стендта торган рəсеменə карап мин шуны уйлыйм. Революция биргəн канатлар кешене белем һəм фəн күклəренə мендерə. Шул биеклектəн Хаҗи Габидуллин узган бөтен юл балкып күренə: əнə унтугыз яшьлек Хаҗи —революция көрəшчесе, яшерен оешмада тимер юлчыларга социал-демократлар турында сөйли... Əнə егерме бер яшьлек Хаҗи — кызыл гвардеец, кулына корал тотып революцияне якларга чыккан... Егерме өч яшьтə ул — кызыл полк комиссары, егерме дүрттə — Татарстан АССР Эчке эшлəр Халык Комиссары урынбасары һəм республика милициясе начальнигы... Егерме җиде яшьтə исə ул инде Татарстан хөкүмəте башлыгы... Утызда — РСФСР Совнаркомы члены, утыз җидедə — тарих профессоры һəм Мəскəү дəүлəт университетында кафедра мөдире. Җиргə таянудан көч алган легендар Антей шикелле, ул да рухи куəтне пролетариаттан, белемне марксизм-ленинизм хəзинəсеннəн алды. Республика тарихына гына түгел, бөтен илебезнең тарих сəхифəлəренə ул шундый булып мəңгелеккə керде.

# НИКОЛАЙ ГАВРИЛОВИЧ ЧЕРНЫШЕВСКИЙНЫҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

**Камил Фасеев,**
**Яхъя Абдуллин**

## ЧЕРНЫШЕВСКИЙ ҺӘМ ТАТАР ИЖТИМАГЫЙ ФИКЕРЕ

Бөтен совет халкы һәм прогрессив кешелек дөньясы быел рус халкының бөек фикер иясе һәм революцион демократы Николай Гаврилович Чернышевскийның тууына 150 ел тулуны билгеләп үтәләр.

Н. Г. Чернышевскийның эшчәнлеге һәм иҗаты гаять күп кырлы. Узган гасырның алтмышынчы елларында азатлык хәрәкәтенең юлбашчысы буларак, ул чыныккан революционерлар тәрбияләде һәм аларның патша самодержавиесенә һәм алпавыт-крепостнойлык строена каршы көрәшен җитәкләде. Ул энциклопедик белемле галим иде: философия һәм социология, политик экономия һәм тарих, эстетика һәм әдәбият тарихы, этика һәм педагогика, табигать белеменең философик проблемалары һәм фән тарихы мәсьәләләре белән шөгыльләнде һәм шушы өлкәләрнең һәркайсын кеше зиһенен караңгылык богауларыннан азат итүгә юнәлдерелгән өр-яңа фикерле әсәрләре белән баетты.

Язучы буларак ул гуманизм рухы белән сугарылган һәм иҗтимагый изүгә һәм тиранлыкка каршы көрәшкә өндәгән әсәрләрен иҗат итте. Шунлыктан аның шәхесе, эшчәнлеге һәм иҗади мирасы Россиядәге барлык халыкларның иҗтимагый фикере үсешенә куәтле тәэсир ясады, алар арасыннан халыкның авыр хәлен аңларга сәләтле һәм аны һәртөрле изелүләрдән азат итү эшенә үз тормышын багышларга әзер булган эшлеклеләр җитлегүенә булышты.

Н. Г. Чернышевскийның эшчәнлеге, ул тараткан идеяләр татар халкының рухи тормышында гаять зур әһәмияткә ия булды. Николай Гаврилович Чернышевский Идел һәм Урал буе татарларының тарихын һәм культурасын яхшы белә иде, аларның телен, фольклорын һәм башка культура истәлекләрен өйрәнде. Аның мирасында татар халкының тарихы һәм культурасына караган ифрат кыйммәтле материаллар бар. Революцион демократның кульъязма фондында татар теле буенча ике йөзләп бит язма саклана. Алардан күренгәнчә, галим татар теленең үзенчәлекләрен шактый нечкәлекләре белән белгән. Ул язмалардагы фактик материал, белгечләр фикеренчә, хәзер дә үзенең фәнни кыйммәтен югалтмаган; аларда татар теленең тарихын, аның лексикасын һәм грамматикасын өйрәнгәндә файдалы күп мәгълүматлар бар.

Татар халкының тарихы һәм культурасы буенча тупланган материалны Н. Г. Чернышевский үзенең хезмәтләрендә теоретик фикерләрен нигезләү максатларында файдалана. Мәсәлән, «Община белән җир биләүгә каршы философик карашларга тәнкыйть» исемле хезмәтендә иҗтимагый үсеш закончалыкларын нигезләгәндә мисал итеп ул телнең камилләшү үрнәкләрен китерә, шушы фикерен үсеш барышында татар теленең грамматик формалары гадәттән тыш катлауануын күрсәтү белән раслый. (Н. Г. Чернышевский. Избранные философские сочинения. Т. II. М., 1950, стр. 464.)

Н. Г. Чернышевский һәм аның көрәштәшләренең эшчәнлеге колач җәя башла-

ган чорда татар иҗтимагый фикере ислам схоластикасы һәм фанатизмы коллыгында иде. Патша самодержавиесенең азчылык милләтләргә карата шовинистик политикасы, авыр социаль һәм милли изү, фикер хөрлегенең һәртөрле чагылышын эзәрлекләү аны торгынлыкка һәм катып калуга дучар иткән иде. Шул ук вакытта феодаль мөнәсәбәтләрнең таркалуы һәм капитализмның үтеп керүе инде халыкның рухи тормышында яңа агымнар китереп чыгара башлады, милли аң уянуына һәм милли хәрәкәт җанлануына булышлык итте, татар хезмәт ияләрен алпавытлар һәм байлар хакимлегенә каршы гомумроссия көрәшенә тартты. Рухи тормыштагы үзгәрешләр татарлар арасыннан демократик иҗтимагый фикер һәм культураның күренекле вәкилләрен — халыкның социаль һәм рухи ихтыяҗларын гәүдәләндерүче вәкилләрен күтәрде. Шундыйлардан күренекле мәгърифәтчеләр плеядасы аеруча игътибарга лаеклы урын алып тора.

Бу демократик хәрәкәтнең вәкилләренә алдынгы рус культурасы һәм иҗтимагый фикеренең тәэсире көчле булды. Дөрес, аларның Н. Г. Чернышевский һәм башка революцион демократлар белән турыдан-туры бәйләнешләре хакында бездә әлегә тулы мәгълүматлар юк. Хәлбуки, бу — андый якын бәйләнешләр булмаган диярга нигез түгел әле. Мәсәлән, бөек рус революцион демократларының эшчәнлеге киң колач белән җәелеп киткән чорда Петербург университеты адъюнкты булып эшләгән күренекле татар мәгърифәтчесе Хөсәен Фәезханов (1828—1866) Н. Г. Чернышевский хезмәтләрен укымый булмагандыр. Ул русның А. К. Казембек, Р. В. Розен, В. В. Вельяминов-Зернов, В. И. Стасов, В. А. Дорн, Н. И. Лерх кебек күренекле галимнәре белән якын мөнәсәбәтләрдә торган, демократик карашлы җәмәгать эшлеклеләре белән аралашкан, алар белән еш һәм иркенләп әңгәмәләр алып барган. Х. Фәезханов шулай ук казакъ мәгърифәтчесе Ч. Вәлихановның якын дусты һәм фикердәше булган. Ч. Вәлиханов исә Омскида петрашевчы С. Ф. Дуров белән танышкан һәм Петербургта яшәгәндә Ф. М. Достоевский белән очрашкан. Биредә Ч. Вәлиханов Н. Г. Чернышевский белән әңгәмәдә булган һәм Николай Гаврилович аңа искиткеч зур тәэсир ясаган. Шушы очрашудан соң Вәлиханов: «Нинди гаҗәеп кеше бу Чернышевский һәм рус булмаганнарның да тормышын ул ничек яхшы белә»,— дип язган. (Н. М. Чернышевская. Летопись жизни и деятельности Н. Г. Чернышевского. М., 1953, стр. 232.) Ч. Вәлихановның фикердәше булган һәм аның белән аралашып яшәгән Х. Фәезхановның да Н. Г. Чернышевский һәм революцион карашлы рус интеллигенциясенең башка вәкилләре белән таныш булуы бик ихтимал, яки, һич югы, ул аларның эшчәнлеге хакында белгән һәм алар пропагандалаган идеяләр белән таныш булган. Бөек рус фикер иясенең исеме һәм эшләре татар мәгърифәтчелегенең икенче бер күренекле вәкиле Шиһаб Мәрҗани өчен дә таныш булгандыр, чөнки ул башкалада Фәезханов кебек шәкерте һәм дусты булуын үз эшчәнлеге өчен мөһим таяныч итеп санаган.

Әгәр татар мәгърифәтчеләренең Н. Г. Чернышевский белән турыдан-туры бәйләнешләре шулай ярдәмче мәгълүматлар нигезендә расланса, аның идеяләренең татар фикер ияләренең дөньяга карашларына тегe яки бу рәвештә тәэсире турында исә ныклап сөйләргә мөмкин. Татар мәгърифәтчелегенең төп вәкилләре Каюм Насыйри (1825—1902), Шиһабетдин Мәрҗани (1818—1889), Габдрахман Ильяси (1854—1895) һәм башкаларның эшчәнлеге революцион-демократик фикер учакларының берсе булган Казан университеты галимнәре белән хезмәттәшлектә колач җәя.

Университет укытучылары һәм студентлары арасында Н. Г. Чернышевскийның исеме аеруча ихтирам ителә, ә аның революцион-демократик карашлары зур теләктәшлек таба. Замандашларыннан берәү 1857 елда язганча, Казанда «Николай Гаврилович турында гына сөйлиләр», «Современник» һәм «Колокол» кулдан-кулга йөри, күчереп алына, таушалып беткәнче укыла...»

Н. Г. Чернышевский идеяләренең Казан университеты укытучылары һәм студентларына рухландыргыч тәэсире ул Россия революцион-демократик хәрәкәтенә турыдан-туры җитәкчелек иткән чорда гына түгел, бәлки Николай Гаврилович патша палачлары тарафыннан Себер каторгасына илтеп бикләнгәч тә, ә аннары озак еллар дәвамында сөргендә яшәгәндә дә гаҗәеп көчле була. Әле XIX гасырның алтмышынчы елларында ук аның тарафдарлары «Земля и воля» оешмасының Казан комитетын

оештыралар, ә җитмешенче елларда революцион народникларның эшчәнлеге җәелә, студентларның чуалышлары һәм демократик карашлы профессорларның протестлары ешая. Рус разночинецларының демократик хәрәкәтендә кайбер татар студентлары да: А. Габдерәхимов, М. Котлыбаев, И. Рәҗәпов, А. Габделгалләмов, П. Алиев һәм башкалар актив катнаша. (С. М. Михайлова. Формирование и развитие просветительства среди татар Поволжья, 1972, стр. 215—223.)

Н. Г. Чернышевский идеяләренең Казанның алдынгы карашлы даирәләрендә таралуы патша властьларын бик борчый. Алар студентлар һәм укытучылар артыннан туктаусыз күзәтәләр, Россиянең «беренче социалисты»ның исемен искә алуны да тыярга маташалар. Ләкин юкка гына! Алар аның популярлыгын кимет алмыйлар. Мәсәлән, Казан укыту округы попечителе кушуы буенча Саратов округы инспекторы Н. Г. Чернышевскийны күмгәндә аның табутына «Мәскәүдән, Казаннан, Әстерханнан һәм башка шәһәрләрдән» дә чәчәк бәйләмнәре куелуын хәбәр итә. Бу — бик мәгънәви факт. Ул бөек революцион-демократка Казанда дистәләрчә еллар дәвамында сүнмәс ихтирам булганлыгы турында сөйли.

Казан университетының алдынгы карашлы җәмәгатьчелеге һәм рус интеллигенциясенең демократик рухтагы даирәләре белән тыгыз бәйләнештә яшәгән татар мәгърифәтчеләренең алар арасында хупланган идеяләр, шул исәптән Н. Г. Чернышевский идеяләре белән дә сугарылган булуы табигый. Татар мәгърифәтчеләренең идея-теоретик мирасын анализлау шулай дип расларга нигез бирә.

Татарларда мәгърифәтчелек фикере формалашу, башка халыклардагы кебек үк, милләт формалашкан, милли үзаң уянган чорда бара. Шунлыктан аңарда милләт, милли тарих һәм культура мәсьәләләре төп мәсьәләләрнең берсе булып әверелә. Халыкның рухи тормышында хакимлек итеп килгән мөселман руханилары татарлар мөстәкыйль халык түгел, алар «бердәм мөселман милләте»нә керәләр дип раслап маташа. Икенче яктан, формалашып килгән татар буржуазиясенең аеруча сугышчан рухлы даирәләре һәм патша самодержавиесенең рәсми идеологлары, татарлар алар Идел буйларына басып кергән Чыңгызхан һәм Батый гаскәрләренең нәселе дип тукый торалар. Мондый шартларда татар мәгърифәтчеләре алдына халыкның килеп чыгышын һәм тарихи үткәнен өйрәнү мәсьәләләре аеруча кискен булып килеп баса. Шушы мәсьәләләргә караштa алар Н. Г. Чернышевский позициясен кабул итәләр. Үзенең «Философиядә антропология принцибы» дигән хезмәтендә Николай Гаврилович «хәзерге Кырым, Казан һәм Оренбург татарлары арасында нәселе Батый сугышчыларыннан килгән бер генә кеше бармы икән, хәзерге татарлар — әлеге җырларда Батыйга кадәр үк яшәгән һәм, руслар кебек үк, Батый тарафыннан буйсындырылган элекке кабиләләрнең нәселе, ә килмешәк-басып алучылар барысы да югалганнар, буйсындырылган халык тарафыннан рәхимсез рәвештә барысы да кырып бетерелгәннәр». (Н. Г. Чернышевский. Избранные сочинения. Т. III, М., 1951, стр. 245—246.)

Татар мәгърифәтчеләре дә хәзерге татарларның турыдан-туры бабалары итеп Идел-Кама төбәгендә элек-электән яшәп килгән болгар һәм кыпчак кабиләләрен санаганнар. Алар шушы карашларын тарих фәне мәгълүматларына, археология һәм этнография фәннәре тикшеренүләренә, татар халкының кабер ташы язмаларына, теле һәм фольклорына нигезләнеп раслаганнар. Мәсәлән, Шиһаб Мәрҗани Казан татарларының теле борынгы болгар-кыпчак теле нигезендә формалашкан һәм аның килмешәк монгол кабиләләре теле белән берниндн уртаклыгы юк дигән фикергә килә.

Үз халкының тарихын тикшерүгә, аның килеп чыгышы һәм формалашуы проблемасына зур игътибар итүчеләрнең берсе Каюм Насыйри була, ул да бу мәсьәләгә Н. Г. Чернышевский карашында тора. «100—150 ел элек язылган китаплардан күренгәнчә,— дип яза Насыйри,— ул вакытта яшәгәннәр үзләрен болгарлар дип атарга яратканнар һәм бу хакта буыннан-буынга онытмый килгәннәр». (К. Насыйри. Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары. Казан, 1948 ел, 102 бит.) Тагын шунысы игътибарга лаеклы: Насыйри татар милләтенең формалашуы һәм үсеше күрше халыклар белән үзара бәйләнештә баруын ассызыклап әйтә. Аның бу фикере бөек рус галименең карашлары рухына бик тә туры килә. К. Насыйри татар халкының формалашу һәм үсеш процессына руслар, чувашлар, мордвалар, марилар һәм башка халыкларның тәэсире зур булган дип күрсәтә.

Н. Г. Чернышевский һәм башка революцион-демократлар кебек ук, татар мәгърифәтчеләре төрле халыкларның тигезлеге, аларның хуҗалык һәм әхлакый-мәдәни үсешкә бердәй хокуклылыгы идеясен яклыйлар. Николай Гаврилович кебек ук, алар кешеләрнең сәләтлелеге нинди милләттән һәм расадан булуына түгел, бәлки матди тормыш һәм иҗтимагый факторларга бәйле дигән материалистик караштан чыгып эш итәләр, раса аерымлыклары халыкларның экономик һәм акыл үсеше дәрәҗәсен билгеләргә тиеш түгел дип саныйлар. «Бу гакли гыйлемнәр, фикер иясе кешеләрнең табигате, табигый сәләте белән ирешелгәнгә күрә, бер милләткә генә хас түгелләр, аларны тикшерү, иҗат итүдә барлык милләтләр тигез хокуклы»,— дип яза, мәсәлән, Ш. Мәрҗани. (Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты архивы, 22 ф., 1 тасвирлама, 20 саклау берәмлеге, 55 бит.) Татарның икенче мәгърифәтчесе З. Бигиев тә (1872—1902) шул ук карашны яклый. Әхлакый яктан җитлекмәгән халык дип, татарларны кимсетергә маташкан Казан аллавыты В. И. Волгинга кискен төстә каршы төшеп, ул: «...Русларның һәм безнең татарларның бер мәкальләре бар: җәмәгать сикыйсыз булмас (гаилә гарипсез булмас) диләр. Сез күрсәткән... кызганыч хәлләр бездә гомуми түгел ул. Безнең арабызда булганы шикелле, руслар эчендә дә кешелектән, турылыктан ерак киткән кешеләр күп... Татарларыбыз хакында русның фикере, карашы гомуми булса, ялгыш булачак...» (З. Бигиев. Моваразннәһергә сәяхәт. Казан, 1908, 17—18 битләр.)

Н. Г. Чернышевский Россия мәгърифәтчеләрен халык массалары идеологлары, «публика ихтыяҗларына үзләренең мөнәсәбәтен» яхшы аңлый торган «белгечләр генә түгел, бәлки энциклопедистлар булырга», «үз милләтенең мәгърифәтчеләре булырга» көчле ихтыяҗ сизгән фидакарьләр дип бәяләгән. (Н. Г. Чернышевский. Избр. философские сочинения. Т. II, М., 1950, ст. 12.)

Мондый бәя Насыйри, Фәезханов, Мәрҗани, Күлтәсигә һәм татарның башка мәгърифәтчеләренә дә тулысынча туры килә. Алар туган милләтнең үсеш юлларын эзлиләр, аны дөньякүләм цивилизация казанышларына якынайту гаме белән яшиләр. һәм алар халык мәгарифенең көченә ихлас күңелдән ышаналар, аны иҗтимагый һәм мәдәни артталыктан чыгуның төп шарты итеп саныйлар. Чернышевскийның «һәр яхшылыкның нигезендә мәгърифәт ята» дигән фикерен алар үзләренең девизы итәләр. Бөек революцион демократның шушы фикеренә нигезләнеп: Ш. Күлтәси: «Барлык дөнья эшләренең асыл нигезе һәм башлангычы — мәгърифәттер... Кешенең хайвани табигате — тукланмак, ә кешелек табигате белем һәм мәгърифәт белән бәйледер»,— дип язды. (Ш. Күлтәси, һәйәте җәдидә (Яңа астрономия) Казан, 1896, 2 бит.)

Фәнгә һәм гыйлемгә таянган хәлдә генә кешеләр үзләренә кешеләрчә тормыш тәэмин итә һәм прогресс юлыннан алга бара алачаклар. Гыйльми белемнәр һәм мәгърифәт тарату, мәгърифәтчеләр фикеренчә, кешеләрнең дөньяга карашын киңәйтүгә һәм җитештерүнең заманча төрләрен җәелдерүгә алып барачак, наданлыкны, хорафатларга ышануны һәм әхлакый бозыклыкларны җиңәргә булышачак, аларны максатлы рәвештә көн күрергә өйрәтәчәк. һөнәрләр үзләштерү һәм кешеләрдә дөньяга дөрес караш тәрбияләү, үз чиратында, иҗтимагый мөнәсәбәтләрне үзгәртүгә китерәчәк.

Шунлыктан татар мәгърифәтчеләре үз милләттәшләре арасында европачыл гыйлем һәм укымышлылыкны таратуны, мәгариф, сәүдә һәм җитештерүне үстерүдә русларның тәҗрибәсен куллануны кайнар төстә хуплыйлар. «Үз милләтебезнең яшьргә тырышуы, үз эшен үзе эшли алуы, хәят мәйданында изелеп калмавы өчен Европаның гыйлем вә мәгарифенә, һөнәр вә сәнгатенә зур ихтыяҗыбыз бар. Европа мәктәпләрендә укымак безнең өчен файдалы. һөнәр вә мәгариф кайда* булса, шунда барып тәхсил[1] итәргә кирәк. Гыйлем белән мәгарифнең хас ватаннары, хас лисаннары[2] юк»,— дип яза Ш. Мәрҗани. (Мәрҗани Мәҗмугасы[3]. Казан, 1915, 528 бит.)

Н. Г. Чернышевский һәм башка революцион-демократлар дөньяга материалистик карашны зур тырышлык куеп пропагандаладылар. «Чернышевский,— дип билгеләп үтте В. И. Ленин,— 50 нче еллардан алып 88 нче елгача бөтенлекле философик мате-

[1] Тәхсил итү — гыйлем алу, алырга омтылу.
[2] Лисан — тел.
[3] Мәҗмуга — җыентык.

риализм югарылыгында торып кала алган һәм яңа кантчыларның, позитивистларның, махистларның һәм бүтән төрле буташтыручыларның кызганыч сафсатасын читкә алып ыргыткан берданбер чын бөек рус язучысы». (В. И. Ленин. Әсәрләр. Дүртенче басмадан тәрҗемә, 14 том, 381—382 битләр.) Шунлыктан Россиянең алдынгы фикерле кешеләренә, шул исәптән рус булмаган милләтләр демократик интеллигенциясенең яшь вәкилләренә, аның тәэсире гаҗәеп көчле булды.

Татар иҗтимагый-философик фикер тарихында материалистик карашларны пропагандалауда күренекле энциклопедист галим К. Насыйри зур эшләр башкарды. Ул рус телен бик яхшы белгән кеше буларак, Казан университеты галимнәре белән иң якын мөнәсәбәтләрдә торып эшләде. Аның барлык әсәрләрендә Н. Г. Чернышевский үзенең «Философиядә антропология принцибы» дигән һәм башка хезмәтләрендә күтәргән идеяләр кызыл җеп булып сузыла. К. Насыйри дөньяга карашның алла тарафыннан билгеләнгән булуы турындагы раслауларны тәвәккәллек белән кире кагып чыкты, аның үсешен бераүгә дә бәйләнмәгән объектив процесс итеп күрсәтте. Кояш һәм Кояш системасы, Җирнең һәм башка планеталарның Кояш тирәсендә хәрәкәт итүе хакында сөйләп, ул Галәмнең төзелешен сурәтләп бирде. Аның табигать күренешләрен аңлатуга, яңгыр явуы, кар төшүе, ел фасыллары алмашынуы сәбәпләрен төшендерүгә, үләннәр дөньясына, кешенең анатомиясе һәм физиологиясенә кагылышлы хезмәтләрендә материалистик тенденция ачык ярылып ята. Бар нәрсәнең нигезе итеп К. Насыйри материяне санады. «һава да җисемдер»,— дип язды ул. (К. Насыйри. Сайланма әсәрләр. Казан, 1945, 184 бит.)

Татарның икенче бер мәгърифәтчесе Шәмсетдин Күлтәси, Насыйри кебек үк, Чернышевскийдан аермалы буларак, идеалистик һәм дини карашлардан бөтенләй үк азат булмаса да, дөньяның матдилеге, материянең пространствода һәм вакытта хәрәкәте, кешенең объектив чынбарлыкны танып белүе, фәннең тормыштагы роле турында кызыклы гына фикерләр әйтә.

Татар мәгърифәтчелегендәге реалистик һәм демократик агым XIX гасырның икенче яртысында татар халкының социаль-экономик, политик һәм рухи тормышында барган сизелерлек уңай үзгәрешләр тәэсирендә барлыкка килә. Шул ук вакытта — бу үзгәрешләр гомумроссия күләмендәге процессларның чагылышы һәм аерылмас өлеше булып тора. Мөһим иҗтимагый һәм фәлсәфи проблемалар буенча рус һәм татар демократик фикер ияләре карашларының уртаклыгы нәкъ менә шулар белән билгеләнә дә.

Рус культурасы һәм иҗтимагый-политик фикеренең татар демократик җәмәгатьчелегенә тәэсире XX гасыр башында, эшчеләр сыйныфы җитәкчелегендә яңа революцион күтәрелеш чорында тагын да көчәеп китте. Бу вакытка татар халкы үз арасыннан демократик культураның менә дигән энтузиастларын — язучылар, шагыйрьләр, журналистларны, татар вакытлы матбугатын, театрын, әдәби тәнкыйтен башлап җибәрүчеләрне үстереп өлгертте. Аларның кайберләре — Хөсәен Ямашев, Гафур Коләхметов, Галимҗан Сәйфетдинов һәм башкалар Беренче рус революциясе елларында марксизм-ленинизм идеяләрен үзләштерү дәрәҗәсенә күтәрелде. Шулай ук күренекле язучылар-публицистлар — Галиәсгар Камал, Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Шакир Мөхәммәдов, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, социал-демократик, марксистик-ленинчыл идеологиянең көчле тәэсирен тойган һәм аңа кайнар теләктәшлек белдергән хәлдә, революцион демократизм позициясендә тордылар.

Шул ук вакытта үзенең формалашуы һәм халык азатлыгы көрәшендә гаять уңышлы роль уйнавы белән татар революцион-демократик фикере фәнни социализмга гына түгел, бәлки асылда «рус социал-демократиясенең элгәрләре булган Герцен, Белинский, Чернышевский...» кебек «гүзәл плеядасы»ның идея тәэсиренә дә бурычлы. (В. И. Ленин. Әсәрләр. Дүртенче басмадан тәрҗемә. 5 том, 380 бит.) Большевикларның лозунглары татар халкының иң яхшы улларын азатлык һәм социализм хакына фидакарьләрчә көрәшкә рухландырды, аларда теория белән, русның алдынгы иҗтимагый фикере, шул исәптән революцион демократлар мирасы белән кызыксыну уятты.

Татар культурасының югарыда исемнәре телгә алынган эшлеклеләре рус әдә-

бияты һәм публицистикасын җентекләп күзәтеп бардылар, аны тәрҗемә иттеләр һәм тараттылар, Лермонтовка, Пушкинга, Ломоносовка, Крыловка, Тургеневка, Гогольгә, Островскийга, Достоевскийга, Толстойга, Чеховка, Некрасовка, Салтыков-Щедринга, Горькийга, Белинскийга, Добролюбовка, Писаревка... булган кайнар мәхәббәтләрен ачыктан-ачык белдерә килделәр. «Мәҗлесләрдә сөйләнгән сүзләр русларның яңа һәм иске мөхәррирләренең әсәрләре, алар хакында язылган тәнкыйтьләр, рус әдәбиятының тарихлары хакында була иде,— дип язды Тукай.— ...Белинский, Писаревларның тәнкыйтьләрен чагыштыралар, берсе Белинскийның сүзен мәгъкулли, икенчесе Писаревны куәтли иде». («Аң» журналы, 1914 ел, 7 сан, 139 бит.)

Н. Г. Чернышевскийның Россия алдынгы иҗтимагый-фәлсәфи фикер һәм азатлык хәрәкәте тарихында күренекле урын тотуы татар культурасының демократик эшлеклеләренә яхшы билгеле була. Аның әсәрләрен үзен социалистларның чын тарафдары дип санаган Габдулла Тукай укый. Ул, каты авыру хәлендә дә, рус телендәге художестволы һәм политик әдәбият белән кызыксынудан туктамый. «Ул укыган китаплар арасында «Колокол»ның аерым номерлары, Герценның «Былое и думы» дигән әсәре, Чернышевскийның «Что делать» дигән әсәре һ. б. барлыгы хәтеремдә. Ул бу әдәбиятны бик зур кызыксыну белән укый иде»,— дип искә алган профессор Клячкин. (Г. Тукай. Шагыйрьнең тууына алтмыш ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары. Казан, 1948, 87 бит.)

Рус-татар укытучылар мәктәбендә укыган елларында Н. Г. Чернышевский әсәрләрен беренче татар большевигы Хөсәен Ямашев өйрәнә. «Рус телен белүе аңа рус революцион демократлары — Герцен, Белинский, Чернышевский, Добролюбов әсәрләре белән танышырга мөмкинлек бирде». (Х. Хасанов. Хусаин Ямашев. Казань, 1954, стр. 28.) Бу елларда шулай ук Х. Ямашев белән бергә укыган һәм соңыннан татар пролетариат әдәбиятына нигез салган Гафур Коләхметов та Н. Г. Чернышевский иҗаты белән таныша. Н. Г. Чернышевский һәм башка рус революцион демократларының Ф. Әмирхан белән Г. Ибраһимовка шифалы тәэсире хакында бу әдипләр иҗатының бөтен рухы, бөтен идея-художество эчтәлеге раслый.

Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал, М. Гафури социализм идеяләре белән рухланып иҗат иттеләр, большевик Х. Ямашев белән бердәм эш алып бардылар, социал-демократик әдәбиятны тәрҗемә итеп тараттылар. «Минем чын мәсләгем-юлым бөтенләй социаллардай»,— дип белдерде Тукай. (Г. Тукай. Әсәрләр, 1 том, Казан, 1955, 35 бит.) Социализм белән көрәш алып барган реакцион даирәләрдән, шул исәптән татар буржуаз милләтчеләреннән дә, көлеп, Ф. Әмирхан: «Фәкать шуны гына беләсе иде: мондый һөҗүмнәрдән социализм фикеренең нинә шөребе какшады икән?» — дип язды. (Ф. Әмирхан. Сайланма әсәрләр. Ике томда. 2 том, Казан, 1958, 201 бит.) Татар революцион демократлары царизмны һәм феодаль тәртипләрне камчыладылар, капиталистик изү системасын фаш иттеләр, эшчеләр сыйныфы формалашуын һәм үсүен күрделәр, аның тормыш хәленә һәм көрәшенә теләктәшлек белдерделәр. Әмма алар Чернышевскийның утопик социализмы дәрәҗәсендә тукталып калдылар. Милли эшче сыйныфның аз санлы һәм җитлекмәгән, сыйнфый каршылыкларның үсеп өлгермәгән булуы, царизм тарафыннан кимсетелгән милләтнең барлык катлауларының, бөтен демократиянең мәнфәгатьләре уртак булып тоелуы күпчелек алдынгы татар фикер иияләренең социалистик идеалының вак буржуаз характерда булуын билгеләде. Чернышевский кебек үк, алар үзләрен хезмәт ияләре идеологлары итеп санадылар. Бөтен хезмәт халкы, барлык иҗтимагый түбән катлауларның өметләрен чагылдырып та, алар пролетар партиялелек дәрәҗәсенә күтәрелә, «сыйныфлардан өстен» буржуаз демократизм иллюзияләреннән пролетариатның каты, баш имәүчән, җиңелмәс сыйнфый көрәшенә» тәмам күчә алмадылар. (В. И. Ленин. Әсәрләр. Дүртенче басмадан тәрҗемә, 18 том, 11 бит.)

XX гасыр азатлык хәрәкәтендә, аеруча рус булмаган милләтләрнең ышанычөметләрендә социализм узган гасырның 60 нчы елларындагы кебек үк крестьян демократиясе белән тыгыз бәйләнгән иде. Шулай итеп, татар революцион демократлары белән Чернышевский карашларының бердәмлеге алар арасындагы субъектив мөнәсәбәтләр белән генә түгел, бәлки нигездә җитди объектив хәлләр белән аңлатыла иде.

Н. Г. Чернышевский һәм башка рус революцион демократларының тормышы

үзләренең туган халкына һәм Ватанына турылыклы хезмәт итүгә багышланган иде. Аларның интернациональ рух белән сугарылган ялкынлы патриотизмы татарның алдынгы фикер ияләре өчен якты үрнәк булды һәм аларның да эшчәнлеген халыкка чиксез мәхәббәт һәм тугрылык хисе, аның иҗади мөмкинлекләренә ышаныч тойгысы рухландырды. Хәерчелектә һәм җәбер-золым астында узучы тормышның кара пәрдәләре аркылы алар халыкның бетмәс-төкәнмәс революцион-иҗади куәтен күрә алдылар. «Дөресен әйткәндә, халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул. Ул, әле әллә нинди кара көчләр басканга күрә генә, бу күренештә йөри. Ләкин бу хәл, вакытлы гына килгән бер авыру кебек, гаризи[1] бер хәлдер».— дип язды Габдулла Тукай. (Тукай. Әсәрләр, Дүрт томда. 4 том, Казан, 1974, 267 бит.)

Алдынгы фикер ияләренең хезмәте зур: алар массаларны милли һәм интернациональ мәнфәгатьләрне бердәм итеп карарга өйрәттеләр. Россиядәге изелгән халыкларның дошманы рус халкы булмавын, бәлки җирле байлар белән берлектә эш итүче рус царизмы, рус алпавытлары һәм капиталистлары икәнлекне аңлаттылар. Ф. Әмирхан, мәсәлән, «бөтен рус милләтенә бер-ике кешенең эшләгән эшләрен» сылтауны, «рус милләте белән бюрократиясен» аера алмауны гаепләп чыкты. (Ф. Әмирхан. Сайланма әсәрләр. 2 том, Казан, 1958, 201, 238 битләр.) Революцион демократларның халыклар дуслыгы һәм туганлыгы идеяләрен тайпылышсыз рәвештә яклап килүләрендә без пролетар интернационализм идеологиясенең, һәм шулай ук теге яки бу халыкның башка милләт кешеләрен кимсетергә, ә инде үзен генә зурайтырга хаклы булмавын раслаган Чернышевский мәктәбенең дә шифалы тәэсирен күрәбез. (Н. Г. Чернышевский. Избранные философские сочинения. Т. III, стр. 589.)

XIX йөз ахырында һәм XX йөз башында милли культура үсеше проблемаларының көн тәртибенә күтәрелүе буржуазия белән пролетариат арасында кискен көрәш китереп чыгарды. «Бердәм милли агым» дигән булып татар буржуазиясе ислам дине традицияләрен мәңгегә ныгытырга, милли аерымлыкны культлаштырырга, башка милләтләрнең культура кыйммәтләрен санга сукмау карашлары тәрбияләргә маташты.

Алдынгы фикер ияләре халыкның рухи тормышын томаларга омтылыш белән килешә алмадылар. Демократик эчтәлекле мәгърифәтчелектән революцион позицияләргә күчә барган саен алар бер милли культурада ике культура булуына һәм чын демократик милли культураның бары тик буржуаз-клерикаль реакция белән көрәштә генә үсә алачагына төшенә килделәр. Алар рухи тормышны кешеләрнең социаль-экономик һәм политик хәле белән тыгыз бәйләнештә карарга өйрәнделәр, үз халыкларының мәдәни үсешен иҗтимагый гаделсезлеккә каршы көрәштә күрделәр.

Чернышевский һәм аның фикердәшләренең йогынтысы татарлар арасында эстетик фикер үсешенә тәэсир итүдә аеруча сизелерлек чагылды. Бу нәрсә татар мәгърифәтчеләренең сәнгатькә кагылышлы фикерләрендә үк ярылып ята. Алар татар халкы тарихында беренчеләр булып сәнгатьне катып калган мөселман руханилары һөҗүмнәреннән яклап чыктылар. Ш. Мәрҗани һәм К. Насыйри кешенең тормышны сәнгать чаралары белән чагылдырырга хокукын дауладылар. Алар Чернышевскийның «тормышны гәүдәләндерү — сәнгатьнең асылын тәшкил итүче гомуми характерлы сыйфаты» дигән тәгъбиренә охшаш фикерләр әйттеләр. Мәсәлән, Мәрҗани фольклор әсәрләрендә татарлар һәм шулай ук аларның бабалары — Идел-Кама болгарлары тормышы һәм йолаларының ачык чагылышын күрде. Гарәп поэзиясе турында сөйләгәндә ул «шигырь — ул гарәпләрнең диваны. Анда аларның гыйлемнәре, хәбәрләре, фәлсәфәләре тупланган; шигырь аларның олылык һәм юмартлыкларының, турылык һәм хаталарының шаһите» дип язды. (Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты архивы. 22 ф., I тасвирлама, 20 саклау берәмлеге, 51 бит.) Чернышевскийның «чын гүзәллек чынбарлык гүзәллеге ул» дигән гаҗәеп идеясе дә татар мәгърифәтчеләренә якын һәм аңлаешлы иде. Гүзәллек идеалын аллага һәм аның мифик даирәсенә — фәрештәләр, җәннәттәге хур кызлары, дию перийләре образларына кайтарып калдырган мөселман суфичыларыннан аермалы буларак, мәгърифәтчеләр эстетик ләззәт һәм илһамның чыганагын халыкның реаль тормышыннан эзләргә һәм шуннан табарга өйрәттеләр. «Хәкимнәр димешләрдер ки, агар суга карамак,

[1] Гаризи — очраклы.

яшел үләннәргә карамак, матур вә күркәм йөзгә карамак күзнең нурын вә гакылны арттырыр».— дип язды К. Насыйри. (К. Насыйри. Фәвакиһелҗөләса, Казан, 1884, 446 бит.)

Н. Г. Чернышевский карашларына кушылып, татар мәгърифәтчеләре җирдә иң гүзәл зат итеп кешене санадылар. Аның төс-кыяфәтенә, эчке рухи дөньясына, акылына, әхлак сыйфатларына соклану белдерделәр.

Сәнгать төрләре арасында Н. Г. Чернышевский шигърият белән музыканы «югары, камил» сыйфатлы итеп аерып карады. Аның бу фикере дә татар мәгърифәтчеләре игътибарыннан читтә калмаган булса кирәк. Мәсәлән, Ш. Мәрҗани сәнгать төре буларак шигъриятне аеруча югары бәяләде. К. Насыйри шигъриятле иҗатны «көйләп укымак яки шигырь әйтмәк гүзәлләрдән янә гүзәл нәрсәдер» дип атады. (К. Насыйри. Сайланма әсәрләр. Казан, 1953, 46 бит.) Музыка исә җан азыгыдыр, «...Фәһем[1] не саф кылыр, зиһенне нечкәртер, табигатьне йомшартыр, мәрхәмәтлене мактатыр, җөбенне[2] баһадирландырыр, саранны юмартландырыр» дип язды. (К. Насыйри. Фәвакиһелҗөләса. Казан, 1884, 442 бит.)

XX йөз башында демократик милли культураның үсеше Г. Тукай, Г. Камал, Х. Ямашев, Г. Коләхметов, М. Гафури, Ш. Мөхәммәдов, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Г. Кариев кебек эшлеклеләр исемнәре белән бәйләнгән. Алар иҗади фикер азатлыгын, халыкның иң яхшы рухи традицияләрен яклап, мәдәни прогресс юлында коточкыч тормозга әйләнгән феодаль-клерикаль кадимчелеккә һәм милли чикләнгәнлеккә каршы чыктылар. «Безнең милләт тә Пушкиннарга, граф Лев Толстойларга, Лермонтовларга мохтаҗ,— дип язды Тукай.— Кыскасы гына, безнең милләт тә башка милләтләрнең тәрәккыйләренә сәбәп булган чын мөхәррирләргә, рәссамнарга, бардакханәләрдән чыкмаган яңа-яңа милли шигырьләргә, музыкаларга вә гайреләргә мохтаҗ». (Г. Тукай. Әсәрләр дүрт томда. 3 т., Казан, 1976, 156 бит.)

Мещанлык-декадентлык әдәбиятын тәвәккәллек белән кире кагып һәм «сәнгать сәнгать өчен» дигән ялган концепция тарафдарлары белән көрәшеп, Тукай һәм аның фикердәшләре халык тормышын дөрес итеп һәм һәръяклап чагылдырырга, җәмгыятьнең гарип якларын фаш итәргә, иҗтимагый үсешнең тормышчан тенденцияләрен ачарга, массаларның аңын уятырга, аларга иҗтимагый күренешләрнең катлаулы чоңгылларын төшенүдә ярдәм итәргә, яктыны караңгыдан, алдынгыны зарарлыдан, дусларны дошманнардан аерырга өндәргә тиешле әдәбият һәм сәнгатьне хупладылар.

Алдынгы карашлы татар художник-фикер ияләренең шушы ачык эстетик позициясе, бер яктан, аларның иҗтимагый-политик тормышта һәм азатлык хәрәкәтендә актив катнашулары, икенче яктан, рус теоретик фикеренә, беренче чиратта, Белинский, Герцен, Чернышевский, Добролюбов, Писарев, Некрасов әсәрләренә аеруча игътибарлы булулары нәтиҗәсе иде. Революцион социал-демократия белән дә тыгыз элемтәдә торган хәлдә, алар марксизм-ленинизмның эстетик принципларын тәэсирен дә тойдылар. В. И. Ленинның «Партия оешмасы һәм партияле әдәбият» исемле мәкаләсе, Г. В. Плехановның әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләре буенча кайбер хезмәтләре аларның игътибарыннан читтә калмады. Ә пролетариат әдәбиятының нигезләрен салган М. Горькийны алар барысы да укый килделәр, аның талантына, иҗади кыюлыгына һәм новаторлыгына сокландылар.

Өлкән рус туганнары артыннан барып, татар революцион демократлары халыкның эстетик ихтыяҗларын канәгатьләндерә, аның иң яхшы идеалларын гәүдәләндерә торган чын сәнгать өчен көрәштеләр. Халыклар азатлыгы һәм бәхете өчен һәртөрле изүчеләргә каршы көрәштә корал булырлык шундый сәнгатьне алар үзләре тудырдылар. Аларның традициясен бүген социализм шартларында үсеп җитлеккән әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре уңышлы дәвам иттерә һәм үстерә бара.

Үзенең иҗаты һәм шәхси батырлык үрнәге белән милли культураның берничә буын алдынгы эшлеклеләрен һәм халык бәхете өчен көрәшчеләрне тәрбияләгән Николай Гаврилович Чернышевскийның данлы исемен Совет Татарстаны хезмәт ияләре тирән хөрмәт белән искә алалар. Бөек рус галиме һәм художнигының, фикер иясе һәм социалистының бай һәм кыйммәтле мирасы хәзер киң хезмәт ияләре массасының хәзинәсенә әверелде, ул күп милләтле, интернациональ социалистик культураның алтын фондына керде.

---

[1] Фәһем — аң, аңлау, төшенү.

[2] Җөбен — куркак.

Аида Алмазова

# ИЛЛӘР ГИЗӘР АЛДЫННАН...

Фәрит Яруллинның тормышы һәм иҗат юлы белән таныша башлагач, композитор калдырган мирасны өйрәнү эшенең шактый сүлпән баруын күреп гаҗәпкә каласың. «Шүрәле» балеты һәм аның иҗатчысы хакында Ч. Бахтиярованың монографик очеркыннан тыш күләмле фәнни чыганак дип атап әйтерлек башка нинди дә булса хезмәт күренми. Әлеге хезмәттә Ф. Яруллин иҗаты белән бәйләнешле барлык сорауларга да җавап табу мөмкин түгел. Очерк өчен бу табигый дә.

Казанлылар әле хәтерлиләр булыр: 1945 елның мартында, «Шүрәле» балеты башлап сәхнәгә чыккан көннәрдә, әсәрнең авторлары дип Фәрит Яруллин һәм язучы Әхмәт Фәйзи игълан ителгән иде. Бераз соңрак, 1950 елда, балет С. М. Киров исемендәге Ленинград опера һәм балет театрында яңадан куелды. Әсәрнең исеме бу постановкада «Али Батыр» дип үзгәртелгән һәм авторлар арасында, либретточы буларак, Леонид Якобсон, музыка авторлары итеп, В. Власов һәм В. Фере фамилияләре өстәлгән иде. Табигый ки, укучыда либреттоны иҗат итүгә Ә. Фәйзи һәм Л. Якобсон нинди өлеш керткәннәр һәм шулай ук әсәрнең музыкасын язуда Яруллинның роле нинди булган икән соң, дигән сорау туа. В. Власов һәм В. Ференың автордашлар булып исәпләнүе балет клавирының 1971 елгы басмасыннан да күренеп тора. Анда әсәрне инструментларга салучылар, эшкәртү һәм редакцияләүчеләр В. Власов һәм В. Фере дип әйтелә. Алай да сүзне либреттодан башлыйк.

Тукайның «Шүрәле» әкиятe буенча балет язу фикере 1938 елда ук туган булса кирәк. Чөнки беренче инструменталь фрагментларны кәгазьгә төшерү, жанрның ачыклануы шушы вакытка туры килә. Либретто язу эше Әхмәт Фәйзигә тапшырыла. Композитор Н. Җиһанов архивында шундый фоторәсем сакланып калган: «Шүрәле» либреттосын «кече коллегия»дә тикшергән көнне Г. И. Литинский, Н. Җиһанов, Ф. Яруллин, Ә. Фәйзи бергә рәсемгә төшкәннәр. Либреттоның Ленинград дәүләт архивында саклана торган беренче варианты 1939 елның 27 февралендә тәмамланган[1]. Димәк, Ф. Яруллин балетны 1939 елның башында яза башлаган дип әйтә алабыз.

Балет либреттосын язуга Әхмәт Фәйзи бик зур җаваплылык белән алына. Халык әкиятләрен, Тукай әсәрләрен тагын бер мәртәбә карап чыга. Үзенең сүз башында әйткәнчә, либреттога нигез итеп шагыйрьнең «Кышкы кич», «Кәтмәгәндә», «Буран», «Суык», «Су анасы», «Бала белән күбәләк», «Таз», «Һәр ялтыраган алтын түгел» шигырьләрен һәм, әлбәттә, «Шүрәле» поэмасын ала. Либретто үз вакытында матбугатта чыкмаган, ә кульязмасы исә яңа табылды.

Либретто халыкчан сюжетка корылган, образларның милли характеры, халык фантазиясе белән тудырылган әкият дөньясы анда күркәм чагылыш таба, ул милли

[1] Ленинград дәүләт архивы, 3827 фонд, I тасвирлама, 161 эш.

уен һәм биюләр, шаян һәм тапкыр Таз малайның хәйләләре һәм башка яклары белән күңелне җәлеп итә.

Либреттода Шүрәле татар халык иҗаты рухын тирән сеңдергән образ булып күз алдына баса. Халык телендә йөргән Шүрәле ул, дию кебек дәһшәтле зат булмаса да, шактый ук куркыныч һәм сәер җан иясе. Явыз түгел, әмма кодрәтле, иң яраткан эше — урманда очраган ялгыз кешеләрне кытыклау. Әгәр «кети-кети» итәргә тотына икән, ул инде бу эшне җиренә җиткереп башкара һәм адәм баласының көлә-көлә җан тәслим кылуы да бик ихтимал.

К. Насыйри үзенең «Ышанулар» исемле язмасында болай дип сөйли: «Әгәр аңа кеше заты очраса, ул аны үтергәнче кытыкларга мөмкин. Әмма үзенең ахмаклыгы белән ул күп очракта кешедән алдана». Кешеләр кайчагында Шүрәлене утта яндыралар, ләкин, халыкның ышануы буенча, аның каргышы бик зур. Шуңа күрә кайбер авылларны «Шүрәле каргаган авыл» дип йөртәләр. Имеш, Шүрәлене яндырсаң, авыл ишәйми, нәсел артмый. Шуңа күрә кешеләр аңардан хәйлә белән котылырга тырышалар. Әхмәт Фәйзи либреттосында Шүрәле образының нәкъ шул үзенчәлекләре тәгәл гәүдәләндерелә. Былтыр да акыллы, тапкыр яшь егет буларак күрсәтелә. Әмма, шулар белән бергә, либреттода вакыйгаларның шактый таркау булуы, сюжет чуарлыгы күзгә ташлана. Сәнгать белгече Чистякова язганча, «Биюле жанр үзенең табигате белән тормыш-көнкүреш детальләреннән, төрле вак нәрсәләрдән арынуны таләп итә... Шигъри гомумиләштерелгән образлар, көчле тәэсирле, киеренке-эмоциональ конфликт — нәкъ әнә шулар балетның рухына җавап бирә»[1]. Әхмәт Фәйзи либреттосында вакыйгаларның күплеге, социаль һәм көнкүреш детальләре белән чуарлау нык сизелә. Асафьев сүзләре белән әйтсәк, «театраль романтика» җитеп бетми, төп конфликт тиешле дәрәҗәдә калку гәүдәләнми кала.

Әмма шунысын да әйтергә кирәк, әлеге кимчелекләр табигый күренеш тә була. Башлап җибәрү һәр вакыт кыен. Авторның балет либреттосын язуда тәҗрибәсе булмый диярлек. Ә жанр хосусиятен үзләштерү балет өчен аеруча мөһим нәрсә. Шуңа күрә әле 1939 елда ук балетмейстер белән бергә либреттоны тиешле дәрәҗәгә җиткерү мәсьәләсе килеп баса. Һәм балетны 1941 елда Мәскәүдә үтәсе булган Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында күрсәтергә карар ителгәч, «Шүрәле»нең балетмейстеры итеп билгеләнгән Л. Якобсон либреттога күп кенә үзгәрешләр кертә. Либреттога карата Муса Җәлилнең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият, тарих институтында саклана торган бәяләмәсе кызыклы. Түбәндә без аның кайбер өзекләрен тәрҗемә итеп китерәбез. «Шүрәле» либреттосының Леонид Якобсон китергән варианты Фәйзи либреттосына (беренче вариантына да, икенче вариантына да) аз охшаш. Катнашучы геройларның исемнәре (Шүрәле, Былтыр) һәм Тазның шаяруы кебегрәк икенче дәрәҗәдәге күренешләр генә элеккечә калган.

Якобсон драматик сюжетны бөтенләй башкача кора, интрига да, вакыйгалар да бөтенләй башка, хәтта әсәрнең идеясе дә икенче якка үзгәреп киткән».

Алга таба М. Җәлил балет либреттосына Якобсон керткән үзгәрешләрне бәяләп үтә. Чыннан да, либреттоның яңа редакциясе театраль драматургия таләпләрен нык истә тотып эшләнгән, драматургик конфликт үсешенә монда зур игътибар бирелә, образлар күренештән-күренешкә эзлекле төстә ачыла бара, вак деталь һәм эпизодлар төп максатка хезмәт итә. Шул ук вакытта, Якобсон либреттосы җитди кимчелекләрдән дә азат түгел. М. Җәлил рецензиясендә дә алар ачыктан-ачык күрсәтелә. «Алар (образлар — А. А.) шулай ук халык әкиятләре һәм Тукай әсәрләреннән безгә таныш булган теге яки бу образны күз алдына бастырмыйлар. Якобсон либреттосында Шүрәле Сөембикәне гыйшкы белән эзәрлекләүче явыз демон итеп бирелә. Ул татар халык әкиятләрендә һәм халык шагыйре әсәрләрендә сурәтләнгән лирик образлардан диюне хәтерләтә төшә. Нәкъ менә дию матур кызларны нәфселе сөю белән эзәрлекли, урлап алып китеп, бик эчендә тота, сихерли һәм башка күп хәвеф-хәтәрләр белән яный. Ә әкиятләрдә һәм Тукай әсәрләрендәге Шүрәле исә — бөтенләй башка. Ул караңгы урманнарда яши һәм аның бернинди дә тылсым көче юк. Ул һәрчак үзенә кызык эзләп йөри... Ул көлке ярата һәм кешеләрне кытыклаудан кызык таба. Нәкъ менә шуңа күрә дә Г. Тукай юмористик әсәрләрен «Шүрәле» исеме белән бас-

---

[1] В. Чистякова. «В мире танца». Ленинград — Мәскәү, 1964 ел, 24 бит.

тырган. Шүрәленең кайчан да булса гыйшык тотуы, мәхәббәте белән кызларны әзәрлекләве, нинди дә булса тылсым куәсе булуы хакында сөйләнүен мин белмим. Шүрәдән чыгып, мин Якобсон либреттосындагы бу образның Шүрәле исеме белән аталуын уңышсыз дип саныйм. Ул булса «Дию», «Урман иясе», урман патшасы булыр. Былтыр исеме дә уңышсыз алынган. Тәрҗемәдә ул «үткән ел» дигәнне аңлата һәм Тукай әкиятендәге мәгълүм ситуация белән бәйләнештә тора. Монда исә ул нәрсә юк һәм, димәк, исем дә үзен акламый. Якобсон либреттосы бик кызыклы корылган. Анда татар халык иҗаты өчен һич тә ят булмаган әкият мотивлары бар. Мәсәлән, тылсымлы канатларда очып килүче торна-кызлар. Ләкин шулай да либреттодагы кайбер моментлар шик уята. Халык әкиятләрендә кеше гадәттә мифик көчләр һәм табигать көчләре белән көрәштә акылы һәм тапкырлыгы аркасында җиңүгә ирешә. Әкиятләрдәге мифик көчләр һәм табигать көчләре кешедән көчлерәк итеп биреләләр, әмма кеше — җитез, зирәк һәм хәйләкәр. Шуңа күрә ул өстен чыга да. Тукай әкиятендә егет Шүрәлене хәйлә белән җиңә, ә Якобсон либреттосында Былтыр Шүрәле белән көч сынаша һәм аңардан көчлерәк булып чыга. Ул аны бүрәнә янына көчләп сөйрәп алып килә һәм бармакларын ярыкка кыстыра. Әлбәттә, бу бөтенләй икенче нәрсә һәм болай иткәндә халык әкиятенең бөтен хикмәте һәм матурлыгы югала. Шүрәлене яндыру күренешендә дә без хәйлә һәм акыл өстенлеген күрмибез...» — дип яза М. Җәлил.

Моңа өстәп тагын шуны әйтәсе килә: халык ышануы буенча, Шүрәлене утта яндыру яңа кавышкан Былтыр белән Сөембикәгә бәхетсезлек китерүе мөмкин. Ә инде урманга ут төртү халыкта һәр вакыт җинаять санала. Балеттагы Шүрәле образы һәм Былтырның аңа карата кылган гамәлләре татар әкиятләрендә таралыш алган мотивлар белән ярашмый.

Якобсон балетка канаты урланган кошның кызга әверелүе мотивын керткән. Беренче карашка, бу мотивның «Аккош күле» балетындагы сюжет белән аваздаш булуы шикләндереп куя. Ләкин алар арасында җитди аерма бар. «Аккош күле»ндә Одетта — явыз зат тарафыннан сихерләнгән кыз һәм ул бөтен күңеле белән кешеләргә тартыла, үзен коткарырлык бердәнбер нәрсә — тугрылыклы мәхәббәт турында хыяллана. «Шүрәле»дәге Сөембикә иркенле кош булып туган, ул үзен бәхетле, азат итеп тоя, дөнья аның өчен иркен, якты, ямьле, чөнки ул бүтән тормышны, башкача яшәүне белми. Канатларын җуйганнан соң гына ул кешеләр арасына керергә мәҗбүр була. Кешеләрнең күңел җылысын тойган, мәхәббәт һәм гүзәллек дөньясын таныганнан соң ул кешеләр арасында кала. Татар халык поэзиясендә моңа тәңгәл килә торган сюжет булмаса да, охшаш мотивлар бар. Мисалга «Хезмәтче һәм кошлар патшасы» һәм «Өч күгәрчен» әкиятләрен алырга мөмкин. «Өч күгәрчен» әкиятендә өч туган, күгәрчен кыяфәтенә кереп, дию тарафыннан урланган кызны эзләп китәләр. «Хезмәтче һәм кошлар патшасы» әкиятендә егет күгәрчен кыяфәтендәге кызның канатларын яшерә һәм аны үз янында калдыра.

Инде балетның икенче пәрдәсендәге туй күренешенә тукталып үтик. Якобсон тарафыннан кертелгән бу күренеш татар театрының художество советы утырышларында бер генә тапкыр тәнкыйтьләнмәде. Чөнки анда хәмердән авыз итеп кызып алган картлар, кода белән кодагыйның мәзәк биюләре, үз-үзен тотышлары татарлардагы электән килгән туй йоласы гадәтләре һәм тәртибе белән сыешмый. Традиция буенча, туй мәҗлесендә картларның яшьләр белән бергә җәелеп күңел ачуын, бергәләп җырлап-биюләрен күз алдына китерүе кыен. Татарлардагы милли гореф-гадәт һәм йолалар белән таныш булган тамашачылар өчен балет спектаклендәге ул күренешләр бик сәер тоела.

Театр драматургиясе таләпләре җәһәтеннән караганда, либретто, әлбәттә, җыйнакланган, сюжет бөтенлеге яхшырган. Һәм, шул ук вакытта, ул милли фольклор рухына җавап биреп бетерми, җитди тәнкыйтькә мохтаҗ булып кала. Балетта алынган сюжет әгәр чыннан да «Дию» дип исемләнгән булса, ул үзенең исеменә туры килә төшәр иде. Әмма либреттодагы мондый эчтәлек балетның музыкасына туры килми, чөнки Ф. Яруллин музыкада нәкъ менә Тукай поэмасында сурәтләнгән сәер урман карачкысы Шүрәле образын тудырган!

Шулай булгач, либретто авторы итеп кемне танырга соң? Әхмәт Фәйзинең шәхси архивындагы материаллардан күренгәнчә, әдип 1938 елдан башлап либреттоның бер-

ничә вариантын яза. 1941 елның башыннан бу эшкә балетны сәхнәгә куючы балетмейстер Л. Якобсон да кушыла. Якобсон белән очрашулар, фольклор материалларын сайлау, иҗади эзләнү, либреттоны камилләштерү процессында Ә. Фәйзи Г. Тукайның сабакташы Каюмовны балетмейстер белән очраштырып, мәдрәсәдә Тукайдан ишеткән әкиятләрне сөйләттерә. Шушы әкиятләр арасында кыз кыяфәтенә керүче кош һәм аның канатын урлаган егет турындагы әкият тә очрый. Шүрәле поэмасы белән бергә бу сюжет соңрак балетның нигезенә салына.

Балет татар опера һәм балет театры сәхнәсендә Бөек Ватан сугышы чорында куела һәм либретто авторы буларак Әхмәт Фәйзи күрсәтелә. Ә. Фәйзинең үз кулы белән язуынча, Якобсон варианты аңа кадәр әле Ә. Фәйзи язган вариантлар һәм фикер алышу барышында әйтелгән тәкъдимнәр нигезендә төзелгән. Чыннан да, 1941 ел башында балетмейстер Якобсон белән Ә. Фәйзигә балет либреттосын тиешле дәрәҗәгә җиткерү бурычы йөкләнә. Ләкин алар арасында якын иҗади хезмәттәшлек урнашып китә алмый. Ә. Фәйзи авырып шифаханәгә керә, ә җәен Бөек Ватан сугышы башланып китә. Ә. Фәйзи фронттан кайтканда балет инде татар театры сәхнәсендә куелган була.

Спектакльне куярга алынганда Л. Якобсон кулында барлык материаллар: Ә. Фәйзи либреттосы, тәкъдимнәре һәм материаллары, «Шүрәле» поэмасы, балетмейстер В. Варковицкийның кызга әверелүче кош турындагы сюжетны эченә алган сызмалары[1] булган. Якобсон исә, балет жанрының үзенчәлекләрен яхшы белгән хәлдә, үз карамагындагы материалларны драматургия таләпләренә туры китереп, бер сюжетка тезеп чыккан дип нәтиҗә ясый алабыз. Якобсонның Ленинградтагы дәүләт архивында табылган һәм «Шүрәле» балетының туу тарихына караган язмасы да шундый ук фикергә китерә[2]. Әмма үзенең сәләтенә, балет сәхнәсе кануннарын белүенә генә ышанып, Якобсон гасырлар буенча формалашкан фольклор традицияләрен, аның рухын һәм бай хасиятләрен тиешле югарылыкта гәүдәләндерә алмаган.

«Шүрәле» либреттосы беренче татар балетын мәйданга чыгару кебек четрекле эшнең башы гына була әле. Балетның музыкасы да билгеле бер калыпка кергәнче шактый каршылыклы, сикәлтәле юллар үтә.

Фронтка киткәнче, Фәрит Яруллин балетның тулы клавирын (ягъни фортепианода ике кул белән башкару өчен нота язмасын) һәм беренче пәрдәнең оркестр партитурасын тәмам итәргә өлгерә. Икенче һәм өченче пәрдә партитураларын сугыш чорында Мәскәү консерваториясе педагогы Ф. Е. Витачек эшләп чыга. Балетның бу редакциясе 1945 елда Татар дәүләт опера һәм балет театрында Л. Жуков һәм Г. Таһиров тарафыннан куела. Ә 1950 елда «Шүрәле» балетын Киров исемендәге Ленинград опера һәм балет театрында кую мәсьәләсе килеп баскач, композиторлар В. Власов һәм В. Фере балетның яңа редакциясен (партитура һәм клавирын) әзерлиләр. Шушы редакциядә әсәр киң масштабта танылып китә һәм бөтен дөньяга дан казана.

1971 елда Мәскәүнең «Музыка» нәшриятында басылган клавирга сүз башында Власов һәм Фере болай дип язалар: «Балет музыкасында, авторның үлеменнән соң сакланган хәлендә, билгеле бер дәрәҗәдә төгәлләнеп җитмәгән элементлар, фрагментлылык бар, кайбер урыннарда профессиональ яктан тиешенчә өлгереп җитмәгәнлек билгеләре сизелә. Автор партитурасы бөтенләй юк иде». Әсәрнең яңа редакциясенә үзләре керткән иҗат өлешен күрсәтеп, алар болай дип өстиләр: «Балетны сәхнәгә кую өчен клавирны бик җентекле рәвештә редакцияләп чыгарга, автор материаллары нигезендә күп кенә номерларны язып бетерергә һәм әсәрне тулысы белән инструментларга салырга кирәк иде. Үз вакытында бу эш безгә йөкләтелде».

В. Власов белән В. Ференың бу раслаулары каршылыклы фикерләр уята. Иң элек беренче пәрдәнең музыкасы өчен автор үзе төзегән партитура (ул хәзер Татарстан дәүләт музеенда саклана) хакында алар ничек белмәде икән дигән сорау туа. Җитмәсә, Витачек эшләгән партитура хакында да кереш сүздә берни әйтелми.

Власов һәм Ференың әсәрне төгәлләнеп җитмәгән, фрагментлы характерда дип бәяләүләре белән дә килешеп бетәсе килми. Чөнки әсәр сәхнәгә кую өчен кабул

[1] В. Варковицкий, Ленинград опера һәм балет театры балетмейстеры, 1941 елда Татар дәүләт опера һәм балет театрында хезмәттәшлек итә.
[2] ЛГАЛИ, 3827 фонд, 1 тасвирлама, 168 саклау берәмлеге.

ителгән, сугыш беткәнче үк куелган һәм шактый зур уңыш казанган. Әсәр клавирының Витачек партитурасына туры килә торган оригиналы сакланып калган. Хәзер әсәрнең әнә шушы төп нөсхәсенә күз салыйк.

Ф. Яруллин клавиры белән танышкан һәр кешене аның музыкасының гади һәм шул ук вакытта күңелгә тирән үтеп керә торган самими моңы дулкынландырмый калмый. Ул тышкы эффектлылыкка дәгъва итми, көчле аһәңлеге белән дә аерылып тормый, ул — хисләрнең эчке байлыгы, нечкә шигъри уй-тойгылар ятуы белән гүзәл.

Саф һәм садә музыкаль аһәңнәрдә иҗади фикер тибеп тора, чын илһам нурлары сирпелә. Балет образлары чын милли сыйфатларында гәүдәләнәләр, халык иҗатының сихри дөньясы синең алдыңда тирән ачыла бара. Һәр персонаж фольклор традициясе стихиясендә үзенә хас яңгырашта тасвирланган. Шүрәле образында сәер уенчаклык, кыргый шуклык сыйфатларына басым ясала. Былтыр исә намуслылык, тугрылык, тыйнаклык символы булып күз алдына баса. Сөембикә күңел нечкәлеге, оялчанлык, назлылык сыйфатларын үзенә җыйган. Образларның һәр группасы үзенә генә хас музыкаль сурәтләү чаралары аша сынландырыла. Шүрәле һәм аның иярченнәре төрле алымнарның катлаулы синтезы аша, пентатониканы рус музыкаль әкият классикасында формалашкан лад, тональ һәм гармоник чаралар белән кушу аркылы гәүдәләнә. Сөембикә һәм Былтырның мәхәббәт хисләрен тасвирлаганда композитор халык моңнарына гаять якын торган, шул ук вакытта кабатланмас иҗади романтик яңгырашлы дуэтлар тудыра.

Әсәрдәге реаль образларның гына түгел, фантастик персонажларның да (әкият музыкасы классикасында гаять сирәк очрак) үз үсеш сызыгы бар, ягъни автор алар өчен симфоник үстерелеш чараларын тапкан. Әгәр беренче пәрдәдә Шүрәле сәер һәм мәзәк урман сарыгы булып күренсә, соңга табан ул ачулы һәм усалрак була бара. Тик автор монда да Шүрәлене гротесктан тулысынча азат итми, образның мәзәк, көлке нюансларын юкка чыгармый, шуның белән кешенең акыл көченә, зирәклегенә басым ясала. Автор моңа Шүрәле темасының яңгырашына ялган тоннар кертү, музыкаль ноталар арасындагы интервалларны кечерәйтү кебек чаралар ярдәмендә ирешә, теманың дәһшәтлелеген көтмәгәндә йомшартып куя.

Эшлекле авыл егете Былтыр спектакль барышында тәвәккәл һәм дәртле романтик образ дәрәҗәсенә үсеп җитә. Шат күңелле, тәкәллефсез, яклаучысыз Сөембикә, күп сынаулар кичеп, күңел тетрәнүләре кичереп, эмоциональ баеый һәм тирәнәя.

Балетның музыкасы гомумән алганда басынкы-тыйнак булуы белән аерылып тора. Формасы белән ул җыйнак һәм үтемле. Спектакльдә табигать күренешләрен, урманның сихри тормышын сурәтләү Сөембикә һәм Былтырның дулкынландыргыч хис-тойгыларын, нечкә күңел моңнарын тасвирлау белән бергә үрелеп бара. Витачек тарафыннан эшләнгән партитура авторның төп фикер юнәлеше белән тыгыз бәйләнештә тора.

Бу беренче редакциядә балетның оркестр составы әле шактый ярлы. Ул шул чордагы Татар дәүләт опера һәм балет театры оркестрына яраклаштырылган. Партитура оркестрның парлы составын[1] күздә тотып эшләнгән, бизәгеч уен коралларыннан исә анда бары өч инструмент: өчпочмак, ксилофон һәм арфа файдаланыла. Төрле тембрдагы уен кораллары образларның характерларына тулысынча туры килерлек итеп сайланган. Әйтик, Шүрәле образын сурәтләүдә инглиз мөгез-быргысының үзенчәлекле тембрлары һәм сурдиналы быргылар тавышы зур урын тота. Былтыр образы курайны хәтерләтүче гобой авазлары аша күз алдына баса. Ә инде нечкә һәм нәфис Сөембикә образы ялгыз скрипка һәм бер тавышка уйнаучы кыллы музыка кораллары аша җиткерелә. Шул ук вакытта партитурадагы инструменталь фактураның чикләнгән булуын әйтергә кирәк. Витачек автор калдырган клавирга хәтта бер генә аваз да өстәми. Оркестр палитрасындагы бизәкләр, тембрларның бай мөмкинлекләре тиешле дәрәҗәдә ачылмыйча кала. Йөкнең иң зурысын анда кыллы музыка кораллары группасы алып бара, башка группаларның аваз мөмкинлекләре шактый ук йомшак файдаланыла.

Балетны Ленинград опера һәм балет театры сәхнәсендә куярга хәзерләгәндә яңа партитура эшләү мәсьәләсе алга килеп баса. Чөнки Витачек партитурасы театрның

[1] Оркестр составы тынлы агач уен кораллары саны буенча билгеләнә. Парлы составта һәр төрдән икешәр уен коралы: ике флейта, ике гобой, ике фагот була.

зур составлы симфоник оркестры колачына җавап бирми, ә әсәрнең масштабын киңәйтү, фактураны баету таләп итеЛә. Балетның яңа редакциясе әнә шул максатны күздә тотып эшләнә дә. Әмма эш шунда ки, бу яңа редакция оркестр алымнарын һәм чараларын киңәйтү, әсәрнең гомуми яңгырашын үстерү белән генә чикләнми, ул интонация материалларына, әсәрнең формасына да кагыла. Ни өчен бу болай? Шундый җитди үзгәрешләр кертү ник кирәк булган? Күрәсең, редакторлар Фәрит Яруллин музыкасындагы образлар сурәтләнешенең либретто белән тәңгәл килмәвенә игътибар иткәннәр. Бигрәк тә Шүрәле һәм Былтыр образларының Л. Якобсон интерпретациясендә гәүдәләнеше аларны аптырашта калдырган булса кирәк. Һәм алар бу тәңгәлсезлекне төзәтергә булалар. Нәтиҗәдә балет музыкасына күп кенә үзгәрешләр кертелә һәм ул үзгәрешләрнең байтагы әсәрдә яңа каршылыклар китереп чыгара.

Әсәрдәге һәр образга диярлек В. Власов һәм В. Фере яңа төсмерләр өстиләр. Шүрәле образында, мәсәлән, аның явызлыгына, буйсындыру көченә, куркыныч кодрәтенә басым ясала. Шүрәле партиясендә өстенлек иткән кискен хәтәр интонацияләр бу «урман сарыгы»ның нәкъ шундый сыйфатларын күпертеп күрсәтә. Ул гына җитмәсә, Шүрәлебез әле алдан корган мәкер белән эш итә торган астыртын һәм хәйләкәр җан да икән. Аның партиясенә әледән-әле килеп керә торган үткен һәм зәһәр тоннар шул хакта сөйли. Шул рәвешчә образның гротескы, шаянлыгы югала. Бу исә аны халык хыялында туган Шүрәледән ераклаштыра. Яңа редакциядә Былтыр образы да бөтән кыяфәт алган. Монда инде ул урманга утынга килгән чая бер егет кенә түгел, ә коеп куйган баһадир. Шуңа ярашлы рәвештә аның исемен дә Али батыр дип үзгәртәләр[1] һәм ул урман айкап йөрүче сунарчы итеп сурәтләнә. Аның барлык биюләре күтәренке мәһабәт күренеш бирә, тамашачыга ул барыннан да элек әнә шундый импозантлы, мәгърур кыяфәте белән тәэсир итәргә тиешле булып чыга. Бу исә образның күп кырлылыгын, ышандыру көчен киметә. Яңа куелышта Сөембикә образы да үзгәрешсез калмаган. Спектакль башында ук ул, үз язмышын алдан сизенгән күк, түземсезлек белән нидер көтә, мәхәббәт турында хыяллана. Аның музыкасындагы диссонанслы гармонияләр, тональ көчеш-тайпылышлар шул хакта сөйли. Редакторлар бер үк төрле сурәтләү алымнарын төрле характердагы образларга көчереп йөртәләр. Мондый талымсызлык образларның эзлекле үсешенә комачаулый. Әсәрнең экспозициясендә үк алар төгәлләнгән яңгыраш алалар һәм калган күренешләрдә балет образларының музыкаль гәүдәләнешендә нинди дә булса үзгәреш күрү бик кыен. Бу кимчелекне «Татар балеты Ленинград сәхнәсендә» дигән рецензиядә Ю. Золотницкий да билгеләп үтә: «Музыкаль характеристикаларны тирәнрәк үстерүгә ирешкән очракта композиторның хезмәтен тагын да югарырак бәяләргә мөмкин иде,— дип яза ул.— Алар спектакльнең буеннан-буена бер үк яңгырашта бирелгән»[2]. Күренә ки, бу кимчелеккә автор түгел, ә редакторлар сәбәпче булуы рецензия авторының башына да килмәгән. Композитор Ф. Яруллинның иҗат стиленә хас эчке бер самими тыйнаклык, басынкылык, лаконизм редакторларны канәгатьләндереп җиткермн. Әсәрдәге аерым номерларга да, аның бөтен яңгырашына да алар киңрәк масштаб бирергә тырышалар. Власов һәм Фере әсәрдәге көч алышу, көрәш күренешләрен аеруча көчәйтәләр, аны калкурак, дәвамлырак итәргә омтылалар. Әмма алар кулланган алымнар һәм чаралар чын киеренкелек тудырудан бигрәк, музыкаль диапазонны берьюлы колачлап алып, соңыннан бер урында өзлексез «таптанып» торуга этәрә. Шулай итеп, музыкаль үстерелеш осталыгы, форма динамикасын нечкәләп тою ягыннан балет авторының биредә өстенрәк торганлыгын танырга туры килә. Редакторлар исә нәкъ шушы җәһәттә уңышсызлыкка очраган.

Балетның яңа редакциясендә әсәрнең төп темаларына нигезләнгән зур яңгырашлы көрәш, беренче һәм икенче пәрдәләрдәге кайбер номерларны кабатлаган саллы финал өстәлгән. Ләкин алар әсәргә салынган фикер һәм хисләрне баетудан бигрәк, күләмне киңәйтүгә генә хезмәт итә.

Күргәнебезчә, әсәрнең яңа редакциясендә, аны баетырга, колачын киңәйтергә омтылганда, редакторлар күп кенә төгәлсезлекләр җибәргәннәр.

---

[1] Балетны ислам дине тарихындагы Али (татарча дөрес әйтелеше Гали) исеме белән атау ул вакытта ук музыкаль җәмәгатьчелек тарафыннан тәнкыйть ителә.— Ред. искәрмәсе.

[2] Ю. Золотницкий. «Татар балеты Ленинград сәхнәсендә». «Советская Татария», 1950, 24 июнь саны.

Яңа куелышның уңай яклары нидән гыйбарәт соң? Күңелне җәлеп иткәне шул: инструменталь яктан әсәр яңа бизәкләргә баеган, алар тагын да куера төшкән. Яңа партитура зур, составлы оркестрда башкарыла, анда күп санлы бизәгеч инструментлар (фортепиано, ике арфа, ксилофон, челеста, кыңгыраучыклар, саксофон, өчпочмак) һәм там-там эшкә җигелә. Оркестр чын-чынлап бай һәм отышлы симфоник яңгыраш ала. Ф. Яруллинның аккордлар бәйләменә редакторлар яңа гармоник һәм полифоник авазлар өстиләр, аваз чыгаруның ясалма алымнары, флейта-пикколо, бас-кларнет кебек гадәттәгедән түбән яисә югары тембрлы үзгә уен коралларыннан мул файдаланалар. Хезмәтнең бу ягы тиешле профессиональ югарылыкта башкарылган. Шул ук вакытта төп тембрларның кулланылуы канәгатьсезлек хисе дә уята. Монысы, алда әйтелгәнчә, либреттодан ук килә һәм образларның асылын үзгәртүгә, аларны яңа сыйфатта күзаллауга бәйләнгән. Мәсәлән, Шүрәле партиясендә үзгә тембрлы инглиз мөгез-быргысын салкын тембрлы кларнет, Былтыр образында гобойны күбесенчә кларнет һәм быргылар алыштыра. Бу хәл образларның тембр каршылыгын юкка чыгара. Сөембикә номерларында исә, аңа бик ятышып торса да, ялгыз башкару аз катнаша.

«Шүрәле» балетының ике редакциясен янәшә куеп тикшерү түбәндәге нәтиҗәләргә китерә: Ф. Яруллинның клавирын тиешенчә бәяләп җиткермәүләре белән редакторлар хаклы булмаган, ул — тирән оригинальлеккә ия булган үзенчәлекле әсәр, сәнгатьлелек ягыннан аның мөстәкыйль әһәмияте зур. Индивидуаль иҗат йөзе һәм новаторлык принциплары булган талантлы композиторның гүзәл иҗат җимеше ул. Әсәрне яңадан кулга алудан бердәнбер максат — зур составлы оркестр өчен партитура әзерләү генә була ала иде.

Кызганычка каршы, авторның төп иҗат юнәлеше һәм стиленә хас күп үзенчәлекләр редакторлар игътибарыннан читтә калган. Моңа мәгълүм дәрәҗәдә Л. Якобсон либреттосы да комачаулык иткән. Шул ук вакытта редакторларның татар музыка культурасын йомшаграк белүләре дә киртә булган. Шул сәбәпле образларның үзенчәлекле музыкаль сурәтләнешен алар тәҗрибә җитенкерәмәү галәмәте дип уйлаганнар, басынкы яңгырашны стиль камиллеге җитмәү, лаконизмны — төгәлләнмәгәнлек билгесе дип кабул иткәннәр.

Укучыларда бик табигый рәвештә шундый сорау туарга мөмкин: балет ни өчен нәкъ менә В. Власов һәм Ф. Фере редакциясендә дөньяга танылган? Болай дип җавап бирә алабыз: ничек кенә үзгәртелмәсен, ул шулай да нигездә Фәрит Яруллин музыкасы булып кала һәм аның музыкаль җәүһәрләре матур бизәкле кысага салынган.

Мөхәммәт Мәһдиев

# БҮГЕН ДӘ ХӘРӘКӘТТӘ

Әдәбият, гыйлем, культурабыз тарихында Гали Рәхимнең үзенчәлекле урыны бар. Әдәбият галимнәребезнең хезмәтләрендә аның исеме еш очрый. Кайбер җыентыкларга аның мәкаләләре дә кертелә. Филология фәннәре докторы М. Хәсәнов аны Галимҗан Ибраһимовның тормыш юлы һәм иҗатына багышланган зур хезмәтендә гражданнар сугышы чорында халык ягына чыгып, хезмәт халкы интересларын яклау позициясенә баскан кеше дип атады[1]. М. Абдуллин һәм С. Батыевларның уртак хезмәтендә исә Г. Рәхимнең 1930 елда матбугатта чыккан мәкаләсенә зур бәя бирелде һәм Г. Рәхимнең коммунистлар партиясе һәм совет хөкүмәтенең милли политикасын яклап язган бу хезмәтенең тарихи әһәмиятенә басым ясалды[2].

Шулай да Гали Рәхимнең эшчәнлеге аерым алып тикшерелгәне юк әле. Аның хезмәтләре бик күп урыннарда басылганнар, аның кулы, көче кергән язмалар архив шүрлекләрендә яталар. Г. Рәхимнең бергә укыган, эшләгән иптәшләреннән күбесе инде дөньяда юк.

Г. Рәхим — XX йөз башында ук язучы, драматург, шагыйрь, тәрҗемәче һәм фольклорчы буларак танылган әдип. Октябрь революциясеннән соң ул күбрәк әдәбият тарихы һәм тарих белән шөгыльләнә. Андый күп кырлы, киң диапазонлы галим һәм язучының иҗат эшчәнлеген бер мәкаләдә генә яктыртуны автор үз өстенә йөкләми. Бу хезмәттә Г. Рәхимнең тормыш юлындагы төп этапларны күзәтеп чыгу һәм аның эшчәнлегенә теге яки бу дәрәҗәдә анализ ясау максат итеп куелды.

Г. Рәхим, унынчы елларда ук әдәбият дөньясына килеп, ике революция чорында әдәбият, фән өлкәсендә эшләде. Аның революцияне кабул итүе шактый катлаулы булды. Тормышы һәм дөньяга карашлары белән ул социалистик революцияне аңлауга хәзерләнеп җитмәгән иде һәм шул хәлдә революция көннәрендә әдәбият, сәнгать мәйданында кайнады, абынды, егылды, тагын торып юл эзләде, шулай да хезмәт халкына хыянәт итмәде, күп кыенлыклардан соң, үзенең юлын тапты. Бу юл — совет фәненә, димәк, социалистик Ватанга хезмәт итү юлы иде.

Әдипнең биографиясе буенча безгә билгеле булганнары шулар: архивта Г. Рәхимнең метрикасыннан күчермә сакланган. Моннан күренгәнчә, аның тулы исеме Мөхәммәтгали Мөхәммәтшакир улы Габдрәхимов. Ул Казанда 1892 елның 4 ноябрендә туган. Әтисе Лаеш өязе Олы Мәтәскә авылы крестьяны булган, Казанга килеп сәүдә эшенә катнашып киткән. Әнисе Бибигайшә — Исхак Айтуганов дигән Казан купецы кызы. Крестьяннан чыккан Мөхәммәтшакир сәүдә фирмаларыннан берсенең хуҗасы була. Ул үзенең улы Галине дә сәүдәгәр итү турында хыяллана. 1905 елда Гали Казандагы Коммерческое училищега керә һәм шул чорда өйләренә китерелгән хәлфәдән дә

---

[1] М. Х. Хасанов. Галимджан Ибрагимов. Казань, 1969, стр. 248.
[2] М. Абдуллин, С. Батыев. Татарская АССР: реальность и буржуазные мифы. Казань, 1977, стр. 157—158.

укый. Сәүдә училищесында уку дәверендә Гали үзлегеннән һәм хәлфәдән гарәп, фарсы, төрек телләрен өйрәнә. 1913 елда училищены тәмамлый. Аның әдәбият, фән белән кызыксына башлавы да шул училище чорына туры килә. Әтисе улын тагы да зуррак белемле сәүдәгәр итәргә тели һәм аны Мәскәүдәге Коммерческий институтка җибәрә. Бу институтның экономика бүлегендә Г. Рәхим 1917 елга кадәр укый, ләкин сәүдәгәр булырга күңеле ятмый. Шул җирлектә еш кына әтисе белән ике арада тавыш чыга. Аның саен Г. Рәхим әдәбият, фән дөньясына якыная бара. Ул Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Газиз кебек язучылар белән тыгыз элемтәдә була, «Ак юл» журналы редакторы Фәхрелислам Агиев, «Аң» журналы редакторы Әхмәтгәрәй Хәсәни һ. б. белән дуслаша. 1917 елда Мөхәммәтшакир абзый үлгәч, аңа күңеленә ятмаган сәүдә институтын ташларга мөмкинлек туа һәм ул Казанга кайта. Октябрь революциясеннән соң ул Казандагы «Өчьеллык педагогия курслары»нда, 1920 — 21 нче елларда хәрби политик курсларда, Казандагы Көнчыгыш академиясендә төрки-татар әдәбияты тарихын һәм татар фольклорын, 1922 елдан 1930 елга кадәр Көнчыгыш педагогия институтында шул ук фәннәрне укыта. 1927 елның 25 октябрендә аңа доцент исеме бирелә. 1930 — 1931 нче елларда ул Татар фәнни тикшерену экономик институтының татар теле һәм әдәбияты кабинетында секретарь булып эшли. Болардан тыш ул күп төрле гыйльми җәмгыятьләрдә фәнни эш алып бара. Казан университеты каршындагы тарих, этнография, археология җәмгыятендә, Татарстанны өйрәнү җәмгыятендә, ТАССР Мәгариф халык комиссариаты каршындагы Гыйльми үзәктә әгъза булып тора. 1926 — 30 нчы елларда Татарстанны өйрәнү җәмгыятендә гыйльми секретарь була. 20—30 нчы елларда аның 50 дән артык фәнни хезмәте басылып чыга. Рус һәм татар телләрендә язылган бу хезмәтләрдә төрки әдәбияты, яңа татар әдәбияты, тәнкыйть, фольклор, татар сәнгате һ. б. турында кыйммәтле мәгълүматлар бар.

1934 елның 21 октябреннан ул Казан университетының фәнни китапханәсендә кульязмалар бүлегенең гыйльми консультанты булып эшли. 1936 елның 9 ноябреннан Казан Дәүләт банкысына эшкә урнаша һәм 1938 елга кадәр шунда эшли.

* * *

Инде әдипнең иҗат эшчәнлегенә килик. Г. Рәхим бер үк вакытта хикәяләр, драма әсәрләре, шигырьләр язган, фольклор буенча тикшеренүләр алып барган. Матбугатта беренче мәртәбә ул 1909 елда күренә. Шунысы гаҗәп, булачак әдип (аңа бу вакытта нибары 17 яшь) матбугатка беренче тапкыр шигырь белән дә, хикәя белән дә түгел, ә «Җир йөзе» — дигән җәгърафия дәреслеге белән чыга. Ул рус телендәге «Вокруг света» дигән китапка нигезләнгән. Схоластик әсәрләр белән башы әйләнгән татар шәкертләренә андый дөньяви китапларның килеп җитүе хуплап каршы алына. Китапка бәя бирүче кешеләрнең беренчесе күренекле язучы Г. Камал була. Бу китапның «лисаны гаять җиңел һәм гүзәлдер» дип яза ул. Г. Камал шул ук вакытта яшь мөхәррирнең каләмендә өмет барлыгын сизенә, аны «киләчәктә әдәбиятымызга хили (байтак — М. М.) зур хезмәтләр күрсәтүе мәэмүл булган кәнҗ (яшь — М. М.) мөхәрриремез» дип атый. «Китапның язылуына, гыйбарәләренең гүзәллегенә, ифадәсенең садәлегенә караган кешенең,— ди Г. Камал,— Мөхәммәтгали әфәндедең кабилиятенә тәхсин (яхшы күрү — М. М.) идәчәгенә һәм киләчәктә Мөхәммәтгали әфәндедең әдәбиятымызга зур хезмәтләренә өмид идәчәгендә шөбһә кыйлмыйбыз»[1].

Г. Рәхим матур әдәбиятка көннән-көн ныграк тартыла бара. Һәм беренче каләм сынаулары аның өй шартларында үтә. Аларның йортында балалар өчен әдәби түгәрәк сыман бер төркем туплана. Г. Рәхим бу балалар өчен кечкенә-кечкенә әкият китапларын үзе хәзерли — эчтәлеген яза, кулдан язган битләрдән китапчык итеп тегә һәм балаларга укый, кулларына бирә. Шуның өстенә ул акварель белән дә шөгыльләнә, аерым әдәби әсәрләргә иллюстрацияләр ясый. Бераздан үзенең сеңелләре һәм дус-ишләренең балалары өчен йорт спектакльләре оештыра башлый. Бу спектакльләрдә Г. Рәхимнең үзе язган пьесалары да куела, кайвакыт ул балалар өчен көнбатыш классикасын да тәрҗемә итә. Аның сеңлесе Рауза Габдрәхимованың сөйләвенә

[1] «Йолдыз», 1909, 377 сан.

караганда, шундый спектакльләрнең берсендә Гетенең «Урман патшасы» дигән әсәре сәхнәгә куела. Бу әсәрне Г. Рәхим үзе тәрҗемә иткән (тәрҗемәнең Г. Рәхим кулы белән язылган ике варианты табылды). Истәлекләргә караганда, урман патшасы булып Г. Рәхим үзе киенгән һәм спектакль яшүсмерләргә искиткеч көчле тәэсир иткән.

Шулай итеп, унынчы еллар башында Г. Рәхим иҗат эшенә чума. 1913 елдан башлап ул даими рәвештә «Ак юл» журналына язышa. Бу журналда аның халык иҗатына нигезләнгән әкият-хикәяләре басылып чыга. Күпчелек хикәяләрендә Г. Рәхим авыл табигатенең матурлыгын җырлый, тереклек дөньясының гармониясен матур картиналар аша бирә. Г. Рәхимнең бу чордагы хикәяләре өчен бернәрсә хас: яшь язучы табигать белән кеше арасында гармония табарга тырыша. Бу омтылыш анда шул кадәр көчле ки, автор образлар тудырганда рационализм методы белән эш итә. Үсеп килә торган капиталистик укладның крестьян тормышын ничек җимергәненә тырышып-тырышып күзен йомган хәлдә, Г. Рәхим «Габдерәшит бабай»ны иҗат итә. Ул бөтен күңеле белән патриархаль крестьян хуҗалыгының идиллиясен эзли, шул шартларда гармоник шәхесне тасвирлый. Бу хикәя Г. Рәхимнең әле XIX йөз әдәби эстетик принциплары коллыгында икәнлеген дә күрсәтә.

Прозаик буларак, ихтимал, Г. Рәхим халык әдәбияты сюжетларына корылган хикәяләре белән танылгандыр. Алар унынчы-егерменче еллар тирәсендә мәктәп балалары арасында иң популяр әсәрләр булган. Мәсәлән, «Үги кыз», «Гөлчәчәк», «Камыр батыр», «Алдар таз», «Алты аяклы айгыр» кебек әкиятләр беренче тапкыр Г. Рәхим тарафыннан балалар өчен эшкәртелеп хикәя формасында бирелгәннәр. Соңыннан беренче баскыч совет мәктәпләре өчен чыгарылган «Балалар күңеле» сериясе буенча бу әкият-хикәяләр аерым китаплар итеп басылалар.

Г. Рәхим — драматургия өлкәсендә дә каләм сынап караган кеше. Революциягә кадәр татар театрында аның «Дача кайгысы» исемле комедиясе бара. Алдына куйган проблемасы бик үк яңа булмаса да (яңача күренергә теләгән татар бае белән аның мещан хатыны арасындагы каршылыклар), Г. Рәхим җиңел генә телдә, тәзек сюжетлы пьеса тудыра алган. «Йолдыз» газетасы аның бу пьесасына уңай бәя бирә. «Ул — чын-чыннан әдәби әсәр,— дип яза газета.— Анда фәлсәфә сату, фикер сөйләү катгыян юк. Тормыш — менә «Дача кайгысы»ның күрсәтергә тырышкан ягы. Бу әсәрдә тормыш дөрес алынган. Шулай булмый да хәле юк, аның мөхәррире шул сыйныфтан чыккан. Мөхәррир хәкыйкатән шул мөхиттә үскән. Ул аны сүкми, орышмый, бары күрсәтә:— Мә, ди ул, караңыз, менә сезгә бу тыштан гына ялган Аурупа мәдәнияте кергән буржуа татар тормышы!» [1]

Г. Рәхимнең Октябрь революциясенә кадәрге хезмәтләреннән тагын бер тармагы — әдәби тәнкыйть һәм әдәбият теориясе. Әдәби тәнкыйть өлкәсендә аның хезмәтләре әллә ни күп түгел. Арадан әһәмиятлесе — «Тукаев — халык шагыйре» дигән мәкаләсе.

«Аң» журналының 1924 елгы саннарында Г. Рәхимнең «Халык әдәбиятымызга бер караш» дигән зур тикшеренүе басыла. Кайбер кимчелекләре булуга карамастан, монда яшь галимнең халык әдәбиятына мөнәсәбәттә Тукай мәктәбе шәкерте һәм әдәбиятта гомумән халыкчанлык тарафдары икәнлеге ачык күренә. Ислам дине хаким сыйныфларның идеологик коралы булган бер заманда Г. Рәхим халык әдәбиятына ислам дине салган зарар турында буржуаз матбугатта кыю рәвештә әйтеп чыга. Борынгы мәҗүсилек заманындагы халык әдәбияты үрнәкләрен табуның бик кыенлыгын ул болай аңлата: «Музыка вә җырлар шикелле һәр төрле күңел ачуларга каршы булган ислам дине татар җырларын да кыскан, аларны җырлауны да нәмәшруг (шәригатьтә булмаган — М. М.) дәрәҗәсенә төшереп, татар җырларының начарлануына иң зур сәбәпләрдән булган» [2]. Бу — заманы өчен бик кыю адым була. Аннан соң Г. Рәхимнең бу тикшеренүендә цивилизация үсү белән халык әдәбиятының урынын язма әдәбият ала дигән фикере дә бөтенләй үк нигезсез булмаса кирәк.

Кыскасы, Г. Рәхим әдәбият өлкәсендәге теоретик хезмәтләрендә, әлегә материалистик фәлсәфәне үзләштереп бетермәгән хәлдә, халыкчанлыкны яклаучы буларак формалаша.

---

[1] «Йолдыз», 1914, 1108 сан.
[2] Аң», 1914, 16—17 сан.

1917 ел Февраль революциясеннән соң үзен теге яки бу сыйныф белән бәйләмәгән яшь татар интеллигенты өчен катлаулы чор башлана. Монархияне бәреп төшергәнгә шатлану гына җитми, алдагы көн өчен конкрет кыйблаңны билгеләргә кирәк иде. Эзләнү, яктылыкка, тагын да зуррак хөрриятка өмет, дәртләнү Г. Рәхимгә дә хас була. Тәҗрибәсезлеге аны «Корылтай» газетасына алып килә. 1917 елның 7 июль санында басылган «Сәнгать вә әдәбият» дигән мәкаләсендә Г. Рәхим язучының, шагыйрьнең бөтен язмышы революция белән бәйле, революция үзе поэзияне уята, үстерә торган күренеш икәнлеген кыю рәвештә әйтә. «Инкыйляб заманы — аз гына сизгер булган кешене шагыйрь ясый. Инкыйляб вакытында гакыллар, фикерләр җитезрәк эшли, хыял, зиһен кайный... Фитрәт заманында күгәреп басылып яткан сәнаигы нәфисә абелхәят белән сугарылган иреклек һавасында җанлана, хәрәкәтләнә, аякка баса» [1],— ди ул.

*

* *

Г. Рәхим Бөек Октябрь революциясе көннәрендә хезмәт халкын яклап сыйныфлар көрәшенә ташланган язучы түгел. «Г. Р.» инициалы белән «Корылтай»да басылган мәкалә әгәр аныкы булса, Совет властеның беренче айларында ул әле сәнгатьнең демократлашуына тискәре мөнәсәбәт булган. Шул позиция аны: «Демократлашкан сәнгать, шөбһәсез, чын сәнгать булудан чыга. Аның кыйммәте югала» [2],— дип язуга китергән. Ләкин корылтайчы, милли шурачыларның хезмәт халкына карата кулланган политикасы яшь әдипне тиз айныта. «Элек битарафта торган интеллигентлар ачыктаначык совет ягын сайладылар» [3],— дип яза Х. Госман Г. Гобәйдуллин, Г. Рәхим кебек авторларны да күздә тотып. Бу турыда заманында Ф. Бурнаш та язып чыккан иде. Ул болай ди: «Гали Рәхим һәм Г. Газиз (Газиз Гобәйдуллин)ләр Октябрь революциясенең баштагы елларында да Октябрьга каршы тартыну күрсәтмичә, аның идеологиясен кабул иттеләр һәм һәр икесе әдәби хезмәттән бигрәк гыйльми эшләргә бирелеп киттеләр» [4]. Әдәбият белгечләреннән А. Яхин тапкан мәгълүматларга караганда, Г. Рәхим бу елларда Хәрби коллегия кушуы буенча русчадан драма әсәрләре тәрҗемә иткән [5].

Дөрес, язучы буларак, Г. Рәхим революцион әсәрләр иҗат итүгә кадәр күтәрелә алмады. Аңа өлешчә «саф сәнгать» шаукымы зарарлы йогынты ясады. Бу бигрәк тә аның шигырьләрендә сизелде. Ләкин шагыйрь буларак Г. Рәхим катлаулы эзләнү чорын кичерде. Ул кыю рәвештә Көнчыгыш шагыйрьләрен тәрҗемә итәргә керешә, укучыларга аларның бөек гуманистик идеяләрен, дөньяви фикерләрен җиткерергә тырыша. Һәм Г. Рәхим инициативасы белән татар әдәбияты тарихында беренче буларак Хафиз, Җ. Руми, Г. Хәйям, Сәгъди, Тагор әсәрләреннән торган китап дөньяга чыга [6]. Г. Рәхим тәрҗемәләренә нигезләнеп «Кызыл дәфтәр» журналы «Рабиндранат Тагорның капиталистлар дөньясына карашы» дигән мәкалә дә бирде [7].

Г. Рәхимнең унсигезенче-егерменче еллардагы иҗаты аеруча күп кырлы һәм үзенчәлекле. Бу чорда ул Ибсенның «Гыйшык комедиясе» дигән пьесасыннан яшьләр хорын тәрҗемә итә (татар шагыйрьләреннән аңа кадәр дә, аннан соң да Ибсенны тәрҗемә иткән кеше әлегә юк). Ни өчен Г. Рәхим нәкъ менә Ибсеннан һәм шул бер җырны гына тәрҗемә иткән? Бәлки аның эчтәлеге шагыйрьнең фикер һәм хисләре эволюциясенә туры килгәндер? Моны кистереп әйтүе кыен, әлбәттә.

**Ыргытып бәрдем суга мин баштагы акылым йөген,**
**Бәлки инде ташка бәрелеп парчаланыр бу кораб;**
**Һич үкенмим, әйдә, бетсен: мин йөземен бит бүген —**
**Күкрәгем киргән килеш тик, мин барам алга карап.**

---

[1] «Корылтай», 1917, 2 сан (7 июль).
[2] «Корылтай», 1918, 1 январь саны.
[3] Х. Госман. Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чорында татар поэзиясе. Казан, 1960, 113 бит.
[4] Ф. Бурнаш. Инкыйляб һәм татар әдәбияты. «Мәгариф вә укытучы» журналы, Ташкент, 1929, 1 сан.
[5] Бу турыда: «Совет әдәбияты», 1959, 10 сан, 118 бит.
[6] Иран шагыйрьләре. 1919, Казан. Төзүче һәм тәрҗемәче Г. Рәхим.
[7] «Кызыл дәфтәр», 1921, 1 сан.

Тәнкыйтьчеләр хаксыз түгел: шагыйрь социалистик революциянең ялкынлы җырчысы була алмаган. Менә вакытлы матбугат сәхифәләрендә аның «Сонет»ы басылып чыга.

**Утырып урманның аузында төнләдем мин,**
**Бу моң төнне сандугачтан көнләдем мин;**
**Гаҗәеп, бу матур төндә әле дә ничек**
**Тулылыгыннан бәхтемнең үлмәдем мин![1]**

«Канәфер» дигән шигырендә дә шагыйрь әле мәхәббәт колы, романтик шәхес булып күренә.

**Күзем салдым нечкә пәрдә аркылы**
**Көлгән аваз килгән шул якка,**
**Әллә нишләп сине канәфергә**
**Тиңләтәсем килде шул чакта.**

**[1918]**

«Бер шагыйрьнең өйләнүе» дигән романтик хикәясендә («Шәрык кызы», 1918, 5 сан) ул үз хисләре эченә баткан романтик шәхесне бирде. Монда берниндәи вакыйга юк. Хикәя бары тик шагыйрьнең хыяллары, аның хисләренең суынуы турындагы эмоциональ истәлек формасында. Шул ук мотивлар аның «Кичке җыр» дигән шигырендә дә яңгырады.

**Айлы төннәрдә**
**Төн моң, төн боек,**
**Серле күлләрдә**
**Йоклый төнбоек...**

**[1922]**

Шагыйрь яңа әдәбиятка хиссият колы, демоник шәхес буларак атлый. Аның талантлы гына язылган лирик шигырьләре Ф. Бурнаш тарафыннан төзелгән «Керәш җырлары» җыентыгына кертеләләр.

Шәхес азатлыгы проблемасын үзенчә чишәргә омтылу аның драматургия өлкәсендәге эшчәнлегендә дә сизелә. 1919 елда Г. Рәхимнең «Җанвар» исемле ике пәрдәлек пьесасы аерым китап булып басылып чыга. Җанвар — реаль тормыштан аерылган, матурлыкка табынучы шәхес. Ул мәхәббәт иреге, шәхес иреге тарафдары. Автор төп геройдан татар тормышындагы искелек калдыкларын тәнкыйть иттерә һәм ул иҗтимагый тормыштан аерылган булуы аркасында иллюстратив, рациональ бер образга әйләнә.

Реаль тормыштан аерылган романтик шәхес Г. Рәхимнең «Идел» хикәясендә дә күренде. Аның үзегендә язучыны гомер буе борчыган проблема — җәмгыятьтә шәхеснең урыны мәсьәләсе. «Идел» әдәбият дөньясында күп тәнкыйтьләнде. Г. Рәхимнең бу әсәре «Иске милли язучының белә торып кирле-морлы язуы»[2] дип бәяләнде. Хикәя Г. Нигъмәти тарафыннан да каты тәнкыйтькә очрады[3]. С. Җәләл дә әсәрнең бераз төчерәк тонда һәм реализмнан ерак икәнлеген күрсәтеп узды. «Дөнья дигәннәре — ул коры гыйшык җырлары белән мәхәббәт җырларыннан гына гыйбарәт түгел»[4],— дип язды ул.

Әсәрнең төп герое — журналист Ильяс шәһәр, тормыш шау-шуыннан туеп, ялгызлыкка омтыла. Ул дачада тора башлый. Табигать эченә чума, рухи гармониягә ирешә. Ләкин бераздан морза кызы Рабига һәм аның сеңелесе Әминә белән таныша. Рабига белән алар арасында роман башлана һәм шәхес ирегенә шуның белән нокта куела. Бераздан Ильяс яшь кыз Әминә артыннан йөри башлый һәм Рабиганы газаплаудан ләззәтләнә. Бу инде бераз гына Печоринны хәтерләтә. Ләкин Печорин ихтыяр көче булган усал шәхес. Ильяс исә — меланхолик. Аның ихтыяр көче бик зәгыйфь. Менә көз җитә, дачалар бушап кала, империалистик сугыш кабына. Ильяста шәхес бунты башлана. Ул әдәбиятның, мәхәббәтнең тормыштагы роле турында уйлана. Халыкны көчләп мәгънәсез сугышка кууларына рухи протест белдерә. Анда

[1] «Сөембикә», 1918, 2 сан.
[2] Г. Толымбайский. Китапларны ничек нәшер итмәскә? «Татарстан», 1923, 205 сан.
[3] Г. Нигъмәти. Октябрь һәм әдәбият. «Кызыл шәрык», 1922, 1 сан.
[4] С. Җәләл. «Ярдәм» мәҗмугасы. «Татарстан хәбәрләре», 1922, 30 сан.

жирне, аның тормышын кызгану хисләре уяна. Кыскасы, Ильяс — Октябрь революциясе алдыннан татар әдәбиятында очраган күп геройларның берсе. Ул яктан караганда, бу романтик әсәрнең дөньяга чыгуы бик табигый хәл. Ләкин әсәр, инде революция булып, илебез эчендә сыйнфый көрәш барган чорда дөньяга чыкты. Бу чор татар әдәбиятының нигезләрен Г. Ибраһимов болай билгеләгән иде: «Хезмәт, көрәш моментлары, иҗтимагый коллективларның кузгалышлары, бәрелешләре — боларның (әдәби әсәрләрнең — М. М.) икътисади тамырлары». Шуңа күрә Г. Ибраһимов та Ильясны «череп» таркалган бер буржуаз интеллигент»[1] дип бәяләде. «Идел» — Г. Рәхимнең прозада соңгы әсәре булды һәм шуннан соң ул бөтенләе белән әдәбият, сәнгать тарихына чумды. Әмма шуны искәртеп узу әһәмиятле, Г. Рәхим соңрак «Идел»не үзе үк «иске дәвер рухындагы әсәр» дип атады. Рәхимнең татар сәнгатендә калдырган иң кыйммәтле мирасларыннан берсе, мөгаен, «Кәккүк» җырыдыр. «Кәккүк»нең көе С. Габәши тарафыннан Г. Рәхим текстына язылган һәм беренче тапкыр бу җыр аның квартирасында яңгыраган. Татарстан радиосыннан Г. Рәхим тексты буенча «Кәккүк» егерменче еллар ахырында еш яңгырый. Җырның тексты болай:

**Карлар китте, су килде, яз җитте,**
**Җир яшәрде, далалар чәчәкле.**
**Таң алдыннан төрле кошлар**
**Моңая, сайрый.**
**Йөрәккәем ник әрни ул,**
**Нишләп җилкенә икән лә, һай-һай.**
**Тыңлап кара,**
**Кара урман күкесе,**
**Кошларның моңлысы,**
**Кемнәрнең кайгылы бәндәсе.**
**Иртә белән дә һаман,**
**Кичләрен дә һаман,**
**Төннәрен дә шулай**
**Йокламый, моңая, саргая.**
**Ул да шул, мескенкәй,**
**Хәсрәтле бәндәкәй**
**Гамь чигә минемдәй.**
**Ерактан авазы яңгырый.**
**Моңлы бала түгел идем,**
**Миңа ниләр булды икән!**
**Моңаям, саргаям, мин көям.**
**Һай, йөрәгем яна...**
**Син кай җирдә, йолдызым,**
**Кай җирләрдә ялгызың,**
**Кәккүк, кәккүк,**
**Мин саргаймый, кем саргайсын —**
**Юк янымда йолдызым**[2]**.**

Инде Г. Рәхим эшчәнлегенең иң әһәмиятле өлешенә — тәнкыйть һәм әдәбият тарихы өлкәсенә күчик. Аның Көнбатыш әдәбияты, классика белән таныш булуы, яшьтән үк Гете балладаларын, Ибсен әсәрләрен тәрҗемә итүе, Шекспир үрнәгендә сонетлар иҗат итүе турында язган идек. Яшь пролетариат әдәбияты вәкилләре өчен бу бик кыйммәтле сыйфат була һәм моның чагылышын без Г. Рәхимнең тәнкыйть мәкаләләрендә дә күрәбез. Мәсәлән, 1921 елда «Отелло»ның татар театрында куелуы уңае белән ул Шекспир әсәрләренең дөньякүләм тарихи әһәмияте турында язып чыга. Тәнкыйтьче фикеренчә, Шекспир әсәрләренең озын гомерле булуы «аларның бөтен инсаният галәме өчен уртак булган кеше психологиясен тәшрих итүче (кешенең рухи галәмен ярып күрсәтүче — М. М.) әсәрләр булуындадыр»[3].

[1] Г. Ибраһимов. Татар әдәбияты. «Татарстан», 1924, 1 сан.
[2] Бу җырның текстын Г. Әлмөхәммәтов архивыннан музыка белгече З. Хәйруллина күчереп алган. Текст З. Хәйруллинаның рөхсәте белән мәкаләгә кертелде.
[3] Татарстан хәбәрләре, 1921, 85 сан.

Пролетариат әдәбиятының формалашуы чорында урта гасырлар әдәбияты (Сервантес, Шекспир һ. б.) пролетариатка азык була аламы, дигән сорау бик еш куела иде һәм татар тәнкыйтьчеләре бу мәсьәләгә мөнәсәбәттә төрле позицияләрдә тордылар. Күргәнебезчә, Г. Рәхим бу уңайдан, нигездә, марксистик позициядә тора.

Г. Тукайның үлүенә 10 ел тулуны билгеләгән вакытта Тукай «татар телендәге балалар әдәбиятына... нигез салучы» дип кыю рәвештә матбугатта чыгучы да Г. Рәхим булды. «Тукай,— диде ул,— бер яктан, татар шигыренең атасы булса, икенче яктан, шөбһәсез, татар телендәге балаларга махсус әдәбиятны да башлап тудыручыларыннан хисапланырга тиеш»[1]. Г. Тукай мирасының вульгар социологизм елларында нинди катлаулы бәхәсләр, каршылыклар тудыруы яхшы мәгълүм. Г. Рәхим исә, әнә шул катлаулы атмосферада Тукай мирасын, аның халыкчан иҗатын яклаучы һәм пропагандалаучыларның берсе була.

Татар халкының, әдәбиятның тарихын яхшы белгән галим үзенең тәнкыйть мәкаләләрендә әдәбиятны иҗтимагый процесстан аерып карауның ялгыш икәнлеген һәрвакыт әйтеп килде. «Әдәбият кешеләрнең иҗтимагый тормышыннан килеп чыккан бер килеш булганга,— дип язды ул,— аны тарих агымына салып тикшергәндә, шул иҗтимагый тормыш ягыннан торып карамый мөмкин түгел[2]. Ләкин егерменче утызынчы еллар тәнкыйтьчеләре (Г. Сәгъди, Ф. Сәйфи-Казанлы, Г. Толымбайский) иҗтимагый формациянең гади өскормасы гына дип бәяләп, әдәбиятның үзенчәлеген искә алмыйлар иде. Моның өчен аларга марксизмның сәнгать теориясен ныклап өйрәнергә кирәк иде. Г. Рәхим исә нәкъ менә шуңа игътибар юнәлтә. Әдәбият-сәнгать тәнкыйтьчеләрен кисәтеп ул болай ди: «Әдәбият тарихын өйрәнү анда гакес ителгән (чагылдырылган — М. М.) фикер вә идеология тарихын гына өйрәнүдән гыйбарәт икән дип уйланмасын. Әдәбиятның бу ягын өйрәнү аны эстетика (нәфасәт) һәм форма ягыннан өйрәнүне читтә калдырмый, ул һәр ике яктан өйрәнелергә тиеш». Бу фикер заманына күрә бик кирәкле иде һәм шул ук вакытта ул Г. Рәхимнең әдәбиятчы буларак алга таба үсешен дә күрсәтте. Әдәбият турында нәрсә генә язмасын, ул һәр вакытта да югары сәнгатьлелек өчен көрәш алып барды, поэзиядә үгет-нәсихәтчелекне тәнкыйть итте. Татар совет шагыйрьләренең «Көрәш җырлары»на кертелгән шигырьләре турында ул: «Татар шигыренең соңгы елларда никадәр алга атлаганын ничаклы яңа гүзәлләкләр кәшеф иткәнен күрү зур бер ифтихар вә канәгатьлек хисе уятадыр»,— дип язды[3].

Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» әсәре иң беренче тапкыр Г. Рәхим тарафыннан югары бәя алды. Тәнкыйтьче бу әсәрнең «турыдан-туры тенденция вә агитациягә бирелмәстән, тыныч этика тонында тасвир» ителүен хуплады, «хикәя... гаҗәп көчле, җанлы бер әйбер булып чыккан»,— дип язды[4].

Кайбер каршылыклы фикерләре булуга карамастан, Г. Рәхимнең «Нәләтләр шагыйре» исемле мәкаләсе дә тәнкыйть тарихында зур игътибарга лаек. Ихтимал, Такташ иҗатына гомуми бәя бирү юлында бу иң беренче зур тикшеренүдер. Г. Рәхим бу мәкаләдә яңа күтәрелеп килгән яшь Такташта зур талант барлыгын күрсәтә. Ул аны «татар әдәбияты күгендә кинәт яктырып яна башлаган яңа йолдыз» дип атады. «Хәзер бездә булган революция вә дингә каршы көрәш һавасында Такташка үзенең каләмен һичбер киртә белән чикләмәскә мөмкин булды»[5],— дип язды ул. Шуңарга да игътибар итик, мәкалә әдәбият мәйданындагы группачыларның Такташка төрлечә гаепләр ыргытып мавыккан чорында язылды. Әнә шуңа күрә дә аның бу мәкаләсе ул чорда имажинист булган К. Нәҗми һәм башкалар тарафыннан кире кагылды.

Бездә бик аз өйрәнелгән өлкәләрнең берсе — татар сәнгате тарихы. Әгәр беренче татар опералары турында тикшеренү алып барсак, без, һичшиксез, бу өлкәдә Г. Рәхим эшчәнлеге белән очрашыр идек. Мәгълүм булганча, татарның беренче опералары «Сания» һәм «Эшче» үз чорында матбугатта зур шау-шу уятканнар. «Сания» операсы турында Берлин, Рим журналларында уңай рецензияләр күренә, татар сәхнәсенең беренче казанышы турындагы хәбәр Америка, Япония

---

[1] Г. Рәхим. Тукай һәм балалар әдәбияты. «Мәгариф», 1923, 3—4 саннар.
[2] Г. Рәхим. Урта мәктәпләрдә әдәбият укыту турында. «Мәгариф», 1924, 5 сан.
[3] «Безнең байрак» газетасы, 1923, 15 сан.
[4] «Безнең юл», 1925, 5 сан.
[5] «Безнең юл», 1923, 10—11 саннар.

газеталарында басыла[1]. «Сания» операсын татар сәхнәсенә чыгаруда составында Г. Рәхим дә булган Гыйльми үзәкнең редакцион коллегиясе күп эш башкара. Гыйльми үзәк опера авторларына эшләү өчен уңай шартлар тудыру буенча махсус карар да кабул итә. 1927 елда Г. Рәхим үзе дә «Бүзьегет» исемендә опера либреттосы яза башлый. Матбугаттагы хәбәрләргә караганда, операда «саф мәхәббәт калыбында гына калмыйча, иҗтимагый нигезнең көчле итеп алынуына игътибар ителәчәк» булган[2]. Кызганычка каршы, бу опера дөньяга чыга алмый кала.

1927 елда Г. Рәхим Бөтенроссия культура мөнәсәбәтләре җәмгыятенең (ВОКС) соравы буенча рус телендә «Татарстан республикасында сәнгать» дигән мәкалә яза. Бу мәкаләдә ул татар музыкасының үзенчәлеге, татар театрының кыскача тарихы турында мәгълүматлар бирә. Ф. Бурнаш һәм К. Тинчурин кебек сәнгать осталарын «революцион настроениеле яшь көчләр» дип атый[3]. Ул шунда ук М. Парсин, К. Тинчурин, З. Солтанов, Ф. Бурнаш, К. Әмирилар белән берлектә Гыйльми үзәкнең театр комиссиясендә дә эшли[4].

Г. Рәхимнең «Эшче» операсы турында матбугатта махсус мәкалә белән чыгуы да игътибарга лаеклы. Анда ул «Эшче»нең «Сания» операсына караганда эшләнеше ягыннан югары икәнлеген күрсәтә. Музыкасының да, милли рамкаларда гына калмыйча, «интернациональ музыкага таба зур адым» ясаганлыгын әйтә. «Эшчеләр арасында көрәш настроениеләренең үсүен күрсәтүдә моментлар булганы шикелле, милли халык музыкасы да крестьян авылы тормышын, кайгы моментларын, изелү тойгыларын бирү юлында гаҗәп уңышлы кулланылган. Менә бу якны композиторларның зур уңышларыннан санарга кирәк»,— дип яза тәнкыйтьче. Г. Рәхим беренче буларак операның җитди кимчелекләрен дә күрсәтте. Алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1. Операда бөтен бер вакыйга әсәр буенча кызыл җеп булып сузылып барырга тиеш. «Эшче»дә исә бу принцип сакланмый һәм шуңа күрә аның драматизмына зарар килә.

2. Операда төп герой алгы планда торырга тиеш. Ләкин Нигъмәт алай бирелмәгән. Ул гел бер лейтмотивка гына җырлый. Изелгән крестьян вакытында «аның җырында нинди изелү һәм өметсезлек аһәңнәре яңгыраса, революция көрәшендә үлгән вакытында да аның авызында шул ук көй яңгырый. Менә бу инде иске мәндәриҗә белән музыканың бәйләнмәвен күрсәтә».

3. Әсәрдә Нигъмәт губернаторны атып үтерә, индивидуаль террорист булып күренә иде. Режиссер моны алып ташлап дөрес эшләгән. Чөнки «большевизмның революция тактикасына әсасән каршы булган бер көрәш юлының героизм дәрәҗәсенә мөнгерелеп күрсәтелүе революцион пролетариат идеологиясенә каршы булган, әсәрлек йогынтысын чагылдыра торган бер момент иде».

4. Шулай да операда Нигъмәт әле пассив рәвештә үтерелә. Аны алгы планга чыгарырга, кулына корал тоттырып баррикадалар көрәшендә корбан итәргә кирәк иде. «Ул вакытта тәэсир әллә ничә мәртәбә көчәер..., көрәшче революцион пролетариатның роле алгы сафка чыгарылган һәм идеологиясе дә кирәгенчә җанландырылган булыр иде»[5]. Әлеге мәкалә һәм аннан китерелгән өзекләр, безгә калса, Г. Рәхимнең марксизмны эзлекле рәвештә үзләштереп килгән сәнгатькяр икәнлеген раслыйлар.

Егерменче елларның урталарында татар сәнгате кинематограф белән тыгыз бәйләнештә була. Бу елларда Казанда «Койрыклы йолдыз» һәм «Булат батыр» исемле кинофильмнар эшләнә. 1925 елның 25 октябрендә Гыйльми үзәкнең татар редакция коллегиясе утырышында татар фильмы мәсьәләсе карала. Киңәшмәдә татар тормышы турындагы фильмның нигезенә 1905—1917 еллгы вакыйгаларны алырга дигән уртак фикергә килена һәм Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романы сайлап алына. Бу роман буенча сценарий эшләү Г. Рәхимгә тапшырыла[6]. Безгә билгесез сәбәпләр буенча бу фильм эшләнмичә кала.

---

[1] Кара: «Мәгариф», 1927, 2 сан, 106 бит.
[2] Шунда ук.
[3] Советский Союз. Спец. выпуск инф. бюлл. ВОКС, 1927, 23—25 саннар.
[4] ТАССР ҮА, 147 эш, 4 док.
[5] «Яңалиф», 1930, 3 сан.
[6] ТАССР ҮА, 147 эш, 4 док.

*
* *

Гали Рәхим яшьли тарих белән кызыксына. Тарих, борынгы кабер ташы язмалары, кульязмалар белән кызыксыну җирлегендә ул тарихчы, әдәбиятчы, язучы Газиз Гобәйдуллин (Г. Газиз) белән якынлаша. Октябрь революциясенең беренче көннәреннән соң ук бу ике галим борынгы татар әдәбияты буенча беренче кулланмалар язу эшенә керешәләр. 1921—1923 нче елларда әлеге кулланмалар өч бүлектә аерым-аерым китап булып басылып чыгалар. Егерменче еллар матбугаты Г. Газиз һәм Г. Рәхимнең ул хезмәтләре турында күп шаулады, күп төрле фикерләр әйтелде. Бу хезмәтләргә тулы бәя бирү тарихчылар эше. Әлбәттә, аларның методологиясендә хаталар бар иде һәм бу хаталар үз вакытында ук күрсәтелделәр дә. Бу хезмәтләр уңаена язылган тәнкыйтьтендә Г. Ибраһимов авторларның кимчелекләрен ачу белән генә чикләнмичә, аларның уңай якларына да игътибар итте. Заманында без төрекме, татармы дигән сорау бар иде, дип язды Г. Ибраһимов, без төрек дияючеләр әдәбият тарихын Алтайдан, Урхоннан башламакчылар иде. «Язучыларның бер дөрес эшләре шул булган ки, болар андый хыяллардан ваз кичеп, тик «татар әдәбияты» мәфһүменең реаль мөндәриҗәсен генә нигез итеп алганнар». Шул ук вакытта Г. Ибраһимов әлеге хезмәтләрдә марксизм теориясе тиешенчә кулланылмаганлыкны күрсәтә һәм киләчәктә «бу мәүзугны чын бер марксист-коммунист эшләп чыгарга тиешледер»[1],— диде. Г. Ибраһимов билгеләп үткәнчә, Г. Газиз һәм Г. Рәхим борынгы татар әдәбияты буенча таркау материалларны бергә туплап китапка кертүләре белән киләчәк буын әдәбиятчылары өчен кыйммәтле мирас калдырдылар.

Г. Рәхимнең әдәбият, культура тарихы буенча язылган мәкаләләрен аерым-аерым бәяләү түгел, санап чыгуы да кыен. Бу өлкәдә аның иң нәтиҗәле хезмәте Гыйльми үзәктә эшләгән чорга туры килә. Марксизмны үзләштереп үсеп килүче галим 1925 елда болай дип яза: «Тарихи материализм карашында тора торган тарихчы өчен сәнгать... күктән төшкән бер нәрсә түгел... Аның тарихын аңлар өчен безгә халыкның иҗтимагый тарихы белән танышырга кирәк[2]. Ихтимал, Г. Рәхим мирасының иң әһәмиятле тармагы аерым шәхесләрнең биографияләредер. Бу яктан караганда ул тарихчы Риза Фәхретдиновның дәвамчысы булып тора. Татар язучыларының, культура әһелләренең тормыш юлын, аерым чыганакларны өйрәнүдә Г. Рәхим ару-талуны белмәс галим иде. Ул күрсәтеп калдырган чыганаклар буенча без бүгенге көндә XIX йөз әдәбиятын тулырак, киңрәк беләбез. Мәсәлән, К. Насыйриның беренче тапкыр тулы биографиясен язучы Г. Рәхим булды. Биография язудан тыш ул К. Насыйриның кульязмаларын юллады, аларның адресларын матбугатта күрсәтеп чыкты[3]. Гомумән, К. Насыйри мирасын бүгенге хәлдә күрүебез белән без иң элек Г. Рәхимгә бурычлы. 1926 елда Г. Рәхим кулына К. Насыйриның бер өлеш язмалары килеп керә һәм шул материаллар нигезендә ул «Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре һәм йөзьеллык бәйрәме материаллары» дигән китап чыгара. 1925 елның 15 февралендә Татар театрында К. Насыйриның тууына 100 ел тулу уңае белән зур җыелыш ясала. Анда Г. Ибраһимов, Ш. Әхмәдиев, М. Корбангалиев белән бәрләктә Г. Рәхим «Насыйриның гыйльми-фәнни хезмәтләре» дигән темага доклад ясый.

Егерменче еллар урталарында Гыйльми үзәк үз кулында бик күп функцияләрне туплаган оешма була. Нәшрият, әдәбият, сәнгать, театр мәсьәләләре барысы да Гыйльми үзәк карамагында булалар. Гыйльми үзәк бу елларда «Татар әдәбияты китапханәсе» дигән серия белән бик күп китаплар бастыра. Аларны басарга әзерләү, рецензияләү, сүз башы язу һ. б. эшләрнең байтагын Г. Рәхим башкара. Мәсәлән, Муса Акъегетнең «Хисаметдин менла» повесте, Г. Камалның сайланма әсәрләре шушы серия белән Г. Рәхим тарафыннан дөньяга чыгарылалар. Ул Г. Камал иҗаты турында беренче тапкыр зур күләмле сүз башы яза. XIX йөз мәгърифәтчесе Г. Ильясиның биографиясе 1930 елга кадәр бөтенләй билгесез иде. Г. Рәхим аның турында да бик күп материал туплый һәм нәтиҗәдә Г. Ильясиның беренче тапкыр биогра-

[1] Г. Ибраһимов. Татар әдәбияты тарихына материаллар. «Татарстан», 1923, 28 сан.
[2] «Мәгариф», 1925, 1—2 саннар.
[3] «Безнең юл», 1922, 4 сан.

фиясе языла[1]. Әхмәт Уразаев Курмашиның тормыш юлын белүебез белән дә без Г. Рәхимгә бурычлы.

Шул ук елларда Г. Рәхим татарда матбагачылык тарихы буенча киң күләмдә тикшеренү эше алып бара. 1925 елда Татарстан республикасы төзелүгә биш ел тулу датасы билгеләнә. Юбилей хөрмәтенә Татарстан китап нәшрияты «Биш ел эчендә» дигән зур күләмле китап чыгара. Анда Г. Рәхимнең «Биш ел эчендә татар әдәбияты» дигән киң пландагы тикшеренүе басылган. Автор Октябрь революциясеннән соң татарларда китап бастыру эшенең (политик, иҗтимагый һәм матур әдәбият) торышына тирән анализ биреп мондый нәтиҗә ясый: «Ленин әсәрләре мәҗмугаларын нәшер итү белән дә безнең Татарстан әле моңарчы һичбер шәрыкъ җөмһүрияте тотына алмаган җаваплы бер эшкә керешеп, мөһим бер башлангыч ясады»[2].

Соңгы елларда татар телендә Пугачев указларын, хитабнамәләрен өйрәнү эше җайга салынып бара. Заманында татарлар арасында Пугачев хәрәкәте белән профессор Г. Гобәйдуллин кызыксынган иде. Әлеге мәсьәләдә Г. Рәхимнең дә өлеше бар: ул татар телендә Пугачев указларын өйрәнә һәм бу турында матбугатта чыга[3]. Аның 1878 елгы татар крестьяннары восстаниесе турындагы хезмәте дә тарихчылар өчен зур хәзинә. Г. Рәхим 1927 елда Олы Мәңгәр авылына барып, бу восстаниедә катнашкан бердәнбер исән кешедән сөйләтеп кала. Бу кеше (Шаһиәхмәт Мөхәммәдиев) үзенең көндәлек вакыйгалар язып барган кульъязмасын Г. Рәхимгә бирә («Мирьат-эл-вакыйгать»). Ш. Мөхәммәдиев аңа граф Скарятинның авылга килүен һәм татар картларын үз кулы белән җәзалавын бик тәфсилләп сөйләп бирә[4]. Тарихка тагы да эчкәрәк кереп, Г. Рәхим археологиягә әһәмият бирү кирәклеген кайнар рәвештә яклап чыга, Чыпчык, Ашытбаш, Әйшә, Мәңгәр, Байлар Орысы кебек авыллардагы каберлекләрне өйрәнүне оештыручыларның берсе була. Утызынчы елларда, кайбер «новатор»лар үткән заманга борылып карауны гаеп иткән чорда, Г. Рәхим болай дип яза: «Иҗтимагый формацияләр тарихын өйрәнгәндә ерак гасырларга мөнәсәбәттә нәкъ менә археология материал һәм документаль нигез бирә. Моның белән археология бу өлкәдәге идеалистик карашларның җимерелүенә һәм бөтен фәннәр арасында иң марксистик булган социология фәнендә материалистик-марксистик карашның ныгуына ярдәм итә. Шулай булгач, сүз археология фәне гомумән кирәкме яки юкмы икәнлеге турында бармый, ә бары тик аның мәгълүматларын нинди максатларда файдалану, аңа нинди караштан чыгып якын килү турында гына бара ала. Алай булса, археология фәне социалистик төзелеш эшенә «чит» кенә түгел, бәлки аның ярдәмчесенә әйләнә»[5] (русчадан тәрҗемә безнеке — М. М.).

Татар халкын коточкыч рәвештә эксплуатацияләүгә сәбәпче булган лашман хезмәте турындагы тикшеренүе белән дә Г. Рәхим үзен тирән белемле, киң карашлы тарихчы итеп күрсәтте[6]. Аның бу тикшеренүендә лашманчылыкның бөтен тарихы күз алдына бастырыла, шул хезмәттә һәлак булган конкрет кешеләр турындагы бәетләр мисалга китерелә.

Г. Рәхимдә фән кешесе өчен кирәкле булган сыйфатларның иң кирәге — фәнни намуслылык көчле була. Ул һәрвакытта да теге яки бу мәсьәләдә үзеннән элек тикшеренү алып барган әлгәрләрен искә ала, чыганакларны күрсәтә һәм башка галимнәрдән дә фәнни төгәллек таләп итә. «Икенче кулдан» булган чыганакларны берни белән дә аклап булмаслык рәвештә файдалану бик җитди методологик кимчелек[7] — дип язды ул хезмәтләренең берсендә.

«Татарстанны фәнни өйрәнү җәмгыяте» (1923—1929) үз заманында шактый зур файдалы эш эшли. Җәмгыять Мәскәүдәге Бөтенроссия Көнчыгышны өйрәнү ассоциациясе инициативасы белән ачыла. Бу җәмгыятьтә барлыгы 98 член булып, шуның берничәсе почетлы член иделәр (академиклар Покровский, Бартольд, Самойлович, проф. Бороздин). Бу оешма беренче татар совет галимнәренең күренекле

[1] «Безнең юл», 1930, 3—4 саннар.
[2] Биш ел эчендә. Казан, 175 бит.
[3] «Татарстан» журналы, 1929, 5—8 саннар.
[4] Али Рахим. К вопросу о татарском крестьянском движении 1878 г. Журн. «Вестник научн. об-ва татароведения», 1928, № 8.
[5] Али Рахим. Татарские этнографические памятники XVI века. «Труды общества изучения Татарстана», 1930, 1 том.
[6] Г. Рахим. Халык зарларыннан. «Безнең юл», 1929, 3—4 саннар.
[7] «Вестник научного общества татароведения», 1928, № 8.

рус галимнәре белән кулга-кул тотынып фән өйрәнү мәктәбе булды. Монда Г. Ибраһимов, Н. И. Воробьев, Җ. Вәлиди, В. А. Богородицкий, Г. Гобәйдуллин, П. М. Дульский, Н. Ф. Калинин, И. Н. Бороздин, Г. Рәхим, Н. И. Ашмарин, Г. Сәгъди, А. Н. Самойлович, Н. Хәким, Н. Н. Фирсов, Г. Шәрәф һ. б. фәнни докладлар ясадылар. Җәмгыять татар халкының авыз иҗатын, сәнгатен, этнографиясен, эпиграфик истәлекләрен өйрәнү өчен күп санлы экспедицияләр оештырды, Татарстанның археологик картасын төзеде. Берлин, Гамбург, Лондон, Рим, Гельсингфорс университетлары. Харбин, Дерпт, Нью-Йорк китапханәләре белән бәйләнештә торды[1]. Г. Рәхим әнә шундый зур фәнни оешмада даими рәвештә секретарьлык вазифасын башкарды. Татарстан тарихына кагылышлы бик күп материаллар бу чорда Г. Рәхим тарафыннан эшкәртелделәр. 1930 елда аның хәзерге тел галимнәре өчен бик кыйммәтле булган «Моннан йөз ел элек татарча аңлатмалы сүзлек төзү проекты» дигән тикшеренүе матбугатка чыкты. Г. Рәхим монда Казан университетының тел бүлеге деканы Ф. И. Эрдман тарафыннан 1829 елда төзелгән сүзлек проекты турында киң мәгълүмат бирә. Сүзлекләр төзү тарихына тирән экскурс ясаганнан соң, ул мондый нәтиҗәгә килә: «Бары тик Бөек революция генә бүгенге лингвистик фән югарылыгында торырлык тулысынча фәнни нигезләнгән татар теленең аңлатмалы сүзлеген татар галимнәренең үз көчләре белән төзергә һәм Татар Совет Социалистик Республикасының дәүләт культура-мәгариф органнары исәбенә бастырып чыгарырга мөмкинлек ачты. Мөхтәрәм татар галиме лингвист Җ. Вәлиди тарафыннан төзелеп, хәзерге көндә Гыйльми үзәктә бастырылырга хәзерләнгән татар теленең тулы сүзлеге нәкъ менә шундый җитди хезмәт булып исәпләнә»[2]. (Тәрҗемә безнеке.— М. М.).

Болардан тыш Г. Рәхим Татарны өйрәнү җәмгыятендә һәм Гыйльми үзәктә күп санлы докладлар белән чыга, рецензияләр яза, тәрҗемәчелек белән шөгыльләнә. Мәсәлән, Татарны өйрәнү җәмгыятендә ул «М. Корбангалиев эшчәнлегенең 30 еллыгы» дигән доклад ясый, бу доклад соңыннан аерым китап булып басылып чыга. Гыйльми үзәк 1926 ел, 20 май утырышында татар халык иҗатын җыю мәсьәләсен карый. Бу утырышта татар халык иҗатын өйрәнү эше өч юнәлештә булырга тиеш дип билгеләнә: 1. Халык арасыннан язып алу. 2. Җыелган әсәрләрне бастыру. 3. Халык иҗаты буенча теоретик хезмәтләр бастырып чыгару. Татар халык иҗатын туплау, эшкәртү буенча төзелгән комиссиягә М. Корбангалиев, Х. Бәдигый һәм Г. Рәхим кертеләләр[3]. Профессор В. Ф. Смолинның өлкәне өйрәнү буенча кулланмасын татар җирлегенә күчереп эшләүне Гыйльми үзәк Г. Рәхимгә тапшыра. Болардан тыш ул тагын берничә иҗтимагый-политик китап тәрҗемә итә (мәсәлән, Феликс Кон. «9 гыйнвар» һ. б.). 1927 елда аның балалар өчен «Америка нинди җир?» исемендә рәсемле китабы чыга. 1930 елда Авылны өйрәнү» дигән програмга-кулланма китабы басыла һ. б.

*

* *

Гали Рәхим татар совет фәнен үстерүгә күп көч куя. Алда әйткәнебезчә, бер мәкаләдә аның хезмәтләрен санап чыгу да, аларга бәя биреп бетерү дә мөмкин түгел. Әлегә аның әдәби, фәнни мирасы бик таркау ята. Безнең уебызча, бу галимнең совет фәненә иткән файдалы хезмәтен бәяләү, тәкъдир итүдә әле байтак эшлисе бар. Галим мирасының егерменче, утызынчы еллардан килгән авазы безне рухи байлыгыбызга карата игътибарлы булырга чакыра. Чөнки галимнең күп кырлы һәм бай мирасы бүген дә безнең арада, һаман хәрәкәттә.

---

[1] «Вестник научн. общества татароведения», 1930, № 9—10.

[2] А. Рахим. Проект составления толкового словаря татарского языка 100 лет тому назад. Журн. «Вестник научн. общества татароведения», 1930, № 9—10.

[3] ТАССР ҮА, 147 эш, 33 документ.

Тәлгат Галиуллин

# ҖИТМЕШЕНЧЕ ЕЛЛАР АВАЗЫ

## Шигъри өлгергәнлек юлына

Поэзиябезне чорыбызның әхлакый-фәлсәфи проблемалары, яшәешнең төрле аспектлары, ил һәм дөнья мәшәкатьләре, мәңгелек хакыйкатьләр борчый, мәхәббәт һәм яшьлек, табигать яме һәм рухи үлемсезлек, тарих һәм киләчәк кебек сәнгатьнең үзәк проблемалары үзенә тартып тора. Тәнкыйть әледән-әле шигърияттә интеллектуаль башлангычның көчәюе, лирик геройның рухи дөньясы катлаулануы, зиһен хәрәкәтен, фикер эшчәнлеген тулырак ачарга омтылышның үзенә бер тенденция буларак үсеше турында искә төшереп тора. Бу хөкем чыннан да шигъри эзләнүләрнең бер юнәлешен ачып бирә.

Шул ук вакытта чынбарлыкның үзе кебек бай һәм катлаулы шигъри байлыгыбызны бер агымга гына кайтарып калдыру хата булыр иде. Без еш кына поэзиядә фәнни-техник революциянең чагылышын барлау, галәм, йолдызстан, биосфера проблемаларына багышланган шигырьләрне хуплау белән мавыгып, аларда заман рухы чагылышын, яңачалык күреп, башка юнәлешләрдә, айсбергның күзгә бәрелеп тормаган өлешләрендә алып барылган эзләнүләргә игътибар итмибез.

Хәзерге поэзиядә тематика артык әһәмияткә ия түгел дияргә мөмкин. Сүз тематик актуальлекне санга сукмау яисә мәгълүм бер проблемаларга турылыклы калу белгән шагыйрьләр иҗатын кабул итмәү турында бармый. Кеше рухы киңлекләрен, кичереш тирәнлекләрен, «җан диалектикасын», фикер хәрәкәтен ачу максаты белән язылган шигырьләрдә төрле яссылыкта яткан төшенчәләр үзара аралашалар, кушылалар. Мәсәлән, нефтьчеләр, химиклар, машина ясаучылар тормышына, шәһәр ритмын сурәтләүгә багышланган шигырьләрдә «сандугач моңы», «каеннар рәте», «чишмә сафлыгы» кебек образлар табигый яңгыраса, авыл тормышын, игенче хезмәтен олылау нияте белән язылган шигырь-поэмаларга, җырларга галәм, дөнья хәлләре турында фәлсәфи, публицистик уйланулар килеп керә. Шагыйрьләр табигый нәфислек һәм табигать яме белән кеше акылы, кеше зиһене, кеше иҗаты тудырган төшенчәләр арасындагы бердәмлек һәм каршылык хакында фикер йөртәләр. Яшәешнең бер үк проблемаларын төрле образлы рәтләр, бер-берсенә охшамаган борылышлар, төсләр, нәкышьләр белән сурәтләү юллары эзләнелә.

Р. Мингалимовның «Якташлар яныннан» шигырендә «буровой», «трактор», «вертолет» кебек техник прогресс алып килгән образлар «кыз кебек яшь каен», «кояш-ае төлинкә» кебек табигать сурәтләре фонында ачылалар. Шуңадыр, бу шигырьне тематик рамкалар белән чикләве кыен. «Якташлар яныннан»— яңа чынбарлык һәм аны үз куллары белән яңартучы олы язмышлы кешеләр турында сөйли.

З. Насыйбуллин замандашның җыелма образын тудыру, аны үзенчә олылау рухы белән яши. Совет кешесен ул пьедесталга күтәрә, романтик идеаллаштыра, аның характерын иң каты корычтан да югарырак бәяли.

Нидән тора корыч!
Коелган ул
Ышанычтан, якты өметтән,
Кеше аңа изге хыялларын
Ачы тирен кушып эреткән.
Кеше аңа асыл сыйфат биргән...
Шуңа күрә корыч нык.

Яшь шагыйрь Нур Әхмәдиев «Ничек әйтим» дип исемләнгән әсәрендә чордашына гаять югары әхлакый таләпләр куя. Замандашым дияргә лаеклымы син? Совет кешесе характерының асыл сыйфатларына турылыклымы? Лирик герой үзенең яңа кеше турындагы идеалына бәрабәр кешене эзли, үзенең тормыштагы урыны турында җитди уйлана.

Төрле милләт, төрле ләгать кешеләре арасында, аларны аерып торучы сыйфат-билгеләргә караганда, уртаклык, рухи якынлык зуррак икән. Р. Мингалимов тән төсләре, холыклары, яшәү һәм фикерләү рәвешләре төрле булган халыклар арасында уртак өлгеләр, уртак билгеләр таба.

Яшик әле сокланышып,
Сокланырга күпме төс бар;
Күпме илләр, төрле милләт —
Нинди келәм, матур, чуар.

Хәзерге поэзиянең реалистик көче, гуманистик рухы халыклар дуслыгы, тарих һәм заман, кешелекле хис һәм киләчәк турында уйлану рәвешендә язылган шигырьләрдә тулырак ачыла. Аерым алганда шигърияттә тарихилык рухы, халык үткән олы юлны яңача аңларга омтылышның көчәюен билгеләп үтәсе килә. Сүз Х. Туфан, С. Хәким, И. Юзеев, Р. Харис, Р. Гатауллиннарның тарихи шәхесләр эшчәнлеген, батырлыгын, тормыш юлын олылап, шигъри үргә күтәреп сурәтләгән биографик-мемуар әсәрләре турында гына бармый. Бу юнәлеш аерым сөйләшүгә лаек. Поэзиядә гомумән тарихка, үткәнгә игътибар үсте. Халыкның иҗтимагый тарихы белән горурлану, аның аерым баскычларын яңача, бүгенге фәлсәфи-эстетик югарылыктан, XX гасырның икенче яртысы тәҗрибәсе күзлегеннән чыгып бәяләргә омтылыш шагыйрьләрнең фикерләү сәләтләрен баета, хис-тойгыларын зирәкләндерә.

Г. Афзал катлаулы метафоралар, борылмалы-сыгылмалы чагыштырулар, ассоциатив алымнар эзләп тормыйча, «анохронизмда» гаепләүдән курыкмыйча, мәкаль-әйтем, хикмәтле сүз традицияләренә таянып, олы бер хакыйкатьне берничә юлга сыйдыра алган:

Әшәке кешеләр була,
Әшәке халык булмый;
Әшәке тарихчы була,
Әшәке тарих булмый.

Шагыйрь тарихка халык идеаллары югарылыгыннан килеп күз ташлый, үзенең рухын да шул олы бизмән яссылыгында аңларга тырыша. Туган ил аңа бөек тарихы белән газиз.

Еракларданкилде ул, гасырлар түреннән,
Риваятьләр, җырлар аһәңенә төренгән,
Елаган-көлгән, җиңгән-җиңелгән,
Алтын өмет дигән рухым минем.

Кешелек җәмгыятенең үсеш этапларын күздән кичереп, шагыйрьләр анда яңага омтылыш, караңгылык белән яктылык, вәхшилек белән матурлык арасында көрәш эзләрен күрәләр. Тарихи эпизод Ф. Шәфигуллинга кеше холкының катлаулылыгы, тормыш драматизмы турында фәлсәфи гомумиләштерү ясауга җай тудырган. Үзәктә варварлык чоры өчен гадәти бер күренеш: олы мәйданда ханның күңелен күрер

өчен ике егетне сугыштыралар. Берсе үләр, икенчесе данга күмелер. Әхлакый нәтиҗә шактый киң:

**Ә Дан инде нәкъ җәллады ханның —**
**Күләп карый үлем уенына.**
**Ә Дан инде нәкъ уйнашчы хатын —**
**Кайсы җиңсә,**
**Сарылыр ул шуның муенына.**

Поэзиябезгә алтмышынчы еллар башында Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Мингалимов, Г. Рәхим, Р. Гатауллин кебек бертөркем яшьләр килде. Алар торгынлыкка, сорылыкка, вәгазьчелеккә, катып калган калыпларга каршы чатнап күтәрелеп, метафорага, җисемле, пластик детальгә, шартлылыкка, иркен сурәтле фикерләүгә, синтетик формаларга юл ачтылар. Яңа буын үзен соңгы унъеллыклар поэзиясе казанышлары белән генә чикләмичә, Дәрдмәндкә, С. Рәмиевкә кул бирде, егерменче еллар поэзиясе казанышларын яңартты, татар шигъриятенә Э. Межелайтис, Л. Мартынов, Б. Слуцкий, А. Вознесенский, И. Драч, Е. Евтушенко, Р. Рождественский кебек шагыйрьләрнең эзләнүләр рухын алып керде. Поэзиядә сөйләм интонациясе, публицистик аһәң көчәйде, шигырь эстрадага менде. Бу чорда «тыныч лириклар», шул исәптән М. Әгъләмов кебек яшьләр, олы поэзия диңгезендәге җилкәнсез көймә шикеллерәк, югалып калдылар, арткы плангарак күчтеләр.

Ә инде җитмешенче елларның урталарыннан шау-шулы эстрада поэзиясенә ихтыяҗ кими төшеп, анда уйлану рухы, медитативлык, психологик нечкәлекләргә игътибар көчәя, халык иҗаты байлыклары белән кызыксыну арта башлады. Матурлык, табигыйлык билгесе булып поэзиябездә яңадан кырыс классик шигырь өстенлек ала бара. Шигърият үз ярларына — фикер һәм хис тирәнлегенә кайтты. Бүген инде Р. Фәйзуллиннар буыны да үткәндәге ачышларга киңрәк таяна, интим дөнья катлаулылыкларын яңача тасвирларга омтыла.

Җитмешенче еллар шигъри авазында М. Әгъләмов, Зөлфәт, К. Сибгатуллин, Рәшит Әхмәтҗанов, Ф. Сафин, Р. Миңнуллин, Р. Вәлиев, З. Насыйбуллин, З. Мансуров тавышлары торган саен аныграк яңгырый. Гражданлык тәҗрибәләре, рухи дөньяны, тормыш муллыгын аңлаулары, шигъри индивидуальлекләре төрле-төрле булган бу шагыйрьләрне лиризм, якты тоннарга өстенлек бирү, сүзнең күп мәгънәлелегенә таяну, образлы рәтләрнең тыгызлыгы якынлаштыра. Яңа буын поэзиянең эчке гүзәллеген, самими яңгырашын сакларга, фикер белән хиснең бердәмлеген табарга тырыша.

**Ачылалар үткәннәрнең**
**Серле капкалары,**
**Хакыйкатьнең ни гомерләр**
**Эзләп тапмаганы,**
**Бәгыремнең дөрләп-дөрләп**
**Яну сәбәпләре —**
**Я, ни әйтер Бөек Вакыт**
**Галиҗанабләре!**

— дип яза М. Әгъләмов «Баралмасам әгәр» шигырендә.

М. Әгъләмов иҗатын бәяләүдә әлегә уртак фикергә килгәнебез юк. Берәүләр аның шигъри эзләнүләренә уңай бәя бирсә, икенчеләр аның берише әсәрләренә заман билгесе җитешми, аларда гражданлык пафосы тонык яңгырый, вакыт-вакыт шагыйрь артык сентименталь, тар булып китә диләр. Бу хөкемдә хакыйкать бар. Шул ук вакытта М. Әгъләмовның үз-үзенә таләпчәнлекне арттыра баруы, артык каударланмыйча, каушамыйча гына тарих белән заман, табигать белән сәнгать арасында якынлык эзләве, милли бизәкләрне үзенчә үстерергә, баетырга тырышуы хакында да әйтеп үтәсе килә.

Милли нәкышләргә, үз көенә, җырына мәхәббәт чикләнгәнлек билгесе түгел. Һәр халык уртак социалистик культурага, олы океанга койган елга төсле, үз байлыгын алып килә.

**Көйнең, телнең, гореф-гадәтләрнең**
**Бар үз моңы, бар үз хисләре...**

**Ә табигать, нәфрәт, мәхәббәтнең**
**Юк һәм булмас милли чикләре.**
**(«Өзелмәс кыллар», И. Юзеев.)**

Тарихчыны күбрәк халык язмышында, хәятендә урын алган олы иҗтимагый хәлләр, маҗаралы һәм фаҗигале вакыйгалар, сугыш күренешләре, дәүләт мәсьәләләре җәлеп итсә, шагыйрьнең компасы, тарихи үткәнгә борылганда да, рухи дөнья байлыкларына, интеллект казанышларына юл ала.

Зөлфәт ерак дәвердә туып, безнең чорда да нәфислеген, сафлыгын югалтмаган халык җыры, халык моңы белән соклана, шуннан ямь, илһам ала. Халыкның җыр мирасында уелып-уелып галиҗанаб тарих эзләре калган, ди шагыйрь.

**Ерак тарих сыман серле яклар.**
**Моңның туган иле синме бу!**
**Нинди төшләр күреп йоклый гөлләр!**
**Җирдә төнге гөлләр тынлыгы...**

Халыкның олы күңелендә туган рухи кыйммәтләр белән соклану хисе поэзиядә үз урыныңны, үз кыйблаңны эзләү ялкыны белән кушыла.

**Үз моңыңны табу җиңел түгел,**
**Тамырлары аның, һай, тирәндә —**
**Үлчәп булмый нәрсә белән дә,**

— дип язуы белән Р. Закиров бик хаклы.

Төрле буын татар шагыйрьләре изге төшенчәләр, поэзиянең кеше тормышындагы урыны турында бергәләп уйланалар, сурәтле фикерләү мөмкинлекләрен киңәйтү юлларын эзлиләр. Сүз сәнгате тормыш күренешләрен яңача күрү һәм тасвирлаудан башка яши алмый. Хәзерге поэзиядә символик һәм гадәти мәгънәгә ия, тормыш драматизмын һәм кеше психологиясен тулырак иңләргә мөмкинлек биргән шигъри детальнең әһәмияте үсте.

Кешелекнең яшәү чыганагы, яңару символы—яңгыр яву күренеше турында язмый калган шагыйрь юктыр. Н. Арсланов, берәүне дә кабатламыйча, аңа бөтенләй башка яктан күз ташлый алган. Нәтиҗәдә татар поэзиясе яңа метафорага байый.

**Кай диңгезгә шәлен манган бу күк,**
**Бер туктамый сыга суларын.**

Шагыйрь туган җиренә, үзенә җан һәм илһам биргән туфрагына мәхәббәтен дә үзенчә әйтеп бирә белгән.

**Күзгә сөрмә итәр идем,**
**Туфрагың табалмадым.**

Әйтергә кирәк, яшь шагыйрьләр татар поэзиясен яңа шигъри табышлар, метафоралар, чагыштырулар белән баету юнәлешендә (сүз гражданлык тәҗрибәсе, фәлсәфи гомумиләштерү киңлеге турында бармый) остазларыннан калтыш эшләмиләр.

М. Галиевнең яраткан алымы — киңәйтелгән метафора. Егерменче гасырның иң тетрәткеч фаҗигасе — Ватан сугышы башланган көнне ул халык лирикасы образын яңача сынландыру аша күз алдына бастыра:

**Сабан туйда көрәш барган мәйданнардан**
**Сугыш җиле әтиләрне тартып алган.**
**Сөлгеләре — яшел чирәм өсләрендә**
**Яраланган аккош кебек ятып калган.**

Бер яктан афәтнең олылыгына ишарә итеп «сугыш җиле» образы килеп керә, икенче фразеологик рәттә традицион ак сөлге сурәте яңа образның нигезенә ята.

«Кая соң?» шигырендә М. Галиев күз яшен ашкынулы, дәртле чакларын исенә-ядена төшереп, сагынып, тыныч кына аккан инеш төбен бизәгән чуерташларга тиңли, хәтерне күк кабырчыкларга охшата. Кеше рухы, кеше күңеле табигать сурәтләре, дөнья гармониясе белән бизәлә, шулар фонында ачыла.

Туктаусыз үзгәреп, яңарып торган чынбарлыкны, кешене тирәнрәк аңлау хасияте шигъри фикерләүнең тыгызлануын, психологик анализның тирәнәюен таләп итә. Соңгы елларда бер шигъри детальне үзәк образ итеп алып, аны метафорик рәткә үстерү тенденциясе активлашып бара. Табигый матурлыкка шактый сизгер Зиннур Мансуров «Кул астына шәфәкъ алып кергән...» метафорасы белән иң элек тышкы дөнья матурлыгын җанландыра да, табышына янәдән кайтып, тышкы күренешне «җан рухын» ачу максатына буйсындыра: «Кул астына төннәр агып кергән, көннәр агып кергән бүз булып...»

Поэзиядә лирик-психологик башлангычның көчәюе аның элегрәк ирешелгән уңышларыннан баш тарту, читенү яисә аларны кире кагу дигән сүз түгел. Җитмешенче елларның шигъри авазында хикмәтле сүз, яңартылган антитеза традициясе дә кешене яңача аңлауга һәм сурәтләүгә хезмәт итә. Мөхәррәм Каюмовның тәүге шигъри тәҗрибәсен укып карыйк:

**Ике йөрәк — ике яфрак,—**
**Серләшеп бетми сере,**
**Ялгыз яфрак — җансыз кошчык,**
**Пар булса әгәр — тере.**

Р. Низамиев, Ә. Мәхмүдов, Б. Сөләйманов, Р. Әхмәтов, Н. Измайлова, Ф. Искәндәр, А. Минһаҗева иҗатларыннан да хәзерге сурәтле фикерләүнең яңача үсә, тыгызлана баруын дәлилләүче мисалларны табып булыр иде.

Поэзиядә элек-электән традицияләр көче белән яңачалык арасында тартыш, көрәш бара. Бер яктан, шигырь үзенең даими, тотрыклы билгеләрен, чал гасырлар сынавын үткән традицион алымнарын, жанрлык өлгеләрен, ритмик сыйфатларын сакларга тырыша. Бу җәһәттән поэзия сүз сәнгатенең иң консерватив төрләреннән берсе. Элгәрләрнең эстетик ачышларын яңа чорның фикерләвенә, интеллектуаль үсеш дәрәҗәсенә якынлаштыру шагыйрьдән зур осталык һәм сизгерлек таләп итә. Сәләте, кыюлыгы җитсә, ул таныш образларны яңача яңгырата, зиһене һәм тойгысы хыянәт итсә, гади кабатлау юлына төшә һәм шагыйрь булудан туктый. Күзгә сарылып торган бер мисалга тукталыйк. Соңгы елларда шигъри яңгырашлы «мизгел», «кайтаваз» сүзләре актив кулланыла башлады һәм еш кабатлаудан алар үзләренең төсен җуйды. Яшьләр «мизгел» сүзен һәр шигырьгә алып керүне мәҗбүри саный башладылар. Н. Измайлова аны шигырьнең исеменә чыгара («Зәңгәр кар мизгеле»), Ф. Искәндәр мизгелләрнең шавы, ярсуы турында озын итеп яза...

Икенчеллек һәм кабатлану — поэзиянең иң төп дошманнары. Еш кына яңа дип укыган шигырьнең дә образлары, мотивлары таныш булып чыга.

**Күбәләк килеп кунгач,**
**Чәчәк ачылып көлде.**
**...Кеше искәрмәде.**
**Туй күлмәген салгач,**
**алмагач**
**оялып куйды кояштан.**

Укыла, хәтергә сырылып кала. Ләкин татар поэзиясе өчен яңалык түгел. М. Галиев «Нюанслар иле» циклы (Р. Фәйзуллин) йогынтысында калган. Кыска шигырьдә тар мәйданда үз индивидуальлеген ача алмаган.

Шәхеснең рухи дөньясында урын алырлык шигырь тормышны үзенчә күрүе һәм таныш образларны ассоциация һәм хисси борылышлар ярдәмендә яңача яңарта алуы белән характерлана. Бу уңайдан Хатип ага Госман мәкаләсендә дә кызыклы һәм гыйбрәтле фикерләр әйтелде. («Казан утлары», 1978, 5 сан.)

Ә. Баянов КамАЗга багышланган шигырьләр циклында «Күктә Җидегән бу елларда экскаватор чүмечене охшап калды» кебек яңа, матур образлар тапкан, күңел сюжетының, психологик анализның мөмкинлекләрен киңәйткән. Шул ук вакытта шагыйрь элгәрләре алып кергән традиция йогынтысыннан арынып җитә алмаган.

**Ялгыз атлар кала ымсынып:**
**Чабарга соң кемгә кушылып!—**

Шатлык һәм моң тояп, «КамАЗ»лар
Яланнарда чаба, чабалар...

Безнеңчә, биредә ат белән «КамАЗ»лар арасында каршылык күренми, яңа белән иске арасындагы тартышның драматизмы ачылмаган.

Хәтер яңа аналогияләр эзли. Чаллыга багышланган шигырьдә С. Хәким дә КамАЗ янына, үткәннең бер символы итеп, атны «китереп бастыра».

КамАЗда ат. Ерак бер вәкил.
Көтүләрдән чабып монда кил.

Үткәнең белән аерылышу — яшьлегең белән аерылышу ул. Шигырь юлларына моңсу, сагышлы хис дулкыны үтеп керә. Ләкин биредә трагизм, икегә бүлену юк. Лирик герой заманында атка зур өмет баглаган, өмет акланмаган, хәзер исә ул киләчәкнең бөек КамАЗ ягында икәнлеген аңлый.

Җитмешенче еллар сурәтле фикерләве нормативлыкны һәм ясалмалыкны кабул итми, шигырьнең мәйданын һәм офыгын киңәйтүне, кеше рухына үтеп керү юлларын төрләндерүне таләп итә. Шагыйрь өзлексез эзләнгәндә, яңа бер образ, рифма табу өчен, Маяковский әйткәнчә, меңләгән тонна сүз рудасын актарганда гына чордашына эстетик ләззәт бирә алыр.

Шәхси тәҗрибә чикләрен үтә алмау, бер үк мотивларны кабатлау, «икенчеллек» яшьләрнең шигъри диапазонын чикли. М. Галиев, мәсәлән, үзенең каршылыклы уйлары, ахыргача ачыкланып бетмәгән хисләре турында язарга ярата («Күңелемдә адашырга яратам мин, андый чакта син чакырма мине»), буыннар алышынуны, дәвамлылыкны берьяклы аңлый. («Китә барган саен аксакаллар, урыны буш кала — күрәбез».)

## Чор таләбе

Илебез тарихын берсеннән-берсе гүзәл сәхифәләре белән баеткан җитмешенче еллар олы Дөнья һәм Кеше проблемасын, алар арасындагы катлаулы һәм каршылыклы мөнәсәбәтне яңача калкытып куйдылар. Бу яңалыклар сурәтле фикерләүгә, әдәби жанрлар, шул җөмләдән поэма үсешенә дә көчле тәэсир ясады.

Чорыбызның әхлакый-фәлсәфи проблемаларын, кешенең заман һәм вакыйгалар белән күп яклы бәйләнешен тулы һәм масштаблы итеп сурәтләү максаты шагыйрьләрне эзләнүләр юлына алып чыкты. Е. Исаевның «Хәтер киңлеге», С. Наровчатовның «Василий Буслаев», Ю. Марцинкявичюсның «Собор», В. Соколовның «Сюжет», Д. Кугультиновның «Акыл фетнәсе», В. Федоровның «Дон-Жуанның өйләнүе», Шукуруллоның «Ут һәм чәчәк», М. Каноатның «Сталинград тавышлары» кебек кеше һәм дөнья проблемасының мөһим мәсьәләләрен үзәккә алган үзенчәлекле поэмалары укучыга иреште. Бу әсәрләрнең үзәгендә шәхес белән җәмгыять, шәхес белән табигать арасындагы мөнәсәбәт, кешенең дөнья каршындагы әхлакый бурычы, рухи халәтенең баюы мәсьәләләре тора.

Татар поэмасы да бер урында таптанмый. С. Хәкимнең «Дәверләр капкасы», Р. Харисның «Җитмеш икенче ел икмәге», «Рәссам», Р. Фәйзуллинның «Керәшчеләр», Р. Мингалимовның «Күз карасы», «Юл өстендә тургай», И. Юзеевның «Өзелмәс кыллар» кебек соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләре эпик жанрның чорны һәм рухи дөньяны тасвирлау мөмкинлекләре чикләнмәгән икәнлекне исбат итте.

Хәзерге укучыны озын-озын тасвирый поэмалар белән шаккатыруы кыен. Хикмәт вакытның кыйммәте артуда гына түгел, ә укучының интеллектуаль үсешендә, фикерләүдә барлыкка килгән прогресста. Укучы мөмкин чаклы тар мәйданда ачылган олы фикер, кичереш тирәнлеге таләп итә.

Сүз осталары поэманы иҗтимагый тормышка, кешенең рухи дөньясына, зиһен эшчәнлегенә якынайту юлларын эзләп, бай традициягә, сөйләм теленә, ритмик ирекләккә, метафорага киң таяналар.

Поэзия турында сөйләшүне башлап җибәргән диалогта поэма тукымасында барлыкка килгән яңалыклар турында кызыклы фикерләр әйтелә: «Поэма хакында әдәбиятчылар күптәннән бәхәсләшәләр. Ләкин бер төгәл фикергә килгәннәре юк, ихтимал, килә дә алмаслар... Чөнки яңа әдәби күренешләрнең әледән-әле хасил булып торуы да ниндидер бер тотрыклы нәтиҗәгә килергә ирек бирми... Хәзер безне поэманың классик төшенчәсе канәгатьләндереп бетерми, ә яңа формалары турында фикер туплап бетерә алганыбыз юк».

Һәр эзләнүчән шагыйрь поэма үсешенә үзеннән өлеш кертә. С. Хәким тарих белән бүгенге арасында җанлы җепләрне эзли, романтик экспрессив алымнарны киң куллана, Р. Фәйзуллин замандаш характерында үзгәрешләрне публицистик гомумиләштерү ярдәмендә аңларга омтыла, эчке монологка киң таяна. Роберт Әхмәтҗанов шигъриятгә фәнни фикерләү алымнарын яңгырату рухы белән яши...

Драма жанры ачышларына, үтә шартлы алымнарга таянып язылган фәлсәфи-әхлакый поэмалар авторы И. Юзеев «Өзелмәс кыллар» исемле лирик-психологик әсәр язып чыкты. Биредә яшьлек поэмасы «Таныш моңнар»ның лиризмы «Тынлык белән сөйләшү», «Соңгы сынау» поэмаларының уйлану, эзләнү пафосы белән кушыла. Поэмада сүз автор — лирик герой исеменнән бара. Ул — замандашына һәм туачак буыннарга әйтер сүзе, бүлешер тәҗрибәсе, «гомер көен» үз аңлавы булган, җитлеккән шәхес. «Актык көчем җыеп тауга мендем: ниндидер бер нечкә кыл тартты...»,— ди ул яшьләргә мөрәҗәгать итеп. Лирик герой кеше өчен иң газиз төшенчәләр арасыннан өмет, мәхәббәт, нәфрәт, иҗат кебек «тормыш кылларын» аерып ала, калкытып куя, аларны гомумиләштерелгән символик образлар дәрәҗәсенә күтәрә. Поэманың композициясен дә дүрт «өзелмәс кыл» билгели.

Вәхшилеккә, явызлыкка, сугышка нәфрәт контрастлы антитеза, капма-каршы мәгънәле күренешләрне янәшә кую алымы ярдәмендә чагылдырыла:

**Концерт залы — концлагерь,**
**Консерватория — зиндан.**
**Көй уйнаган куллар — курокта.**
**Ярын кочкан куллар — курокта.**

Шагыйрь фикер эшчәнлеген, кичереш динамикасын, кеше психологиясен тулырак ачу юлларын эзли. Рухи халәттәге өермәле, шашкынлы хисләр басымы тәэсирендә тышкы дөньяны башкача, өлешчә «бозып» күрү алымы да «җан диалектикасын» ачу максатына буйсына:

**— Ул юк.**
**— Ул юк. Күзалларым — талган,**
**Кап-карадыр**
**Декабрьның салкын ак кары.**

Шагыйрьнең игътибар үзәгендә — рухи сфера, замандашының фәлсәфи-әхлакый эзләнүләре, сагышлары, табышлары, борчулары. Идеалын укучысына тулырак ирештерү нияте белән автор төп фикерен кат-кат такрарлый. Урыны белән киңәш бирү, дидактика юлына да баса.

**Вилданнардан калган шушы кылны**
**Саклагыз сез, яшьләр, өзмәгез...**

И. Юзеев аллитерация, ассонанс, рефрен, авазлар уйнату кебек сурәтләлек алымнарыннан мул файдалана. «Өчәү чыктык ерак юлга...» поэмасында ул сүз-аваз яңгырашын композицион өлге итеп үстергән иде. Соңгы поэмада да шул юнәлештә эзләнүләр дәвам итә. Ләкин вакыты белән ул ясалма контрастлылык, шакли охшашлык белән мавыгып, чама хисен югалта: «Диң-даң. Диң-даң. Миллион гомерләрне биреп алган ирекка дан». Чынлыкта бит сүз олы фаҗига, азат тормышның кадере — кыйммәте хакында бара. Бу очракта какофония урынсыз.

Р. Харисның «Рәссам» поэмасы детектив романнар шикелле эффектлы деталь белән башланып китә: «Сарафанын салды да котмагәндә бөтенләй ялангач калды...» Шагыйрь гомумән предметлы сурәткә, тыгыз, мускуллы тропларга, төсле буяуларга өстенлек бирә. «Гүзәл тән» дип исемләнгән беренче бүлекчәдә ул табигый матурлыкка, хатын-кызның чибәрлегенә, тән гармониясенә дан җырлый, шуңа тиң сурәт-

ләр, җисемле детальләр эзли («Яшерен теләк тулы серле күзләр», «Эретеп иркәли торган серле күзләр»). Әсәрнең структурасы катлаулы образларга, ассоциатив сурәтләргә киң юл ача. Бер яктан, шагыйрь мәшәкатьле олы дөньяны җисемле, предметлы, аһәңле образлар ярдәмендә реаль бөтенлегендә тасвирласа, икенчедән, ул шул ук күренеш-хәлләрне рәссамның сурәтле кабул итүендә күз алдына бастыра. Гүзәл кыз һәм аның киндердәге сыны, рәссамның табигый сынга һәм үзенең иҗат җимешенә мөнәсәбәте, сугыш һәм художникның афәтне күзаллавы бергә аралашып зиһенне зирәкләндерерлек, хисне хәрәкәтләндерерлек шактый катлаулы структур һәм стилистик бердәмлек тудыра. Шагыйрь рәссамның рухи дөньясына, фикерләү рәвешенә тирән үтеп керә алган.

**Һәр төсне кырыкка яра белүче,**
**Һәр сызыкта җан хәрәкәте сизүче,**
**Һәр хәрәкәттә кырык мәгънә күрүче күзләр**
**Сокланудан каушап калдылар,**
**Беравыкка йомылудан туктадылар.**

«Рәссам»нан эзлекле, тасвирый сюжет эзләү дөрес булмас иде. Аның үзәгендә кичереш динамикасы, шәхеснең тормыш һәм үзе турында, рухи яңарышта сәнгатьнең роле хакында уйланулар ята. Р. Харис дәвернең катлаулы проблемаларын калкытып куя алган. Әсәрне мәгълүм бер художник истәлегенә генә багышлау, физиологик детальләр белән артык мавыгу кебек үк, поэманың офыгын тарайта, яңгырашын чикли кебек.

Р. Мингалимовның «Юл өстендә тургай» поэмасының төп иҗади принцибы — конкрет сурәт аша олы проблемаларга хәрәкәт. Шагыйрь үзен борчыган вакыйга-хәлләр, Татарстаны, туган җире турында тукми-чәчми сөйләп бирү юлына басмый, әһәмиятсез, төссез нәкышләрне сурәткә кертми, заманны үз шәхси кабул итүе аша иңләргә омтыла. Табигать күрке, матурлык символы тургай җыры, тургай моңы турындагы сөйләм чорыбызның олы шатлыклары һәм авырлыклары турында уйланулар га кушылып китә. Поэманың үзәк хөкеме Вакыт агышы турында фикер йөртү белән бәйле. Шагыйрь Вакытка мөнәсәбәтен берсен-берсе кысрыклап һәм ачыклап килгән катлаулы образлы рәтләр аша ача. Дөнья тизлегенә иярә алмаучылар да бар. Берәүләр «канатсыз кош булып утырып кала, ятып кала башсыз яу булып...», икенчеләре «ак күбеккә баткан ат кебек...» төшеп кала. Шул уйланулардан соң шагыйрь җитди нәтиҗә чыгара:

**Бүген алган тизлек бүген ярый,**
**Яңа тизлек кирәк иртәгә.**

«Юл өстендә тургай» сыйдырышлы детальләргә, лирик чигенешләргә бай: «Шомырт чәчәкләре ап-ак дәрья, ак дәрьяда хыял көймәсе».

«Хыял көймәсе» метафорасы халыкның иҗтимагый тарихын иңләргә («хәрабәләр арасына посып, поэмасы килгән, эпосы»), тормышның кыйммәте, туып-үскән җиренең яме хакында уйлануларга алып чыга. Тургай җыры туган ил җыры белән кушыла.

Карап үткән өч әсәр арасында мәгълүм уртаклык та бар. Поэмада лиризмның көчәюе, сурәтле фикерләүнең баюы, күләмнең кыскаруы күз алдында. Шуның өстенә анда лирик герой үзәк фигура булып бара, шигъри деталь гомумиләштерүгә алып килә. Поэма тукымасында барлыкка килгән структур һәм стилистик үзгәрешләр борынгы жанрның яңаруы, чор таләпләренә, кешенең заманча фикерләү үзенчәлекләренә якынлаша баруы турында сөйли.

Поэманы башка жанр алыштыра алмый. «Ясалмарак поэмаларга караганда төзек шигырь цикллары күбрәк ошый төшә»,— дип, бер жанрны икенчесенә каршы куюы белән Р. Фәйзуллин хаклы түгел. Уртак идея, хис тирәсендә берничә әсәрне берләштергән, лирик шигырь белән поэма арасында торган лирик цикллар сәнгатьнең, әдәбиятның төрле жанрлары үзара аралашуы, синтетик фикерләү җимеше буларак туа. Алар поэма үсешенә дә уңай тәэсир ясады, әмма аны кысрыклап чыгармадылар. Начар жанр юк. Начар әсәрләр генә бар. Һәр уңышлы әсәр жанрны үстерә. Кешенең акыл һәм рухи үсеше таләп иткәнчә, поэманың үсешендә дә киләчәктә яңадан-яңа үзгәрешләр туар, әмма шигъриятнең романы, эпосы — поэма яшәүдән туктамас, юкка чыкмас.

# Сүзне шигырьгә бирик

Елганың башы, йортның нигезе, һәр эшнең башлангычы була. Шуңа күрә хәзерге поэзия турында сөйләшүне башлап җибәргән мәкаләне дә фикер уятырлык, хисне хәрәкәткә китерерлек җирлек дип кабул итәргә тырышасың. Әйтергә кирәк, И. Нуруллин белән Р. Фәйзуллинга диалог формасы хәзерге поэзиягә мөнәсәбәтләрен анык һәм төгәл итеп ачып салырга, үзләрен борчыган мәсьәләләрне, теге яки бу күренешкә мөнәсәбәтләрен калкытыбрак куярга мөмкинлек биргән. Авторлар шигъри байлыгыбызның хәзерге торышы, барыр юллары турында уйланып, борчылып һәм куанып язарга омтылалар.

Ләкин бу мәкаләне өлге итеп алып хәзерге поэзия хакында җитди сүз алып баруы кыен. Авторлар шигъри әсәрләр һәм аларның иҗатчылары турында конкрет анализны, бергәләп бәхәсләшердәй, киңәшләшердәй проблемаларны читләтеп үтеп, поэзия турында гомуми фикер йөртү юлына басалар. «Аңлаешлы» һәм «аңлаешсыз» шигырьләр яки поэзиянең гражданлык йөзе» дип исемләнсә дә, хөрмәтле тәнкыйтьчеләр атаманың икенче, төп өлеше турында онытып, матбугатта күп тапкырлар күтәрелгән, чынлыкта «локаль» бер проблема — шигъри фикерләүнең бер хасияте турында бәхәскә кереп китәләр һәм ахыр чиктә сүзне күбрәк поэзияне шәхси кабул итүләре турында алып баралар, шул җирлектә «конфликтлы» яисә «проблемалы» ситуация тудыралар.

Ибраһим аганы «буразна» гомуми теория ярларына алып чыга. Ул Г. Кутуйны футуристлар, К. Нәҗмине имажинистлар лагерена теркәп, алар белән «бил алышу»га көчен сарыф итә.

Р. Фәйзуллин да үз «хоббиына» турылыклы кала. Ул хәзерге поэзия турында сөйләшүдән бүленеп, тәнкыйтьнең торышы турында фикер йөртүгә кереп китә. Поэзия тәнкыйтенә мөнәсәбәтен кайта-кайта ачыклый. «Минемчә, әле тәнкыйть шигъриятебезнең үсү тенденцияләрен ачыклау, барыр юлларын билгеләү процессында үз ролен үтәп җиткерми шикелле... Тәнкыйтьченең шагыйрьне ничек язарга өйрәтә алуына шикләнәм мин, ә булышуга килсәк, ул чын мәгънәсендә булыша алыр иде. Бу җәһәттән безнең бүгенге тәнкыйтьчеләребез үзләренең төп миссияләрен үтәп бетермиләр шикелле... Мин үзем бүгенге поэзия тәнкыйтьчеләренең фикри ярлылыкларына хәйран калам».

Р. Фәйзуллин Галимҗан Ибраһимовның яшьлегендә язган, үзенчәлекле, әмма поэзиянең төп көчләренә бәясендә субъектив позицияле «Татар шагыйрьләре» китабына югары бәя бирә һәм шундый нәтиҗә ясый: «һәрхәлдә, шуңа охшашлы «тере» хезмәтне күргәнем юк әле минем». Бу логикага ияреп, аны дәвам иттерсәк, Тукайдан соң татар поэзиясе «тере» шагыйрьне бирә алганы юк дип кенә раслыйсы кала.

Тәнкыйть киң катлау укучы өчен языла. Гадәти укучы тәнкыйтьтән әдәби процесска объектив идея-эстетик, әхлакый бәя бирүгә, яңа әсәрләр, яңа исемнәр ташкынында «адашып» калмаска өйрәнә. Ә язучы тәнкыйтьне күбрәк үз эстетик үсеш дәрәҗәсеннән, шәхси иҗат тәҗрибәсеннән, зәвыгыннан килеп бәяли.

Икенче яктан шундый бер закончалык турында да онытырга ярамый. Олы тәнкыйть олы әдәбият белән бергә туа, янәшә атлый, аңа юнәлеш бирә. Пушкин, Лермонтовлар иҗатына объектив бәя бирә алырлык Белинский, Добролюбов кебек талантлар үсеп чыга, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, һ. Такташ, Х. Туфаннар иҗаты Г. Сәгъди, Г. Нигъмәти, Г. Гали кебек тәнкыйтьчеләрне рухландыра, илһамландыра. Бүгенге татар поэзиясенең намусы булырлык шагыйрьләр бар икән, аларга лаеклы тәнкыйтьчеләре дә күтәрелер.

Тәнкыйть чыннан да хәзерге поэзиянең көчен, матурлыгын, шигъри яңалыгын ачып җиткерә алмый әле. Талантларны вакытында күтәрә белү бу жанрның изге бурычы. Тәнкыйтьне аклау ниятем юк. Ләкин поэзия турында башланып киткән фикер алышуны тәнкыйтьнең сыйфаты, өлгерлеге турында сөйләшүгә борып кую шулай ук дөрес булмас иде.

Йомгак урынына әйтәсе килгән фикер шул: поэзиябезнең актуаль мәсьәләләре турында фикер алышуда катнашучылар үзәк проблемалардан читкә чыгып китмәсеннәр иде. Хәзерге поэзияне, аны әйдәп баручы төп көчләрнең эзләнү — уйлануларын ачыклау өчен «сүзне шигырьгә бирик»! Хакыйкатьне шуннан эзлик!

# ХАКЫЙКАТЬНЕ ТАПЛАП БУЛМЫЙ

Империализм ялчылары милләтләр һәм милли мөнәсәбәтләр үсеше өлкәсендә Коммунистлар партиясе политикасын, милли мәсьәлә турында марксизм-ленинизм тәгълиматын бозып күрсәтү өчен ифрат күп тырышлык куялар. Шул сәбәпле антисоветизм һәм антикоммунизмның реакцион асылын, милләтчелек ялчыларын фаш итү — иҗтимагый фәннәр алдында торган иң җаваплы бурычларның берсе.

Бу җәһәттән гыйльми җәмәгатьчелек, киң катлау укучылар М. Абдуллин һәм С. Батыев хезмәтен тирән кызыксыну белән каршыладылар [1]. Китапта Татарстан тарихын бозып күрсәтүче буржуаз фальсификаторларның төп концепцияләре үтергеч тәнкыйть ителә. Авторлар Англия, Америка, Франция һәм Көнбатыш Германия буржуаз тарихчыларының, шулай ук ак эмигрантлар һәм сатлык җаннарның әлеге мәсьәләгә караган күп кенә хезмәтләрен совет тарихчылары тикшеренүләрендә, матбугатта чыккан документ һәм материалларга таянып фаш итәләр, тәнкыйть күзлегеннән үткәрәләр. Китапта шулай ук хәзерге буржуаз әдәбиятны анализлау нигезендә империализм идеологлары хезмәтләренең фәнни нигезсезлеге, явыз ният белән сугарылган булулары, аларның бу өлкәдәге таушалып беткән ысуллары һәм методлары күрсәтелә.

М. Абдуллин һәм С. Батыев буржуаз тарихчыларның политик карашларына марксистик позициядән торып бәя бирәләр, ачы тәнкыйть угын Р. Пайпс, Ф. Бархорн кебек яманаты чыккан антисоветчыларга, Э. Карр, С. Зельковский кебек буржуаз объективистларга юнәлдерәләр.

Буржуаз тарихчылар партиябезнең милли политикасын, милли мөнәсәбәтләрне бозып күрсәтүне гадәттә милли мәсьәлә буенча марксистик-ленинчыл тәгълиматтан, КПССның милли программасыннан башлыйлар. Китапның беренче бүлегендә авторларның ленинчыл милли программаны «тәнкыйтьләүчеләр» белән бәхәскә керүе шуның белән аңлатыла. Советологлар, милли мәсьәләне һәр очракта буржуазия һәм аның политик партияләре генә хәл итә алды, милләтләргә үзбилгеләнү хокукын буржуазия генә бирергә мөмкин, дип исбатларга маташалар. Бу җәһәттән китап авторлары партиябез милли программасының чын асылын, революцион һәм фәнни характерын ышандырырлык итеп ачып бирәләр. Буржуаз фальсификаторларны тәнкыйть итү белән бергә, алар дәүләт төзелешендә федерация һәм автономия принципларына ленинчыл якын килүгә тирән анализ ясыйлар.

Күпчелек буржуаз авторлар, Бөек Октябрь революциясе тик «саф рус» характерындагы күренеш, ул рус булмаган халыкларга көчләп тагылды, дип расларга маташалар. Алар фикеренчә, Октябрь революциясе барлык милләт хезмәт ияләренең аңлы көрәше нәтиҗәсе түгел булып чыга. Аерым алганда, ул хезмәтләрдә татарлар арасында сыйныфлар юк иде дигән караш та үткәрелә һәм татар хезмәт ияләрен революцион хәрәкәттән аерып карауга зур урын бирелә. М. Абдуллин һәм С. Батыев китабында аларның бу уйдырмалары конкрет фактик материаллар нигезендә инкарь ителә. «Совет белгечләре»нең татарлар арасында сыйнфый кө-

---

[1] М. Абдуллин, С. Батыев. Татарстан АССР: реальность и буржуазные мифы. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1977.

рәшнең булмавы, татар пролетариатының йомшаклыгы, алар арасыннан революцион җитәкчеләр үсеп чыкмавы турындагы уйдырмалары буш һәм дәлилсез. Алар тырышып-тырмашып татар революционерларының Казан большевиклар комитеты һәм Мөселман социалистлар комитеты җитәкчелегендә хезмәт ияләрен пролетар рухта тәрбияләү, аларны революцион көрәшкә тарту эшчәнлеген күрмәскә тырышалар. Күп төрле һәм бай фактларга нигезләнгән тарихыбыз исә моның киресен сөйли.

Антикоммунизм идеологлары совет властеның беренче елларыннан ук партиябез һәм хөкүмәтебезнең милли мөнәсәбәтләр өлкәсендәге политикасына котырынып һөҗүм итәләр. Коммунистлар партиясенең милли политикасын патша хөкүмәтенең колониаль политикасының дәвамы ул дип күрсәтергә маташып, алар берниндн пычрак алымнардан да чирканмыйлар. Империализм тегермәненә су коючы «совет белгечләре» көчәнә-көчәнә татар халкының гасырлар буе килгән хыялы Идел-Урал штатлары иде дигән уйдырмага ышандырмакчы булалар. Ә чынлыкта исә Идел-Урал штатлары төзү проекты милли буржуазия хыялы гына булып, ул совет властен урнаштыруга юл куймау максаты белән эшләнгән көчсез бер провокация иде. Шунысын да онытмыйк, чит илдә ак эмигрантлар тарафыннан төзелгән «Идел-Урал» комитеты икенче бөтендөнья сугышында немец фашистлары белән актив хезмәттәшлек алып барды, ә аның реакцион идеясе яманаты чыккан антикоммунизмның коралы итеп алынды.

Совет властеның милли мөнәсәбәтләр өлкәсендәге беренче уңышлы адымнарыннан ук куркуга төшкән империализм ялчылары, ул казанышларны тактик маневр гына булды дип аңлатырга азапландылар, янәсе моның милли дәүләтчелек төзү белән берниндн уртаклыгы да юк иде. Аларның Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүне иске колонизаторлык политикасының «бүлгәлә һәм хакимлек ит» политикасының дәвамы дип расларга маташулары да хакыйкатьтән читтә тора. Чөнки Совет Татарстанының бүгенге уңышлары — партиябез милли политикасының дөреслеген исбатлаучы иң зур дәлил. Ә моны буржуаз ялганчылар берниндн хәйләле юллар белән дә кире кага алмыйлар. Хакыйкатьне таплап булмый!

Буржуаз фальсификаторлар партиябезнең милли политикасын бозып аңлатуда буржуаз милләтчелек һәм милләтче-тайпылучылар кулланган төрле ялган «теория» һәм положениеләрдән дә киң файдаланалар. Татарстан тарихын фальсификацияләү максатыннан чыгып, алар үзләренә Солтангалиев идеяләрен калкан итеп алалар, янәсе бу идеяләр милли мәсьәлә өлкәсендә партия линиясенә каршы килми. Хезмәттә исә мондый раслауларның тулысынча нигезсезлеге Солтангалиев концепцияләренең контрреволюцион асылын ачып бирү юлы белән күрсәтелә.

Совет чынбарлыгын тапларга тырышучылар илебездә социалистик төзелеш елларында милли мәсьәләнең хәл ителүен дә бозып күрсәтергә азапланмыйлар түгел. Бу мәсьәлә күп кенә «хезмәтләр»дә милли районнарда социалистик төзелеш бурычларына каршы куела. Алар фикеренчә, Татарстанда социалистик индустрияләштерү, коллективлаштыру һәм культура революциясе үткәрелү «совет империализмы» политикасының гәүдәләнеше булып чыга. М. Абдуллин һәм С. Батыев татар халкының социалистик культурасы «милли түгел» дип игълан иткән, революциягә кадәрге татар буржуаз культурасына мәдхия җырлаган буржуаз тарихчылар белән кискен бәхәскә керәләр. Китапта мондый «тәнкыйтьчеләргә» тәпле җавап бирелә. Авторлар әйткәнчә, татар милли буржуазиясенең дә төп максаты киң халык массаларын рухи коллыкта тоту иде. Татар социалистик культурасы казанышларын революциягә кадәрге буржуаз культура белән чагыштырып карау советологлар телəгән нәтиҗәне бирми. Шунлыктан антисоветчылар татар милли культурасының, янәсе череп таркалуы турында һәртөрле «дәлилләр» китерәләр, татар алфавитының реформасын да милли культураның руслашуына таба бер адым иде, дип расламакчы булалар. Ә чынлыкта исә, китапта бик дөрес әйтелгәнчә, реформа 40 нчы еллар башына татарлар арасында укый-яза белмәүчелекне нигездә бетерергә мөмкинлек бирде һәм татар халкы алдында СССР халыклары культурасы һәм аның аша дөнья халыклары рухи хәзинәсенә юл ачкан зур яңа мөмкинлекләр туды.

Илебез халыклары социалистик төзелеш елларында идея-политик яктан ныгып берләштеләр. Бу аерата Бөек Ватан сугышы елларында ачык чагылды. Төрле милләт сугышчыларының, шул җөмләдән башка милләт вәкилләре белән иңгә-иң торып көрәшкән татар солдатларының ба-

тырлыгы фашист Германиясенә каршы сугышка татарларны көчләп тагу турында сөйләнгән буржуаз ялганчыларның һәр төрле уйдырмаларын фаш итә һәм себереп түгә.

Партиябез милли политикасының бүгенге уңышлары, илебез халыкларының тигез хокуклылыгы, туганлыгы һәм какшамас бердәмлеге советологларның җен ачуын чыгара. Чөнки байтак кына капиталистик илләрдә нәкъ менә шул проблемалар кискенләшкәннән-кискенләшә бара. Антикоммунизм идеологлары, бер яктан, КПССның интернациональ политикасын бозып күрсәтү өчен, икенче яктан, СССРда милли мәсьәләнең, янәсе, бүгенге көнгәчә хәл ителмәвен «исбатлау» өчен күп көч куялар. Шуның белән алар СССРда һәм башка тугандаш илләрдә социализм позицияләрен какшатырга маташалар. Әйе, маташалар гына!

Китапның тулы бер бүлеге бүгенге Совет Татарстанының төрле өлкәләрдәге казанышлары турында сөйли. Авторлар экономика, культура һәм милли мөнәсәбәтләр өлкәсендә советологларның һәр төрле уйдырмаларын һәм ялганнарын фаш итә торган күп төрле һәм бай материалга, бер сүз белән әйткәндә, республикабызның бүгенге чынбарлыгына таяналар. Ә антикоммунизм идеологлары исә, «экономик һәм культура империализмы» турында таушалып беткән концепция үткәрәләр, Татарстан мисалында социалистик яшәү рәвешен бозып аңлаталар. Аларның нык үскән социализм этабында СССР халыкларын, шул исәптән татарларны да, «үтә югары милләткә»— совет халкына көчләп берләштерү турындагы тезислары да нигезсез. Яңа тарихи гомумилекне рус булмаган халыкларны «руслаштыру», «ассимиляцияләштерү» нәтиҗәсе дип аңлатырга маташкан буржуаз тәнкыйтьчеләргә җавап итеп, М. Абдуллин белән С. Батыев СССРда төрки халыкларның бердәм совет халкының аерылгысыз состав өлеше булуы турында, аларның мөстәкыйль рәвештә яшәүләре һәм ирекле рәвештә үсүләре, чәчәк атулары турында язалар. Китапта әйтелгәнчә, социалистик җәмгыятьнең объектив закончалыклары милләт һәм халыкларның акрынлап үзара якынаюына, коммунистик төзелешнең төрле өлкәләрендә алар арасында тагын да тыгызрак хезмәттәшлек һәм үзара ярдәмләшү урнашуга китерә.

Безгә калса, әлеге җитди хезмәттә кайбер кимчелекләр дә юк түгел. Авторлар буржуаз ялганчыларны тәнкыйть иткәндә кайбер очракта кирәгеннән артык хискә бирелеп китәләр. Фактик чыганаклар базасын тагы да киңәйтү һәм советологлар куллана торган чыганакларны тәнкыйтьләү буржуаз фальсификаторлар концепциясен фаш итүдә тагын да нәтиҗәлерәк булыр иде. Хезмәттә әле билгеле бер кабатлауларга да юл куелган.

Тулаем алганда, М. Абдуллин белән С. Батыев монографиясе — КПССның милли политикасын бозып күрсәтүчеләрне фәнни тәнкыйтьләү эшенә зур өлеш керткән хезмәт. Ул фән эшлекләре, белгечләр, пропагандистлар өчен генә түгел, киң катлау укучылар өчен дә кызыклы һәм кыйммәтле кулланма булып тора. Китап матур тел белән язылган һәм мавыктыргыч укыла. Сүзне йомгаклап, аны татар телендә дә чыгару зур әһәмияткә ия булыр иде дигән фикер белдерәсе килә.

**Наил ШӘФИГУЛЛИН,**
**тарих фәннәре кандидаты.**

# ДӨНЬЯНЫ СҮЗ БИЗӘР

Соңгы елларда язучы һәм тәнкыйтьчеләрнең вакытлы матбугатта басылып килгән мәкаләләрен туплап, җыентык итеп чыгару гадәткә кереп бара. К. Нәҗминең «Әдәбият дөньясында», Ф. Хөснинең «Ни әйтергә? Ничек әйтергә?», Г. Бәшировның «Бүген дә, иртәгә дә», Р. Мостафинның «Алга барышлый», Ф. Миңнуллинның «Якты юллар» китаплары дөнья күрде. Дәрәҗәсен төшермичә дәвам иткәндә, Татарстан китап нәшриятының бу эше, һичшиксез, һәр төрле хуплауга лаек. Х. Сарьянның «Уеңны уйдырып сал...» китабы алда саналганнардан бераз аерылып тора: анда тел, стиль, әдәби осталык мәсьәләләре үзәккә куелган.

1969—76 нчы елда язылган хезмәтләрне туплаган бу җыентык ике бүлектән тора. «Уеңны уйдырып сал...» бүлегендә хәзерге проза һәм поэзия турында уйлану-

лар, яшь язучыларның беренче әсәрләре, аерым шагыйрьләр, язучыларның иҗат портретлы, рус әдәбиятыннан тәрҗемәләр турындагы мәкаләләр урнаштырылган.

Хәзерге әдәбиятның төп үзенчәлеген Х. Сарьян дөрес билгели: «Ул иң әүвәл бүгенге Кешене эзли, шуңа хас булган сыйфат-холыклар эзли... Совет прозасының күренекле вәкилләре, татар язучылары Кешене өйрәнү, батырлыкның нигезе булган рухын анализлау — кулын кулга, аягын аякка аерып түгел, ә психологик осталык белән фәлсәфи анализлау юнәлешендә иҗат итәләр; Кешенең Үзем дигән эчке дөньясына киңәеп тә, тирәнәеп тә төшеп баралар» (6 б.).

Әдәби ел йомгакларында булсын, аерым әсәрләргә анализда булсын, тәрҗемә турында булсын, Х. Сарьян, башка тәнкыйтьчеләрдән, язучылардан аермалы буларак, төп игътибарны әдәби осталыкка юнәлтә. Зур, мәгънәле идеяне начар, корама тел белән әйтеп булмый. Форма һәм эчтәлекнең бөтенлеге бит ул әдәби әсәр: «...сәнгать теле булмаганда, бернинди гүзәл идеяләрне дә сәнгать дәрәҗәсенә менгезеп булмый. Чөнки **идея** һәм **тел** — бер кешенең ике күзе, ике кулы, ике аягы; ниһаять, ул — бер кешенең сөяге белән каны, акылы белән йөрәге! Чын идея чын тел белән язганда гына халык күңеленә төшеп сеңә» (139 б.).

Кем турында гына язмасын, Х. Сарьян, иң беренче чиратта, язучының, шагыйрьнең, тәрҗемәченең уңышларын күрә белә, аларга саранланмыйча, ихлас күңелдән ышанып, объектив бәя бирә белә. М. Әмир, Г. Ахунов, М. Хәсәнов, Б. Камалов, Х. Хәйруллин, М. Шабаев, К. Миңлебаев, М. Рафиков, М. Хәбибуллин, М. Харисов, М. Насыйбуллин әсәрләренең хәзерге татар әдәбиятына алып кергән яңалыкларын, үзенчәлекләрен дөрес бәяли. М. Әмирнең «Җан көеге» повесте турында «йодрыктай йомарланган, пружинадай кысылган, кирәкле-кирәксез детальләрдән арчылган, бер сулыш белән укыла торган әсәр» (33 б.) дип әйтер өчен, автор укучыны, чыннан да, тулысынча ышандыра торган әдәби-эстетик анализ үткәрә. Г. Ахуновның «Хуҗалар» романында җитәкче кадрларны бер-берен кабатламастан сурәтли алу осталыгын, фәлсәфи тирәнлеген, табигый матур, ягымлы-йомшак, салмак телен, бу романның «Хәзинә» романы белән тыгыз бәйләнештә булуын күрсәтеп, кара җир куеныннан кара алтын чыгаручы «ак йөзле, ак күңелле», кешеләрне сурәтләгән бу әсәрне «ак йөзле, якты әсәр» дип бәяли (36 б.). Янсә менә Б. Камаловның иҗат портретын сурәтләп, ул аның үзенчәлекле якларын бик оста тотып алган. Б. Камалов — яшьләр тормышы темасына турылыклы оста хикәяче, сюжетны кысып төйнәгән кебек ясый белә, «кырыслык, уткәзеп әйтелгән катылык, хәтта дорфалык эченә кешеләргә булган мәхәббәт, күңел йомшаклыгы» төреп әйтә белә, ул — заман язучысы, анда тел чишмәсе һәр вакыт чылтырап агып тора.

Тәнкыйтьченең фикерләре шул кадәр дәлилләнгән, аларга каршы куярлык сүз табу да шактый кыен. Х. Сарьян үз сүзен ахырынача әйтеп бетерергә ярата. Мактаса — мактый, тәнкыйтьләсә — тәнкыйтьли белә. Х. Хәйруллинның «Картлык... кемгә шатлык?» повестендагы Асыл карт образындагы шикләндерә торган моментларны күрсәткәндә, М. Хәбибуллинның «Чоңгыллар» романындагы персонажларның артып китүен дәлилләгәндә, Г. Ахуновның «Хуҗалар» романындагы аерым картиналарның акланмавын күрсәткәндә, VI—VII класслар өчен өстәмә әдәбият җыентыгындагы тәрҗемә әсәрләрнең теле турында язганда да, яшь язучы М. Харисов хикәяләрен тикшергәндә дә Х. Сарьян үзе булып кала.

Китапның «Тел белмәгән — теленнән абыныр» дип исемләнгән икенче бүлегендә Татарстан радиосына килгән сорауларга җаваплар (дүрт мәкалә), «Исемең кем синең?», «Алай да була» — булмасын!» кебек мәкаләләр бар. Х. Сарьян телебез өчен бик әһәмиятле мәсьәләләрне күтәрә: алынмаларга мөнәсәбәт, телебезнең чисталыгы, дөрес язу, синонимия, әдәбиятыбызда ялгызлык исемнәре, лексик, семантик калькалар, кушма сүзләр, тыныш билгеләре кебек темаларга караган фикерләре гаять кызыклы формада әйтелгәннәр. Язучы бәхәсләшә, борчыла, ачына, шатлана (бусы сирәгрәк!), телебезне бозучыларга үтергеч тәнкыйть уты яудыра.

Сарьян туган телнең барлык нечкәлекләрен оста сиземли, сүзлек байлыгын кузаллый, телнең эчке механизмын хәрәкәткә китерүче бөтен көчләрне күрә белә. Мәгъсүм Хәбибуллин хикәяләренең теленә анализ ясаганда, ул берничә киңәш әйтә: кулга каләм алгач, бу фикерне әти-әни ничек әйтер иде икән? дип уйлану кирәк. Бу запас беткәч, «инде моны авылның иң

җор, телгә беткән кешесе Сәйфетдин ничек әйтер иде икән?» дип, урамда ишеткән, поездда ишеткән, авылларда ишеткән сүз вә тәгъбирләрне исенә төшерергә тиеш. Дүртенчедән, һич туктамастан, халык җырларын, мәкальләрен өйрәнмәк тиеш. Бишенчедән, әле әйтелгән дүрт шарт белән параллель төстә, татар әдәбиятының үз классикасын (борынгысыннан бүгенгесенә хәтле) казынмак-өйрәнмәк тиеш. Чөнки әдәби осталыкка башка телдән өйрәнеп булса да, үз телеңә фәкать үз телеңнән генә өйрәнеп була» (45 б.).

Автор күп кенә кушма сүзләрнең ясалмалылыгы турында бик дөрес әйтә: «...бихисап күп болар! Яратышмый, көчләп өйләндерелгән егет белән кыз кебек. Миңа калса, бу сүзләрне кушып язучыларның башына: «Кайчан соң бөтен сүзләрне дә кушып чыгарбыз икән!» диган кайгы төшкән булса кирәк. Әйткәнемчә, аларның җавабы бер: ике сүз бер мәгънәне аңлата янәсе! Алайга китсәң, **ат башы** белән **атаң башы** да бер мәгънәне аңлата. Әйдәгез, аларны да кушыйк!» (131 б.)

Х. Сарьян кызыклы итеп яза белә. Аның фикерләве әзлекле, теле эмоциональ, бай, бер генә җирендә дә сөрлекми. Укучы белән фикер алышып, анык булуын тоеп яза Х. Сарьян. Шуңа күрәдер, әйтәсе сүзен әйтеп бирә һәм аны үзенчә, Сарьянча, җор, тапталмаган формаларда әйтеп бирә. Берничә мисал белән генә чикләник: «Ниһаять, алтын мәсьәләсе. Бер бетмәгән алтын булды бит бу тамансы! М. Әмирнең «Саф күңел»ендә дә, Г. Мөхәммәтшинның «Йөрәктәге эзләр»ендә дә, Ф. Хөснинең «Алтын эзләүчеләр»ендә дә, Хәниф Хәйруллинның «Картлык... кемгә шатлык?»ында да, М. Хәбибуллинның әлеге «Чоңгыллар»ында да — һаман табылып кына тора! Тик без аны, алтын күреп үскән малайлар булмаганлыктан, кая куярга гына урын таба алмыйбыз. Киләчәктә бу темплар белән тапсак, бөтен әдәбиятыбызны алтынга батыруыбыз ихтимал» (21 б.). Х. Сарьянны укыганда: «кара, телебездә мондый сүз дә бар бит әле!» дип шатланып укыйсың. «Нигә шулай сирәк очрый икән бу форма?» — дип ачынып куясың.

«Алай да була» — булмасын!» мәкаләсендә хәзерге ике теллелек шартларындаискиткеч актуаль булган бер мәсьәлә — алынмалар мәсьәләсенә зур урын бирелә. Х. Сарьян күп гасырлар буе татар теленә тәэсир итеп килгән гарәп, фарсы телләренең ролен, урынын да хаклы рәвештә билгели, хәзер инде бераз архаиклашкан алынмаларның стилистик кулланыла алу мөмкинлекләрен объектив хәл итә. Урыны белән, мәсәлән, **санагат**, **сил** сүзләрен кулланудан «Татар әдәби теленең бер чите дә кителеп төшмәячәк» (112 б.) дип дөрес әйтеп, Р. Харисовтан бер мисал китерә: «Синең аша үткән җилләр **силгә** әйләнсен шатлык булып». Һичшиксез, шулай. Әмма укучы аңлармы соң? «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге»ндә бу сүз ташкын мәгънәсендә теркәлгән. Ярый ла, бу сүзлек һәр укучыда булса! «Татарча-русча сүзлек»кә мөрәҗәгать итсәк, монда **сил** түбәндәгечә аңлатыла: сало, тонкий осенний лед (елга **сил** белән капланган). Диалектологик сүзлектән **сил** сүзенең Оренбург татарларында «аяк тавышы тыну, хәрәкәт туктау, тынычлык урнашу» мәгънәсендә йөрүен беләбез. Укучы кайсысын аңларга тиеш соң?!

Рус һәм башка телләрдән алынмалар кабул итү мәсьәләсен Х. Сарьян көне-сәгате белән үзгәреп, яңарып торган иҗтимагый тормышка бәйли: «Башка бер телдән ихтыяҗ белән, кирәккәнгә сүз алу әдәби телебез өчен гаять тә зарур бер хәл» (113 б.). Бик хаклы рәвештә, «чит бер сүзне кабул итү яки итмәү ул — хакимнәр эше дә, галимнәр эше дә түгел, ул — халыкның үз эше» (76 б.), дип яза автор. Мәсәлән, телебездә хәзер параллель йөри торган коррелят сүзләр бар. Аларны синоним дип әйтеп булмый, чөнки мәгънә төсмерләре белән аерылып тормыйлар, ә бер үк мәгънә белдерәләр. Кайсысын калдырыр халык, кайсысы активлашып китәр — моны вакыт хәл итәр дип уйлыйбыз. Бер үк язучы, бер үк әсәрдә куллана аларны: детдом — балалар йорты (Л. Гыйльми), ремень — каеш (М. Мәһдиев), чакрым — километр, уха — балык шулпасы, срок — вакыт (М. Зарипов), дневник — көндәлек, атака — һөҗүм, доход — табыш (Г. Әпсәләмов), гариза — заявление (Г. Минский), ашханә — столовой (Ф. Хөсни) һ. б.

Яшерен-батырын түгел, Х. Сарьян әйткәнчә, «Колхоз рәисе кайда?» дигәнгә авылда «Председатель кырда» диячәкләр. Гомумән, халыкта хәзер бу сүзләрнең русчаларын куллану өстенлек итә. Татарчалары (ә аларның күбесе күптән кереп, телебездә инде үз булган гарәп-фарсы алынмалары) язма әдәби тел өчен хас. Франциядә рәсми кәгазьләрдә чит сүзләрне кулланган өчен штраф салына икән: шул уңай белән Х. Сарьян бик тапкыр әйтә:

«Әгәр безнең халык, әйтик, яшеннән алып картына кадәр, **председатель** дип сөйләшә икән, председатель дип язган өчен мең штраф салудан ни файда? Бөтен халыкка штраф салып булмый бит» (80 б.). Нәкъ шулай шул. Телнең дә котылгысыз, иҗтимагый сәбәпләргә, шартларга бәйле объектив законнары бар. Тел шуларга буйсынып үсә, яши.

Х. Сарьян һәр төрле штампның, әзер өлгеләр белән эш итүнең дошманы. Бу — әдәби әсәрдәге геройларга да, аларның үзара мөнәсәбәтләренә дә, алар сөйләшә торган телгә дә, язучының үз теленә карата да шулай. Дежур сүзләрне җене сөйми Х. Сарьянның. «Зур роль уйный», «зур әһәмияткә ия», «зур урын алып тора», «өлеш кертү» һ. б. — телебездә тапталып беткән мондый сүзләрне тагын күбрәк тә китерергә мөмкин булыр иде. Х. Сарьян телдә инде йөри-йөри таушалган сүзләр турында бик вакытлы сөрән сала. Менә ул сүзләр: **көрәшү, катнашу, тудыру, чакыру, белдерү, җәелдерү, күрсәтү, күрсәткеч, буенча, почмак, бара** һ. б. Язучы шуларның кирәгеннән артык кулланылуы турында сөйли, телебездәге менә дигән сүзләрне кысрыклап чыгаруларын күреп борчыла. Бу сүзләрне без аздырып бетердек, ди автор. Сәбәбе — телебезне белмәү, мөмкинлекләрне эшкә җикмәү. Х. Сарьян белән тулысынча килешеп, бу урында бер генә фикер әйтәсе килә. **Буенча** бәйлек сүзе рус телендәге **по** предлогы тәэсирендә бездә искиткеч активлашып бара. Рус теленең үзендә дә бу предлогның агрессиясе бара дип күрсәтеп үтәләр галимнәр. Гәрчә бу бәйлек белән ясалган тезмәләрнең дистәдән артык синонимы булса да, бу хәл безгә дә тәэсирсез калмаган икән.

Телебезнең матурлыгын, аһәңен, моңын, табигый агышын җимерә торган тагын бер **«авыру»** бар. Бу — кирәкмәгәнгә кулланылган калькалар, икенче телнең — бу очракта рус теленең — грамматик калыплары җирлегендә татар җөмләсе төзү. Турысын әйтик: калькалаштыру юлы белән сүз ясау, сүзтезмәләр төзү татар телендә соңгы 20—30 ел эчендә искиткеч күп очрый. Бу — объектив хәл, рус теленнән тәрҗемәләр арту, рус теленең милләтара аралашу теле булуына бәйле процесс. Ләкин телебезнең бөтен байлыгын кузаллмый торып, нигә калькага мөрәҗәгать итәргә соң әле? Чыннан да, менә бу җөмләләрдә сүзләре генә татарча, ә җөмләсе русча уйлап язылган бит: «Гомер буе **станок артында басып торуның** нинди кызыгы булсын инде» (45 б.). «Сез качкан **шәһәрдән Ибраев бирелә»**. «Гәрчә ул **җинаятьтән ерак торган** булса да...». «Кемнәрдер **машиналарны куып алып** китәләр дә...» (57 б.).

Татар теленең эчке кануннарын бик нечкәләп, тирәнтен белгән Х. Сарьянның күп кенә фикерләре әһәмиятле, дөрес, дәлилләнгән. Әмма аерым очракларда ул кирәгеннән артык мавыгып китмиме икән дип тә уйлап куясың. Әйтик, язма әдәби телдә инверсия, ягъни сүз тәртибе үзгәреше бик нык чикләнгән. Туры сөйләмнән соң килгән деепричастный (хәл фигыльле), причастный (сыйфат фигыльле) әйләнмәләрне нәкъ рус телендәгечә, автор сүзләреннән соң кую тәрҗемә әсәрләрдә генә түгел, оригиналь әсәрләрдә дә күренә. Сарьян китергән мисалларда бу тәртип, чыннан да, уңышлы түгел (61—62 б.), әмма нәтиҗә ясарга ашыкмыйк. Шул ук тәртиптә килгән менә бу җөмләләрне татарча түгел дип кем әйтер икән: «Әллә килеп тә җиттеләрме? — дип уйлады Хәмдия, **телсез-өнсез калып»** (Н. Фәттах). «Алай булса, син хафаланма...— диде шәкертләрнең кычкырып һәм яңгыратып көлә торганы, **үзенең көлүен кинәт туктатып»** (С. Кудаш). «Нигә тындылар? — диде ул, **пошынып»** (И. Гази). «— Хәмдияттәй! — дип кычкырып җибәрде малай, **поскан җиреннән кинәт чыгып»** (Ф. Хөсни). «Саумы, Акъәби? — диде ул, **таза кешегә дәшкәндәй юри кычкыра биреп»** (Ә. Еники).

Язучыларыбызда андый мисаллар тулып ята. Хәзер инде Ә. Еники, Ф. Хөсни, И. Газилар да татарча язмаганнар булып чыга түгелме соң?! Димәк, инде телдә «татарча түгел» дип кенә куып чыгарырга мөмкин булмаган бер төзелмә котылгысыз рәвештә барлыкка килгән һәм, күрәсең, урынына карап, аның белән килешергә кирәктер. Г. Ибраһимов әсәрләрендә мондый төзелеш юк югын, Г. Бәширов та нәкъ Х. Сарьян язганча төзи мондый җөмләләрне. Ләкин телнең экономиягә даими рәвештә омтылышы, әйтү өчен җайлылык эзләү, укучыга фикерне кисәкләп-кисәкләп биреп җиткерергә омтылыш, күрәсең, мондый җөмләләрнең татар теле өчен дә кулай булуын исбатлый.

Җыентыкта орфография мәсьәләләренә дә зур урын бирелгән. Урамдагы, йортлардагы язулар, паспорттагы исем-фамилияләрнең дөреслеге, татарча язуларның республикабызда татарча булырга тиешлеге һ. б. мәсьәләләр күтәрелгән.

Х. Сарьян радиога килгән сорауларга тәфсилле, фәнни дәлилле аңлатмалар бирә. Әмма китапның үзендә хәзерге орфография кагыйдәләре белән туры килә алмый торган очраклар да шактый. Гарәптән кергән **иҗад, шәһид, гарәб, әдәб** кебек сүзләрне **иҗат, шәһит, гарәп, әдәп** дип язу гамәлгә кергән. Әмма Х. Сарьян аларны **д, б** хәрефе белән язып китә. Нигә кирәк мондый тәҗрибәләр?! Китапны укучылар, укытучылар, студентлар укый. Х. Сарьян «д» белән язсын, без «т» белән языйкмыни инде?!

Татар тел белеменең гамәли бурычларыннан берсе итеп Х. Сарьян тыныш билгеләре кагыйдәләрен камилләштерү мәсьәләсен күтәрә. Кереш сүзләр кергән берничә мисалны тикшереп, автор болай ди: «...адым саен өтергә абынып, ни йөгереп кенә укып китә алмыйча, ни мәгънәсен аңлап бетерә алмыйча утырасың инде! Андый мәгънә боза торган өтерләр безгә нигә кирәк?» (138 б.) Филолог студентлар да шулайрак: «Өтерне кая телим, шунда куям» дип, дистәләгән пунктуация хаталары ясыйлар. Сарьян үзе дә бу китапчыгында шактый күп өтер хаталарын аңлы рәвештә төзәтмәгән. **Ниһаять, мәсәлән, ахры, күрәсең** кебек кереш сүзләр янында, синтетик иярчен җөмләләр, хәлләр аерымланганда бик күп өтерләр төшеп калган.

Дөрес, тыныш билгеләрен кую кагыйдәләре бездә тулысынча хәл ителгән, камил дип әйтеп булмый торгандыр. Сөйләмнең интонацион-мәгънәви кисәкләргә — синтагмаларга бүленеше җитәрлек өйрәнелмәгәнгә һәм традицияләр бик тотрыклы булганга, тыныш билгеләрен куюда төгәл фәнни принциплар сакланмый. «...Тыныш билгеләрен кую, чынлабрак тикшереп караганда, аерым интонация һәм пауза белән әйтүгә нигезләнмәгән, бәлки традицион күнегүгә генә нигезләнгән... Тыныш билгеләре куюның да һәм аерымланган иярчен кисәкләр теориясенең дә нигезендә тел төзелешен өйрәнүдән килеп чыккан фәнни принциплар түгел, бәлки синтагмаларның аерым очракларын гына күрүдән туган традицион принцип ята» (М. З. Зәкиев. Хәзерге татар әдәби теле. Казан, 1974, 163 бит). Димәк, тыныш билгеләре кую мәсьәләсендә дә нык уйланырга кирәк. «Ничек телим, шулай куям» белән генә мәсьәләне хәл итәргә ярамый.

Х. Сарьянның теле кайчак XX йөз башы әдәби телен хәтерләтеп җибәрә. Юри шулай эшлиме ул, әйтеп булмый. Сүзебезне дәлилләп берничә мисал китерик: «Мондый йә моннан да әйбәтрәк әдәби сурәтләнмеш картина йә вакыйгалар әсәрдә җитәрлек» (7 б.). «Хәтта **нә яңгырашы, нә** мәгънәсе булмаганнары да бар» (119 б.). Искергән, архаик кушымчаларны язучы аеруча ярата: «...түшәме биек булып та, өйрәсе сыек **булмактан** ни файда!» (37 б.). «Дүртенчедән, һич туктамастан халык җырларын, мәкальләрен **өйрәнмәк тиеш»** (45 б.). «Әгәр кешенең **тумышыннан** алып үлмәшенә кадәр...» (95 б.) һәм башкалар. Кайбер искергән сүзләрнең **кулланылышы да** урынлы дип әйтеп булмый. Бертуктаусыз сүзлеккә мөрәҗәгать итеп укып булмый бит инде мәкаләне!

Язучы кирәкмәгәндә алынма сүзләрне кулланмау ягында. Әмма, кайчак үзе дә сизмичә, мин әле менә нәрсәләр беләм дигәндәй әйтеп куя шул: «Менә бала туды. **«Де-факто!»** (120 б.). Киң катлау укучыларның барысы өчен дә аңлашыламы бу сүз? Ул нинди мәгънә белдерә? Әйбәт сүзме? Аннан башка да котылып булмас идемени? Тагын бер җөмлә: «Әмма **келлесенең дә кәсафәте** бер: телне бозалар!» (117 б.). Кем телне боза **икән?! Сарьян** үзе түгелме?

Х. Сарьянның бу китабы укучыны борчый, бәхәскә чакыра, ышандыра, кайбер шикләр уята, беркемне дә битараф калдырмый. Автор өчен моннан да дәрәҗәлерәк хәл булыр микән?! Әдәбият сөючеләр Х. Сарьянның әдәби әсәрләрен генә түгел, һәр публицистик, тәнкыйть чыгышын көтеп алалар. Һаман шулай булып калсын иде!

**ФЛЕРА САФИУЛЛИНА,**
**филология фәннәре кандидаты.**

# БӘЯН ГЫЙЗЗӘТКӘ 60 ЯШЬ



Татар әдәбияты һәм сәнгатенең олы тарихы, гүзәл традицияләре бар. Бай культура мирасыбызны барлау, тикшерү, гомумиләштерү, әдәбият һәм сәнгатьнең агымдагы торышын күзәтү, анализлау процессы да туктаусыз дәвам итә. Бу өлкәдә һәр чорның актив тикшеренүчеләре, галим һәм тәнкыйтьчеләре үсеп чыга. Бәян Гыйззәт тә — әнә шундыйлардан берсе.

1918 елның 16 июлендә Башкортстанның Кушнаренко районы, Талбазы авылында крестьян семьясында туган Фәтхелбәян Нурлыгаян улы Гыйззәтуллин (Бәян Гыйззәт) әдәбият һәм сәнгать дөньясына зур тормыш тәҗрибәсе туплап, илебез язмышын хәл иткән зур керәшләрдә катнашып килеп керә.

Ул 1936 елны Уфада рабфак, 1941 елны Казанда педагогия институтын тәмамлый. Бөек Ватан сугышының башыннан алып Б. Гыйззәт — фронтның алгы сызыгында. Ул артиллерия офицеры сыйфатында Кенигсбергка кадәр барып җитә. Курск дугасында сугышлар башланган җитди бер моментта Коммунистлар партиясе сафына кабул ителә. Фашист илбасарларына каршы күрәштә күрсәткән батырлыклары өчен ике Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр белән бүләкләнә.

Әдәбият һәм сәнгатькә мәхәббәте Б. Гыйззәтне 1946 елда Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрына алып килә. Ул анда күп кенә еллар әдәби бүлек мөдире булып эшли. Бу чорда турыдан-туры аның катнашлыгы белән Т. Гыйззәт, Н. Исәнбәт, М. Әмир һәм башка драматургларның күренекле әсәрләре сәхнәгә менә, илебездәге тугандаш халыклар авторларының актуаль проблемаларны күтәргән спектакльләре куела, классикага игътибар арта. Аның бу юнәлештәге эшчәнлеге «Советское искусство» (1947, 4 июль) газетасының баш мәкаләсендә башкаларга үрнәк итеп куела.

Шушы ук чорда вакытлы матбугатта Б. Гыйззәтнең театр һәм драматургиягә кагылышлы мәкаләләре еш күренә башлый. Бер үк вакытта ул СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы тел, әдәбият һәм тарих институтында аспирантурада укый. 1951 елда пролетар язучы Гафур Коләхметов иҗаты буенча диссертация яклап, филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала һәм шунда ук эшкә калдырыла. 1953 елдан алып хәзергә кадәр Б. Гыйззәт — шул институтның өлкән гыйльми хезмәткәре, 1968 елдан шул институтта сәнгать секторы мөдире до.

Б. Гыйззәтнең инде утыз елдан артык дәвам иткән тикшеренүләрен бер-берсе белән тыгыз бәйләнгән ике зур тармакка, ягъни драматургия һәм театрга бүлеп карарга мөмкин. Башта ул төп игътибарны драматургиягә юнәлтә һәм тора-бара, заман таләпләреннән чыгып, театрга ныклы борылыш ясый.

Б. Гыйззәтнең драматургиягә кагылышлы күләмле тикшеренүләре «Егерменче йөз башында татар әдәбияты» (1954 ел), «Татар совет әдәбияты тарихы» (1960), «Заман сулышын тоеп» (1967 ел), Мәскәүдә рус телендә чыккан «Татар совет әдәбияты тарихы» (1965 ел) исемле китапларда урын алды. Таҗи Гыйззәт иҗатына багышланган монографиясе 1957 елда аерым китап булып басылып чыкты.

Татар театры тарихын булдыру мәсьәләсе дә өлгереп җиткән иде. Б. Гыйззәт эшчәнлегенең дә зур өлеше әнә шул бурычны тормышка ашыруга бәйле. Мәскәүдә сәнгать тарихы институтында әзерләнгән «Совет драма театры тарихы» исемле алты томлык хезмәткә ул, автор һәм редколлегия члены буларак катнашып, татар театры тарихы хакында очеркларын урнаштырды. Аларны театрыбызның үсеш этапларын эзлекле рәвештә яктырткан беренче җитди эзләнү дип атарга мөмкин.

Б. Гыйззәт җитәкләгән сәнгать секторында татар театрының аерым тарихын язу процессы да җанлана төште. Шуның нәтиҗәсе буларак, 1975 елда «Татар совет театры» дигән күләмле хезмәт дөнья күрде. Күптән көтелгән бу китапта да Б. Гыйззәт язган берничә бүлек — егерменче елларның икенче яртысында һәм утызынчы елларда татар театры дигән бүлекләр бар.

Шушы юнәлештәге эшчәнлекне дәвам итеп, сәнгать секторы гыйльми хезмәткәрләре «Октябрьга кадәрге татар театры» дигән яңа хезмәт тәмамладылар.

Б. Гыйззәтнең тикшерену объекты гаять киң. Күрсәтелгән хезмәтләрдән тыш, аның драматургия һәм театрга кагылышлы язмалары төрле җыентыкларда, әдәбият һәм театр энциклопедияләрендә, республика газета-журналларында, үзәк вакытлы матбугатында да байтак басылды. Алар арасында Г. Камал, Г. Кариев, К. Тинчурин, Ф. Бурнаш, Һ. Такташ, Г. Кутуй, Г. Насрый һ. б. бик күпләргә багышланган иҗади портретлар, аерым әсәр яки спектакльләр турында рецензияләр, сәнгатьнең җитди проблемаларын күтәргән күләмле мәкаләләр дә бар.

Б. Гыйззәт әдәбият һәм сәнгатьнең үсеш этаплары яки бүгенге актуаль мәсьәләләре турында төрле конференция, киңәшмә, фикер алышуларда да докладлар белән күп тапкырлар чыгыш ясады һәм ясап килә.

Галим һәм тәнкыйтьче буларак, Б. Гыйззәткә әдәбият һәм сәнгатьне тикшерүдә билгеле бер идея-эстетик проблемалардан чыгып эш итү, гомумиләштерергә омтылу, әдәбият һәм сәнгатьнең үсеш тенденцияләрен принципиаль позициядән яктыртырга тырышу хас.

Профессор М. Гайнуллин үзенең бер мәкаләсендә «Бәян Гыйззәт — тыйнак табигатьле, туры сүзле, кыю фикерле, үзенә һәм башкаларга таләпчән галим»[1] дип әйткән иде. Бу сүзләр Б. Гыйззәтне һәм белгеч, һәм кеше буларак та ачык характерлый. Бу сүзләрнең дөреслеген аның бөтен тормышы, эшчәнлеге, кешеләргә мөнәсәбәте ачык раслый. Чөнки Б. Гыйззәтнең әдәбият-сәнгать турында сүз барганда принципиаль, таләпчән булуы, бер үк вакытта һәр язучы, драматург, артист яки режиссерга үзенең киңәшләре белән һәрвакыт ярдәм итеп килүе күпләргә билгеле.

1957 елдан Б. Гыйззәт — СССР Язучылар союзы члены. Ул Татарстан Язучылар союзының тәнкыйть секциясе җитәкчесе буларак та, озак еллар актив эшләде.

Әнә шулай, Б. Гыйззәт катлаулы тормыш юлы үтеп, күпкырлы эшчәнлеген дәвам иттерә.

Бүгенге көндә театр, музыка һәм башка тармакларда җитди тикшеренүләр алып барган, бу өлкәдә кадрлар әзерләүгә елдан-ел игътибарны көчәйткән сәнгать секторының да, аның җитәкчесе Б. Гыйззәтнең дә планнары зур. Юбиляр драматургия һәм театр тарихын тагын да тирәнрәк һәм киңрәк планда тикшерү юнәлешендә җиң сызганып эшли, зур хезмәтләрен төгәлләү алдында тора. Киң колачлы, тынгысыз, туктаусыз эзләнүчән юбилярыбызга мактаулы хезмәтендә зур уңышлар телибез.

**РИЗА ИШМОРАТ,**
**ҺӘНҮЗ МӘХМҮТОВ.**

---

[1] М. Гайнуллин. Әдәбият һәм сәнгать белгече. «Казан утлары», 1968 ел, 7 сан, 133 бит.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ҖЫРЛАР ЛЕНИНГА БАГЫШЛАНА

Апрель — дөньяга В. И. Ленин туган ай. Шушы айда Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе ел саен музыкаль фестиваль үткәрә.

Быел республикабыздагы бу традицион сәнгать бәйрәме — В. И. Ленинның туган көненә багышланган XVI музыкаль фестиваль — Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрында ачылды. Партия, Ленин, туган ил турындагы бәйрәм җырлары Татарстан башкаласының культура сарайларында, концерт залларында, Зеленодольск шәһәренең «Родина» культура йортында яңгырады. Юлбашчы туган көнгә багышланган музыка бәйрәменә Мәскәү, Ленинград, союздаш һәм автономияле республикалардан, өлкәләрдән кунаклар — сәнгать осталары килде. Казанлылар Юрлов исемендәге рус дәүләт академик хор капелласын тыңлады. Бородин исемендәге дәүләт квартеты, Белоруссиядән «Чаровницы» вокаль инструменталь ансамбле, Башкортстан АССРның халык артисты Зәки Мәхмүтов катнашындагы инструменталь ансамбль, Бөтенсоюз конкурсы лауреаты — Украина ССРның атказанган Закарпатье халык хоры чыгышларын тыңлаучылар һәркайда алкышлап каршылады.

Бәйрәм көннәрендә республикабыз кинотеатрларында В. И. Ленинга багышланган фильмнар куелды.

Татарстан радиосы һәм телевидение музыкаль фестиваль уңае белән махсус тапшырулар оештырды.

Филармониянең сәнгать осталары Казан спорт сараенда меңләгән тамашачы-тыңлаучы алдында чыгыш ясады. РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисты Илһам Шакиров, республиканың халык артисткасы Әлфия Афзалова, Татарстанның атказанган артисткасы Нәфисә Василова, Флера Сөләйманова һәм башка җырчыларның концерты музыка бәйрәменең таҗы булды.

Татарстанның халык артисты, Тукай бүләге лауреаты Айрат Арсланов фестиваль концертларында татар совет шагыйрьләренең Ленинга һәм туган илгә багышланган шигырьләрен укыды.

Фестивальдә республикабызның иң күренекле музыкаль коллективлары—Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбле, симфоник оркестр, «Идел» һәм «Казан утлары» инструменталь ансамбльләре катнашты.

## ИҖАТ ИНТЕЛЛИГЕНЦИЯСЕ СЕМИНАРЫ

Иҗат интеллигенциясенең даими эшли торган семинар занятиесе КПСС өлкә комитетының Политик мәгариф йортында үткәрелде. Анда язучылар, рәссамнар, актерлар, театр һәм сәнгать белгечләре катнашты. Алар ТАССР культура министры И. Н. Алиевның «Замандашыбыз һәм аның татар совет сәнгатендә художестволы-образлы гәүдәләнеше» дигән темага чыгышын тыңладылар. Фикер алышуларда язучылардан Ф. Хөсни, тәнкыйтьче Б. Гыйзәт катнашты.

## ҖӘЛИЛ ӘСӘРЛӘРЕ — НЕМЕЦ ТЕЛЕНДӘ

Берлиндагы «Фольк унд Вельт» нәшриятында «Интернациональ лирика китапханәсе» сериясеннән Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең Моабит шигырьләре тупланган җыентык немец телендә басылып чыкты. Бу — татар шагыйренең Германия Демократик Республикасында чыгарылган шигырьләренең өченче басмасы инде. Китап моңарчы дөнья күргән ике җыентыктан да күләмлерәк. Шигырьләр турыдан-туры оригиналдан — татарчадан тәрҗемә ителгән. Тәрҗемәчеләре — Вильгельм Ткачик һәм Хельмут Прайслер. Кайбер әсәрләр татар телендә дә урнаштырылган. Җыентыкка кереш сүзне Әминә ханым Җәлил язган. Китапның соңгы битләрендә Рафаэль Мостафинның Җәлил иҗаты турындагы мәкаләсе дә бирелгән.

## ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕ — ИЛЕБЕЗ СӘХНӘЛӘРЕНДӘ

Март уртасында Ленинградта милли драматургия һәм СССР халыклары театраль сәнгатенең III Бөтенроссия фестивале тәгәлләнде. Аның йомгаклау өлешендә күрсәтү өчен театр сәнгате ярышында куелган 300 спектакльдән унikeсе сайлап алынган иде. Шулар арасында татар драматургы Илдар Юзеевның «Сандугачлар килгән безгә» (русчага «Не по злобе» дип тәрҗемә ителгән) пьесасы буенча Тува музыкаль-драма театрында куелган спектакль дә бар. Ул Ленсовет исемендәге театр сәхнәсендә ике кат куелды. Ленинград телевидение студиясе бу спектакльне видеотасмага язып

та алган иде. Апрель аенда «зәңгәр экран» аны тамашачыларга күрсәтте.

Ленинградның сәнгать сараенда фестивальгә багышланган конференция булды. Анда РСФСР культура министры урынбасары Е. Зайцев, РСФСРның халык артисты Р. С. Агамирзян, сәнгать фәннәре докторлары В. А. Сахновский-Панкеев, Ю. А. Дмитриев, татар драматургы Аяз Гыйләҗев һ. б. сөйләде.

Россия халыкларының милли драматургиясен үстерүдәге зур хезмәтләре өчен бер төркем драматурглар Беренче Дәрәҗә Диплом белән бүләкләнде. Алар арасында татар драматурглары Туфан Миңнуллин, Аяз Гыйләҗев, Илдар Юзеев, Диас Вәлиев бар.

Шулай ук Г. Камал исемендәге Ленин орденлы татар дәүләт академия театрының башкорт драматургы М. Кәрим трагедиясе буенча сәхнәгә куелган «Ташлама утны, Прометей» спектакле дә Беренче Дәрәҗә Диплом белән билгеләнде.

Бүләкләнүчеләргә дипломнарны СССРның халык артисты, Социалистик Хезмәт Герое Ю. Толубеев тапшырды.

## «КАЗАН ЯЗЫ» — ШИГЪРИ ЯЗ

«Казан язы...» Шагыйрьләр һәм шигъри ят белән очрашу!.. Бу инде поэзия сөючеләр өчен дә, шагыйрьләребез өчен дә күркәм традициягә әверелде. «Казан язы» җиттеме, поэзиябезнең көр авазы культура сарайларында, эшчеләр арасында—завод цехларының кызыл почмакларында, шәһәр яны районнары колхозларында-совхозларында яңгырый.

Быелгы «Казан язы»ның истәлекле очрашуларыннан берсе Дербышка эшчеләр шәһәрчегенең Ленин исемендәге культура сараенда булды. Поэзия сөючеләр анда РСФСРның М. Горький исемендәге дәүләт премиясе һәм республикабызның Г. Тукай бүләге лауреаты Сибгат Хакимне бик җылы каршылады. Шагыйрь яңа шигырьләрен укыды.

Кичәдә шагыйрьләрдән М. Хөсәен, Р. Вәлиев, Р. Миңнуллин, прозаик М. Мәһдиев катнашты. Алар әдәбият дусларын яңа әсәрләре белән таныштырдылар.

Җырчылардан В. Гыйззәтуллина, Р. Ильясов, Р. Сәхәбиев, З. Җаббаровларның дәртле-моңлы җырлары «Казан язы» кичәсенең шигъри матурлыгын тагын да арттырды.

## КӨЛКЕ КИЧӘЛӘРЕ

Халык телендә «мәзәкләр һәм алдашу көне» булып саналган 1 апрельдә Казанның Актерлар йортында шаян программалы әдәби кичә үткәрелде. Керү — бушлай, көлү — ихтыярый һәм туйганчы булган ул кичәдә татар әдипләренең һәм шагыйрьләренең юмористик-сатирик әсәрләре укылды, елмайта һәм уйландыра торган җырлар яңгырады.

Шундый ук кичә язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында да булды. Монысында да «тозлы-борычлы» шигырьләр, чәнечкеле хикәяләр укылды, шаян-шаян җырулар әйтелде. Кичәдә әдипләрдән һәм шагыйрьләрдән Әхмәт Исхак, Гәрәй Рәхим, Роберт Батуллин, Роберт Миңнуллин, Җәүдәт Дәрзаманов, Камил Кәримов, нәфис сүз остасы һәм «тел бистәсе» Фәйзи ага Юсупов катнашып, үзләре бер дә елмаймыйча, тыңлаучыларны көлдерделәр.

## ТАТАРСТАНДА КИНОФЕСТИВАЛЬ

«Совет кинематографистлары — бишъеллыкның удар төзелешләре эшчәннәренә» дигән девиз белән республикабызда апрель башында кино сәнгате фестивале үтте.

Кинофестиваль Казанда башланды. Аны үткәрү өчен Татарстан башкаласына СССР Кинематографистлар союзы идарәсе секретаре, сәнгать фәннәре докторы А. В. Караганов житәкчелегендә бер төркем актерлар, режиссерлар, кинодраматурглар килде. Кунакларны КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев кабул итте, аларга республикабызның экономикасы һәм культурасының үсеше турында сөйләде.

Фестиваль Казан кинотеатрларында «Ленфильм» студиясе тарафыннан төшерелгән «Кире элемтә» картинасын күрсәтү белән ачылды. Партия, ил, халык алдында җаваплылыкны арттырырга чакыра торган бу фильм үзенең эчтәлеге белән кино сәнгате бәйрәменең девизына бик тә туры килә. Шунысы да әһәмиятле, әлеге тасмада Түбән Кама нефть химиясе комбинатында төшереп алынган күренешләр дә бар. Ул республикабыздагы зур төзелешләргә хас булган проблемаларга багышлана.

Казанлылар белән кино сәнгате осталары арасындагы дусларча аралашулар онытылгысыз булды. Кунаклар Татарстан башкаласының тарихи-истәлекле урыннарында йөрделәр, предприятиеләрдә эшчеләр белән очраштылар. Аларны һәркайда чәчәкләр, көләч йөзләр, кайнар алкышлар каршылады. Кинофестивальдә катнашучылар Казан университетында В. И. Ленин мемориалын карадылар, студентлар белән сөйләштеләр.

Актерлар йортында үткәрелгән матбугат конференциясендә КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

Кинофестиваль Яр Чаллы шәһәрендә дәвам итте. Анда иҗат труппасы «Энергетик» культура сараенда «Кама буендагы батырлык» дигән документаль фильм карады. Түбән Кама ГЭСы, КамАЗ берләшмәсе заводлары һәм яңа шәһәр белән танышты, төзүчеләр һәм автозавод эшчеләре арасында булды. Очрашуларда А. В. Караганов Бөтенсоюз удар төзелеше булган КамАЗга СССР Кинематографистлар союзының шефлык итүен, аның Чаллы эшчеләре белән иҗади элемтәдә торуын әйтте. Композитор В. Зубков үзенең камазлыларга багышланган җырын башкарды, аны зал алкышлап каршылады.

Кино сәнгате бәйрәме Түбән Кама шәһәрендә төгәлләнде.

## «ЛИРА» ИШЕКЛӘРЕН АЧА

Казандагы Яшьләр үзәгендә шигърият сөючеләрнең «Лира» клубы эшли башлады. Аны РСФСР китап сөючеләр җәмгыятенең Татарстан бүлеге һәм ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты оештырды. Клубның беренче мәҗлесендә поэзия сөючеләр шагыйрь Николай Беляев һәм Бөгелмә шәһәрендә яшәүче инженер — үзешчән композитор һәм башкаручы Владимир Ченцов белән очрашты.

«Лира» клубында мондый мәҗлесләр даими уздырылачак. Поэзия сөючеләрне Мәскәүдән килгән кунаклар, КамАЗда каләм тибрәтүче яшьләр һәм татар шагыйрьләре белән таныштыру күздә тотыла.

## ОТКРЫТКАЛАРДА — КАЗАН КҮРЕНЕШЛӘРЕ

Мәскәүдә «Правда» газетасы нәшрияты «Казан шәһәре» дип исемләнгән нәфис һәм төсле открыткалар җыелмасы бастырып чыгарды. Анда Татарстан башкаласындагы тарихи урыннарны, һәйкәлләрне, шәһәребезнең бүгенге тормышын чагылдырган унбиш фоторәсем кертелгән. Аларны фото сәнгате осталарыннан В. Анин, Б. Елин, Л. Раскин, В. Стрихарь төшергән.

Открыткалар җыелмасы 100 меңле тираж белән басылган.

## МУЗЫКА БӘЙРӘМНӘРЕ

Илебездә балалар һәм яшүсмерләр өчен «Музыка бәйрәмнәре» үткәрү күркәм традициягә әверелде. Аны күренекле совет композиторлары Дм. Шостакович, Дм. Кабалевский, А. Пахмутова һәм музыка сәнгатенең башка осталары башлап җибәргән иде.

Татарстанда музыка бәйрәменең үзәге итеп быел КамАЗ автогигантын төзүчеләр һәм аның эшчеләре яши торган Яр Чаллы шәһәре сайланды. Казанның А. Алиш исемендәге пионерлар һәм мәктәп укучылары сараеның хоры, халык инструментлары оркестры, хореография студиясе, Түбән Камадагы 53 нче профтехучилищеның бию коллективы, шул ук шәһәрдәге 1 нче музыка мәктәбенең хоры һәм С. Сәйдәшев исемендәге музыка училищесы укучылары бәйрәмдә үз осталыкларын күрсәттеләр.

Музыка бәйрәме барышында республикабыз композиторлары һәм күренекле сәнгать осталары укучылар белән очрашты. Фестивальдә РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Х. Вәлиуллин, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе М. Латыйпов, Халыкара конкурслар дипломанты һәм Бөтенроссия конкурслары лауреаты Ирина Лазарева, скрипкачы — Казан дәүләт консерваториясе укытучысы Шамил Монасыйпов, Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе җырчысы, ТАССРның атказанган артисткасы Нәҗия Теркулова һәм башкалар катнашты.

## КҮРГӘЗМӘ БҮЛӘКЛӘРЕ

СССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең Баш комитеты Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Казан тел һәм әдәбият институтын Беренче Дәрәҗәдә Диплом белән бүләкләде. Мондый бүләккә институтның татар тел гыйлеме һәм гомумтюркология проблемаларын өйрәнү һәм тикшерү юнәлешендәге хезмәтләре лаек табылган.

Институтның сектор мөдире, филология фәннәре докторы Н. Г. Юзиевка, патриот-шагыйрь Муса Җәлил әсәрләренең дүрт томлыгын фәнни әзерләгәне һәм бастырып чыгарганы өчен, Күргәзмәнең Көмеш медале тапшырылды. Тарих фәннәре докторы М. К. Мөхәррәмовның Октябрь һәм Татарстанда милли дәүләт төзелеше хакындагы зур монографиясе һәм республикабыз тарихына кагылышлы башка хезмәтләре, тарих фәннәре докторы А. Х. Халиковның Идел буе һәм Урал алды төбәкләренең борынгы һәм урта гасырлар тарихын өйрәнүгә багышланган хезмәтләре Бронза медаль белән бүләкләнде.

Баш комитет Г. Ибраһимов исемендәге тел һәм әдәбият институты хезмәткәрләреннән Н. Ханзафаров, Ф. Ибраһимова, Җ. Гыйльманов, Х. Хәсәнов, А. Җәләлов, Ю. Смыковны, фәнни-тикшерену эшләренә югары бәя биреп, күргәзмәдә катнашучылар итеп раслаган.

## УКЫТУЧЫЛАР СЪЕЗДЫ

Казанда апрель аенда укытучыларның V республика съезды булды. Анда Татарстан АССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов доклад сөйләде.

— Мәгариф работникларының нык үскән социализм чорындагы яңа бурычларын тикшергәндә, без үткән юлга әйләнеп карыйбыз, — диде докладчы. — Татарстанда яңа мәктәп төзүгә нигез салучыларны — Совет иленең беренче халык мәгарифе комиссары А. В. Луначарскийның шәкерте Шаһид Әхмәдиев, Татарстанда иң беренче совет укытучылары вәкиле А. А. Максимов, язучы һәм педагог Галимҗан Ибраһимов, педагог Исхак Казаков һәм башкаларны без хөрмәт белән искә алабыз...

Докладта республикабызның халык мәгарифе өлкәсендә ирешкән уңышлары һәм алда торган бурычлар билгеләнде. Фикер алышуларда мәгариф органнары җитәкчеләре, педагоглар катнашты. Съездга әдипләр вәкиле булып барган балалар язучысы Ләбибә Ихсанова яшь буынны тәрбияләүдә язучы сүзенең, китапның көче турында сөйләде. «Татар совет балалар әдәбияты, олылар әдәбияты кебек үк, сыйфат ягыннан зур үзгәрешләр кичерә, — диде ул. — Хәзер безнең балалар әдәбияты вакыйгаларны өстән-өстән сурәтләү белән мавыкмый, ә яшь геройларның эчке дөньясына һаман тирәнрәк үтеп керә. Аяз Гыйләҗев, Барлас Камал, Вакыйф Нуруллин, Фаил Шәфигуллинның яшь укучыларга атап язган повестьлары нәкъ әнә шул яктан кыйммәтле».

Съезд делегатлары, укытуны тормыш белән, хезмәт белән ныграк бәйләргә чакырып, барлык педагогларга, халык мәгарифе работникларына, ата-аналарга, республиканың предприятие, колхоз һәм совхоз җитәкчеләренә мөрәҗәгать кабул иттеләр.

## МӘСКӘҮДӘ ТАТАР МОҢНАРЫ

Габдулла Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе артистларыннан бер төркем Мәскәү эстрада театрында зур концерт бирде. И. Шакиров, Ә. Афзалова, Н. Теркулова, Г. Ильясов, В. Гыйззәтуллина, Р. Ибраһимова һәм башка җырчылар татар халык көйләрен, композиторларыбызның яңа җырларын башкардылар. Нәфис сүз остасы А. Арсланов татар совет шагыйрьләренең әсәрләрен укыды. Мәскәүлеләр концертның һәр номерын бик җылы каршылады.

## КУРЧАК ТЕАТРЫ — ҖИҢҮЧЕ

Татар дәүләт курчак театрына СССР культура министры П. Н. Демичев һәм культура работниклары профсоюзы үзәк комитеты председателе М. В. Пашков имзасы белән шатлыклы хәбәр — телеграмма килде. 1977 елның икенче яртысында театраль-тамаша оешмалары арасындагы Бөтенсоюз социалистик ярышында Татар дәүләт курчак театры өченче урынны яулаган. Мәскәүдән килгән телеграммада шул җиңү турында хәбәр ителә.

Бөек Октябрь юбилее елында курчак театры Г. Андерсенның «Су кызы» һәм Ә. Фәтхуллинның «Бөркет баласы очарга өйрәнә» дигән әкиятләрен сәхнәгә куйган иде. Театр коллективының шушы спектакльләре югары бәяләнгән.

## ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Тукай бүләге лауреаты Гамил Афзал, шагыйрә Саҗидә Сөләйманова, драматурглар Сәет Кальметов һәм Ю. Әминов, башлап язучы шагыйрь Виктор Дьяченко Ленин комсомолы исемендәге Миңлебай газнефть эшкәртү заводы коллективы белән очраштылар, яңа әсәрләрен укыдылар, иҗат планнары турында сөйләделәр.

x
x x

Тукай бүләге лауреаты шагыйрь Гамил Афзал, шагыйрә Саҗидә Сөләйманова, язучы Җәмит Рәхимов Лениногорск шәһәренең нефтьчеләр йортында комсомолның 60 еллыгына багышланган поэзия кичәсендә катнаштылар, үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

x
x x

Шагыйрә Саҗидә Сөләйманова Әлмәт шәһәренең 13 нче урта мәктәбендә әниләргә багышланган пионер дружинасы сборында чыгыш ясады.

## КАЛӘМДӘШЛӘР ХӨКЕМЕНӘ...

Март аенда Әлмәт язучылары һәм Минзәлә татар дәүләт драма театры артистлары драматург Ю. Әминовның «Алыштыргысыз хатын» исемле яңа комедиясе белән таныштылар.

Фикер алышуда Тукай бүләге лауреаты шагыйрь Гамил Афзал, прозаик Рафаил Төхфәтуллин, драматург Сәет Кальметов катнашты.

Минзәлә драма театрының партком секретаре артистка Роза Җиһаншина, Татарстанның атказанган артистлары Гадел Галләмов, Әхмәдиша Җиһаншин, артистлардан Рәшит Мәрдеханов, Фәнисә Зәйнетдинова, Венера Нигъмәтҗанова, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Тукай бүләге лауреаты Сабир Өметбаев яңа әсәрнең художество үзенчәлекләрен анализладылар. Комедиягә нигездә уңай бәя бирелде, драматургка әсәрне тагын да камилләштерү юнәлешендә киңәшләр әйтелде.


## КОТЛЫЙБЫЗ!

Совет архитектурасы өлкәсендәге хезмәтләре өчен Казан төзүче-инженерлар институтының кафедра мөдире **Сәйяр Ситдыйкович Айдаровка** РСФСР Верховный Советы Президиумының 1978 ел, 29 март Указы белән **РСФСРның атказанган архитекторы** дигән мактаулы исем бирелде.

# МИН БЕРЕНЧЕ ЧӘЧӘКЛӘРНЕ ЭЗЛИМ

**ФАСИЛ ӘХМӘТОВ** музыкасы
**СИБГАТ ХӘКИМ** шигыре

*Andantino con affetto.*







Мин язларны алдан көтеп алам,
Моңнарына биреләә башкаем,
Мин беренче чәчәкләрне җыйган
Урыннарга барам яз саен.

Мин беренче чәчәкләрне эзлим,
Алар бәлки башка төштәдер...
Беренчеләр мине сагындыра,
Беренчеләр минем истә гел.

Яз авышса, җәйнең уртасы бар,
Чәчәкләре аның ишлерәк.
Югалтуның ни икәнен белә,
Юатуны белми һич йөрәк.

## *Хөрмәтле укучыбыз!*

Журналның киләсе — 8 саны язучы Гариф Ахуновның «Без бит Арча яклары» дигән репортажы белән ачыла. Үзенчәлекле формада язылган бу документаль-художестволы әсәрдә әдип республикабызның бүгенге тормышын җанлы картиналарда сурәтли, замандашларыбызның илкүләм зур эшләрен, уй-фикерләрен чагылдыра.

Проза әсәрләреннән тагын Г. Рәхимнең «Саргаймагыз, каштаннар» исемле повесте аеруча яшьләр күңеленә хуш килер дип өметләнәбез. Анда геройның тормышта үз урынын табарга омтылышы ачыла.

Июль санында «Замандаш» конкурсына килгән әсәрләрдән Ә. Гаффарның «Ак каен дегете» дигән хикәясе бирелә. Яшь язучы Р. Гыйззәтуллин «Казлар» исемле әсәре белән катнаша.

Быел дөньяның шигърият шаһларыннан берсе — Ф. Гарсиа Лорканың тууына 80 ел тулды. Шул уңай белән аның турында «Җәлилнең рухи туганы» дигән язма һәм бөек испан шагыйренең поэтик энҗеләреннән тәрҗемәләр урнаштырыла.

Истәлекләр бүлегендә «Хәтернең кайнар күмере» дигән язма биреләчәк. Аның авторы М. Зорин патриот-шагыйрь Муса Җәлил белән сугышта очрашкан көннәрне искә төшерә.

Сигезенче санның да сәнгать, әдәби тәнкыйть бүлекләрендә кызыклы материаллар, китап күзәтү бирелә.

Ш. Галиевнең «Әз-мәз мәзәк яки Котбетдиннең кырык тартмасы» дигән материалы «Елмаеп та, көлеп тә...» бүлегендә урын алачак.

Гадәттәгечә, әдәбият һәм сәнгать яңалыклары хәбәр ителә.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210